ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

Бертуган РӘМИЕВЛӘР

Фәнни-биографик җыентык

Казан
«Рухият» нәшрияты
2002

УДК 9(с46)
ББК 63.3 (2 Рос. Тат.)
Р 92

Китап «Татнефть» ААҖнең Фәрит Вафин
җитәкчелегендәге «Чулпан» иминият компаниясе
матди ярдәме бедән нәшер ителде

Фәнни мөхәррир
Миркасыйм Госманов,
тарих фәннәре докторы,
Татарстан Фәннәр академиясе академигы

Төзүче-авторлар
Лирон Хәмидуллин, Раиф Мәрданов, Рамил Миңнуллин

Бакый Урманче
рәсемнәре

Бизәлеш рәссаме
Шамил Насыйров

Фото
Зөфәр Бәширов

Р 92 **Бертуган Рәмиевләр:** Фәнни-биографик җыентык. –
Казан: Рухият, 2002. – 368 б. – («Шәхесләребез» сериясе)
ISBN 5-89706-044-4

Бу китап татар халкының алтын бәрабәрендә кыйммәтле, затлы һәм мәртәбәле шәхесләре – бертуган Шакир һәм Закир Рәмиевләргә багышлана. Җыентыкта аларның тормышларын һәм эшчәнлекләрен яктырткан мәкаләләр, чыганаклар бергә тупланды.

Китап милли мәдәниятебез һәм әдәбиятыбыз тарихы белән кызыксынучы киң катлау укучыларга тәкъдим ителә.

ББК 63.3 (2 Рос. Тат.)
УДК 9(с 46)

ISBN 5-89706-044-4

© «Рухият» нәшрияты, 2002

«Бертуган Рәмиевләр» китабы

Татар милли-мәдәни тарихы затлы исемнәргә бай. Бертуган Шакир (1857–1912) һәм Закир (1859–1921) Рәмиевләр иң күренекле һәм иң бәһале шәхесләребездән.

Закир Рәмиев-Дәрдемәнд исеме тирән мәгънәле фәлсәфи, искиткеч нәзакәтле шигырьләре аша һәркемгә мәгълүм. Күпсанлы алтын приискалары хуҗасы һәм иҗтимагый-сәяси эшлекле буларак та ул күпләргә таныш. Ә аның бертуган агасы Шакир Рәмиевнең эшчәнлеге һәм тормышы турында моңарчы аз язылды. Китапны кулларына алган укучылар Шакирнең милләтпәрвәр шәхес, тирән гыйлемле фикер иясе, матбагачы-нашир, тәҗрибәле эшкуар һәм уйлап табучы булганлыгын да белерләр. Шулай ук энесе Закиргә ярдәмче һәм киңәшче булуы белән бергә берникадәр юнәлеш тә биргән алдынгы фикерле зат икәнлеге күренә.

Ике бертуганның эш-гамәлләре, фикер-мәсләкләре милләт мәнфәгатенә хезмәт итү, татар халкының аң-мәгърифәтен киңәйтергә омтылудан гыйбарәт булган. Бу изге максатка ирешү өчен Рәмиевләр көчләрен дә, малларын да кызганмаганнар. Үз чорының югары сыйныф-катлавына нисбәтле хәлдә алар татар милләтенең тәрәккыяте өчен җан атканнар. Бертуган Рәмиевләрнең әдәплелек һәм тыйнаклылык, кешелеклелек һәм киң күңеллелекләре гаҗәеп һәм соклангыч. Аларның бу күркәм сыйфатлары һәр заман өчен дә эталон булып торырлык.

Китапка Рәмиевләрнең нәсел шәҗәрәсе, бертуган Шакир һәм Закирнең әти-әниләре, тәрҗемәи хәлләре турында тәфсилле мәгълүмат туплап бирелде. Иҗтимагый һәм алтын сәнагате, матбагачылык һәм наширлек эшчәнлекләре дә мөм-

кин кадәр киң яктыртылды. XX йөз башында чыккан төрле татар газета һәм журналларында Рәмиевләргә багышлап язылган мәкаләләр китапта беренче мәртәбә гамәлдәге татар язуында тәкъдим ителә.

Бертуган Рәмиевләр тарафыннан озак еллар дәвамында Оренбург каласында нәшер ителгән, татарлар һәм башка төрки халыклар яратып укыган мәртәбәле «Шура» журналы һәм «Вакыт» газеталары турында да махсус мәкаләләр бирелде.

Китапта Закир Рәмиев-Дәрдемәнднең аһәңле шигъриятеннән үрнәкләр сайлап тәкъдим ителде.

Аның иҗаты турында әдипкә чордаш галимнәр һәм соңгы дәвер фән әһелләренең әтрафлы мәкаләләре китаптагы материалларның аерым бер өлешен тәшкил итә.

Рәмиевләрнең архивларда сакланган хатлары да беренче мәртәбә җыйналып, кыскартуларсыз китапка кертелделәр. Хатларда Рәмиевләрнең олуг максат һәм ниятләре, риясыз фидаи затлар һәм никадәр оста оештыручы булганлыклары ачыла.

Рәмиевләргә бәйле матбугат библиографиясенең дә тәфсилле исемлеге китапта урын алды. Китап бай фоторәсемнәр тупламы белән бизәлде.

Җыентыкта тупланган мәгълүматлар милләтебезнең үткәне белән кызыксынучы һәркем өчен файдалы булыр.

«Бертуган Рәмиевләр» фәнни-биографик җыентыгын төзегәндә материаллары файдаланылган Татарстан Милли архивы, Казан дәүләт университетының фәнни китапханәсе, Татарстан китапханәсе хезмәткәрләренә, китапта фоторәсемнәре кулланылган Зөфәр Бәшировка, мәкаләләре белән катнашкан Нурмөхәммәт Хисамовка һәм Җәүдәт Миңнуллинга ихлас рәхмәтләребезне җиткерәбез.

Лирон Хәмидуллин, Раиф Мәрданов, Рамил Миңнуллин.

Миркасыйм Госманов

Яңадан танышу, яки Фидакяр хәйриячеләребез хакында

1959 елның 23 ноябрендә уздырылган бер әдәби кичә хәтеремдә нык уелып калган.

СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы конференц-залында (Лобачевский бакчасы янындагы бинада) булган иде ул кичә. Тыштагы җепшек, салкынча көзге һавадан соң монда ниндидер ягымлы җылылык хөкем сөрә. Әйтерсең лә, шыксыз һавалы узган көннәр артта калган да, алда исә шушы шыгрым тулы зал кебек якты, нурлы, җылы киләчәк көтә...

Кичәгә җыелган халык та ничектер аерылып тора иде. Бәйрәмчә киенгән зыялы кыяфәтле агайлар, ханымнар; чал чәчле олыгайган олпат картлар, апалар – моннан 40-50 еллар элек үк иҗтимагый тормышка, әдәби хәрәкәткә катнаша башлаган кешеләр.

Нигездә әдипләрдән, галим-голәмә һәм артистлардан, кыскасы, интеллигенциядән, шулай ук беркадәре студентлардан тупланган халыкта бәйрәмчә хис хөкем сөрә: таныш кешеләр бер-берсе белән кул алышып күрешәләр, котлашалар. Олы яшьтәгеләре мәгънәле рәвештә ым кагышып елмаеп куялар. Тыгыз тезелгән кәнәфиләргә барып утыралар. Утыручыларга карасаң, кайбер олы яшьтәге кешеләрнең үз оныкларын да алып килгәнлеге күренеп тора: әби-бабайлары янында әле генә буй җиткән кызлар, мыеклары төртә башлаган үсмер егетләр күренгәли. Залга соңрак керүчеләрне алданрак урын алучылары кул изәп сәламлиләр, якын-тирәдә буш урын бул-

са, ишарәләп шунда чакыралар. Һәрхәлдә, теләктәшлек һәм чын бәйрәмчә атмосфера иде монда...

Ул кичәдә туган, дөресрәге, хәтеремдә оешып калган тәэсир хакында, хәзер төптәнрәк уйлап карасам, андый атмосфера урнашуның җитди сәбәпләре, зур иҗтимагый мәгънәсе булган икән. Коммунистлар партиясенең мәшһүр егерменче съездыннан соң туган (бүген ни өчендер «Хрущев җепшеклеге» дип авыз кыйшайтыбрак әйтелә торган, чынлыкта күпләр өчен сүнеп барган өметләргә яңа рух өргән) мәгълүм елларның берсендә уздырылган һәм чын мәгънәсендә вакыйга булган икән ул кичә. «Халык дошманнары» дип тамгаланган, төрмәләрдә тапаланган Галимҗан Ибраһимовлар, Кәрим Тинчуриннар әле генә «кайтарылган» еллар бит. Бу кичә исә иң күренекле татар шагыйре Дәрдемәнднең – күп еллар буена «буржуаз эстет», гади халыкны изүче «миллионер» сыйфатында сүгелеп кенә телгә алына торган Закир Рәмиевнең 100 еллыгына багышланган тантаналы җыелыш иде. Дөресрәге, элек гел читкә тибәрелгән, хәтта хурланган иҗатның әдәби һәм мәдәни хәятебезгә яңадан кайтарылуын рәсмиләштерә торган тарихи вакыйга!

Сәхнә түрендә затлы кыяфәтле шагыйрьнең фотосыннан эшләнгән зур сурәт тора. Докладны ул чактагы әдәбият буенча бердәнбер профессор булган Мөхәммәт ага Гайнуллин укый. Зал тып-тын, докладны йотлыгып тыңлыйлар. Гүяки докладчының һәр сүзен, хәтта һәр авазын да отып калырга теләгән сыман...

...Бүген исә, әлеге кичәдә яңгыраган докладны, дөресрәге, аның басылып чыккан тулырак текстларын укысаң, сәер генә хисләр туарга мөмкин. Бер яктан тирән фикерле шагыйрьнең гаҗәеп осталыгы, намуслылыгы хакында шактый җылы сүзләр әйтелгән; икенче тарафтан аның дөньяга карашы, тоткан юлы «буржуазлыкта» һәм ниндидер аңлаешсыз «чикләнгәнлектә» гаепләнә. Аның «Вакыт» гәзите, «Шура» журналын чыгарудагы эшчәнлеген, тырышлыгын да кыскача беләбез. Әчын буржуйның һәм иҗтимагый аңы чикләнгән кешенең күп

еллар дәвамында андый басмалар өчен үз акчасын түгеп ятуы – моның сәбәпләре аңлашылмый кала. Мин үзем Дәрдемәнд дигән бер шагыйрьнең «Кораб» исемле шигырен элек тә яттан белә идем (мин туып-үскән якларда аны җыр итеп тә башкаралар иде бугай...). Ләкин ул шигырьдә тирән мәгънә, чишелмәс «каршылык» булуы хакында ишетмәгән идем әле. Һәрхәлдә, әлеге кичә минем өчен үзенә күрә бер ачыш – билгеле дип исәпләнгән шагыйрь белән яңадан танышу булды...

Соңрак уйлап карасам, ул кичә совет чорында дөньяга килгән яки шул заманда тәрбия алган урта һәм кечерәк яшьләрдәге буын вәкилләре өчен, хәтта XX гасырның илленче еллар ахырындагы әдәби, мәдәни тормыштан азмы-күпме дәрәҗәдә хәбәрдар булган киң җәмәгатьчелек өчен дә Дәрдемәнд дигән олы шагыйрь белән яңадан танышуның бер рәсми акты булган икән.

Мөхәммәт ага Гайнуллинның, уңга-сулга карый-карый дигәндәй ташламалар ясап, саклык белән язган доклады, аның «Совет әдәбияты» журналында һәм шагыйрьнең 1959 елда чыккан «Сайланма әсәрләр»ендә кереш мәкалә буларак басылган текстлары – алардан бүген нинди генә кимчелекләр эзләп тапсаң да – үз вакыты өчен билгеле дәрәҗәдә кыюлык, актуаль яңалык булган икән. Гомумән, Мөхәммәт аганың ул елларда һәм аннан соңрак та 1917 елга кадәр иҗат иткән әдипләрнең исемнәрен кайтару юлындагы эшчәнлеге, әгәр төптәнрәк уйласаң, үзенчә бер фидакярлек тә иде. Әлбәттә, ул елларда тоталитар хәлдә хөкем сөргән рәсми идеологияне, аңа хезмәт итүче «чын партияле» тәнкыйтьчеләрнең арка терәкләре (дирижерлары) ныклыгын, Йосыф Акчура, Риза Фәхретдин, Фатыйх Кәрими кебек кешеләрнең исемнәре генә дә аталуның «зур политик хата» дип игълан ителүен исәпкә алганда...

Әйе, беркадәре соңрак без, яшьрәк каләм ияләре, М.Гайнуллин хезмәтләренә хасрак «өстән-өстәнлекне» күреп, аның үзеннән дә «каршылыклар» һәм «чикләнгәнлекләр» эзләсәк тә, 1950 нче еллар ахырында аның зур кыюлык, хәтта фида-

кярлек күрсәткән шәхес булуында хәзер минем бернинди шигем юк. Чөнки аның белән чагыштырганда, «теоретик җәһәттән» күпкә әзерлеклерәк, күпкә кыюрак дип исәпләнгән, иң мөһиме, «партия өчен ышанычлырак» дип саналган тәнкыйтьчеләрнең һаман ажгырып торган чаклары иде. Алар тагын күп еллар дәвамында Дәрдемәндне «символист» булуда, буржуаз «эстетлыкта» гаепләүләрен дәвам иттерделәр.

Фидакярлек хакында сүз чыккан икән, тагын бер мәсьәләгә махсус тукталу кирәк булыр дип исәплим. Бер иҗат хакында кыю сүз әйтүне фидакярлек дип бәяләп, әмма шул иҗатның үзе турында шома гына узып китү бик үк дөрес булмас иде, әлбәттә. Чөнки зур иҗатлар хакында авыр шартларда дөреслекне ярып әйтүчеләр берләтә батырлык күрсәткән булсалар, андый мирас калдырган шагыйрьләрнең үз фидакярлекләре, һичшиксез, икеләтә, өчләтә кыйммәткә иядер. Мәсәлән, теге яки бу иҗат хакында әйтелгән теләсә нинди кыю фикер вакыт узу белән үзгәрергә, ягъни киңәйтелергә, үстерелергә яки төзәтелергә – «үз урынына» утыртылырга мөмкин. Дәрдемәнд иҗатына карата әйтелгән күп фикерләр белән дә шулайрак килеп чыкты. Әмма аның үз әсәрләре – заманында әдәби хәрәкәтебезгә керткән бәхәссез өлеше, соңрак чор эстетик фикеребезгә ясаган тәэсире – үзгәрмичә яши бирә, һаман тәэсирен арттырганнан-арттыра бара. Башка олы шагыйрьләребез, язучыларыбыз белән дә шундый ук хәл. Мисал кирәк икән, әнә Кол Гали мирасы, Гаяз Исхакый иҗаты һәм төрле елларда аларга карата булган мөнәсәбәтләрнең язмышлары.

Шулай итеп, 1959 елда уздырылган әлеге кичә Дәрдемәнд белән яңадан чын-чынлап танышу вакыйгасы булды, дөресрәге, аның әдәби тормышыбыз кочагына кайтуы рәсми рәвештә гамәлгә ашырылды. Нәтиҗәдә аның мирасына карата игътибар көчәйде. Әгәр 1966 ел башында, Уфада Диния нәзаратында беренчеләрдән булып Ризаэтдин Фәхретдин архивы, «Асар»ның кульязма томнары белән танышкан чагымда, төп игътибарны андагы Дәрдемәнд биографиясенә караган мате-

риалларга, аның моңарчы билгесез булган шигырьләренә юнәлткән булсам («Казан утлары», 1966, 7 сан, 118-123 бб.), моның өчен мин, һичшиксез, әлеге 23 ноябрь кичәсендә алган тәэсирләремә бурычлымын.

Өр-яңа чор шигъриятебездә советча шома такмазалар урынына мәгънәле кыска шигырьләрнең активлашуы да (әйтик, Р.Фәйзуллин, Р.Харис һ.б. иҗатларында) шулай ук Дәрдемәнд мирасының тәэсире иде. Әдәбият белгечләреннән Н.Хисамовның зәвекъ белән язылган мәкаләләре барлыкка килү, Р.Даутов тарафыннан сыйфатлы итеп «Исә җилләр» җыентыгы төзелү дә (1980) шул ук тәэсирнең дәвамы. Ниһаять, иң характерлы совет чоры тәнкыйтьчесе булган Гали Халитның элекке социологизм схемаларыннан баш тартып, шагыйрь иҗатына яңача бәя бирергә омтылуы да, шагыйрь эстетикасының тантанасы булган кебек, тәнкыйтьченең дә гражданнарча батырлыгы – фидакярлеге иде.

Ләкин мин бу урында Дәрдемәнд поэзиясенең кабатланмас әһәмияте һәм аның иҗаттагы гражданлык дәрәҗәсе хакында артык сөйләп тормастан (бу турыда без бүген кичәгегә караганда күбрәк беләбез инде), шагыйрьнең зур фидакярлектән гыйбарәт булган икенче бер сыйфаты хакында махсус әйтүне кирәк табам. Сүз Дәрдемәнднең, дөресрәге, бертуган Шакир һәм Закир Рәмиевләрнең хәйриячелек, химаячелек, хәтта олы меценатлык юнәлешендә күрсәткән бәхәссез зур фидакярлеге хакында булыр.

***

Хәйриячелек, меценатлык турында сүз чыккач, бу төшенчәләр хакында, теманы киңәйтебрәк дигәндәй, мәсьәләгә төрле яктан карап, махсус аңлатмалар бирү кирәк булыр. Мондый төпченүгә, тәфсиллеккә җитди ихтыяҗ бар. Чөнки коммунистик идеологиянең большевистик варианты хөкем сөргән тоталитар совет чынбарлыгында хәйрия эше, хәйриячелек дигән күренеш «буржуаз мәкерлек» сыйфатында тулаем кире кагылган, хәтта каһәрләнгән иде. Мәсәлән, хәйрия-

челек хакында махсус гыйльми эзләнүләр булмау, бу күренешкә объектив бәя бирелмәү бер яктан торсын, бәлки шул чорда рус телендә чыккан төрле характердагы сүзлекләрдә әлеге атаманың эквиваленты булган «благотворительность» сүзе я бөтенләй юк, яки гаделсез рәвештә иске буржуаз тормышының зарарлы галәмәте сыйфатында аңлатыла килде. Хәтта С.И.Ожеговның сәясәт белән әлләни бәйләнмәскә тиешле (шундый хокукка хаклы) булган «Словарь русского языка» исемле лингвистик сүзлегендә дә аңа «одно из средств маскировки эксплуататорской природы буржуазии» дип, яла табигатьле хөкем чыгарылган.

Татар теленең өч томлы аңлатмалы сүзлегендә (1981) хәйриячелек, химаячелекнең берсе дә юк. Мәгәр «хәерче, хәер-сәдака, хәер-фатиха» ише тар мәгънәле төшенчәләр бар. Әмма 1966 елда Мәскәүдә чыккан татарча-русча сүзлектә «хәйрия, җәмгыяте хәйрия» төшенчәләре, мәгънәләре махсус ачылмаган хәлдә, кыскача гына теркәлгән. Ниһаять, Меценат дигән тарихи кеше исемен белсәк тә, шул исемнән ясалып, төгәл бер иҗтимагый күренешне белдергән меценатлык хакында да безнең сүзлекләрдә ләм-мим...

Мондый хәлнең килеп чыгуы, минемчә, тарихи чынбарлыкка концептуаль мөнәсәбәт белән бәйле. Мәсәлән, ул х о с у с ы й , ягъни, русча әйтсәк, ч а с т н ы й   милекнең табигыйлеген танудан баш тартуга, хәтта аның барлыкка килүе, урнашуы кануный икәнлеген инкяр итүгә барып тоташа.

Ярар, шул концепциягә таянып, милек ияләренең мохтаҗ кешеләргә, яисә җәмгыять хаҗәтенә үз ихтыярлары белән ярдәм итүләрен инкяр иттек, ди. Әмма шул милекне көч белән тартып-талап алуны, ахыр чиктә, әрәм-шәрәм итүне гаделрәк гамәл дип әйтеп буламы? Моның өчен бездән язмыш бүген «кычкырып көлде»: бөтен XX йөз буена диярлек хосусый милекчелек белән көрәшкән, большевистик шартларда туып үскән, тәрбияләнгән җитәкчеләребез шул гасырның ахырында ук, яңа битлек кигән хәлдә (янәсе «демократлашкан рәвеш-

тә»), өскә караган уч төпләрен алга суза-суза Җир шары буенча хәер соранып йөрделәр бит!

Әлбәттә, мондый хәлнең идеологик банкротлык нәтиҗәсе икәнлеге, аның хурлыклы күренеш булуы ап-ачык иде. Шуңа күрә, хурлыкны үз-үзеңнән яшерү чарасы буларак, «благотворительность», ягъни «изге эш эшләү» дигән гап-гади, җиңел аңлаешлы сүз урынына рус телендә спонсор име серлерәк яңгыраган чит сүз дә кулланыла башлады. (Мәсәлән, 1989 елда чыккан «Словарь иностранных слов» сүзлегендә ул юк.)

Хәйриячелекне буржуаз эксплуатациянең мәкерле төре, явыз коралы, дип расларга маташкан коммунист җитәкчеләребез үзләре дә, яшерен-батырын түгел, халыкны социаль, икътисади изүчеләр катламына әверелеп беткән иде. Ил-дәүләт «хуҗасы» саналган колхозчылар бушка дигәндәй эшләгән, эшчеләр исә сөт-катык, икмәк, арзанлы «чәй» колбасасы өчен чират торган шартларда, түрәләребез, үз дәрәҗәләренә карап, конвертларда исәпкә керми торган өстәмә акча алып яттылар, кибетләрнең арткы ишекләреннән кереп, чит илләрдән китерелгән затлы ризыклар ташыдылар, бал белән майда йөзделәр. Әллә мондый хәлләр булмадымы бездә?.. Аны өстен катлам тарафыннан оештырылган эксплуатация төре димичә, ничек атарга? Яки үз халкы авызыннан тартып алынган милекне бүтәннәргә (чит ил баш күтәрүчеләренә, социализм төзибез дигән африкалыларга, коммунистлыкны дәгъва кылучы башка ил сепаратистларына) «интернациональ ярдәм» дип, бушлай һәм үз халкыннан яшерен рәвештә өләшүләре белән совет җитәкчеләре үзләре үк төпсез һәм законсыз хәйриячелек эше белән шөгыльләнмәделәрме соң?.. Яисә үз илендәге халыкларның милли, рухи ихтыяҗларына кирәкле чыгымны бөтен ил милкен талап алып үзләштергән Мәскәү һәм җирле түрәләрнең, кул сузып, үтенеп сорагач кына, тамчылап-тамызып дигәндәй «бүлеп» бирүләре шул ук хәйриячелек күренешенең бер төре булмадымы икән?!.

Шулай итеп, төптән һәм әтрафлырак рәвештә уйлап карасак, эксплуатацияне бетерү дигән талпынышның тормышка ашмый торган, һәрхәлдә бездә чынбарлыкка аша алмаган буш хыял – утопия, ә хәйриячелек дигән нәрсәнең исә реаль милек хөкем сөргән шартларда котылгысыз күренеш икәнлеген белербез. Теләсәк тә, теләмәсәк тә... Шулай булгач, элекке милекле кешеләрне, аларның хәйрия юлындагы гамәлләрен кире кагуның яки хосусый хәйриялекнең әһәмиятен күрмәмешкә салыну үзе үк тормышчан һәм тарихи гаделсезлекнең бер чагылышы, дөресрәге, демагогик алдашуы була икән.

Ике чордагы ике төр (дәүләти һәм хосусый) хәйриялек арасында, һичшиксез, уртаклык бар. Ул бер нәрсәгә – кешеләр һәм халыклар эшләп тапкан милектән, байлыктан «башкаларга» өлеш чыгаруга кайтып кала. Аерма да бар, әлбәттә. Хакимият ияләре, хөкүмәт вәкилләре, ягъни чиновник-түрәләр законлы (тиешле һәм гадел күләмдә салым җыю), яисә законсыз (ягъни экспроприация юлы белән тартып-талап) тупланган байлыктан күп очракта үз өстенлекләреннән, үз кәнәфиләреннән колак какмас өчен генә милексез калган, «хәерчелектә тигезләнгән» халыкка мәҗбүри рәвештә, тамчылап-тамызып дигәндәй, «сәдака» бүлү белән шөгыльләнгән. Җылы урыныннан «очу», яки «өстән» шелтә алу куркынычы булмаса, гадәти чиновник халык ихтыяҗына бармак аша карый, хәтта төкерә генә аңа! (Дәүләтнеке дип исемләнгән байлыкның зур өлеше, безнең тарихтан күренгәнчә, иң элек түрәләр катламын туендыруга, сугыш кораллары ясауга, яки, югарыда бер әйтелгәнчә, «интернациональ ярдәм»гә китеп бетә иде.)

Ниһаять, чиновник-түрәләрнең, шулардан торган хөкүмәт-дәүләт аппаратының халыкның рухи һәм мәдәни ихтыяҗларына бик өстән карауларын, аларны сәяси һәм идеологик мәнфәгатьләргә буйсындыруларын, кирәге чыкса, корбан итүләрен татар тарихы яхшы белә. Әйтик, без тарыган, тәмен мул татыган «дәүләт хәйриячелеге» булмаса, бер гасыр эчен-

дә ике-өч тапкыр язу алмаштыру ише фаҗигагә дучар булыр идекме? Яки XVIII-XIX гасырларда татарларның үзләре тарафыннан андый «геростратлыклар» башкарылу мөмкин идеме? Димәк, чиновник-түрәләр матди байлыкны гына түгел, рухи-мәдәни хәзинәне дә туздырырга сәләтле икән. Чөнки алар бер нәрсәгә дә чын хуҗа түгел. Алар вакытлы арадашчылар гына...

Хосусый милек ияләре, чиновниклардан башка буларак, үзләре тырышып-тырмашып, әлбәттә, башкаларны да эшләтеп, ягъни эксплуатацияләп туплаган, яки аталарыннан мирас рәвешендә калган, мәгәр Нух пәйгамбәр заманыннан бирле законлы дип исәпләнгән үз милегеннән аерым мохтаҗ кешеләр яки җәмәгать-халык ихтыяҗы өчен үз ихтыярлары белән өлеш чыгарып торган. (Эксплуатация мәсьәләсенә төртеп, «мәгънәле» авыз ермыйк: совет чорында да, күргәнебезчә, ул күренеш гамәлдә булды.) Әлбәттә, монда да чама хисе хөкем сөргән. Ләкин эш урыныннан, түрәлек өстенлегеннән колак кагу куркынычы астында түгел, бәлки «яхшылык эшлим әле» дигән ихтыяри теләкләр белән «үз авызыннан» бүлеп бирелгән. Димәк, хосусый һәм шәхси хәйриячелек дәүләти һәм рәсми кайгыртучанлыктан, әхлак җәһәтеннән караганда, бер башка биегрәк, өстенрәк булып чыга.

Дөрес, милекле кешеләр, байлар дөньясында, кем әйтмешли, котсыз сараннар, намуссыз бәндәләр җитәрлек булган шикелле, түрә-чиновниклар арасында да халык-кавем, кешеләр мәнфәгате алдында үз бурычларына тугрылыклы, ихлас күңелле игелекле затлар очрап торгалаган. Шулай ук, соңгыларында күпчелекне мәкерле карьеристлар, туң йөрәк формалистлар тәшкил иткән кебек, байлардан да башкаларга карата рәхим-шәфкатьле һәм юмарт, үз кавеменә ихлас теләктәш, аның мәнфәгате өчен янып-көйгән асыл затлар, затлы нәселләр дә чыкканлыгы бәхәссез...

Мәсьәләнең күп очракта без уйлап җиткерми торган катлаулырак яклары да бар. Мәсәлән, без иң элек хәйриялекне, хәйриячеләрне күрәбез һәм аларга бәя бирәбез. Ләкин үзе-

безне яхшылап белеп, үзебезнең аларга карата булган мөнәсәбәтләребезне объектив рәвештә бәяли алдыкмы, алабызмы? Безнең узган тарихыбызда күпме эре хәйрияче, меценат булган, аларның саннарын, конкрет гамәлләрен, исемнәрен төгәл атый алабызмы? Ниһаять, хосусый хәйриячелек дигән күренешнең иҗтимагый җәһәттән төп эчтәлеге, фәлсәфи асылы, әһәмияте һәм кыйммәте нәрсәдән гыйбарәт?!.

Сорауларның беренчесенә карата шуны әйтергә мөмкин. Безнең хәзерге җәмгыятебездә хәйриялеккә һәм, гомумән, милекле кешеләргә карата шактый каршылыклы мөнәсәбәт яшәп килә. Бер ишебез бай кешеләрне гомумән яратмый, күралмый һәм элекке түрәләрнең «гаделлек»ләрен сагынып яши (тик хәзерге яңа байларның күп очракта шул ук түрәләрнең үзләре яки якыннары, балалары икәнлеген уйлап тормый). Икенчеләребез исә һәр «яңа урыс» белән «яңа татар»дан әллә нәрсәләр өмет итә, аларның барысыннан да киң юмартлык, гализат меценатлык көтә.

Чынлыкта чиновник-түрәләр сүзнең төп мәгънәсендәге хәйриячеләр булмадылар, була да алмыйлар. Алар бары дәүләт кулында тупланган милек белән халык ихтыяҗы арасындагы арадашчылар хәлендә.

Яңа байларга килсәк, аларның да зур күпчелеге өчен хәйриялек – кул җитмәслек биеклектәге серле төшенчә. Аларда, – байлыкны эшләп һәм эшләтеп тапмыйча, бары «реформалар», дефолтлар чорында финанс махинациясе, яисә дәүләтнекен юк бәягә үзләштерү юлы яки аракы сәүдәсе белән кинәт баеп калган кешеләрдә һәм, иң мөһиме, үзләре туйса да, күзләре һаман туймаган рухи люмпеннарда – хәйриячелек дигән күренешнең фәлсәфи мәгънәсен, иҗтимагый әһәмиятен аңларлык зиһен, интеллект, эчке культура җитеп бетми әлегә. Бик азлары гына, караңгыда капшанып дигәндәй, әлеге биеклеккә таба елышырга тырыша... Монысына да шөкер итик...

Сүз уңаенда шуны да әйтергә кирәк, соңгы елларда бездә гамәлгә азлап-азлап керә башлаган хәйриячелек фактларына

карата болай икелерәк бәя бирүнең үз сәбәбе бар. Әйтик, төрле авылларда, аерым шәһәрләрдә яңа мәчетләр салыну, моңа киң җәмәгатьчелекнең катнашу фактларын алыйк. Ярдәмгә кайбер оешмаларның, зур предприятиеләрнең җитәкчеләре дә катнашуы мәгълүм. Болар, һичшиксез, күңелле күренеш. Ләкин мәчет салынып беткәч, аңа фабрика яки башка бер оешма җитәкчесенең исеме бирелүе (әйтик, «Альберт мәчете», «Хәйрулла мәчете»ише) гаҗәбрәк күренеш. Беренчедән, ул җитәкчеләр мәчет салдырыр өчен үз акчаларын түгел, бәлки оешма-предприятие милкендәге материалларны җибәртеп, хәтта төп эш урыннары шунда булган эшчеләрне күндереп ярдәм иткәннәр. Димәк, авылдагы ялгыз мәчеткә исем кую шарт булса, түрә-чиновникларның түгел, бәлки завод-фабриканың исемен бирү дөресрәк булыр иде. Соңгы вакытларда кайбер зур, икътисади көчле предприятиеләрнең махсус ярдәм фондлары оештыруы, аңа битарафрак рухлы исем куюлары гаделрәк, дөресрәк алым. Икенчедән, бөтен җәмәгатьнең, төгәл бер мәхәлләнең иман йорты булган урынга аерым бер, кайбер очракта шөбһәле шәхеснең исеме бирелү, дөресен әйткәндә, мәкруһ (начар, кире кагыла торган) күренеш. Мисал китереп маташмыйк: «Мәрҗани мәчете», «Әҗем мәчете» ише исемнәр, соңрак, мәчетләр күбәйгән чакта стихияле рәвештә барлыкка килгән т а р и х и исемнәр. Ниһаять, өченчедән, гыйлем һәм уку йортларына, завод-фабрикаларга исем кую гадәте иң элек Алманиядә барлыкка килгән, аннары Русиядә, бигрәк тә СССРда киң таралган, күп очракта мәгънәсезлеккә китерә торган гадәт (бездәге һәр егерме-утыз ел саен исем алмаштыру «бизгәгенә» игътибар итегез).

Гомумән, хосусый милекчелек гадәти хәл булып исәпләнгән элекке чорларда да, чын хәйриячеләр, дәвамлы меценатлар саннары буенча әлләни күп булмаган. Бу әйтелгәннәрнең дөреслеген татар чынбарлыгы тулысынча раслый. Мәсәлән, XVIII йөзнең икенче яртысыннан, ягъни татарларга үз диннәрен тоту, сәүдә итү, эшкуарлык белән шөгыльләнү өчен чик-

ләнгән хокук бирелгән чордан алып, XX гасырның башына кадәр безнең халыкта меңләгән дип әйтерлек хәлле, милекле кешеләр яшәп узган. Ләкин алар арасыннан чыккан хәйриячеләр, дөресрәге, шундый шәхесләрнең иң күренеклеләре бик аз иде (русларда да шундый ук хәл).

Тарихыбызда менә шундый бармак белән санарлык хәйрияче һәм тагын да азрак сандагы меценатларыбыз арасында беренче бишлеккә керүчеләр исәбеннән бертуган Шакир һәм Закир Рәмиевләрне атарга кирәк. Ләкин бу мөхтәрәм затларның хәйрия-химаяче буларак башкарган эшләрен, әдәп-әхлак җәһәтеннән бөеклекләрен чын-чынлап аңлар, объектив рәвештә бәяләр өчен тарихыбызның башка сәхифәләренә дә күз салып узу зарур.

***

Мохтаҗ кешеләргә, ярлыларга, ятим-толларга һәм авыру-зәгыйфьләргә хәйриялек юлы белән рухи һәм матди ярдәм күрсәтү гамәле, фикер вә идея буларак, бик борынгы заманнарда ук барлыкка килгән. Кешелек җәмгыяте цивилизацияле тәрәккыят, үсү юлына баскач, бигрәк тә китаби диннәр оешып киң таралгач, хәйриялек идеясе дә билгеле бер әхлакый норма, дини тәгълимат күренешенә әверелгән. Кайсы гына диннең өйрәтүләренә мөрәҗәгать итсәк тә, ярдәмчелекнең, ягъни химая-хәйрия эшенең изгелек, иманлылык галәмәте, хәтта хәлле кешеләр тарафыннан эшләнүе зарури бурыч сыйфатында тәкъдим ителүен күрербез. Кайбер дини тәгълиматларда хәйриячелектән баш тарткан сараннарга, каруннарга төрле куркыныч җәзалар вәгъдә ителүе дә диннәрнең шул мәсьәләгә зур әһәмият бирүен күрсәтсә кирәк.

Гомум тәгълиматы, конкрет мәсьәләләр буенча өйрәтүләре бик җентекләп, төрле яклап, тәфсилләп эшкәртелгән Ислам дине дә хәйриячелекне шул диннең үтәлүе һичшиксез тиешле, зарур бер таләбе дәрәҗәсенә күтәргән. Моңа «зәкят» дигән бик борынгылыктан килә торган махсус исем беркетелгән. Милекле мөселманнар (бары мөселманнар гына) мон-

дый бурычтан качмасын өчен зәкятка в а җ и б , ягъни үтәлүе һичшиксез тиеш дигән, ф а р ы з д а н кала икенче урында тора торган дәрәҗәдә бирелгән. Бары зәкят дөрес һәм тиешле кешеләренә, ягъни ярлыларга, тол-ятимнәргә, мохтаҗ илгизәрләргә һәм гариб-горабаларга бирелгән очракта гына мөселманнар өчен милек һәм аннан килгән конкрет керем «пакьланган, аруланган», ягъни х ә л ә л дип исәпләнгән.

Хәйрия эшләренең дини тәгълиматка кертелеп, җитди контроль астына алынуы – аларның җәмгыять тормышындагы функциясен көчәйтә. Милекле гади кешеләр генә түгел, бәлки эш-дәүләт башында торган хакимият вәкилләре дә, үз милегеннән зәкят һәм башка рәсми салымнарны түләүдән тыш, хосусый хәйриячелек, ягъни үз милегендәге байлыктан мохтаҗлар һәм җәмгыять файдасына ихтыяри өлеш чыгару, бигрәктә иҗат әһелләренә: галим-голәмәгә, шагыйрь һәм әдипләргә, рәссам һәм музыкантларга меценатлык ярдәмен күрсәтү белән актив шөгыльләнгәннәр. Хәтта бу юнәлештә үзара ярыш та оештырганнар. Мондый күренешнең заманында шактый киң таралган булу фактларын төрле мөселман илләре тарихында күргән кебек, Болгар дәүләте, Жучи Олысы империясе һәм Казан ханлыгы чорларына караган язма истәлекләрдән, бигрәк тә әдәби әсәрләрдән мул табарга мөмкин. Мәсәлән, мәчет-мәдрәсәләр салыну, әдәби әсәрләр иҗат ителү, галим-голәмәләр тәрбияләү фактлары. Шулай ук дәүләткә бернинди салым түләми торган в ә к ы ф милегенең киң таралган күренеш булуы да характерлы. Вәкыфларның бары хәйрия юлы белән шәхесләрдән җыелган милек нигезендә генә барлыкка килгәнлеген, яши алганлыгын онытмыйк. (Бездәге вәкыфлар тарихы үз алдына мөстәкыйль тема.)

Әмма Казан ханлыгы яулап алынгач, мәчет-мәдрәсәләр җимерелеп, татар вәкыфлары туздырылгач, социаль тормышта шәригать кануннары Русия дәүләте законнары белән алмашынгач, ниһаять, ике-өч гасыр дәвамында татарның милекле өлеше, ягъни аксөяк катламнары, җир биләүчеләре кырыпсебереп дигәндәй юк ителгән иде. Мондый шартларда, вак-

төяк сәдака бирүләрне исәпкә алмаганда, дәвамлы һәм күләмле хәйрия эшләре белән шөгыльләнү турында уйларга да урын һәм мөмкинлек калмаган иде. Бары XVIII гасырның икенче яртысыннан алып, дөресрәге, «Әби патша» чорында, Русиядә элекке кыргыйлыктан китәргә омтылып, аурупача цивилизацияле идарә итү алымнары күренә башлагач, җөмләдән татарларга дин тотуда, икътисади тормышта да беркадәре ирек бирелгәч, хәйриячелекнең кайбер күренешләре барлыкка килә башлый. Әйтик, байлардан җыелган иганә исәбенә яңа мәчетләр салыну, алар янында ачыктан-ачык эшли торган мәдрәсәләр тәрбия ителү фактлары. Бу күренеш, әлбәттә, иң элек сәүдәгәрләр катламы оешып, халыкның бер өлешендә хосусый милек – капитал барлыкка килүнең, шуннан хәйриялек максатына өлеш чыгарылуның нәтиҗәсе иде.

Татар сәүдәгәрләрендә милли капиталның барлыкка килүе, үсүе иң элек руслар үтеп керә алмый торган мөселман Шәрегынә юл ачылу белән бәйле иде. Шәрекъ илләре белән сәүдә эшләрен җайга салу өчен татарлардан файдалану мөмкинлеге идеясен XVIII йөзнең урталарында патша хөкүмәте дә таныргә мәҗбүр була. Оренбург янында махсус Сәгыйть бистәсе салыну, кайбер салым төрләреннән азат ителгән татар сәүдәгәрләренең казакъ сахраларына, «кяферләр» өчен ябык Урта Азия ханлыкларына, «серле» Шәркый Төркестан шәһәрләренә, ерак Иран, Әфганстан, хәтта Һиндстан җирләренә дә үтеп керә башлау фактлары, тәфсилләп өйрәнелмәгән булса да, фәндә яхшы ук мәгълүм.

Русиядә капиталистик мөнәсәбәтләрнең урнаша башлау процессында татарларда тукымачылык, тире эшкәртү (күнчелек), сабын кайнату, шәм кою, милли кием-салымнар тегү ише җиңел сәнәгать төрләренең яралгылары, кайбер очракларда куәтле генә учаклары барлыкка килгән иде. Бу процесс та милли капитал үсүдә, ныгуда мөһим роль уйнаган иде, әлбәттә.

Татарда милли капиталның чын-чынлап оешкан, ныгый барган чоры Русиядә крепостнойлык (ярым коллык!) систе-

масының җимерелүенә туры килүе – бездә электән үк аерым фикер рәвешендә яшәп килгән м ә г ъ р и ф ә т ч е л е к идеясенең иҗтимагый хәрәкәт дәрәҗәсенә күтәрелүен тәэмин иткән иде. Татар мәгърифәтчелегенең дәвамы, югары этабы булган җ ә д и т ч е л е к хәрәкәтенең киң колач җәюе, кайбер сыйфатлары белән милләтне оештыручы, хәтта аны «яңадан тудыручы» кодрәтле көчкә әверелүе дә, әгәр төптән уйлап карасак, шул милли капитал – татарның хосусый милеге химаясендә (ярдәмендә, канаты астында!) тормышка ашкан казаныш иде.

Әгәр егерме-утыз ел эчендә генә Русиядәге татарлар яшәгән төрле җирләрдә йөзләгән-йөзләгән яңа типтагы яки яңартылган мәктәп-мәдрәсәләр барлыкка килүен җентекләп тикшерсәк, алар арасында «Мөхәммәдия», «Хөсәения», «Мәрҗания», «Госмания», «Галия», «Касыймия», «Әмирхания», «Рәсулия», «Мотыйгыя» кебек шәһәр уку йортларын, шулай ук Иж-Бубый, Кышкар, Каргалы, Эстәрлебаш, Бәрәскә шикелле бер-берсенә охшамаган дистәләгән-дистәләгән авыл мәктәп-мәдрәсәләренең тарихларын өйрәнә башласак, без күпләгән химаячеләр, хәйриячеләр белән очрашыр идек.

Әгәр «Тәрҗеман» гәзитенең ничек, кемнәрнең идеясе һәм матди ярдәмнәре белән чыгу, озак яшәү фактларын барлап, 1918 елга кадәр чыккан башка дистәләгән татарча гәзит-журналларыбыз язмышларында да актарынсак, тагын милли хәйриячеләребезнең исемнәрен телгә алыр идек.

Игътибар итик: боларның барысы дүрт йөз елга якын дәүләткә барлык салымнарны түләп килгән, солдатка газиз балаларын биргән (башта һәммә җир милекләре дә «казнага күчкән»), ләкин үзенең рухи, мәдәни ихтыяҗлары өчен шул дәүләттән бер тиен дә алмаган, ала алмаган татарларның үз омтылышлары, үз аң-белемнәре, үз тырышлыклары, үз матди көчләре белән барлыкка китерелгән казанышлары – милли хәзинәсе иде.

Нәкъ шушы урында укучыларның бер сорау куюы ихтимал: кемнәр соң ул йөзләгән мәктәп-мәдрәсәләрне тәрбия-

ләп, әлеге чагыштырмача аз тиражлы, димәк, файда китерми торган гәзит-журналлар чыгаруга матди җирлек тудырган фидакяр затлар?

Дөресен әйткәндә, бу сорауга без бүген (бәлки хәзергә) барлык төгәллекләре белән, эшчәнлекнең төрле якларын чагылдырган хәлдә, тулы җавап бирә алмыйбыз. Нибары шул юнәлешләрдә актив һәм эзлекле рәвештә эшләгән бер уч фамилияне генә атый алырбыз. Мәсәлән: Алкиннар, Апанаевлар, Акчуриннар, Баязитовлар, Борнаевлар, Галиевләр, Дибирдиевләр, Кәримевләр, Насыровлар, Нигъмәтуллиннар, Рәмиевләр, Сәйдәшевләр, Хөсәеневләр, Юнысовлар, Яушевлар...

Тагын күпме исем өстәп булыр боларга? Ә инде һәр авыл саен диярлек үз чыгымнары белән мәчет-мәдрәсәләр салдырган, дәвамлы рәвештә аларны тәрбияләгән яки мәхәллә инициативасы белән җәмәгатьчелектән хәл кадәри һәм чамалы гына акча җыелган шундый эшләргә үзләреннән зур өлеш керткән «уртакул» хәйриячеләребезнең исемнәрен, йөздән унын гына булса да, санап чыга алабызмы? Юк, әлбәттә. Бигрәк тә аерым-аерым рәвештә фикер йөртеп, бер-ике кешенең «хәтер янчыгында» гына казынган чакта...

Элекке чор химая-хәйриячеләребез хакында бүген шулай аз белүебезнең объектив сәбәпләре дә бар, билгеле. Шулардан берсе, югарыда күрсәтелгәнчә, совет чорында хәйриялек идеясен тулаем кире кагудан, хәйриячеләрнең үзләрен исә мәкерлелектә гаепләүдән гыйбарәт иде. Әйтик, татар әдәбияты белемендә китап чыгаручы наширләрне, мөхәррирләрне урыны килгән-килмәгән саен эксплуататор сыйфатында тамгалау гадәткә кергән иде. Хәтта зур хезмәт хакы, шигырьләре өчен төшкә керми торган гонорар вәгъдә итеп, Габдулла Тукайны Оренбургка эшкә чакырганы өчен Рәмиевләрнең гайбәте дә шактый чәйнәлде. 1920-1930 еллардагы иҗтимагый агым, тупас социологизм шаукымына бирелгән Мәҗит Гафуриның «Шагыйрьнең алтын приискасында» исемле, нигездә саерак фикерле язмасы мәктәп дәреслекләрендә урын алып килде. Шул рәвешчә «миллионер шагыйрь» Дәрде-

мәнднең – Закир Рәмиевнең – зур эксплуататорлардан булуы хакындагы фикер яшьтән үк башка сеңдерелде.

***

Эксплуатация мәсьәләсе кузгатылган икән, ул чакта бу күренешне тулаем кире кагу идеясен гел алга сөргән, СССРда аны «бөтенләй бетердек», дип игълан кылган совет чынбарлыгына да мөрәҗәгать итеп карыйк. Ләкин мин бу урында халыкның хосусый милеге тартып алынуы яки туздырылуы, игенче халыкның бушлайга диярлек эшләве, завод-фабрика эшчеләренең ачка үлмәслек хәлдә генә хезмәт хакы алулары, ачтан үлүчеләрнең сөякләре өстендә Беломорканалны, ГЭСлар, Магнитогорск, Чиләбе комбинатларыише башка йөзләгән-меңләгән «гигантлар» төзелүе хакында махсус сөйләп тормыйм. Шулай ук «башкача социализм төзеп булмый иде» дип, ул социаль изүләрне, чын эксплуатацияне, ягъни яңартылган крепостнойлык шартлары белән килешкән, матур вәгъдәләр хакына аларны акларга теләүче кол психологияле люмпеннарга да җавап биреп торуны кирәк тапмыйм... Мин бары конкрет кешеләрнең, бигрәк тә иҗат ияләренең конкрет хезмәтләре өчен нинди бәя, «әҗер» бирелүне күрсәтә торган бер-ике хосусый мисалны китерү белән чикләнәм. Тик рубльдә бирелә торган гонорарның да күләменә, реаль кыйммәтенә кагылмыйм, чөнки «күпме бирә», кем әйтмешли, бу «хуҗаның үз ихтыяры». Мин бары совет кешеләренә чит илләрдә сирәк эләккәләгән премия һәм гонорарлар тарихыннан гына фактлар китерәм.

Беренче мисал. XX гасырның 60 нчы еллары ахырында, Иран дәүләтенең ике мең еллык юбилеен уздырган чакта, совет галимнәреннән Эрмитаж музееның ул чактагы директоры, атаклы археолог Б.Б.Пиотровскийга (хәзерге директорның әтисенә) һәм Ташкенттан иранчы галим Шаһислам Шаһморадовка Шәрекъ илләренең тарихларын, мәдәниятләрен өйрәнүгә керткән зур өлешләре өчен Фирдәүси исемендәге премияләр бирелә. Һәр бүләкнең күләмен 150 мең туман тәшкил итә. Бик зур сумма! Ике галим кичен кунакханәдә бу

кадәре акчаны илгә ничек алып кайтырга, ничек тотып бетерергә, дип баш ваталар. Шаһислам агай «Волга» машинасын сатып алу ниятенең тормышка ашуы хакында хыяллана. Тик акчаның артып калганын кая куеп бетерергә, дип борчыла ул. Әмма юкка гына була бу җәфаланулар. Мәсьәлә гаять җиңел хәл ителә: иртәгесен аларны совет илчелегенә чакырып алалар да, премия акчаларын СССРдагы фәлән-фәлән шәһәрләрдә салыначак музыка мәктәпләре өчен бүләк итәбез, дип гариза язарга кушалар. Үзләре ихтыяри язмасалар, партбилетларын чыгарып салырга кирәк буласын да белдерәләр. Дөрес, үз илләренә кайтып җитәр өчен бераз сумма бүлеп бирәләр. Ачуы чыккан лауреат, Ташкентка кайткач, бурычка алып булса да, бер иске «Москвич» сатып ала-алуын... (Бу вакыйга хакында Шаһислам әкәдән хикәятне үзе ишеткән Җ.Зәйнуллин сөйләде; аның үзенең дә Гыйракта шундыйрак хәлгә эләккәне булган икән.)

Икенче мисал. Татар әдибе Җәвад Тәрҗемановның «Шуктуган» исемле кечкенә генә китабы, белгәнебезчә, бик күп телләргә тәрҗемә ителгән. Бельгиядә чыккан басмасы өчен автор исеменә ике мең доллар чамасы кыйммәткә ия әлләничә мең франк гонорар килеп төшә. Мәскәүгә, әлбәттә. Гонорарны алыр өчен чакырталар үзен. Ичмасам, пенсиягә генә тилмермичә яшәп, иркенләп бер иҗат итәрмен дип хыялланган Җәвад аганың кулына Мәскәүдә, барлык «законлы исәп-хисапны» күрсәткәч, 186 рубль тоттыралар. (Бу хакта автор миңа үзе сөйләгән иде. Әсәрләре чит илләрдә еш басыла торган кайбер мәскәүле язучыларның гонорар исе чыгуга үзләре шунда барып, акчаларының бер өлешенә булса да, киенеп кайтулары гадәткә керүе очраклы булмаган, димәк.)

Сәламәтлекләрен җимерү исәбенә халыкара ярышларда беренчелекне, икенчелекне яулаган совет спортчыларының гонорарларыннан җиңү казанучыларның үз кулларына күпме тию фактларын саный башласаң, сүз артык сузылып, әңгәмәбез дә төп темадан читкәрәк китәр иде. Ләкин китерелгән хәтле һәм җитди, һәм көлкеле мисаллардан да шул нәрсә яхшы күренә: совет чорындагы безнең элекке эксплуататорлар-

ны гаепләвебез угрының күз буяу, башкаларны ялгыштыру өчен акырып каравыл кычкыруына охшаган икән ләбаса!

Эксплуатация мәсьәләсенә җитдирәк мөнәсәбәт белән карасак, матди җитештерү, эшкәртү һәм эшләп чыгару мөнәсәбәтләре хөкем сөргән, кешелек җәмгыятен хайванат дөньясыннан аерып тора торган шартларда аның котылгысыз, хәтта зарури күренеш икәнлеге бәхәссез. Ул булган, бар һәм булачак. Чөнки хезмәт нәтиҗәсенең бер өлеше икенче кешеләр тарафыннан үзләштерелүе, ягъни эксплуатация дигән нәрсә, ахыр чиктә, эш мәйданын булдыручының, анда мөмкинлек һәм тәртипләр урнаштыручыларның шул оештыру, оештыра белү, оештыра алу хезмәтләре өчен эш хакы алуыннан гыйбарәт бит. Киресенчә булса, оештыру дәрәҗәсе хезмәт буларак тиешлечә югары бәяләнмәсә, завод-фабрика, колхоз-совхоз җитәкчеләре, төрле мөдир-директорлар гади эшче, гади хезмәтче белән гадәти колхозчыдан түбәнрәк эш хакы алган булырлар иде. Ә менә милек иясенең оештыру сәләте, тырышлыгы, белеме – хезмәт түгелме соң? Әллә хосусый милек иясе аз эшләгән кешегә күп хак биреп, җыелган милекне туздырырга тиешме? Һәм шундый «тәртип» урнашканда гомумән милек җыелып, халык, ил-дәүләт байлыгы барлыкка килеп, аннан башкалар өчен өлеш чыгар идеме? Әгәр Рәмиевләрнең еллар дәвамында тырышып оештырылган алтын приискалары, анда күпләгән эшчеләр эшләве булмаганда, ун-унөч ел дәвамында өзлексез чыгып торган, узгандагы мәдәни тарихыбызның йөзек кашларын тәшкил иткән «Вакыт» гәзите, «Шура» журналы барлыкка килер идеме? Ниһаять, шул гәзит-журналдан ахыр чиктә татар халкы, аның, хезмәт ияләре зарар күрдеме, әллә файда алдымы?! Мондый сорауларга ниндирәк җавап бирелү ул конкрет шәхеснең иҗтимагый аңына, эчке культурасы белән интеллектуаль ихтыяҗларына бәйле булса кирәк...

Дөрес, кешеләр арасындагы икътисади мөнәсәбәтләрдә эксплуатациянең кыргый, оятсыз төрләренә чик куя торган чараларга да ихтыяҗ булды, бар һәм булачак. Әмма аны хәл итәр өчен башкаларны талауның, экспроприацияләр оештыруның, ягъни мәсьәләне бер кизәнүдә «хәл кылуның» ярак-

сыз, ялгыш гамәл булганлыгы тулысынча расланды инде. Дөньядагы иң бай илләрнең беренчесе булган СССРдагы халыкның гомум ярлылыкта яшәве («хәерчелектә тигез» булганы өчен үзен «бай» дип исәпләргә, алданырга күнегүе...), ниһаять, «явызлык империясе» булган, иң кодрәтле илләрдән саналган милитаристик дәүләтнең бер Әфган сугышы нәтиҗәсендә тезләнүе, шартлап җимерелүе, хәтта бөтен социалистик лагерьның таркалуы моны артыгы белән раслады.

Димәк, яңадан утопиягә бирелмәсәк, хезмәт өчен гадел рәвештә түләү мәсьәләсе, бүген дә актуаль булганы кебек, киләчәктә дә үз көчендә калачак. Минемчә, гаделлек мәсьәләсе бары чама хисе һәм законлылык таләпләре белән билгеләнеп, аның урнашу юлы чагыштырмача дәрәҗәдә генә хәл кылыначак. Шулай икән, киләчәктә дә (әгәр ул киләчәк гомумән реаль нәрсә булса) халык, милләт тормышының, рухи һәм мәдәни ихтыяҗның күп мәсьәләләре милек ияләренең аңнарына, конкрет гамәлләренә бәйле булачак. Чөнки нормаль хәлдә яшәп, нормаль рәвештә тәрәккый итә торган социаль-иҗтимагый шартларда халык һәм милләт үз ихтыяҗлары өчен үзе эшләргә, үзенең киләчәген үзе кайгыртырга тиеш. Ә «үзе» булып беренче планга, кырыс тарих кат-кат күрсәтә килгәнчә, милек ияләре, ягъни мөмкинлекләре булган кешеләр чыга икән. XIX йөзнең икенче яртысы белән XX гасырның башында, ягъни «үз буржуйларыбыз» аякларында нык басып торган чорда, халкыбыз ирешкән рухи-мәдәни казанышлар моны артыгы белән раслады. Бөек фикер иясе, атаклы галимебез Ризаэтдин Фәхретдин хәзрәтләре кат-кат әйткәнчә, халык милләт буларак нормаль яшәсен, нормаль тәрәккый итсен өчен – ул бай булырга тиеш.

Милләт байлыгын исә җыеп алып, бер җиргә өеп куйган, шуннан булдыра алган теләсә кем «чәлдереп», ягъни урлапташып әрәм-шәрәм итә торган конкрет хуҗасыз «уртак мал» түгел, бәлки аерым шәхесләр, традициягә ия нәселләр кулында бөртекләп җыелудан тупланган, яхшы саклануы, үстерелүе тәэмин ителә торган хосусый милек – хосусый капитал тәшкил итә. Мондый байлыкның ничек җыелуын һәм ничек

әрәм-шәрәм ителү ихтималын үзенең бер шигъри парчасында Дәрдемәнд дә образлы итеп тасвирлаган:

Әгәр илгә таратсаң бер хәзинә,
Бер акчадан төшәр һәр өй беренә.
Бер акчадан әгәр алсаң алардан,
Булыр һәр көн дә хасил бер хәзинә.

Димәк, эш оештыра белүләре белән «һәр өйдән» (эшләгән кешедән) берәр тәңкәдән файда алып капитал туплаган Рәмиевләр «тамыры» белән халыкныкы булган шул капиталны, миллионнар рәвешендә халыкның үзенә кайтарган булып чыга. Шулай булгач, Рәмиевләр башкарган хәйриячелек иҗтимагый аңлылык нәтиҗәсе булган икән.

Шул ук вакытта, киләчәк өметләр бары милек ияләрендә, аларның хәйриялек эшендә дигәч тә, башкаларга ярдәм итүнең кирәкле гамәл икәнлеген аңлаган белемле, юмарт бер байга утыз-кырык аңсыз, ачкүз, саран бәндәләрнең туры килүен дә онытмаска кирәк. Халык, милләт мәнфәгатен тирән аңлаган, үз кавеменең гомум тәрәккыяте өчен гомер буе хезмәт иткән олы хәйриячеләр, чын меценатлар тагын да азрак очрый. Шулай булгач, бертуган Рәмиевләр – үз замандашлары булган Хөсәеневләр, Нигъмәтуллиннар, Акчуриннар кебек үк – сирәкләрнең сирәкләреннән булган икән.

Әмма Рәмиевләрнең хәйриялек өлкәсендәге эшчәнлеге кинәт туган вә кыска вакыт кына гамәлдә булган гадәти юмартлык галәмәте дә булмаган. Шакир Рәмиевнең 1881 елда Истанбулда укып яткан бертуган энесе Закирга язган бер хатыннан күренгәнчә, ул яшьтән үк халык өчен кирәкле китаплар чыгару, басмаханә, ягъни нәшрият булдыру нияте белән яшәгән, үз ана телендә гәзит-журнал чыгару хакында да хыялланган. Башка чыганаклардан беленгәнчә, аның Гыйльман ахун Кәримигә нәшрият оештыруга, Исмәгыйль Гаспралыга «Тәрҗеман» гәзитен чыгаруга матди ярдәм күрсәтүе мәгълүм. Шулай ук аның үз акчасыннан татар мәдрәсәләрендә, рус мәктәпләрендә укучы яшьләргә даими стипендияләр биреп торуы, берничә шәһәрдәге хәйрия җәмгыятьләрендә

гамәли яки шәрәфле әгъза булып, аларга да дәвамлы рәвештә матди ярдәм күрсәтүе дә билгеле.

Димәк, кайчандыр бабаларының бабалары нәселле морзалардан булган, соңрак буыннарда сәүдәгәргә әверелгән Мөхәммәтсадыйк Рәминең уллары – бертуган Шакир һәм Закир Рәмиевләрнең «Вакыт», «Шура»ларны өзлексез чыгарып ятулары аларның гомум хәйриялек эшчәнлегенең бер конкрет өлеше, зур өлеше булган икән. Без моңарчы, Дәрдемәнднең әдәби мирасы хакында бераз белгәнебез хәлдә, аның туганы Шакирның әхлакый йөзен, кешелек сыйфатын, кыскасы, сирәк очрый торган асыл кеше булуын, кызганычка каршы, тиешенчә аңлый, бәяли алмадык, күрсәтә дә белмәдек. Бу җәһәттән без заманында Риза казый Фәхретдин ирешкән әхлакый биеклектән күпкә түбән тәгәрәп төштек...

***

Чын хәйрияче олы затларның аз булуына гаҗәпләнмик. Монда үзенә күрә бер закончалык хөкем сөрә. Әнә бит «халык власте»ның гәүдәләнешенә, гомумән, гаделлекнең «соңгы инстанциясе»нә дәгъва иткән совет чорында да ачык бюджеттан халыкның мәдәни ихтыяҗына бүленеп бирелә торган өлеш өч-дүрт процентан артмый иде. Әмма дәүләт бюджетының җәмәгатьчелеккә игълан ителмичә (хәрби һәм сәяси ихтыяҗлар өчен аерым тотылган) яшерен тармакларын да кушып исәпләсәң, әлеге өч-дүрт процентның гомум чыгымга нисбәтенең тагын да азрак булганлыгы беленә. Шул ук вакытта совет власте чорында рухи-дини ихтыяҗлар өчен бер тиен дә бирелмәвен, мәгәр гыйбадәт йортларыннан салым алынуын да яхшы беләбез...

Һәрхәлдә минем якынча исәбем (бәлки капшанып кына ясаган фаразым) буенча, реаль хәйрия эше белән шөгыльләнүчеләр хәлле милек ияләре катламының, ягъни бай кешеләрнең дүрт-биш процентын гына тәшкил иткәнгә охшый. Ләкин шул дүрт-биш «бөртекнең» фидакярлеге аркасында XX йөз башында татар мәдәниятенең нинди казанышларга ирешүен, шул казанышның соңгы чор язмышыбызга да нинди тәэсир ясавын күрүе артык кыен булмаса кирәк. Әлбәттә,

болай раслаганда мин күңел күзләре ачык, реаль белемле кешеләрне күз уңында тотып фикер йөртәм...

Җыеп әйткәндә, аңлылык һәм эчке культура байлыгында химая-хәйриячеләрнең барлыкка килүе ул очраклылык галәмәте, яки примитив юмартлык күренеше генә түгел. Бәлки хәйриячелек эше – милек җәһәтеннән мөмкинлекләре булган шәхесләрнең, олы затларның, үзләрен конкрет бер халыкның, милләтнең аерылгысыз өлеше икәнлеген аңлаган хәлдә, шул бөтеннең дә, өлешнең дә хаҗәтләрен бергә үз өстенә алып, үз җилкәсендә күтәрүеннән гыйбарәт. Дәрдемәнднең: «Аһ, туган каумем газиз!» – дип гомумиләштереп ялкынлы көрсенүе очраклылык түгел иде. Димәк, чын хәйрия эше формасы буенча аерым кешеләрнең игелек гамәле булса, эчтәлеге, функциясе ягыннан ул халыкның, милләт-кавемнең тәрәккыят юлындагы үзенчәлеге икән. Ә мондый үзенчәлек җәмгыятьтә гражданлык мөнәсәбәтләренең яки аның элементлары барлыкка килүнең күрсәткече иде. XIX йөзнең икенче яртысы белән XX гасыр башында, ягъни җәдитчелек чорында безнең тормышта чыннан да гражданлык җәмгыятенең кайбер сыйфатлары гамәлгә керә башлаган иде. Шунысы да мәгълүм булсын: гражданлык мөнәсәбәтләре бары кешеләрдә – милеклелеккә, халыкта исә милли байлыкка хокук булганда гына мөмкин. Белгәнебезчә, 1917 елдан соң мондый шартлар Русиядә тамырдан юк ителде. 20 нче елларның икенче яртысыннан соң исә үзе хакында кайгырта, тырыша ала торган милләт урынына ата баладан курыккан, бала атасыннан йөз чөергән, шәхси һәм хосусый милек түгел, хәтта шәхси фикергә дә хокукы булмаган – күпчелеккә буйсынган – яшәүчеләр, җан асраучылар барлыкка килгән иде.

Күренекле хәйриячеләрнең төрле ярдәм, хәйрия җәмгыятьләре, ятимнәр һәм картлар йорты, хастаханәләр, китапханәләр оештыруга якыннан катнашулары мәгълүм. (Бездә бу мөһим күренешнең тарихы һич тә өйрәнелмәгән, гәрчә ул бик актуаль, зарур мәсьәлә.) Ниһаять, милли-азатлык хәрәкәтенә, иҗтимагый оешмалар, сәяси партияләр оештыруга хәйриячелек эшләре белән мәгълүм затларның актив катнашулары да әлеге милли үзешчәнлек хакындагы фикерне

артыгы белән куәтли. Бәс, шулай булгач, хәйриялекне гомумән һәм тулаем кире кагу – ул халык-кавем тарафыннан күрсәтелә торган инициативаны, аның үз ихтыяҗларын үзе канәгатьләндерү юлындагы үзешчәнлеген, ниһаять, бер кавемнең шундый гамәл вә хокукка, ягъни гражданлык хокукына ия икәнлеген инкяр итү булып чыга...

Милли-мәдәни мәнфәгатьләрне кайгырту юлында халыкның үзешчәнлеген булдыру өчен хосусый милекнең әһәмиятен күрсәтә торган тагын бер гыйбрәтле мисалга мөрәҗәгать итик. Шәркый Төркестанда, дөресрәге, андагы Голҗа һәм башка шәһәрләрдә яшәгән татарлар тормышына багышланган «Ябылмаган китап» исемле әсәремдә мин андагы хосусый милеккә ия татарларның чит ил, ят җирләрдә дә үз көчләре белән озак еллар буе алдынгы рухтагы мәктәп-мәдрәсәләр ачып, үзешчән сәнгать түгәрәкләре, мәчет-зиратлар тәрбияли алуларын беркадәре тасвирлаган идем. Балалар, яшьләр үз ана телләрендә укып, белемле һәм нормаль рухлы кешеләр булып үсәләр иде... XX гасырның урталарына, ягъни Кытайда коммунистлар хакимияте урнашканга кадәр. Аннары, мәгълүм булганча, хосусый милекне бетерү – «культура революциясе» хөкем сөрде...

2000 елның көзендә, ягъни кырык биш елдан соң, миңа Өремче һәм Голҗа шәһәрләренә барып кайту, татар кешеләре белән аралашу насыйп булды. Урамда һәм эштә генә түгел, хәтта гаиләдә дә үзара ата-бабалары телендә нормаль сөйләшә торган яшьләрне күрергә туры килмәде диярлек. Берәүләре уйгырча гәпләшә, икенчеләре казакъча сөйләшә, өченчеләре исә үз яшьләрендәге милләттәшләре белән дә кытайча аңлашуны өстенрәк күрә. Биш меңнән артык кешедән торган зур гына кавемгә милли мәктәп турында хыял итү дә мөмкин түгел. Ә элек илле-алтмыш баланың башы кушыла алган җирдә дә кавемнең үз мәктәбе барлыкка килә иде...

Бары олы яшьләрдәге кешеләр генә, утның карая башлаган куз-күмерләренә өрә-өрә дигәндәй, сүнеп бара торган учакның очкын-өметен сакларга телиләр сыман...

Шулай, хосусый милек бетү белән кешеләрдә үзләренең рухи-мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерерлек мөмкинлек-

ләр дә юкка чыга, кеше буларак мөстәкыйльлеген сакларлык ихтыяр көче дә калмый икән.

Халык-милләтнең узган чор социаль-иҗтимагый хәятебездә мөһим роль уйнаганлыгы бәхәссез булган үзешчәнлеге, аның җәмгыять тормышындагы активлык тарихын моңарчы без, кызганычка каршы, җүнләп өйрәнмәдек, яхшылап белмәдек, белә алмадык. Бәлки «сыйнфыйлык» дигән булып, социаль табигый катламнарның берсен генә мактау, икенчеләрен таптау, иң киме хурлау белән шөгыльләндек. Сыйнфыйлык дигән фәнни, танып-белү өчен кирәкле принципның асылда җәмгыятьтәге һәр катламның табигатен, функциясен махсус өйрәнү, алар арасындагы мөнәсәбәтләрне, табигый каршылыкларны күрә белү, аңлау өчен кирәкле гыйльми алым икәнлеген онытып бетерә яздык – бер яккарак, дөреслеге шөбһәле тарафкарак чалулап киттек. Нәтиҗәдә вульгар социологизм сазлыгына баттык. Һәм хәзер бу гамәлнең кайтарып суккан җәзасын алып ятабыз.

Җәмгыять нормаль яшәсен өчен элек көч белән юк ителгән сыйныфларны кайтарабыз дип, ашык-пошык кылану нәтиҗәсендә дәүләт һәм кеше малын талауга, шул юлда кан коюга сәләтле бандитлар өерен барлыкка китердек, аларны бөтен ил, хәтта планета буйлап диярлек таратып җибәрдек. Үзебездә исә өметсезләнгән, пассивлашкан күпчелек белән бергә сөт-икмәк алырга да акчалары җитмәгән, бушаган шешә җыярга мәҗбүр ителгән миллионлаган картлар, урамга сөрелгән ятимнәр, сәрхушлыкка сабышкан гарип-горабалар утырып калды. «Юрган»ны башка тартсаң, аяк ачыла, ертыкны җөйләсәң, тишек ыржая дигәндәй...

Шулай да, кыенлыкларның күләмен һәм табигатен аңлаган хәлдә, мондый ямьсез, авыр күренешләрнең вакытлы икәнлегеннән өмет итәргә кала. Ике-өч буын алмашынгач, ягъни аталарының ертлачлык, жуликлык юлы белән баюларын белмәгән, ләкин аларга караганда белемлерәк, тәрбиялерәк, инсафлырак булган яңа буыннар үсеп чыккач, ихтимал, вәзгыять беркадәре үзгәрер, дип уйларга урын бар. Чөнки

матди мөмкинлекләрнең аң-белем үсүгә, мәдәният тәрәккыят итүгә җирлек тудыруга сәләтле икәнлеге мәгълүм факт.

Белемлелек, тәрбиялелек төшенчәләре хакында сүз чыккач, андый сыйфатларга ирешү өчен нинди чаралар кирәклеге хакында да уйлану зарур. Күп төрле чаралар арасында, минемчә, тарихны объектив яктырту, җәмәгатьчелекне узган тормышыбызның гыйбрәтле фактлары – һәм казанышлары, һәм югалтулары белән якыннанрак таныштыру да үз урынын алырга тиеш. Узгандагы хәйриячеләребезнең эшчәнлекләрен барлау, аларга объектив бәһа бирү – киләчәк бурычларыбызның берсе булырга тиеш. Чөнки без алар алдында һәрвакыт бурычлы.

Сүзне шагыйрь Дәрдемәнднең мирасы белән яңадан танышу фактыннан башлап, бертуган Рәмиевләрнең хәйриячелек юнәлешендәге конкрет эшчәнлекләренә тукталудан бигрәк, гомум мәсьәләне төрле яктан ачыклый-ачыклый фикер йөртүем, узган тормыш сәхифәләрен мул актаруым шундый тарих белән танышуның бер юлы, чарасы дип исәплим. Һәрхәлдә хосусый милеккә, элекке чорларыбызга хас булганча, хәйриялек эшенә күз йомудан тормыш чынбарлыгына кырын карау гадәтеннән арына башларга вакыт инде безгә.

***

Мәсьәләгә, сүзне кабатлап дигәндәй, махсус игътибар итүнең үз сәбәбе бар. Соңгы елларда ашык-пошык башкарылган вульгар реформалар һәм дәүләт милеген талаудан барлыкка килгән капиталны чит илләргә чыгару нәтиҗәсендә, әле генә әйтелгәнчә, халыкның зур өлеше икътисади җәһәттән авыр хәлдә калды. Мондый аптырашка дучар булучыларның зур өлеше, бигрәк тә олы яшьтәге кешеләр, узганындагы чагыштырмача тотрыклырак тормыш шартларын сагыналар. Аларны аңлап була: бөтен гомере совет чорында узган, башкача яшәү шартларын күрмәгән, белмәгән картлар, асылда, узганның бетмәс-төкәнмәс чиратларын, хәерчелектәге «тигезлекләрен» сагынмыйлар (үткәннең начарлыклары тиз онытылучан була, гадәттә). Алар бәлки үзләренең сәламәт яшьлек һәм киләчәктән өметле чакларын, шулай ук нәр-

сәгәдер ышанып яшәгән, ышанып эшләгән, ягъни иманлы булган елларын да сагыналар. Димәк, аларның сугышчан рәвештә кирегә – совет чорына кайтырга чакырулары, реальлеге чамалы булса да, табигый һәм аңлаешлы күренеш икән.

Әмма соңгы вакытларда Сталин сурәтләрен күтәргән шундый сугышчан картлар арасында яшьләрнең дә арта баруы очраклы булмаса кирәк. Шәхесе булмаса да, шәхес культына таба елышу фактлары, Чеченстандагы хәлләргә карата, 1930 нчы еллардагы репрессияләрне аклаган кебек, агрессив теләктәшлек барлыкка килүе дә шомландыра. Мондый процессның, әгәр Русиядә реформаларны гел контрреформалар белән алыштырылу гадәтен исәпкә алсаң, шактый реакцион нәтиҗәләргә китерүе ихтимал. Нәкъ шушы урында укучының: «Социализм идеясеннән баш тарту, капитализмга кире кайту үзе үк реакцион күренеш түгелме соң?!» – дип соравы табигый.

Әйе, XX гасырның беренче яртысында башкарылган талаулар өстенә тагын яңа (икенче төр) талаулар барлыкка килде, халыкның зур күпчелеге әйтеп бетергесез авыр хәлгә тарыды. Болар Ельцин – Гайдар – Чубайсларның икътисади «реформаларының» формасы буенча реакцион булуын раслый. Ләкин эчтәлеге һәм максаты буенча түгел. Чөнки социализм төзү эксперименты СССР җәмгыятен алды ябык тыкрыкка – тупикка китереп терәгәнлектән, артка чигенү, киләчәге ачык «урамга» чыгарга юл эзләү котылгысыз һәм прогрессив омтылыш иде. Әгәр кайберәүләр өмет иткәнчә, яңадан социалистик юнәлешкә борылсак, минемчә, күнегелә язган кыенлыклардан котелмәгән һәлакәтләргә барып керәчәкбез.

Чөнки тарихи процесс дигән хикмәт иске юлны кабатлаганны белми, һичвакытта да андый чигенүләрне кабул итми. Бүгенге кыенлыкларыбыз шулай чигенүнең нәтиҗәсе, дөресрәге, эшләнгән хаталарның җәзасы...

...Һәрхәлдә яхшыга өмет итик. Киләчәктә хосусый милеккә, гомумән, милекчелеккә карата реалистик мөнәсәбәтләр урнашкан нормаль җәмгыять – г р а ж д а н л ы к җ ә м гыя-

те оешуны да беркадәре өмет итәргә мөмкинлек бирә торган дәлилләр бар кебек. Болай уйларга хәйриячелекнең безнең шартлар өчен хәзергә иң мөмкин, иң дөрес булган яңа формалары барлыкка килүе нигез бирә. Мәсәлән, берәр икътисади көчле хуҗалык, оешма һәм предприятие каршында шуларның керемнәреннән рәсми рәвештә бүлеп бирелә торган акча исәбенә эшли торган махсус фондлар – үзенә күрә цивилизацияле яңа заман вәкыфлары оешып эшли башлау фактлары. Нәселдән килә торган байлыкка ия кешеләребез әлегә бөтенләй юк булган, яңа байлар исә интеллектуаль җәһәттән «өлгереп җитмәгән» хәзерге каршылыклы чорыбыз өчен мондый махсус үзәкләрнең эшчәнлеге, әһәмияте аерата кыйммәткә ия. «Татнефть» каршында оештырылган хәзергәчә берничә юнәлештә актив эшләп килә торган «Рухият» фондының шундый яңа һәм өметле үзәкләрнең берсе булуы миндә шик тудырмый. Мондый күптармаклы фондлар ишлерәк булып, дәвамлырак эшләсәләр, алар үрнәгендә хосусый хәйрия эшенең икенче буыны җанланып китүе, мәдәни-рухи тормышыбызда «яңа сулыш» ачылып, өметле киләчәк барлыкка килүе ихтималдан ерак түгел. Башлангыч гомерле генә булсын иде. Ә безнең шартларда... барысы да булырга мөмкин...

Икенчерәк итеп әйткәндә, һәр халык, һәр милли кавем үз ихтыяҗын үзе хәл кылырга, үз киләчәген гомум үзешчәнлек юлы белән үзе тәэмин итәргә тиеш.

Халыкның милли-мәдәни тормышында шундый үзешчәнлек башлангычы бар һәм көчле булганда гына культура гомуммилли, димәк, чын мәгънәсендә халыкчанлык дәрәҗәсенә күтәрелә ала.

Бары шулай актив эшләгән халыкның гына киләчәге өметле.

***

Бертуган Закир һәм Шакир Рәмиевләргә – шагыйрь Дәрдемәнд белән агасы Шакирның тормыш юлына, эшчәнлекләренә китапның кереш мәкаләсе еш-еш конкрет темадан чит-

кәрәк китеп, гомумирәк мәсьәләләргә тукталу бер дә гаҗәп түгел. Болай эшләүнең үз сәбәбе бар.

Беренчедән, безнең элекке тормышыбызда (һәм, гомумән, һәр аерым этнос-халык, һәр милләт хәятендә) хәйриячелек юлында зур активлык күрсәткән Рәмиевләр эшчәнлеге, аның эчтәлеге, интеллектуаль дәрәҗәсе, тарихи әһәмияте шундый теләккә иң әйбәт, иң ышанычлы мисал, үрнәк булып хезмәт итә.

Икенчедән, хәйриячелек хакында авыз ачып, бары Рәмиевләрнең генә эшчәнлекләре хакында кыскача сөйләү яки китапта басыла торган материалларның эчтәлекләрен кабатлау белән чикләнсәм, ягъни әлеге күренешнең асылына кереп, фәлсәфәсенә киңрәк тукталмасам, Рәмиевләр башкарган олы эшләрнең дә чын кыйммәте – иҗтимагый әһәмияте тулырак ачылмас, калкурак күренмәс иде. Шул ук вакытта Рәмиевләрнең иганәчелек, меценатлык гамәлләренең тарихы да хәзергә җентекләп өйрәнелүгә мохтаҗ.

Өченчедән, безнең алда торган иң зур бурыч – ул элекке мәдәни-рухи тормышыбыз тәрәккыятенә зур өлеш керткән хәйриячелек хәрәкәтен тулаем өйрәнү, башка күренекле шәхесләребезнең дә тормыш юлларын, игелекле гамәлләрен тулырак, төгәлрәк яктырту. Әйтик, шундый ук махсус хатирә китапларына, алфавит буенча санап чыксак, Акчуриннардан, Апанаевлардан алып, Хөсәеневләр белән Юнысовларга кадәрге атаклы фамилияләрнең, аларның күренекле вәкилләренең – барысының да бәхәссез хаклары бар...

Киләчәктә нормаль яшәү һәм алга таба үсүне теләсәк, яңадан-яңа хәйриячеләребез, чын меценатларыбыз җитлегеп торуын өмет итсәк, узган тарихыбызда халык, милләт мәнфәгатен иңнәренә күтәргән ил агалары алдында изге бурычларны онытмаска тиешбез.

Лирон Хәмидуллин

Тарихта үз эзләре бар

«Аһ, туган каумем газиз»

Һәр милләтнең уңай сыйфатларын, мәдәни һәм гыйльми үсеш дәрәҗәсен билгеләүче күренекле шәхесләре була. Алар шул халыкның тәрәккыятенә билгеле бер дәвердә нәтиҗәле йогынты ясаучылар, ул халык яшәешенә рухи көч-куәт өстәүчеләр. Егерменче гасыр башында, шул чор шагыйрьләре язганча, «шуңынчы йокыда булган татар»ның милли үзаңын үстерүгә зур өлеш керткән зыялыларыбызның алгы төркемендә борадәран Рәмиевләр – Мөхәммәтшакир (Шакир) белән Мөхәммәтзакир (Закир) Мөхәммәтсадыйк уллары булган. Галимҗан Ибраһимов билгеләп үткәнчә, болар – күгебездә беренче йолдызлардан иделәр.

Аларның икесенең бәгырендәге илгә, ватанга тугрылык тойгысы чагылышын без кече туганның – шагыйрь Дәрдемәнднең «Аһ, туган каумем газиз» дигән сүзләреннән дә чамалыйбыз. Аннары ул:

Атам-анам йорты өчен
Булса мең җаным фида,
Туган-үскән җирем өчен
Соң тамчы каным фида,–

дип тә өсти бит. Шакир вә Закир Рәмиевләрнең үзләре гомер иткән элекке Оренбург губернасында гына түгел, Бөтенроссия күләмендә кылган изге эш-гамәлләре турында, аларның уй-фикерләре, омтылышлары, холык-гадәтләре хакында,

аларны тәрбияләп үстергән ата-ана һәм әйләнә-тирә мохит турында тәфсилле итеп Ризаэтдин бине Фәхретдиннең «Мөхәммәдшакир әфәнде Рәмиев» («Шура» журналы, 1913) һәм Фатыйх Кәриминең «Дәрдемәнд» исемле мәкаләсендә («Дәрдемәнд әсәрләре». – Казан: Яңалиф, 1929) язылды инде. Шуларга өстәп тагын Ризаэтдин хәзрәтнең Уфада яшәгәндә, 1927 елда иҗат иткән бер кульязмасында да («Асар»-ның 14 нче кисәге дип тамгаланган) ике бертуганга багышлаган күләмле өлеш бар. Зур форматлы амбар кенәгәсеннән гыйбарәт 100 битле бу кульязманың 17а – 32а битләрендә шулай ук берничә хат һәм шигырь күчермәсе дә бирелгән. Кульязма хәзерге Башкортстанның Тел һәм әдәбият институты мирасханәсендә саклана.

Рәмиевләр эшчәнлеген ерактарак торып бәяләүче тагын бер язмага тукталыйк. Җәгъфәр Сәетәхмәт Кырымир (1889-1960) – 1917 елдан кырым татарларының милли азатлык хәрәкәте лидерларыннан булган. 1920 елда, берничә ай яшәп алган мөстәкыйль Кырым җөмһүрияте куып таратылганнан соң, чит илгә киткән. Төркиядә хокук белгече һәм язучы буларак танылган. 1934 елда Истанбулда аның «Гаспралы Исмәгыйль бәй» дигән хезмәте дөнья күрә. Шул китапның 46 нчы битендә түбәндәге өзек урын алган (кара: Гадилә Айда, «Садри Максуди Арсал», Анкара, 1991, 72 б.). «...Рәмиевләр милли иман һәм ватанпәрвәрлек хисе белән танылган шәхесләр иде. Болар Урал якларында алтын чыгардылар. Бу эшне яхшы белүләре һәм тәҗрибәләре нәтиҗәсендә, алар алтын чыгару сәнәгатенең алдынгылары булдылар. Аларның уңышлары хакында Россиядән тыш Көнбатышның фәнни китапларында яздылар. Әмма Рәмиевләр халкыбыз һәм зыялыларыбыз күңеленә алтын чыгарудагы казанышлары һәм шул юлда ирешкән миллионнары белән түгел, ә милләт мәнфәгатенә карата булган уңай мөнәсәбәтләре вә фидакарьлекләре белән якын булдылар. Алар нәшер иткән «Вакыт» газетасы, «Шура» журналы татарлардан тыш Казакъстан һәм Шәркый Төркестанда яшәүче башка кардәш халыклар арасында да зур ихтирам казанды. Мәгълүм журналист Фатыйх әфәнде Кәрими

«Вакыт» газетасының 1912 елгы 1 апрель санындагы мәкаләсендә мәрхүм Шакир Рәмиев турында: «Ул алтын өчен яшәмәде, алтыннарын бөек максатларга ирешү өчен кулланды», – дип язды».

Алда атап үтелгән хезмәтләрдә аерып күрсәтелмәгән, әмма бу ике бертуган башкарган яисә башкарырга омтылган эшләрне тулырак күзалларга ярдәм итәрдәй кайбер фактларны да бергә теркәү мәслихәттер, мөгаен. Бу фактлар төрле елларда тутырылган документ яисә башка төр язмаларда саклананалар. Оренбург төбәге кешеләре белән сөйләшкәндә телдән генә хәбәр ителгәннәре дә бар. Мәсәлән, 1960-70 елларда Орск шәһәрендәге очрашулар вакытында берничә кеше, шул исәптән 1920 елларда шунда Кулланучылар җәмгыятендә эшләгән Габдулла Дәүләтшин дигән бер ветеран-коммунист Дәрдемәнднең 1921 елда шушы төбәктә ачлыкка каршы чаралар күрү комиссиясендәме, хәйрия оешмасындамы үз теләге белән эшләвен сөйләделәр. Мондый хәбәрне раслардай рәсми документ әле табылмаган.

1905 елгы халык күтәрелеше көннәрендә татарның бер төркем алдынгы карашлы зыялысы һәм эшкуары, бердәм булып, патша җәнаплары исеменә хат-петиция юллыйлар. Ул хатта Россиядә яшәүче мөселманнарга барлык өлкәдә дә руслар белән бердәй хокук бирелүе, татарларга Төркестанда милек сатып алуга рөхсәт ителүеише таләпләр дә куела. Аңа Сәетгәрәй Алкин, Ибраһим һәм Йосыф Акчуриннар, Әбүсогуд Әхтәмев, Закир Рәмиев, Мәхмүт Хөсәенев кебек, идарәче даирәләргә исемнәре яхшы мәгълүм булган кешеләр кул куялар. Россия мөселманнары мәнфәгатен якларга тиешле «Иттифак әл-мөслимин» партиясен төзү ихтыяҗы тугач та ике бертуган бу фикерне хуплыйлар. 1906 елның гыйнварында С.-Петербургта яшерен рәвештә уздырылган икенче оештыру корылтаенда Закир Рәмиев катнаша. Шулай ук ул программаларында милләтләрнең мәдәни үзбилгеләнүен яклаган, монархистик империядә демократик үзгәрешләр таләп иткән кадетлар партиясенең Оренбург губерна комитетында бюро әгъзасы булып тора. Беренче Дәүләт Думасында диндәш ха-

лыклар мәнфәгате өчен көрәшәчәк Мөселман фракциясе бюросына сайлана. Шушындый рухтагы җәмәгать оешмалары эшләрен башкарганда Закир һәрвакыт диярлек Шакир абыйсы исеменнән дә сүз йөртә.

Закир Рәмиев – Дәрдемәнд 1906 елда патша Россиясенең I чакырылыш Дәүләт Думасына Оренбург губернасыннан депутат буларак сайлана. Билгеле ки, I чакырылыш Дәүләт Думасы озак эшләми – беренче утырышы шул елның 27 апрелендә, соңгысы июль башында уздырыла. Депутатлар барлыгы утыз тугыз мәртәбә бергә җыелып сөйләшәләр, киңәшәләр. Бу чакырылышта катнашкан 499 кеше ил күләмендә җитди эз калдырган карарлар кабул итәргә өлгерми. Депутатларның күпчелегенең үз чыгышларын патша хакимияте сәясәтен һәм аерым хакимият вәкилләрен каты тәнкыйтьләүдән башлаулары (хөррияткә йөз тоту чоры бит) эшчәнлекләренә тиз чик куя. Шул ук елның 8 июлендә патша Николай II депутатларны тарату турында фәрман бирә. Бу чакырылышта катнашкан егерме биш мөселман депутат үз фракцияләрен рәсми рәвештә теркәргә дә өлгермичә калалар, чөнки Урта Азиядән сайланган депутатларның күпчелеге башкалага бик соңлап килеп җитәләр.

Закир Рәмиев барлык утырышларда да катнашмаган булса кирәк. Шул дәвер Дәүләт Думасы архивын яхшы белгән, мөселман депутатлар эшчәнлегенә багышлап җитди хезмәтләр язган тарихчы Диләрә Госманова әйтүенчә, ул архивта Закир Рәмиевнең депутат анкеталары да юк икән. Мөгаен, ул аларны тутырып тапшырырга өлгермәгәндер. Ә фотога төшәргә өлгергән – «дело»сында бик мәһабәт кыяфәттәге сурәте саклана икән. Хәер, әдәбият сөючеләргә ул фото таныш инде – шагыйрьнең 1929, 1959 елларда нәшер ителгән «Сайланма әсәрләр» китапларында урын алган. Ә менә ул чакырылыш мөселман депутатларның күмәк төшкән фотолары әлегә табылмаган. Бәлки булмагандыр да.

Мөселманнар фракциясе рәсми рәвештә теркәлеп өлгермәсә дә, Кавказлы Галимәрдан Тупчибашев рәислегендә аның җитәкче бюросы сайлана. Закир Рәмиев анда казначы

итеп билгеләнә. Татарлардан кемнәр катнашкан соң ул I чакырылыш депутатлар утырышларында? Аларның исемлеген без II чакырылыш мөселман депутатларның җиде кешелек бер төркеме нәшер иткән «Дума» газетасының фактик мөхәррире, мәгълүм журналист һәм сәясәтче Фуат Туктаровның «Беренче, икенче вә өченче Думада мөселман депутатлар һәм аларның кылган эшләре» китабыннан (Казан, 1909), яки классик әдибебез Галимҗан Ибраһимовның кайбер хезмәтләреннән укып белә алабыз. Мәсәлән, аның «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре» дип исемләнгән китабында (Казан, 1925) түбәндәге юлларны укыйбыз: «Думага үткән татар вә башкорт вәкилләр түбәндәгечә бүленәләр: капиталистлардан Закир Рәмиев, Сәхибзадә Максудов; либерал алпавытлардан, морзалардан Сәетгәрәй Алкин, Әбүсогуд Әхтәмев, Сәлимгәрәй Җантурин, Шаһхәйдәр Сыртланов, Котлымөхәммәд Тәфкилев; муллалардан – Тәтештән М.Миңлебаев (Фәйзелкотдус), Вятка губернасыннан Шәмсетдин Хөсәенев» һ.б. Бу исемлеккә әле Чистай төбәге сәүдәгәре Гариф Бадамшин кермәгән. Олуг әдип аны II чакырылыш депутатлар төркемен барлаганда санап үтә. Ул депутатлыкка ике мәртәбә сайланган.

Күрәбез ки, Закир Рәмиев белән бергә утырдаш булган күпчелек татар депутатлары үз халкының якты киләчәге өчен дип байтак эш башкарган зыялы затлар. Милләт язмышын кайгырткан милләтпәрвәр шәхесләр. Ләкин аларга, Дәүләт Думасы мөнбәрен файдаланып, үз милләтләре язмышын җиңеләйтердәй изге омтылышларын үтәрлек мөмкинлек кенә бирелмәгән. Бергә тупланып та өлгермәстән алар куып таратылганнар. Халык тарафыннан сайланган вәкилләр җыенын болай куып тарату дөрес түгел, дип ризасызлык белдереп чыгучыларны зинданга утыртудан да тартынмаганнар.

Депутат булган айларда Закирны, депутат ярдәмчесе сыйфатында, башкалага әдип Фатыйх Кәрими озатып килгән. Ул вакытта инде Фатыйх «Вакыт» газетасының мөхәррире. Бер үк вакытта ул, әлбәттә, Дума утырышларыннан үз газетасына хәбәрләр дә җибәреп торырга тиеш булган.

Олы яшендә булуга карамастан, Закир Рәмиев 1917 елгы февраль вакыйгаларыннан соң кабат җанланып киткән милли хәрәкәтләрдә дә шәхсән катнашырга тырышкан. Мәсәлән, 1917 елның июль аенда Казанда узган Бөтенроссия мөселманнарының Икенче корылтаенда аның Вакытлы Милли идарәнең Малия (финанс) нәзарәте әгъзалыгына тәкъдим ителүе мәгълүм. Бу корылтайда Оренбургтан тагын Ф.Кәрими, Б.Шәрәф тә катнашкан. 1919 елның гыйнварында Казанда татар язуын камилләштерүгә багышланган Бөтенроссия күләмендәге конференция уздырыла. Ул конференция эшендә дә Дәрдемәнднең катнашуы хәбәр ителә. Гарәп хәрефләрен татар теле үзенчәлекләренә җайлаштырып үзгәртү үрнәкләрен 1910 елларда ук тәкъдим иткән кешенең мондый гыйльми мәҗлестән читтә калмавы берәүдә дә шик тудырмыйдыр, шәт.

Егерменче гасыр башында барлыкка килгән байтак кына хәйрия җәмгыятьләре эшендә дә бертуган Рәмиевләр һәм аларның гаилә әгъзалары бәрәкәтле эшләр башкарганнар. Ризаэтдин хәзрәтнең алда күрсәтелгән хезмәтендә «Шакир әфәнденең Оренбург, Тозтүбә, Ялта, С.-Петербург, Троицк җәмгыяте хәйрияләрендә... гомерлек әгъза булуы» әйтелә. Энесе Закирның да «Оренбург мөселманнары хәйрия җәмгыяте «Белек»не (1906-1918), «Сәгыйть бистәсе мөселманнары хәйрия җәмгыяте»н (1906-1917), «Оренбург мөселман шәкертләренә ярдәм итү җәмгыяте»н (1912-1918 еллар, Закир бай – рәис, Шакир улы Сөләйман, Фатыйх Кәрими әгъзалар) һ.б. оештыруда катнашуы, актив әгъза булуы мәгълүм. «Оренбург мөселман хатын-кызлар җәмгыяте хәйрия» оешмасын (1912-1917) оештыруда Дәрдемәнднең кызы Зәйнәп Рәмиева әйдәп йөрүчеләрдән була. (Оренбург исеме кергән барлык җәмгыятьләрнең дә эшчәнлеге губерна күләмендә җәелдерелгән.)

Ике бертуган «алтынчы байлар»ның Оренбург казна палатасы уздырган алтын чыгару сәнәгате хуҗалары съездларының даими вәкилләре булуын да әйтү кирәктер. Шулай ук алар Бөтенроссия күләмендә уздырылган шундый ук чара-

ларда, рәсми тантаналы вакыйгаларда да катнашалар. Бер генә мисал. Николай II не Россия императоры тәхетенә тәгаенләү тантанасы билгеләнә. Аңа татарның да берничә мәшһүр шәхесе чакырулы була: мөфти хәзрәтләре Мөхәммәдъяр Солтанов, Кырым морзасы Исмәгыйль Гаспралы һ.б. Шул исемлектә «алтын приискалары хуҗасы М.Рәмиев» тә теркәлгән. Исмәгыйль бәйнең шушы тантанада катнашуын тасвирлаучы язмаларның искәрмәләрендә «М.Рәмиев»не Мөхәммәтсадыйк дип шәрехләү очраклары бар. Дөреслектә ул кеше Мөхәммәтшакир булырга тиеш. Николай II не тәхеткә тәгаенләү 1894 елда уздырыла, ә Мөхәммәтсадыйк карт 1892 елда ук вафат булган. Шушы уңайдан тагын бер искәрмә: белүемчә, совет чоры язмаларының күпчелегендә бу ике бертуганның инициаллары «Ш» һәм «З» хәрефләре белән бирелгән булса, 1917 елга кадәрге байтак кына документларда алар икесе дә «М.М» инициаллары белән теркәлгән. Һәм кайвакыт аларның кайсысы турында сүз баруын фәһемләү дә читенләшә.

«Чабаталы морзалар»

Совет хакимияте дәверендә «татар буржуйлары» буларак танылган Рәмиевләр гади татар авылында туган, икенче бер татар авылында тәрбия алганнар. Ләкин, авылда тусалар да, гади крәстиян балалары түгелләр. Ул заманнарда авылларда борынгы аксөяк бабаларының матур сыйфатларын сакларга тырышкан, берничә гаиләдән генә торган аерым кавем, каста вәкилләре дә булган. Аларның аксөяклек билгеләре, шуңа табыну үрнәге – белемгә сусаганлык, үз заманына хас белем дәрәҗәсен үзләштерүгә тырышу. Борадәран Рәмиевләр дә шул даирәдән, шундый тәрбия үрнәгендә тәрбияләнгәннәр. Күрәбез ки, алар яшьтән үк, мәдрәсә гыйлеменнән тыш, рус телен һәм язуын камил үзләштерүгә дә, Шәрекъ дөньясының мәшһүр зыялылары хезмәтләре белән танышырга да өлгергәннәр. Ф. Кәрими «Аурупа сәяхәтнамәсе»ндә Шакирның

русчадан тыш гарәп телендә дә иркен аралашуын бәян итә. Дәрдемәндкә багышланган язма истәлекләрдә өзеп кенә әйтелмәсә дә, аның беркадәр французча белгәнлегенә ишарәләр бар. Аны күреп белгән Оренбург төбәге картларыннан ишетелгән сүз бу. Кайнише Мөхәммәтҗан улы Рәшит тә (1910 елда туган) бер әңгәмә вакытында, Дәрдемәнднең соңгы, Орскида яшәү дәверен искә алып: «Кайвакыт ул ишегалдында французча сөйләнеп йөргән», дип әйткән иде. Оныгы Бәширдә шагыйрь төзәтмәләре булган төрекчә – немецча сүзлек саклана.

Ризаэтдин бине Фәхретдин нәшер иткән шәҗәрәдә Рәмиевләрнең Габделкәрим бине Исмәгыйль бине Рәхимколдан соңгы бабалары Урман морза буларак теркәлгән. Элгәрерәк заманда рус дәүләтенә хезмәт иткән бабалары Тимери тылмач кебек, ул да Россия патшалыгында рәсми танылган морза булгандырмы – әлегә билгесез. Бәлки үзе яшәгән тирәлектә идарәче даирәләрнең берәр төрле вазифасын үтәүче булгандыр? Казан ханлыгы рус патшалыгы тарафыннан яулап алынгач, кайбер ышанычлы бәк-морзаларга Зәй елгасы тирәләрендә казакъ хезмәтен үтәү – яңа чик буен саклауны оештыру бурычы йөкләнүе тарихта теркәлгән бит. Шул ук төбәктә чик буе корылмалары төзетеп, яңадан-яңа авыллар нигезләп йөргән Надир аксөяк эшчәнлеге төбәк тарихчысы Җәмит Рәхимов хезмәтләрендә тасвир ителде ич. Патшалыкның чик буйлары Урал-тауның аръягына күчерелгәч тә ул морзаларның зур өлешенең шул тарафларга «авышуы» да мәгълүм. Ә инде элекке җирләренә берегеп калган, яңа урынга күчәргә теләмәгәннәргә карата югары даирәләрнең сәясәте үзгәргән. Алар инде кирәкләре калмаганлыктан үз ихтыярларына җибәрелеп, гади ясак түләүчегә тиң «чабаталы морзалар» дәрәҗәсенә төшерелгәннәр.

Урман морзадан соңгы буын да шул язмышка дучар ителгән булса кирәк. Шуңа күрә Ризаэтдин хәзрәт тә өлкәнрәк буын Рәмиевләргә карата: «Габделкәримнән элгәреге бабаларының мәгыйшәт вә мәшгулиятләре хакында тәхкыйклы

мәгълүмат юк», дип яза. Габделкәримнең исә баштарак туган-үскән якларында – Тайсуган төбәгендә – бер мәчет имамы вазифасын үтәгәнлеге, аннары атасы һәм ахун абзасы барып урнашкан Эстәрлетамак тарафына күчеп, сәүдәгәр булып китүе бәян ителә. Мөгаен, аның атасы Исмәгыйль электән үк сәүдә белән шөгыльләнгән булгандыр да, олыгая төшкәч, тиҗҗарлык дилбегәсен улына тапшыргандыр. «Габделкәрим... Эстәрлетамак сәүдәгәрләре сыйныфына мәнсүб. Торган урыны – Җиргән карьясе... Вафаты 1851 нче сәнәдә вә кабере Җиргәндәдер», диелгән шәҗәрәдә. Исмәгыйльнең кайчан, кайсы тарафта гүр иясе булуы тәгаенләнмәгән.

Мөхәммәтсадыйк Җиргәндә туган. Җиргән авылы Уфа белән Оренбург шәһәрләрен тоташтырган зур әһәмияткә ия юлның кыл уртасында диярлек урнашкан. Ул унсигезенче йөзнең икенче яртысында, Эстәрлетамак каласы белән бер үк вакытта төзелә башлаган. Җиргән Агыйдел үреннән агызылган салларны кабул итүче пристань буларак төзелсә, аннан илле чакрымнар түбәндәге Эстәрлетамакны Казакъ ханлыгы чигендәге Тозтүбә шахталарыннан китерелгән тозны, заводларда җитештерелгән әйберләрне үзәк өлкәләргә озату өчен төзегән булалар. Сал белән төшерелгән агачның байтак өлеше Җиргәннән егерме чакрымда булган Пашков байларның бакыр кою, селте заводларына озатылган, калганы сәүдә максатында файдаланылган.

1794 елгы бишенче ревизия вакытында Җиргәндә иллеләп татар, шул чамада ук мукшы һәм утыз җиде чуаш* ир заты теркәлгән. Тагын бер гасырдан соң инде анда 633 йорт исәпләнә, халкының күпчелеге татарлар була.

Сәлим белән Исмәгыйль Рәмиевләр 1770 еллар тирәсендә шушы яңа ачылган сәүдә төбәгенә килеп төпләнәләр. Сәлим монда абруйлы дин әһеле буларак таныла, озакламыйча ахун итеп билгеләнә. Исмәгыйль Эстәрлетамакта да, Җиргәндә дә

---

* Россия рәсми кәгазьләрендә XVII – XVIII йөзләрдә «ясаклы» татарларны «чуашлар» дип язу күренеше дә булган (төзүчеләр искәрмәсе).

кибетләр ачкан булырга тиеш. Сәүдә эшләре белән төбәк башкаласы Оренбургка да, Казакъ ханлыгы чик буйларындагы ярминкәләргә дә йөргәндер, мөгаен.

Ул көннәрдән соң ике гасыр чамасы вакыт узгач без, фотограф Зөфәр Бәширов белән икәү, Җиргәндә булдык, анда сәүдәгәр Рәмиевләр эзләрен барларга тырышып йөрдек. Авылның һәм андагы колхозның абруйлы кешеләре белән дә, Рәмиевләр фамилиясен йөртүчеләр белән дә очраштык. (Искә төшереп үтик, бу зур авылда гасыр башында татарның тагын ике абруйлы шәхесе – язучы Мирсәй Әмир белән аның кайнише, күренекле тарихчы Мидхәт Мөхәррәмов та туганнар.)

Авыл элек өч өлештән торган: кайчандыр «Әби патша» төзеткән юлны «иярләп» өч чакрымга сузылган киң урамда урыс вә мукшылар яшәгәнлектән – «урыс очы» булган. Авылның Эстәрлетамак тарафындагы башы – «мещаннар очы». Бүген дә анда рус һәм татар сәүдәгәрләреннән калган, бик затлы кызыл кирпечтән төзелгән, еш кына шундый ук кызыл кирпечле коймалар белән уратып алынган биналар күп. Ләкин аларның борынгы хуҗаларын хәтерләүчеләр юк диярлек. Рәмиев фамилиясен йөртүчеләр дә ерак бабалары тарихын яхшы белмиләр: «Без советчарак тәрбияләндек, картлар безгә бабаларыбыз хакында аз сөйләделәр», – димәкчеләр. Хәер, ул заманнарда андый тарихны сөйләү куркыныч та булгандыр шул.

«Ясаклылар очы»ндагы йортлар гадирәк, фәкыйрьрәк. Егерменче елларда монда волость идарәсендә эшләп киткән Мирсәяф комсомол да, шушы очның мәрхүм мулласы утарыннан зур дөньяга аяк баскан булачак тарихчы Мидхәт тә – ясаклылар саналган.

1856 елда Самара губернасы оештырылганчыга кадәр Зәй буендагы Тайсуган, Агыйдел буендагы Җиргән авыллары да, Эстәрлетамак шәһәре дә Оренбург губернасы биләмәсенә кергәннәр. Соңрак Оренбургта тупланып, татар халкының үзаңын, мәгърифәтен үстерүгә зур өлеш керткән борадәран Рәмиевләрне дә, шул шәһәрдә беренче татарча басмаханә ачучы Гыйльман ахун Кәримине һәм улларын, аның кайнише, «Шура» журналы

мөхәррире Ризаэтдин бине Фәхретдинне дә, икеләнмичә, бер төбәктән чыгучылар, якташлар дияргә була. Аларның барысының да төп ватаны – Татарстанның хәзерге Әлмәт төбәгендәге авыллар: Тайсуган, Кичүчат, Түбән Чыршылы, Миңлебайлар – барысы да элек Оренбург губернасының Бөгелмә (Богырыслан) өязенә кергәннәр.

Матбугатта дөнья күргән шәҗәрәләрдә Мөхәммәтсадыйкның туган елы күрсәтелмәгән. «1892 сәнәсендә апрельнең 22 сендә 63 яшендә вафат итмештер» диелгән. Димәк, ул якынча 1828/29 елда туган булырга тиеш. Сәүдә эшләре белән аңа сәүдәгәрләр бистәсе Каргалыда һәм Оренбургта еш булырга туры килгән. Зурдан кубып иген икмәгән, һөнәрчелекнең күп кенә төрләре белән даими шөгыльләнмәгән, башлыча мал асрау белән көн күргән саф башкорт төбәгендә утырган ерак Юлык авылына да аның юлы төшкәләгән. Юлыкта һәр елны зур ярминкә оештырылган, анда җыелган башкорт бай-түрәләре белән еллык алыш-биреш килешүләре төзелгән. Татар сәүдәгәрләре анда кызыл мал, тарыбодай, көндәлек башка кирәк-яракны китергән. Шунда ук кемнән һәм күпме аяклы мал сатып аласы билгеләнгән. Базары бик үтемле булганлыктан, нигездә губернаның көнбатыш төбәкләрендә урнашкан татар сәүдәгәрләре арасында да ул ярминкә мактаулы саналган.

Шул ярминкәгә бер баруында Мөхәммәтсадыйк Юлыкта бөтенләйгә төпләнергә ният кыла, кечерәк бер сабын заводы һәм өй сатып ала. Үз көче белән тире-күн эшкәртү заводын салдыра. Киң казакъ даласы белән Себер чигендә бихисап зур мәйдан биләгән Орск өязендә, шулай итеп, Рәмиевләрнең яңа тормышы башланып китә. Мирхәйдәр Фәйзи 1917 елда: «Орск өязе Курскиның бөтен губернасы кадәр, чит мәмләкәтләрдән Дания... аңардан кечерәк», дип яза.

Юлык ике зур юл чатында – дәүләт күләмендә әһәмиятле саналган Оренбург – Верхнеуральск һәм Эстәрлетамак – Орск юллары кисешкән урында губерна җитәкчеләре карары белән 1780 еллар башында барлыкка китерелгән. Монда күчерелгән татарлар почта ташучы, дәүләт хезмәтендәгеләрне юл йөртүче ямчы-

лар булалар. Оренбург, Эстәрлетамак кебек, өч йөз егермешәр, өч йөз иллешәр чакрымдагы шәһәрләргә даими рәвештә йөреп торган кешеләрнең, әлбәттә, җир сукаларга, иген игәргә вакытлары да калмаган. Хәер, башкортлар аларга җирне дә аз бүлеп биргән була. Юл йөргәндә алар вак-төяк белән сәүдә иткән, һөнәр үзләштергәннәр. Шунлыктан ул, башлыча, һөнәрчеләр, кәсепчеләр авылы буларак танылa. Юлык – Орск өязенең иң зур авылларыннан, гасыр башында анда биш йөзләп йорт булган. Монда яшәүчеләр аз-ким күләмдә, иләк-чиләк ярдәмендә алтын юу белән дә шөгыльләнгәннәр. Авыл янәшәсендәге Ирендек тау тезмәләре тирәләрендә Бөек Ватан сугышы елларында да алтын бөртекләренә юлыгучылар булгалаган.

Юлыкта Рәмиевләр иганәсенә төзетелгән таш мәчет 1993 елдан кабат үз вазифасын үтәүгә кереште. Ул мәчет каршында ир балалар мәктәп-мәдрәсәсе бинасы да төзелгән була. 1905 елдан соң Гәүһәр Рәмиева тырышлыгы белән монда кыз балалар мәктәбе, кул һөнәре өйрәтү курслары ачылган. Аларда укыту өчен ике белгеч Оренбургтан китерелгән. Шул ук елларда, башлыча Рәмиевләр иганәсе исәбенә, җәмәгать китапханәсе эшли башлый. Аны, өстәмә хезмәт хакы алып, Рәмиевләр мәчете мәзине һәм аның хатыны тоталар. Китапханә дүрт көн ир-атлар, ике көн хатын-кызлар өчен билгеле бер вакытта ачык була. Авылның зур таш кибетен дә Рәмиевләр тоткан.

«Россиянең алтын корольләре»

Шакир кызы Камиләдән туган Гадилә Айда, Төркиянең күренекле җәмәгать эшлеклесе һәм галимәсе алдарак телгә алынган китабында Рәмиевләрне шулай дип атый. «Рәмиевләр гаиләсе Рәсәйнең санаулы байлары катламыннан саналырдай бер гаилә иде... Эшкә сәләтле кеше буларак, Мөхәммәтсадыйк... Рәсәй хөкүмәтеннән Урал тауларында урнашкан бер алтын приискасын туксан тугыз елга дип килешеп сатып

ала. Шуннан соң инде эше җайга салына – алтын хәзинәсе чыганаклары өстәлә бара», ди.

Мөхәммәтсадыйкның 1862 елда Юлыкка килеп урнашуы да, бәлки, киләчәк язмышына бәйле булгандыр. Шул дәвер рус матбугатында бәян ителгәнчә, бу төбәк бит ул елларда «алтын бизгәге» чорын кичергән. Урал тауларының көнчыгыш сыртындагы башкорт һәм аңа чиктәш дала казакълары җирләрендә зурдан тотынып алтын чыгару кәсебенә керешү 1830 елларда башланып китә. Баштарак инеш, чишмә буйларында, тау куышларында ялтырап күренгәләгән сибелмә алтынны аерым һәвәскәрләр, вак артельләр чүпләп баеган булса, утызынчы еллардан соң монда чын алтын шаукымы башлана. Урак өсте басуына карга көтүе ябырылган кебек, төрле тарафтан аңа алтын чыгаруны зур кәсепкә әверелдерергә хыялланучылар ябырыла. Аңа губерна һәм Россия шәһәрләреннән тыш, ерак чит ил байлары да кул сузалар. Элек чик буе сагында булган гаскәриләр һәм аз санлы чиновниклар яшәгән фәкыйрь Орск каласында тиздән инглизләр дә бер ширкәт ачып җибәрәләр.

Хәзерге Баймак районының Күсәй авылы янында беренче зур приисканы генерал А.Шечужников 1837 елда ача, дип яза Башкортстанның баш геологы Басыйр Мәһәдиев. Ике елдан соң Оренбургның эре җирбиләүчесе Н.Е.Тимашев (К.Тәфкилев кияве, атлы казаклар атаманы Тимашев нәселеннән булса кирәк) берьюлы өч прииска нигезли. Дөрес, берничә елдан соң ул аларны ике татар сәүдәгәренә – Динмөхәммәтев белән Байкиев фамилияле кешеләргә сатып җибәрә. Хәнифә Дашкованың нәсел-ыруыннан да кемдер алтын казу эшенә тотынып караган булса кирәк –Урал төбәге алтынчылары исемлегендә Дашков фамилияле кеше дә очрый. Мәгәр, алар берсе дә Рәмиевләр дәрәҗәсендәге алтын чыгару осталыгына күтәрелмәгәннәр.

Мөхәммәтсадыйк беренче приискасын Юлыктан сиксән чакрым чамасы ераклыктагы шул ук Күсәй янәшәсендәге Ишбирде авылыннан сатып ала. Аны бөлгенлеккә төшкән


БЕЛОРЕЦКИЙ РАЙОН
БЕЛОРЕЦК
МАГНИТОГОРСК
АБЗЕЛИЛОВСКИЙ РАЙОН
БУРЗЯНСКИЙ РАЙОН
БАЙМАКСКИЙ РАЙОН
ЗИЛАИРСКИЙ РАЙОН
СИБАЙ
Багряшка
Аргаяды
Урсук
Карасаелга
Юлук
Резиденции Рамеевых:
Земли Тамьян-Тунгауской и Бурзянской волостей, арендованных рамеевыми
Рамеевские прииски на территории Челябинской и Оренбургской областей, за пределами совр. Башкирии:
1. Ащебутакский
2. Шафиковский
3. Хасанский
4. Сахара
5. Мехдадовский
6. Балканский (крупн.)
7. Искандерский (кр.)
8. Амурский
Прииски Рамеевых
Прииски Тамьян-Тунгауского товарищества (с участием Рамеевых)
1871—1917 годы
Владения других золотопромышленников
Масштаб 1:1000000
По Списку-справочнику 1961 г., составленному Центральным государственным архивом Башкирской АССР по материалам архивного фонда треста „Башзолото" (р-1148).
Составил карту Магадеев Б.А.
Уфа,

бер урыс кешесеннән 1869 елда алды, дип язалар. Оныгы Гадилә тасвирлаганча, хөкүмәттән алынмаган булса да, алыш-биреш, билгеле инде, хөкүмәт рөхсәте белән башкарылгандыр. Шуннан соң Садыйк бай ел саен бер-ике прииска ала яисә яңа ятмалар ача торган була. Хөкүмәтнең, хәзинә табылган ятмада бер кешенең өлеше чикләнгән булырга тиеш, дигән таләбен үтәү сәбәпле булса кирәк, Күсәй – Темәс авыллары аралыгында Рәмиевләрнең Хәнифә исеменә ачылган, «Шакирский», «Закирский» дип йөртелгән приискалары, Чиләбе төбәгенең Балкан авылы янәшәсендә «Искәндәрский» (Закир улы исеме), «Мидхәтский» (Шакир улы исеме) һ.б.лар исемендәге приискалар бар.

Мөхәммәтсадыйк карт гомере чигендә улларына ике дистәләп алтын шахталарын мирас итеп калдыра. Уллары ул санны икеләтә арттырып, Совет хакимиятенә кырыктан артык алтын чыганагын «бүләк» итәләр.

Алтын чыгару эшен камилләштерүгә Шакирның зур өлеш кертүе махсус әдәбиятта да теркәлгән. Мәсәлән, ул алтын юу агрегатына җитди үзгәреш кертеп, аны камилләштерүгә ирешкән.

Балкан авылы янындагы приискаларда алтын комын юдыру эшләрен күзаллап үтик. Хәзерге Магнитогорск шәһәреннән алтмыш чакрым чамасында көнчыгыштарак булган ул авылга 1895 ел вакыйгасыннан соң нигез салына. Мул сулы Гүмбәй елгасы буенда кечерәк кенә нагайбәк казаклары авылы – Требия хуторы була. Рәсми документларда ул «Восьмой хутор» дип тә йөртелгән. Шул елда Кувшинов фамилияле кеше коесыннан өч бөртек алтын табыла. Милләттәшлек хисе өстенлек иткәндерме – бу хәбәр тиздән Рәмиевләргә җиткерелә. Алар авыл очында ук яңа прииска нигез салалар да якын-тирәдәге дала җирне дә тикшереп чыгалар. Һәм бу хутордан өч-дүрт чакрымда тагын да байрак ятмаларга юлыгып, анда да берничә шахта ачалар. Һәм шулар иң бай хәзинәле шахталар буларак танылалар.

Булачак Балкан авылы уртасында идарә утары төзелә, шуның янәшәсендә өч ясалма күл булдырыла. Шахталарга, нигездә, чит илдән кайтарылган җиһазлар урнаштырыла. Электр тогы алу өчен локомобильләр кайтарыла. Артезиан коелары казыла. Күлләргә су куәтле насослар ярдәмендә кудырыла. Күл буйларында кырык дәү чиләкле чыгыр, көне буе җай гына әйләнеп, комны юдыру агрегатына су коеп тора. Ул чыгырны дүрт атлы тарттырып әйләндерәләр. Шахталар авызы янында кечерәк чыгырлар әйләнеп тора – җир астыннан комлы, балчыклы бадьяларны өскә күтәрә. Алар янына ике тәгәрмәчле үзбушаткыч арбалар чиратлап килеп, бадьялардан бушатылган йөкне күл ягына таба алып китә торалар. Маширт корылмасы күперчегенә менеп йөкләрен бушаталар да тагын шахталарына китеп баралар. Алар бушаткан ком-ташлар маширт корылмасының махсус иләкләре өстенә коелган арада зур улакларга чиләкләрдән чиратлап су агызыла. Комнар, вак чуерташлар шыбырдап улак буйлап агып китәләр, алтын бөртекләре авыш иләк төбендә ялтырашып калалар.

Ул алтыннар аннары Рәмиевләрнең шул төбәк утарларындагы таш келәтләренә саклануга куелган. Юлык, Күсәй авылы янәшәсендәге Солтан приискасы, Чиләбе төбәгендәге Балкан, хәзерге Оренбург җирләренең төньягындагы Шихан авылы янәшәсендәге Сахара приискасы шундый алтын туплау урыннары булган. Балкан, Юлык авылларында бүген дә шул максат өчен тау ташыннан төзелгән нык келәтләр бар. Англиядә эшләнгән, бертуган Рәмиевләрдән калган серле йозаклы зур бер сейф бүген дә Тубинск руднигы идарәсендә (Баймак) алтын хәзинәсен туплау һәм саклау өчен кулланыла. Шул ук идарә бинасы да, картлар сөйләвенчә, 1929 елда Юлыктан алып кителгән Рәмиев байлар йорты икән. 1920-1929 елларда авыл мәктәбе буларак файдаланылган. Зур-зур унбер сыйныф бүлмәләре булган мәктәп иде, дип сөйлиләр.

Рәмиевләрнең дәүләткә алтын тапшыру кенәгәләренең күпчелеге хәзерге көндә Башкортстан Республикасының гео-

логия идарәсендә саклана. Кайсы төбәктән күпме алтын тапшырылганлыгы мәгълүм. Әмма җир куеныннан күпме алтын алынганын төгәл әйтә алмыйлар: Россиядә бит урлашу гадәте бүген генә барлыкка килмәгән. Мәсәлән, егерменче еллар азакларында Рәмиевләр приискаларындагы бер идарәченең җир астына күмгән яртышар потлы ике алтын коелмасын табалар. Шул уңайдан барлык Рәмиевләрне Чиләбе төрмәсенә җыеп, алтышар-тугызар ай тоталар. Аларның күпчелеге аннан акланып чыга: байлыкны яшерергә алар рөхсәт бирмәгән. 1979 елда икенче бер идарәченең кызы, пенсия яшендәге бер апа, шундый ук алтын коелмасының үз өлешен – 464 грамм итеп киселгән кисәкне Сибай банкы аша Тубинск идарәсенә «бүләк итеп» тапшыра...

Рәмиев байлар, алтын чыгаруга бәйле башка авыллардагы кебек үк, Балканда да мәчет төзетеп (хәзер инде ул юк), аның карамагында ир балалар мәктәбе тоталар. 1906 елда кызлар өчен дә мәктәп ачыла. Шул авылдан чыккан Кояш (Шәмсенәһар) Вәлитова «Азат хатын» журналында урнаштырылган бер истәлек мәкаләсендә болай дип яза: «Башта малайлар белән укыдым... 1905 елның язында, имтихан алу дәресләрендә Дәрдемәнд үзе катнашты, минем тапкыр җавабымны ишетеп сөенде. Соңыннан Дәрдемәнд белән бергәләп фоторәсемгә төштек».

Башкортстанда һәм Оренбург өлкәсендә урнашкан Рәмиевләр приискаларының кайберләрендә алтын чыгару эше бүген дә дәвам иттерелә. Туксанынчы еллар башында Солтан приискасы янында биш кило чамасы авырлыктагы самородок табылуы мәгълүм. Балкан авылы төбәгендә алтын ятмаларын казу эшләре 1925 елда туктатылган була. Мәгәр, авыл урамнары башында, күл буйларында бүген дә әле тау-тау булып җир куеныннан чыгарылган ком, чуерташ өемнәре калкып утыра. Аларны хәзерге заман техникасы аша үткәрсәң кабат хәзинә чыгачак икән. Солтан төбәге приискаларында шулай эшләгән хосусый милекле бер артель зур уңышка ирешкән. 1994 елда Балканнан берничә чакрым читтәрәк шундый ук

«җаваплылыгы чикләнгән» бер артель эшкә кереште дә бугай инде.

Урал-тау төбәгендә алтын чыгару сәнәгатенә багышланган гыйльми китапларда Рәмиевләрнең приискаларына һәм бу өлкәдәге алар эшчәнлегенә дә зур урын бирелә. Бай мәгълүматлы шундый ике хезмәтне телгә алып китәсе килә. СССР Геология комитеты нәшрияты 1926 елда Ленинградта «Материалы по общей геологии и прикладной геологии» җыентыгының 16 нчы чыгарылышын нәшер итә. Анда 1915 елда Балкан авылы төбәгендә тикшеренүләрендә катнашкан галим А.Н. Заварицкийның «Материалы для изучения золотоносных районов Урала» дип исемләнгән зур хезмәте дә урын алган. Ул китапта М.Гафури повестенда телгә алынган «ат башы хәтле самородок» турында да бәян ителә.

1985 елда Уфада нәшер ителгән «Из истории Южноуральских горных заводов XVIII–XIX в.» китабында (авторлары Г.Ф.Гудков белән З.И.Гудкова) да алтын чыгару сәнәгатенә урын бирелә.

Рәмиевләрнең нәсел-нәсәбе, варислары

Рәмиевләрнең борынгы буын вәкилләре шәҗәрәсе Ризаэтдин бине Фәхретдин тарафыннан бәян ителгән. Ул бертуган Рәмиевләрнең бабалары Габделкәрим исеме белән тәмамлана (1 нче таблица)*.

Беренче шәҗәрә нәшер ителүдән соң сиксән ел чамасы вакыт үткәч, 1989 елгы «Казан утлары» журналының соңгы санында язучы Мөхәммәт Мәһдиевнең «Рәмиевләр нәселеннән берәү» дигән мәкаләсе дөнья күрде. Анда Исмәгыйль ага Рәмиевнең әдипкә үз кулы белән язып биргән шәҗәрәсе урнаштырылган. Билгеле инде, Исмәгыйль ага аны төзегәндә «Шура» журналында Риза хәзрәт нәшер иткән өлгедән фай-

* Шәҗәрәгә исемнәре ачыкланган кешеләр генә язылды (төз.иск.)

1 нче таблица

Рәмиевләр шәҗәрәсе



далангандыр. Әмма аның язмасында бер кеше исеме үзгәртелгән – Түләй морза Юлай исеме белән бирелгән*. Шулай ук: «Тимери бине Рәми Мәскәү патшалыгында, Иван III чорында тылмач Митри Рәмиев буларак танылa... Рәмиевләрдән берәү турында Н.П.Загоскинның «Юрий Милослав-

* Түләй һәм Юлай (Йулай) исемнәре гарәп хәрефләре белән язылганда беренче хәрефләр – «т» һәм «й» икесе дә бер-берсенә бик охшаш, ике нокталы хәрефләр. Алар арасындагы аерма фәкать нокталарның хәрефнең өстендә яисә астында булулары белән генә аерыла. Шунлыктан гарәп хәрефләре белән язылган чыганакны ялгышлык белән Түләй дип тә, Йулай дип тә укырга мөмкин (*Төз. иск.*).

2 нче таблица

Мөхәммәтсадыйк (1828/29–1892)
хатыны Хәнифә Дашкова (1825–1896)

Мөхәммәтшакир (1857–1912) | Мөхәммәтзакир (1859–1921)

Камилә Гомәр Галихәйдәр

ский» исемле романында да сөйләнелә», диелгән җөмләләр дә өстәлгән.

1991 елда Рәмиевләр нәселенең хәзерге буын вәкилләреннән ике кеше тагын бер кульязма шәҗәрә төзегәннәр. Машинкада биш бит чамасында булган ул хезмәт белән мине Закир оныгы Бәшир ага Рәмиев таныштырган иде. Ул шәҗәрә, нигездә, Сәлим ахун варислары тармагын – егерменче йөз башында Эстәрлетамак төбәгендә яшәүчеләрне барлаган. Аны төзүчеләр үз хезмәтләренә нигез итеп Исмәгыйль ага вариантын алганлыкларын белдерәләр. Ләкин алар ялгышлык белән хаталану нәтиҗәсендәдерме, яисә башка максат беләндерме, Сәлим ахун белән бер вакыттарак Эстәрлетамакка килгән Исмәгыйль исемен төшереп калдырганнар. Шул рәвешле унтугызынчы гасыр урталарыннан икегә аерылган ике тармак берләштерелгән, Сәгыйть Рәмиев, Исмәгыйль Рәмиевләр дә Дәрдемәнд белән бер тармак вәкилләре булып киткәннәр (2 нче һәм 5 нче таблицалар).

Чынлыкта исә Җиргән, Эстәрлетамак төбәгендә яшәүче Рәмиевләр белән Юлык төбәге Рәмиевләре арасында туганлык элемтәләре бик күптән өзелгән. Мәсәлән, 1917 елның декабрендә Оренбург шәһәрендә узган Бөтенбашкорт корылтаена Галимҗан Ибраһимовның ярдәмчесе һәм сакчысы буларак барган Исмәгыйль Рәмиев, үзе сөйләвенчә, беренче мәртәбә бишенче буын кардәше өендә була. Г.Ибраһимов аны анда шагыйрь белән очрашу көнен билгеләр өчен җибәрә. Билгеләнгән көндә озаклап кич утыру нияте белән Галимҗан

Мөхәммәтшакир нәселе

хатыны Гәүһәр Арабова (?–1918 дән соң)

- Фатыйма
  - Касыйм
  - Диләрә
  - Диләфрүз
- Сөләйман (?–1930дән соң) хатыны Әсма
  - Рәфкат
  - Гөлнур (1900–1980)
- Диләфрүз (?–1972)
- Камилә (1892/93–1973)
  - Гадилә Айда (1912–1990)
    - Гөлнур
    - Гөнел Пултар
  - Наилә Турхан (1914–?)
    - Тугрул Турхан
    - Али Турхан
- Фирдәвес (?–1980)
  - Диләфрүз
  - Диләрә (1924)
- Рәүф

белән тагын Дәрдемәндләргә баралар. Чәй табыныннан соң өчәүләп шагыйрьнең эш бүлмәсенә күчәләр, революция тудырган үзгәрешләр һәм яңа тәртипләр хакында әңгәмә башлана. Исмәгыйль аганың: «Алар янында бераз утыргач та мин торып киттем. Китап киштәләре бик бай иде, шуннан берсен, үземчә бик кызыклысын алып актарырга керештем дә онытылдым», дип сөйләгәне хәтеремдә.

3 нче таблица

хатыны
Мәхүбә
(?–1916/17)

- Зәйнәп (1901/2–1916)
- Назнин (1903/4–1916)
- Мәрьям (1906–1916)
- Фәтанәт (1909/10–?)
- Мәүва (1911/12–1994 тән соң)

хатыны
Фатыйма Габитова

- Әхмәтмидхәт (1895–?)

хатыны
Камилә
(1893/94–?)

- Рәшит (1911/12–1978)

1990 нчы еллар башында Оренбургта яшәүче, төбәк тарихын барлаучы Мәдинә апа Рәхимкулова миңа Дашкин Мөхәммәт һәм аның хатыны Әминә варисларының хәзерге көнгәчә дәвам иттерелгән нәсел тармагы белән танышу мөмкинлеген тудырган иде. Анда Хәнифә Дашкова-Рәмиеваның да балалары һәм Шакир белән Закирдан туган оныклары исемнәре теркәлгән. Дөрес, оныклар исемлеге бик үк төгәл

4 нче таблица

Мөхәммәтзакир (Дәрдемәнд)
хатыны Мәхүбҗамал Борнаева (1861–1943)

- Өммегөлсем (?–1921)
  - Рәбига
  - Суфия
  - Галия (?–1948)
  - Кафия
    - Эльвира
- Искәндәр (1886–1943)
  - Бәшир (1918–1994)
    - Искәндәр (1958)
  - Равил (1927)
- Зәйнәп (?–1977)
  - Баязид (1915–1942)
    - Юрий (1941–1977)
  - Асия (1918–1980 еллар)
- Җәгъфәр (1893–1976)
  - Зөбәрҗәт (1928)
  - Фоад (?–1980 еллар)
  - Морад (?–1990 еллар)
- Гариф (1896–1971)
- Рауза (?–1938)

сыман... Анда хәзерге күпчелек эзләнүчеләргә мәгълүм булмаган тагын өч бала исеме түбәндәге тәртиптә урнаштырылган: Камилә, Гомәр, Гали-Хәйдәр. Мөхәммәтсадыйк белән Хәнифәнең 1850 елда өйләнешүен искә алганда, бу балаларның кимендә икесе Шакирга хәтле үк туган булырга тиеш. Юлык авылы зиратының Рәмиевләргә нисбәтләнгән өлешендә дүрт-биш кабер ташы бер тирәдәрәк урнашкан. Шуларның берсенең язуы Мөхәммәтсадыйк картка, икенчесенеке Хәнифәгә багышланган. Шуларга якын торган өченче таштан әлегә «Гомәр Мөхәммәтсадыйк» сүзләрен генә укый алдык. Аның кайчан туып, ничәнче елда вафат булганлыгы әлегә ачыкланмаган. Ул кабер ташларын фоторәсемгә төшереп ал-

5 нче таблица

Сәлим ахун (1733/34–1819)

- Мөхәммәтҗан
  - Лотфулла
    - шагыйрь Сәгыйть Рәмиев (1880–1926)
- Бәхетгәрәй
  - ?
    - Гариф ахун
      - Габдрахман
- Габделхәлим
  - Габделхалик
    - Габдулла
      - Исмәгыйль Рәми (1895–1969)

дык, бәлки шулардан төгәлрәк мәгълүмат алып булыр. Дәрдемәнднең «Гасырлар авазы» журналында (1999, 1/2 сан, Рамил Миңнуллин мәкаләсе) урын алган хатларында мәгълүм җәмәгать эшлеклесе, фабрикант Хәсән Акчурин һәм Нургали исемле бер кеше «җизни» дип аталганнар. Димәк, болар борадәран Рәмиевләрнең әлегә безгә билгеле булмаган апаларына өйләнгән кешеләр. Шул ук вакытта әлегә аларның бертуган Камилә исемле кардәшләре булуы гына билгеле, аның да язмышы ачыкланмаган. Дашков-Дашкиннар шәҗәрәсендә аналары ягыннан Хәдичә, Гайшә, Фатыйма исемле туталары булуы бәян ителә. Ләкин аларның берсе Чанышев морзаларда, икенчесе Габитов фамилияле кешедә кияүдә дип күрсәтелгән, Фатыйма исемлесе ялгыз теркәлгән.

Мөхәммәтсадыйкның кыз туганнары булганмы-юкмы, әлегә билгесез. Әллә соң, кайбер язмаларда бәян ителгәнчә, Мөхәммәтсадыйкның тагын берничә хатыны булганмы? Мәгәр, ул гомер иткән Юлык, Баймак төбәкләрендә андый хәбәр ишетелмәде. Шакирның дүртме, бишме хатыны булуын

сөйләделәр (берсе яшьли, беренче баладан соң ук вафат булган). Ул турыда язма истәлекләр дә бар. Ә менә Мөхәммәтсадыйк хаҗига карата андый сүз булмады. Бәлки, бик күптәнге хәл буларак, егерменче гасыр азагында аларны хәтерләүче калмагандыр.

Шунысы хак – Юлыкта алтын чыгаручы байлар нәселеннән кала да Рәмиев фамилияле кешеләр яшәгән. Шакирның соңгы хатыны Камилә дә шундый нәселдән. Аның бертуганында кияүдә булган Мәрьямбикә апа белән 1988 елда бик озаклап сөйләшеп утырган идек. «Ирем ягыннан да, әнием тарафыннан да мин байларга туган тиешле. 1918 ел азакларында, хуҗалары авылда булмаганда, аларның кибетләрен таладылар. Мин дә, ун яшьләрдәге кыз, иптәш кызларыма ияреп шунда барып чыктым. Без килгәндә ашамлыклар таланып беткән, киштәләрдә кирәкмәсрәк нәрсәләр генә аунап калган иде. Мин дә күптән кызыгып йөргән ике дәү курчакны кочаклап өйгә кайттым. Шунда анам үземне бик каты орышты: алар безнең якын туганнар, рөхсәтсез әйберләрен алу ярамый дип». Ләкин, онытылып китеп, Мәрьямбикә апаның анасының нәсел-нәсәбен сорашмаганмын. Чөнки без шундук икенче язмыш турында – Мирхәйдәр Фәйзинең якын дусты булган, оста итеп гармунда уйнаган Вафа Әдиһамов турында сөйләшеп киттек. Бу апа, әтисе ягыннан, аңа да туганнан-туган була икән.

Мөхәммәтсадыйк хаҗиның варисларын барлар алдыннан тагын бер үзенчәлекне искәртеп китү кирәктер: бу нәселдә бер үк исемне йөртүчеләр бик күп. Аларны барлау барышында адашып һәм буталып бетәрлек. Шушы язмада гына да өч Камиләне искә алдык инде. Морад, Фуат, Фирдәвес, Диләфрүз, Зәйнәп исемнәре дә еш очраячак әле. Мәсәлән, Шакирның Диләфрүз, Фирдәвес исемле үз кызлары була торып, язмаларда шул ук исемнәрне йөртүче оныклары да теркәлгән. Шакир кызы Фатыйманың Диләрә белән Диләфрүз исемле кызларын, хаталануым ихтимал дип, шәҗәрә таблицасына язмаска да уйлаган идем. Ләкин куен дәфтәренә ул исемнәрнең Фатыймаларда бала караучы хезмәтен үтәгән бер апа яз-

масыннан алынганын истә тотып, теркәргә булдым. Юкса Шакирның икенче кызының балалары да шул ук исемне йөртәләр шикелле. Ризаэтдин хәзрәт улы Габделәхәт кызлары, туксанынчы елларда әле исән-саулар, Ташкентта яшиләр иде. Әмма хатларыма җавап бирмәделәр. Аларның да берсе Диләрә исемле, Яушевлар фамилиясендәге туганнан-туганына адаш иде.

Юлык авылы укытучылары 1980 нче елларда Шакир белән Закирның нәсел-нәсәбен барлаган дәфтәр тутырганнар. Андагы мәгълүмат әле ул елларда исән булган, Рәмиевләрнең күбесен күреп белгән берничә кешедән язып алынган. Шакир гаиләсенең 1900 елга кадәр җәен приискаларда, кышын Юлыкта яшәве сәбәпле, андагы мәгълүматның күбрәге аның варисларына карый. Истәлек сөйләүче әбиләр дә, нигездә, Шакир гаиләсендә хезмәттә булган: бала карашкан, өй эшләрен башкарганнар. Балкан авылында да шундый ук вазифалар үтәгән, әмма сиксәненче еллар азагында гүр иясе булган ике әбинең уллары белән хәбәрләштек. Алар бала чакта, әниләренә ияреп, байлар утарына да баргалаганнар, шул чор тормышын үзләре дә беркадәр хәтерлиләр иде. Шушы эзләнүләргә нигезләнеп, мин дә бер шәҗәрә төзегән һәм аны 1994 елның декабрендә «Шәһри Казан» газетасында бастырган идем. Ул вакыттан соң тагын кайбер нәрсәләргә ачыклык кертелде.

1999 елның 26 ноябрендә «Мәдәни җомга» газетасында Сарман-Әлмәт төбәгенә бәйле шәхесләр тарихын барлаучы Дамир Гарифуллинның «Тайсуган, сиңа күпме сер сыйган» исемле мәкаләсе чыкты. Анда да Рәмиевләр нәселе шәҗәрәсе китерелә (Дәрдемәндкә бәйле тармак). Ләкин ул мәкаләдә дә исемнәрне, вакыйгаларны бутау күренеше күзәтелә.

Шакирның дүрт хатыныннан унөч (кайберәүләр ундүрт дип тә әйтә) баласы туган. Беренче хатыны Гәүһәр Оренбургта тәрбияләнгән кыз булса кирәк. Төп чыгышлары Каргалыдан дигән хәбәр бар. Ф.Кәрими икенче бер сәяхәтнамәсендә Шакир кайнише Хәмитҗанны Оренбургның зыялы яшьләреннән дип, Арабов фамилияле кеше дип таныта. Гәү-

һәрнең алты баласы буй җиткән (3 нче таблица). Олы кызлары Фатыйма Троицк байлары Яушевларда кияүдә була, бер ул, ике кыз үстерә. Чыгышы белән Троицкидан булган, советлар дәверендә туган бер иптәш, Мөхәммәтвәли Яушевның хатыны Дәрдемәнд кызы Рауза булган дип тә сөйли. Кемдер аңа шулай дип әйткән. Ул кеше миңа бер яшь парның фоторәсемен дә биргән иде – Дәрдемәнд кызы шул булырга тиеш, дип. Үз төбәгендә зур эшләр башкарган Мөхәммәтвәли бай 1906 елда вафат булган. Дәрдемәнд кызы Рауза әле ул елларда яшүсмер бала. Ризаэтдин хәзрәт кызы Әсма Шәрәф: «Без Рауза белән бер чордарак үстек. Инкыйлабка чаклы Галимҗан Ибраһимов аңа гашыйк булган иде», дип сөйләгән иде. Рауза 1938 елда Баймакта, әнисе белән Искәндәр абыйсы карамагында вафат булган. Дөрес, Рәмиевләрнең Яушевлар белән бәйләнешләре тулаем ачыкланмаган. Баймак, Юлык төбәге картлары Шакирның бер улы да Яушевлар кызына өйләнгән бугай дип әйткәләделәр. Кем ул?

Диләфрүз – Гәүһәрнең өченче баласы булырга тиеш. Мәдинә апа Рәхимкулова тасвирлавынча, ул Урта Азиядә яшәгән, 1972 елда вафат булган. Балалары ачыкланмаган. Бу гаиләдән Камилә – иң бәхетле язмышлы кыз. Гимназияне тәмамлаган елында ук аны, унҗиде-унсигез яшьлек гүзәл кызны, татарның күренекле җәмәгать эшлеклесе, Дәүләт Думасы депутаты Садрый Максудига ярәшәләр. Булачак кияүнең кыз белән танышырга килү күренеше кызлары Гадиләнең соңгы китабында тасвир ителә. Туй мәҗлесе 1910 елның ноябрендә Оренбург шәһәрендә уздырыла. Камиләнең ике кызы – С.-Петербургта туган Гадилә һәм Казанда туган Наилә 1921 елдан Финляндиядә, 1925 елдан соң Төркиядә яшиләр. Икесенең дә икешәр баласы бар.

Фирдәвес – Ризаэтдин бине Фәхретдин улы Габделәхәттә кияүдә. Өйләнешкәч Уфада һәм Мәскәүдә яшиләр. 1937 елда ире репрессияләнгәч, ул ялгыз ике кыз үстерә. Берсе – Диләрә – хәзер сәнгать фәннәре докторы. Фирдәвес 1980 нче елларда кызлары кулында Ташкентта вафат була. Гәүһәрнең кече улы Рәүфнең Орск төбәгендә 1920 елларда бер маржа-

га өйләнүен, ләкин озак яшәмәвен, яшьли авыру булганын сөйләделәр. Икенче бала булып туган Сөләйман бу гаиләнең генә түгел, борадәран Рәмиевләрнең төп терәге. Шакир вафатыннан соң – 1912 елдан ул барлык приискалар белән фактик идарәчелеккә тәгаенләнә. Хатыны Әсманы берәүләр Яушевлар кызы дип әйтәләр, икенчеләр сәүдәгәр Борнаевлар нәселеннән димәкчеләр. Аларның ике улы, бер кызы туа. Мирхәйдәр Фәйзи көндәлекләрендә телгә алынган Гөлнурның 1980 нче елларда Сәмәркандтә вафат булуы хакында хәбәр бар. Сөләйман совет хакимияте елларында да җитәкче хуҗалык эшләре башкарган. 1930 нчы еллардан соң эзе югала.

Шакирның икенче хатынының төп яшәү урыны – Верхнеуральск шәһәре. Шакир вафатыннан соң дөнья күргән язмаларда аның Гәүһәрдән башка хатыннары телгә алынмый диярлек. Шул ук вакытта аның башка хатыннарының булуы да инкарь ителми. «Вакыт» газетасының 1916 елгы 27 июль санында имзасыз «Фаҗигале вакыйга» хәбәре басылган. «10 июльдә Верхний Урал шәһәре янындагы дачада мәрхүм Шакир әфәнде Рәмиевнең өч кыз баласы илә тәрбияче кызлары Урал суына батып һәлак булганнар», диелә анда. Мәхбүбә биш кыз бала анасы була (3нче таблица). Әлеге фаҗигадән соң исән калган Фәтанәтнең егерменче елларда кияүгә чыкканлыгы мәгълүм. Кече кызлары Мәүва утызынчы еллардан Уфа шәһәрендә укыта. Орск төбәгеннән чыккан Жданов фамилияле бер татарда кияүдә була. 1994 елда Уфадан егерме чакрымнардагы бер авылда яши иде. Уфада элек Рәмиевләр гаиләсе белән аралашкан Орск кешесендә бер фоторәсем саклана. XX гасыр башында, Екатеринбург шәһәрендә Шакир бер чибәр хатын белән басып төшкән, урталарында өч-дүрт яшьлек кыз. Фоторәсем артына: «Уртада мин – Зәйнәп» дип язылган. Урал елгасында батып үлгәндә Зәйнәпкә ундүрт яшь була.

Шакирның өченче хатыны Фатыйма Габитова тумышы белән Юлыктан. Төп яшәү урыны Балкан авылында. Аның бертуганы Харис Габитов Рәмиевләрнең Балкан төбәгендәге приискаларның баш идарәчесе. Икенче бер туганы – Мөбарәк тә бер шахта идарәчесе. (Башкортстанның 1920 елларда алтын, бакыр

чыгару тресты башлыгы да шушы нәселдән.) Фатыймадан туган Әхмәтмидхәт (Мидхәт Рәмиев) 1912 елдан Бельгиядә яши, Льеж шәһәрендәге техник институтта укый. Ике елдан соң, 1914 елның җәй башында монда укырга дип Закир улы Гариф тә килә. Шул елда башланган Бөтендөнья сугышы аларны ватаннарыннан аерып калдыра. Истәлекләргә караганда, Мидхәт 1945 елга кадәр Европада яши, Бөек Ватан сугышыннан соң Америкага китә. Гариф сугыштан соңгы елларда Финляндиядә яши, укыта, өйләнмәгән. 1971 елда, Гадилә Айда Италиядә Төркиянең вәкаләтле вәкиле булып эшләгәндә, ул Камилә туганы белән очрашу өчен Римгә бара, авырып китә, шунда вафат та була.

Фатыймадан Әхмәтмидхәт кенә туып кала. Аның вафатыннан соң Шакир Юлыктан Фазулла (Фәйзулла) кызы Камилә Рәмиевәгә өйләнә. Камиләдән туган Рәшитне (1911/12-1978) Юлык картлары бөтен төс-кыяфәте, хәрәкәтләре белән атасына бик охшаган иде дип сөйлиләр. Ул Баймак төбәгендәге алтын чыгару идарәләрендә инженер вазифасын башкарган, башбирмәс Зәки Вәлидинең «мөстәкыйль дәүләте»нең соңгы башкаласы булган Темәс авылында җитмешенче еллар азагында җирләнгән.

Оренбург шәһәренең хәзерге Пролетарская (элекке Перовская) урамында, драма театры бинасы артында ук, Шакир-Гәүһәр гаиләсе яшәгән йорт исән. Әлбәттә, элеккеге иркен ишегалды, ишегалды бакчасы сакланмаган. Элек аның янәшәсендә Рәмиевләрнең матбугат хезмәткәрләре йорты да булган, Ризаэтдин хәзрәт гаиләсе дә шунда яшәгән, ишегалды бакчалары уртак саналган. Хәзер аның урынында биш катлы зур өй (кара: Шакир Рәмиевне соңгы юлга озату фотосы). Шакир хәзер Оренбург шәһәре уртасында калган Иске татар зиратында җирләнгән. Гани, Мәхмүт бай Хөсәеневләр һ.б. мәгълүм шәхесләрнең дә каберләре шунда ук.

Закир Рәмиев Орск сәүдәгәре Мостафа Борнаев кызы Мәхүбҗамалга (1861-1943) өйләнгән. 1880 нче еллар азагыннан алар Оренбург шәһәрендә яшиләр. Җиде бала үстерәләр (4 нче таблица). Олы кызлары Өммегөлсем шул шәһәрнең уртакул

сәүдәгәре Гариф Камаловта кияүдә була, дүрт кызлары үсә. Кече кызлары Кафия 1994 елда исән, Мәскәүдә яши иде. Өммегөлсем 1921 елның көзендә тиф авыруы йоктырып вафат була. Аны соңгы юлга озатырга дип Орскидан килгән атасы Закирны да тиздән шул ук чир аяктан ега. Ул 1921 елның октябрь аенда Орск янәшәсендәге Ильяс утары дип йөртелгән атлы казаклар авылы зиратында җиргә иңдерелә.

Искәндәр 1886 елда туган, 1943 елда Томск шәһәре тирәсендәге ГУЛаг лагеренда җирләнгән. Дәрдемәнднең өч улы да, Оренбургта яшәгән күпчелек зыялыларныкы кебек үк, башлангыч белемне «Хөсәения» мәдрәсәсендә үзләштергән. Мәдрәсәнең рөшди өлешен тәмамлагач Искәндәрне С.-Петербург гимназиясенә биреп укыталар. Шунда немец телен дә яхшы үзләштергәч, Германиядәге Фрайберг тау академиясенә укырга җибәрәләр. 1914 елда шул академияне тәмамлап иленә кайта, үзләре карамагындагы приискалар канцеләриясендә эшли. Верхнеуральск шәһәре кызы Шәрифзадә Дашковага өйләнә. Уллары Бәшир тугач, 1918 елның май башында алар Орск шәһәренә күчеп китәләр. Искәндәрләр анда Мәхүбҗамал туганнары гаиләсендә 1926 елның февраль башларына кадәр яшиләр. Орскида совет хакимияте ныклап урнашкан көннәрдән, 1919 елның урталарыннан Искәндәр үз белгечлеге буенча совет оешмаларында эшли. 1926 ел башында аны яңарак оешкан «Башкирзолото» трестына эшкә билгелиләр. Шәрифзадә вафатыннан соң ул элек үзләрендә хезмәт иткән, тумышы белән Чистай төбәгеннән булган Минсафага өйләнә. Баймакка күчкәч тә аларның беренче сабыйлары вафат була. Икенче уллары Равил 1927 елда Баймакта туган, Уфада үскән. Институтта геолог белеме алган. Башкортстанда һәм Себердә геология идарәләрендә эшләгән. Хәзер Уфада яши, өч улы, берничә оныгы бар.

Зәйнәп Оренбургта туган, шунда ук гимназия тәмамлаган бугай. Самара шәһәрендә дә ниндидер курсларда укыган. Ире – язучы, драматург Ярулла Вәли, төп чыгышы буенча Буа өязеннән. XX гасыр башында Бозаулык шәһәрендә сәүдәгәр булган. 1906 елда аны «Вакыт» газетасына финанс-хуҗалык эшләрен башкару хезмәтенә чакырып китерәләр. Аннары ул Рәмиев-

ләрнең «Вакыт» басмаханәсенең хуҗалык һәм финанс эшләре өчен җаваплы була. 1936-37 елларда репрессияләнә. Гаиләләре 1927 елдан Уфада яши. Мәхүбҗамал монда 1943 елда кызы Зәйнәптә, Зәйнәп исә 1977 елда кызы Асия кулында вафат булганнар, икесе дә Уфа зиратында җирләнгәннәр. Зәйнәп улы Баязид 1942 елда Бөек Ватан сугышында һәлак булган. Аның 1941 елда туган инженер улы Юрий Уфада машинасын талаучылар тарафыннан үтерелә.

Асиянең буй җиткән ике баласы бар, икесе дә хроник авырулар. Ире 1950 елларда Уфа шәһәренең баш архитекторы булган. Зәйнәп 1959 елда Башкортстан Дәүләт музеена Дәрдемәнднең жилетын, чит илдән кайтарткан затлы, 24 кешелек сервизын, Хәнифә әбисенең бәрхет күлмәген һ.б. кайбер әйберләрне бүләк итә. Вафаты алдыннан тагын анасыннан калган «көмеш» самавырын, «ЗР» вензеле төшерелгән, алтын йөгертелгән кашыкчәнечкеләрен дә тапшырырга ниятләгән була. (Аларның берәр данәсен Татарстан Дәүләт музеена тапшыру өчен дип Казанга да җибәрә.) Зәйнәп соңгы елларда кардәш-ыруын барлау, берберсенә якынайту мәшәкатьләрен дә үз өстенә алган була.

Раузаның да туган елы ачыкланмаган. Ул Самара гимназиясендә укыган. Шул елларда булса кирәк, ике кыз туган фотога төшкәннәр. Ул фото, Зәйнәп һәм Раузаның исемнәре күрсәтелмичә, татар байлары кызлары буларак, бер китапта дөнья күргән. Рәсемнән бу кызларның яшь аралары зур булмавы күренә. Яушев байлар белән кияү-киленлек мөнәсәбәтләрен тикшергәндә Рауза турында алдарак та сүз булган иде.

Җәгъфәр (1893-1976), «Хөсәния» мәдрәсәсенең рөшди өлешеннән соң Оренбург реаль училищесын тәмамлаган. Оренбург, Орск тирәләрендә барган гражданнар сугышында, 1920 елда Муса Мортазин җитәкчелегендәге башкорт атлылары бригадасы белән Киевны поляклардан сугышып алу яуларында катнашкан. Шунда бер кулын өздереп, Орск шәһәренә, әти-әнисе карамагына кайта. Әнисенә кардәш Гөлнур Борнаевага өйләнгән. Аларның ике улы (Морад, Фуат), бер кызы туган. Варисларында үзе язган шигырь дәфтәрләре саклана. Дәрдемәндкә багышланган истәлек кульязмасын һәм атасының кайбер язмала-

рын тотып, илленче еллар урталарында Казанга да килгән. Ул язмалар язмышы әлегә билгесез. Кызы Зөбәрҗәт: «Бездә андый язмалар юк», – ди. Ул вакытта Язучылар берлеге рәисе булган Гомәр ага Бәширов аңа әдәбият галиме Мөхәммәт Гайнуллинга мөрәҗәгать итәргә киңәш биргән. Бәлки ул кулъязма бүген дә галим архивында сакланадыр. Утызынчы еллардан башлап Җәгъфәр Чиләбе өлкәсенең Башкортстан белән чиктәш бер авылында хисапчы булып эшләгән, шунда вафат та булган.

Гариф (1896-1971), мәдрәсәнең рөшди өлешен һәм Оренбург реаль училищесын тәмамлаганнан соң, 1914 елда Бельгиядәге Льеж шәһәрендә укый башлаган дип алдарак язган идек. 1974 елда Истанбулда нәшер ителгән «Казан» журналы аның язмышын ачыклауны үтенеп язылган хат ала. Ул хатны Уфадан Искәндәр улы Равил язган. Май аенда Гадилә Айда журналда «Ариф Рәми» һәм «Камилә Максуди» исемендә ике кечерәк белешмә урнаштыра.

Равил ага Рәмиевкә Гадилә Айда урнаштырган белешмәнең русчага тәрҗемәсен җибәрәләр. Гадилә яза: «1967 елдан мин Римдә Төркия илчелегендә сәркәтиб булып эшли идем. 1971 елның язында Анкарадан әнием Камилә Максуди кунакка килде. Гариф абый пенсиядәге укытучы иде. Егерме еллар элек аның бездә Төркиядә булганы бар иде. Аннан соң Парижда да очрашкан идек. Берничә атна бергә булырбыз дип, Римгә дә чакырдык. Элегрәк ул авырып, хастаханәләрдә дәвалануы турында хатларында хәбәр иткәләгән иде. Ләкин нинди авыру белән авыруын белми идек. Аңарда үпкә шеше авыруы һәм астма икән. Римнең эссе һавасы аңа килешмәде, ике атнадан соң аны хастаханәгә салырга туры килде. Вафат булгач мин аны Римнең мөселманнар өчен билгеләнгән каберлегендә мөселман йолаларын үтәп җирләдем».

Морад – Закир улы, туу һәм вафат булу еллары билгесез. Авырып, 24 яшендә дөньядан киткән дигән мәгълүмат бар.

Закир нәселеннән совет хакимияте дәверендә зур уңышка ирешкән кеше – Искәндәр улы Бәшир була. Ул 1918 елда Оренбургта туган, 1994 елда Мәскәүдә вафат булды. Утызынчы еллар башында, мәктәптә укыганда, ул радиоалгычлар



Бәшир Рәмиев

ясау белән мавыга, атасы ярдәмендә беренче зур радиоалгычын сафка бастыра. 1936 елда Мәскәү энергетика институтына укырга керә. Ләкин 1938 елның май аенда, атасының кулга алынуы сәбәпле, аннан чыгарыла һәм нинди дә булса уку йортында башка укымый. 1941 елда Бөек Ватан сугышына алына. Шул заман радио җайланмаларын үзлегеннән өйрәнгән кеше буларак, тиздән аны махсус элемтә батальонына күчерәләр. 1943 елның декабрендә яңарак оешкан бер ябык фәнни-тикшеренү институтына фронттан эшкә чакырыла. 1947 ел башыннан ул анда радиолокациянең бер юнәлеше буенча әйдәп баручы инженер һәм аерым эшләнмәләрнең баш

Рамееву
Баширу Искандаровичу
в 1954 году присуждена Государственная премия СССР
первой степени и присвоено звание
ЛАУРЕАТА ГОСУДАРСТВЕННОЙ ПРЕМИИ СССР
за работу в области вычислительной техники

№ 8353

ДИПЛОМ
ДОКТОРА НАУК

МТН № 000627

Решением
Высшей Аттестационной Комиссии
Рамееву Баширу Искандаровичу
ПРИСУЖДЕНА УЧЕНАЯ СТЕПЕНЬ ДОКТОРА
ТЕХНИЧЕСКИХ НАУК
Председатель Высшей Аттестационной Комиссии
Ученый Секретарь Высшей Аттестационной Комиссии

конструкторы була. Дөрес, атасы һәм бабасы биографияләренә бәйле рәвештә, аңа тиздән бу фәнни институтны калдырып китәргә туры килә. Әмма фән юлын ташламый. 1955-1968 елларда ул Пенза шәһәрендә электрон хисаплау машиналарын һәм космоска бәйле эшләнмәләрне проектлаштыру вә эшләп чыгаручы фәнни институт белән заводта баштарак төп белгеч, аннары баш инженер була. 1970-80 елларда Мәскәүдә, СССРның Фән һәм техника дәүләт комитетында – Электрон хисаплау системалары баш идарәсендә башлык урынбасары. Ике мәртәбә СССР Дәүләт премиясе лауреаты булган кеше. Күп кенә яңа ачышлар, яңа төр хисаплау машиналары һәм үзе сайлаган өлкәдә космоска бәйле җиһаз һәм эшләнмәләр авторы. 1954 елда ук техник фәннәр докторы дәрәҗәсенә ирешкән шәхес.

Беләнәшир Рәмиевнең Мәскәү үзәгендәге квартирасы да чын иҗат кешесенә хас булган җиһазлар белән җиһазландырылган иде. Шунда ук, бер почмакта, чит илдә эшләнгән кечерәк универсаль станок та тора. Димәк, үзенә кирәк кайбер механик детальләрне шунда үзе үк эшләп тә караган. Эш өс-

тәле тирәсендәге тумбочкаларны, бер стенаны иңләгән китап шкафын да үз кулы белән ясаган икән. Кул эшләгәндә баш ял итә, дигән әйтем хак ул.

– Бабам Дәрдемәнд тә кайбер эшләрне үзе эшләргә яраткан, – дип ул, Зөфәр Бәширов белән миңа ышкылар, чүкечләр дә чыгарып күрсәтте. Аларга, металл өслекләрен ертып, кайчандыр «Рәмиев» дип тамга да салынган. Тубинск рудникы конторасындагы сейфның да эчке ягына, металл җирлеккә, шул фамилия язылуын сөйләделәр. Ләкин ул сейфны ачып күрсәтмәделәр: эчендәге алтын байлыкларын чит-ят кешегә күрсәтергә ярамый, диделәр.

Ә Бәширнең улы Искәндәр бүгенге көндә Мәскәүдә чит ил эшкуарлары белән уртак бер ширкәттә эшли.

Милләтебезнең алтын бәрабәрендә кыйммәтле, затлы һәм мәртәбәле шәхесләре – бертуган Шакир һәм Закир Рәмиевләрнең тормышы һәм эшчәнлеге аларның тулы мәгънәсендә Шәхесләребез булуын раслый.

Лирон Хәмидуллин

Рәмиевләр матбагасы

Бертуган Рәмиевләр үз китап матбагаларын булдыру турында унтугызынчы йөз азакларыннан ук хыяллана башлаганнар. Ләкин патша хакимиятеннән рөхсәт ала алмаганнар. Ә инде Бөгелмә өязе ахуны Гыйльман Кәримев шундый эшкә керешкәч, иң беренчеләрдән булып ярдәм кулы сузучылар Рәмиевләр булганнар. Гыйльман ахунны шундый изге эшкә алынырга күндерүчеләр дә Гани бай Хөсәенев белән бертуган Рәмиевләр булган дип сөйләүчеләр бар. Дөрес, китап дөньясының зур белгече академик Әбрар Кәримуллин «Китап дөньясына сәяхәт» (1979) хезмәтендә ахунны үз басмаханәсен ачарга рухландыручы кеше Ольга Лебедева (Гөлнар ханым) булган, дип яза.

Оренбург шәһәрендә 1901 елга кадәр дә, Г.Кәримев типографиясе эшли башлаганчы да гарәп хәрефләрен кулланган ике басмаханә эшләгән. 1894 елда ачылган Б.Бреслин типографиясендә берничә татар китабы дөнья күргән. Ә губернатор идарәсе карамагындагы басмаханәдә кайбер рәсми документлар, белешмә-брошюралар басылган. Ә.Кәримуллин шул ук хезмәтендә1901-1908 еллар аралыгында, басмаханә тулаем Кәримевләр кулында булганда, 173 китап бастырып чыгарылган дип хәбәр итә. 1902 елда, Гыйльман ахун вафатыннан соң, мирасы аның улларына һәм икенче кызының кияве Тимерша Соловьев кулына кала, 1906 ел азакларына кадәр басмаханә өлкән улы Фатыйх Кәрими исеме белән йөртелә. Шул елның соңгы айларында басмаханә нигезендә китап басу һәм китап сәүдәсе ширкәте оештырыла. «Кәримев, Хөсәенев вә шөрякәсе»нең җитәкче-оештыручылары итеп


М. В. Д.

Оренбургскаго Губернатора Канцелярія.

Февраля 7 дня 1906 г.

№ 367

г. Оренбургъ

СВИДѢТЕЛЬСТВО.

Дано сіе отъ Оренбургскаго Губернатора на основаніи VII отд. п. I ВЫСОЧАЙШЕ утвержденнаго 24 ноября 1905 года закона о печати въ томъ, что въ г. Оренбургѣ разрѣшается издавать газету на татарскомъ языкѣ подъ названіемъ „Вактъ" (Время) газета выходитъ отъ 2 до 5 разъ въ недѣлю по слѣдующей программѣ: 1) отдѣлъ офиціальный; правительственныя распоряженія, 2) передовая статья, 3) внѣшнія и внутреннія извѣстія, городская хроника, 4) Фельетонъ 5) телеграммы, 6) объявленія, 7) смѣсь, переводы и извлеченія беллетристическихъ произведеній съ русскаго и другихъ языковъ, а также статьи на русскомъ языкѣ. Подписная цѣна 4 рубля въ годъ. Издателемъ газеты „Вактъ" состоитъ Орскій купецъ Мухамедъ Закиръ Мухамедъ-Садыковичъ Рамѣевъ. Отвѣтственнымъ редакторомъ газеты - крестьянинъ Самарской губерніи Бугульминскаго уѣзда Мухамедъ Фатихъ Гильмановичъ Каримовъ, имѣющій жительство въ г. Оренбургѣ.

Газета „Вактъ" (Время) будетъ печататься въ собственной типографіи Каримова.

Гербовымъ сборомъ оплачено.

И. д. Губернатора [signature]

Оренбургскаго Губернатора

Правитель Канцеляріи [signature]

Татарстан милли архивы. Ф.1370, 1 тасв., 4 эш, 1 б.

Хөсәен Хөсәенев (рәис), Ф.Кәрими, Мәхмүтгәрәй Фәйзуллин, матбаганың хуҗалык һәм финанс эшләре мөдире итеп Тимерша Соловьев сайланалар.

Рәмиевләрнең «Вакыт» газетасы белән «Шура» журналы да баштарак шул басмаханәдә нәшер ителә. Шул дәвердә берара Т.Соловьев кул астында эшләгән әдип Зариф Бәшири хәтерләвенчә, бу басмаханәнең җиһазы ярыйсы ук таушалган була, шрифт-хәрефләр еш алышынмый, арзанлы начар кәгазь файдаланыла. Үз газета-журналларының сыйфатлырак булып чыгуын кайгырткан Рәмиевләр тиздән заманча җиһазландырылган һәм сыйфатлы кәгазь, буяулар белән тәэмин ителгән «Вакыт» исемле үз басмаханәләрен ачуга рөхсәт алалар. Ул 1909 елның гыйнварыннан эшли башлый.

Ул елларда Оренбург шәһәрендә рус телендә 7-8 журнал (кайберләре алмаш-тилмәшләп), шул чамада ук газеталар нәшер ителә. Журналлардан «Урал», «Юнкер казак», рәсемле «Железнодорожник», сатирик «Саранча», «Кобылка», «Пыль» кебекләрне, газеталардан «Оренбургские губернские известия», «Тургайская газета» кебек дәвамлы чыгып килүчеләрен күрсәтергә була. Татар журналларыннан «Шура» (1908-1917), «Дин вә мәгыйшәт» (1906-1918, февраль), «Икътисад» (1908-1912), көлкеле-рәсемлеләре «Чикерткә» (1906), «Чүкеч» (1906-1910), «Карчыга» (1906-1907), «Мөгаллим» (1913-1915), «Яз» (1917), «Кармак» (1915-1918) чыга. Газеталардан 1917 елга кадәр татар телендә фәкать «Вакыт» кына нәшер ителгән. 1913 елдан казакъ телендә «Казакъ» газетасы чыга башлый. Аның нашир һәм мөхәррире – язучы, галим, казакъ халкының милли азатлык хәрәкәте җитәкчеләреннән берсе Әхмәт Байторсынов була.

Монда санап үтелгән газета-журналларның кайберләре «Вакыт» басмаханәсендә дөнья күргән. 1915 елда русча эшләүче Б.Бреслин типографиясенең ябылуы мәгълүм. Нинди дә булса яңа типографиянең ачылуы хәбәр ителми. Әлбәттә, якындагы ике-өч өлкәне берләштергән генерал-губернатор идарәханәсе карамагында рәсми басмаханә эшләгән. Шул ук елларда дәвамлы рәвештә басылып чыккан күпсанлы


М. В. Д.

Оренбургскаго Губернатора Канцелярія

13 Декабря 1907 г.

№ 3894

Оренбургъ.

СВИДѢТЕЛЬСТВО

Дано на основаніи VII Отд. п. I ВЫСОЧАЙШЕ утвержденнаго 24 ноября 1905 года закона о повременныхъ изданіяхъ, проживающимъ въ г. Оренбургѣ, Орскимъ купцамъ Мухамедъ-Шакиру и Мухамедъ-Закиру Мухамедъ-Садыковичамъ Рамѣевымъ въ томъ, что разрѣшено издавать въ г. Оренбургѣ двухнедѣльное повременное изданіе на татарскомъ языкѣ подъ названіемъ „Шуро" (Совѣтъ) по слѣдующей программѣ:

I) Краткіе отчеты изъ иностранной и отечественной политической жизни.

2) Смѣсь.

3) Объявленія.

4) Рисунки.

Отвѣтственнымъ редакторомъ изданія будетъ состоять крестьянинъ Самарской губерніи Реза Эддинъ Фахретдиновъ. Подписная цѣна въ годъ четыре рубля, а какъ приложеніе къ газетѣ „Вактъ" три рубля. Печататься изданіе будетъ въ типографіи „Товарищества печатнаго дѣла Каримовъ, Хусаиновъ и К-о въ Оренбургѣ. Гербовымъ сборомъ оплачено.

Губернаторъ [подпись]

Управляющій Канцеляріей [подпись]

Татарстан милли архивы. Ф.1370, 1 тасв., 4 эш, 3 б.

белешмәлекләр, шул исәптән безгә кардәш казакъ халкы тарихына мөнәсәбәте булган «Справочная книжка Тургайской области» (1911-1917) кебек дистәләгән басма шул типографиядә җыелгандыр.

Алда санап кителгән татарча журналлардан «Кармак», газеталардан «Казакъ» Рәмиевләрнең «Вакыт» матбага йорты тарафыннан чыгарылган булырга тиеш. Дөрес, бер әңгәмә вакытында Әбрар ага «аларның үз наширләре булган» дигән иде. Әмма нашире булуы әле басмаханәсе дә булган дигән сүз түгел. Шәһәр хәйрия җәмгыяте карамагындагы «Белек» китапханәсе дә, Орск шәһәрендәге «Шәрекъ» китапханәсе дә, Троицк, Чиләбе, Кустанай шәһәрләрендәге китап-газеталар сәүдәсе белән шөгыльләнүче ширкәт һәм җәмгыятьләр дә ул вакытта үзләрен нашир буларак та таныткан, үзләре теләгән китапларны бастырып чыгару өчен Казан һәм Оренбург басмаханәләренә даими рәвештә заказлар җибәреп торганнар.

«Вакыт» басмаханәсендә кемнәрнең нинди китаплары нәшер ителгән соң? Рәмиевләр матбагасы белән иң уңышлы хезмәттәшлек итүче, әлбәттә, Ризаэтдин хәзрәт булган. «Рухият» нәшриятында 1999 елда чыккан «Ризаэтдин Фәхретдин» китабындагы библиографик исемлектә бу әдип һәм галимнең дини, әхлакый-тәрбияви һәм тарихи эчтәлекле 35 хезмәтенең «Вакыт» нәшрияты тарафыннан чыгарылуы күрсәтелә. (Ә.Кәримуллинның «Китап дөньясына сәяхәт»тә 26 саны китерелгән). Хәер, Р.Фәхретдиннең «Вакыт» басмаханәсендә чыккан китаплары саны әле бәлкем 35 белән генә дә чикләнмидер. Р.Мәрданов хәбәр итүенчә, ул авторның Оренбургта нәшер ителеп тә, шул дәвердә ул шәһәрдә эшләгән өч басмаханәнең кайсысында җыелып чыкканлыгы әлегә ачыкланмаган дистә ярымлап китабы бар икән.

Рәмиевләр матбагасында чыгарылган китап саннары буенча икенче, өченче урыннарда Шәриф Камал белән Галимҗан Ибраһимов торалар. Ш.Камалның шул елларда дөнья күргән барлык мәгълүм хикәяләре дә башта «Шура» белән «Вакыт» битләрендә урнаштырылганнар. (Мәсәлән, 1909 елда «Уяну»,



4

МИЛОСТИВЫЙ ГОСУДАРЬ

Мухамедъ-Фатихъ Гильмановичъ!

Издавая на татарскомъ языкѣ газету "ВАКТЪ" и журналъ "ШУРО", я лично за себя и въ качествѣ уполномоченнаго брата своего Орскаго купца - Мухамедъ-Шакира Мухамедъ-Садыковича Рамѣева, симъ уполномачиваю Васъ на слѣдующее: управлять конторой и редакціей вышеозначенныхъ изданій, завѣдывать кассою, нанимать служащихъ, приглашать сотрудниковъ и на - время своего отсутствія, редактора, условится съ ними, разсчитывать ихъ получать и принимать денежную, заказную, и другую корреспонденцію, - посылки, клади и товары присылаемые на имя газеты "ВАКТЪ" и журнала "ШУРО", покупать нужные для изданія ихъ предметы, бумаги и другіе товары, нанимать помѣщенія. Открывать въ банкахъ текущіе счета отъ имени вышеназванныхъ изданій, подписывать чеки, получать переведенные - черезъ банкъ по адресу ихъ деньги. Предъявлять иски къ разнымъ лицамъ ходатайствовать повсѣмъ дѣламъ касающимся изданія означенныхъ газеты и журнала, въ судебныхъ и административныхъ учрежденіяхъ и у должностныхъ лицъ, выступать отвѣтчикомъ отъ лица газеты и журнала противъ - другихъ. Довѣронность эту можете передовѣрять другимъ лицамъ съ правомъ дальнѣйшаго передовѣрія, что Вы или повѣренные Ваши учините, я вѣрю, спорить и прекословить не буду.

Довѣренность эта принадлежить крестьянину Мухамедъ-Фатиху Гильмановичу К а р и м о в у .

За себя и по довѣренности от брата Орского купца Мухамедъ-Шакира Мухамедъ-Садыковича Рамѣева Орскій купецъ Мухамедъ-Закиръ Мухамедъ-Садыковичъ Рамѣевъ

[illegible] девятьсотъ одиннадцатаго [illegible] Марта двадцать четвертаго дня довѣренность эта явлена у меня, Михаила Петровича [illegible] Оренбургского [illegible] Троицкой улицѣ, [illegible] своего лично мнѣ извѣстнымъ имѣющимъ законную правоспособность къ совершенію актовъ, [illegible] Орскимъ куп-

Татарстан милли архивы фондларыннан (1370 ф, 1 тасв.)

«Сулган гөл», 1910 елда «Әүвәл-әүвәл заманда», «Шәкерт», «Депутат», «Буранда», 1911-1912 елларда «Сукбай», «Бәхет эзләгәндә», «Курай тавышы» һ.б.) Аннары «Вакыт» матбагасында 1914 елда шул унбиш әсәр тупланган «Хикәяләр төркеме» җыентыгы, 1910 елда «Козгыннар оясында» хикәясе, 1915 елда «Акчарлаклар» повесте аерым-аерым басылып чыгалар.

Г.Ибраһимовның да беренче иҗат дәвере хикәяләренең күпчелеге, әдәбиятка, мәдәнияткә кагылышлы кайбер мәкаләләре әүвәл «Вакыт» белән «Шура» битләрендә урын алган, аннары шул ук елларда аерым китап буларак басылганнар. Мәсәлән, 1911 елда «Диңгездә», «Ике йөз ел элек», «Уты сүнгән җәһәннәм», 1912 елда «Карт ялчы» китаплары укучылар кулына ирештерелә. Әдипнең күләмле «Татар шагыйрьләре» мәкаләсе дә 1913 елда шул матбага ярдәмендә китап булып чыга. Үз басмаханәсе булган Фатыйх Кәриминең дә кайбер китаплары «Вакыт» матбагасында нәшер ителгәннәр. Мәсәлән, «Истанбул мәктүпләре» исемле мәшһүр, 450 битле калын китабы (1913), «Дөнья халыклары» исемендәге дистәләгән китапчыклары шундыйлардан. (Мондый хәл, бәлки, замандашы З.Бәшири истәлегендә язылганча, унынчы еллар урталарында «Кәримев, Хөсәенев вә шөрякәсе» басмаханәсенең, конкуренциядә җиңелеп, «шартлап таралуы» нәтиҗәсендә тугандыр. Ә.Кәримуллин язуынча да, 1915 елдан соң бу ширкәтнең тынып калуы бәян ителә.)

«Вакыт» исә эшчәнлеген дәвам иттерә. «Шура»да дөнья күргән аерым хикәяләр тупламасы, шул исәптән төрле әдипләрнең «Тел ярышы» конкурсында катнашкан хикәяләре, журнал редакциясенә килеп тә, төрле сәбәпләр аркасында анда урын алмаган шигырьләр җыентыгы, Габдрахман Сәгъдинең «Әдәбият кануннары», Г. Батталның «Габделвәли Яушев», Җамал Вәлидинең «Татар әдәбияты хакында», Казандагы «Таңчылар» төркеменең актив әгъзасы Шакир Мөхәммәдъяровның «Алпавытлар заманы» һәм тагын дистәләгән әдәби, мәдәни һәм сәяси эчтәлекле китаплар басылган. Шулар арасында Төркиянең күренекле әдибе Әхмәт Мидхәт,

инглиз язучысы Конан Дойль әсәрләре, рус әдибе Леонид Андреевның «Ачлык патша»сы һ.б. бар.

Рәмиевләр яшь буынны тәрбияләүгә дә җитди әһәмият биргәннәр. З.Рәмиев, «Хөсәения» мәдрәсәсенең тышкы идарә әгъзасы буларак, аны уку әсбаплары белән тәэмин итүдә катнашкан, физика, химия кабинетларына җиһазларны чит илләрдән кайтарткан. «Вакыт» басмаханәсендә байтак кына дәреслек, балалар өчен уку китаплары нәшер ителгән, шул исәптән Дәрдемәнднең үзе исән чакта чыккан кечкенә җыентыгы (1910). Дәреслек авторларының күпчелеге – «Хөсәения» мәдрәсәсе мөгаллимнәре яки Нәҗип Думави кебек абруй казанган укытучылар. Мәсәлән, Н.Думавиның Казан басмаханәләрендә дә басылып чыккан «Безнең мәктәп» исемле уку китабы кабат нәшер ителгән. Шул ук авторның «Шура» белән «Вакыт» битләрендә дә дистәләгән шигырь һәм хикәяләре урнаштырылган.

Мәдрәсә укытучыларыннан шагыйрь Төхфәт Ченәкәйнең ике китабы – «Кан дулкыннары яки сугыш» һәм «Өмет очкыннары» «Яңа вакыт» басмаханәсендә басылалар. Инкыйлаб җилләре исә башлаган елларда дөнья күргән бу ике шигырь китабының заказчы-нашире, мөгаен, Мәхмүт Галәүнең «Кармак» нәшрияты булгандыр. «Хөсәения» мөгаллимнәре китап-дәреслекләреннән Фатыйх Кәрими һәм Нуретдин Агаевларның икътисади география дәреслеген (ике басма, 1909, 1910), Габдулла Шинаси-Ибраһимовның «Мохтасар химия»сен (1912), Нургали Надиевнең «Ибтидаи мәктәптә хисап укыту ысуллары»н (1917), Мөхәммәтханәфи Бакировның берничә китаптан торган рәсемле «Гыйльме табигыя дәресләре»н атарга була. Мөгаллим Г.Газиз* сүз башы белән чыккан «Язу эшләре» дәреслеге (1911) һәм шул ук авторның җитди эчтәлекле «Халык җөмһүрияте нинди була?» (1917) – шулай ук Рәмиевләр матбагасы җимешләре.

* Бу шәхес татар тарихчысы Газиз Гобәйдуллин түгел (*Төз. иск.*).

Сигез еллап эшләү дәверендә бу басмаханәдә 120 дән артыграк китап басылып чыккан. Аларның күпчелеге Рәмиев байларның матди ярдәме белән нәшер ителгәннәр.

1917 елгы инкыйлабка чаклы Оренбург каласын казакъ халкының да бер мәдәни үзәге булган дияргә ярый. XIX йөзнең яртысында монда казакъ халкы мәгърифәтчесе, беренче язма хикәя үрнәкләрен тудыручы, ике кардәш халыкның уртак улы Ибраһим Алтынсарин яшәгән. XX гасырның унынчы елларында шушы шәһәрдә казакъ телендә беренче күләмле проза әсәрләре – повесть, роман үрнәкләре дөнья күргән. Мәсәлән, Рәмиевләрнең «Вакыт» басмаханәсендә казакъ телендә шундый сигез китапның чыгуы, шул исәптән казакъча иң тәүге повесть булган «Көргенди бала»ның («Тәрбияле бала», авторы М.Нурбаев) 1911 елда басылуы хәбәр ителә.

Язма истәлекләрдә Рәмиевләрнең матбугат хезмәткәрләренә иң югары хезмәт хакы түләгәнлеге хакында әйтелә. Татарстан Милли архивының Ф.Кәрими фондында шуны раслардай бер документ та сакланган. Анда «Закир әфәнде әмере илә 1917 елның март башыннан» билгеләнгән эш хакы таблицасы китерелә.*

Кәбир Бәкер	элек 120 сум иде,	инде 180 сум
Шәриф Камал	– 120 –	–180 –
Җәмалетдин [Вәлиди]	–50 –	–75 –
Кави	– 85–	–120 –
Каюм	–120 –	–160 –
Кәлимулла	–112 сум 50 тиен –	140 –
Зариф Сүнчәләй	–75–	–120 –
Ягъкуб Сүнчәләй	– 5 –	–75 –
Барышня	– 30 –	– 45 –
Ханым	– 60 –	– 70 –
Солтан	– 50–	– 70 –
Машинист	– 80 –	– 100 –
Ярулла Вәлиев	– 180 –	– 250 –
Риза казый	– 225–	– 275 –
Фатыйх Кәримев	– 225–	– 325 –

* Татарстан Милли архивы (ТМА), 1370 ф., 1 тасв., 16 эш, 4 бит.



25 Сент. 1917

Верхнеуральскъ
Закиру Рамѣеву

Требуя около ста процентовъ прибавки рабочіе всѣхъ типографій забастовали газеты городъ не выходятъ вскорѣ ожидается соглашеніе но Ярулла эфенди рѣшилъ прекратить Вакть закрыть типографію Газета данное время крайне необходима также многіе служащіе рабочіе остаются безвыходномъ положеніи прошу распоряженія продолжать изданіе газеты до вашего пріѣзда тоже мнѣнія Гевхарабетасъ Если желаете прекратить не можете ли сдать аренду или продать было бы очень желательнымъ вашъ пріѣздъ Разныя группы мусульманъ тоже просили меня обратиться Вамъ вышеуказанной просьбой ждемъ отвѣта

Фатыйх Кәримидән Закир Рәмиевкә җибәрелгән телеграмма.

Оренбург шәһәрендә яшәүче Мәдинә Рәхимкулова, мәрхүм Сабит ага Якуповлар хәтерләвенчә, шушы басмаханә өчен Закир Рәмиевнең иркен ишегалды почмагында, янәшәдәге Вороной дигән урамда махсус бина корылган була. Шунда ук редакция хезмәткәрләре өчен иркен эш бүлмәләре булдырыла. Хәзерге көндә ул бина юк инде, шагыйрь өенең иркен ишегалдында хәзер башка биналар, башка корылмалар. Ленинская урамына буй белән каратып, кызыл кирпеч-

тән зәвыклы итеп төзелгән Закир бай өендә дә бүгенге көндә «Оренбургнефтепродукт» оешмасы урнашкан.

Рәмиевләр матбагасының хуҗалык һәм финанс эшләрен элеккеге яшь сәүдәгәр, гасыр башында күренекле язучы булган Ярулла Вәли башкарган. Ул шулай ук Закирның икенче кызының кияве дә. 1918 елның февраль урталарында, Оренбург шәһәрендә беренче мәртәбә совет хакимияте урнашкач (бөтенләйгә ул нәкъ бер елдан соң урнашачак әле), табыш китерүче хуҗалыкларны хакимияткә тапшыру карары чыккач, «Вакыт» (1917 елның көзеннән «Яңа вакыт») басмаханәсе дә барлык җиһазлары, буяу, кәгазьләре һәм бинасы белән бергә хөкүмәткә тапшырыла. 1934-1940 нчы елларда Оренбургта татар телендә чыккан «Коммунист» газетасы хезмәткәрләре Сабит Якупов, Фатыйх Кыргызбаевлар һәм 1920 нче елларда шул шәһәрдә хәреф җыючы хезмәтен башкарган Татарстан кешесе Хәбибулла ага Яруллин сөйләвенчә, «Вакыт» матбагасын совет хакимияте вәкилләренә тапшыруда мөдир Ярулладан тыш «шагыйрь Дәрдемәнд» тә катнашкан.

Рәмиевләр басмаханәсе берничә ел совет җөмһүриятенә дә хезмәт итә. Шуның нигезендә иң әүвәл «Оренбург мөхбире» газетасы нәшер ителә. 1917 елның июленнән аның мөхәррире «Вакыт», «Шура»ларда баш мөхәррир урынбасары вазифасын башкарган, шулай ук Кәримевләргә кияү булган Борһан Шәрәф, 1918 елның мартыннан «Вакыт» басмаханәсенең элекке хәреф җыючысы һәм корректоры, Шәриф Камал шәкерте Заһид Шәркый-Йосыпов. Совет хакимияте икенче мәртәбә монда төпләнгәч чыга башлаган «Юксыллар сүзе»нең дә икенче баш мөхәррире (Һ.Такташ эшләгән дәвердә) Заһид була. Газетаның беренче баш мөхәррире Афзал Таһиров. Егерменче елларда казакъ телендә берничә газета һәм журналның да шушы ук басмаханә җирлегендә нәшер ителгән булуы бик ихтимал. Татар яшьләренең әйдәүчесе Сәхи Рәхмәти шул елларда чыгарган «Туплан» газетасы һ.б. газеталар да шул җирлектә барлыкка килгән.

Ризаэтдин Фәхретдин

«Вакыт» матбагасында беренче китап

Мөхтәрәм Мөхәммәдшакир вә Мөхәммәдзакир әфәнделәр!

Бүген «Вакыт» җәридәсе вә «Шура» мәҗәлләсенә махсус бер матбага тәэсис вә кәшшад итмәкдәсеңез. Матбагаңызың ватанымызда, әүляде милләт арасында голум вә мәгарифең интишарына хадим уларак, озын мөддәтләр дәвам итүене Җәнабе Хактан тәмәнни идәрем. Тәэлиф итмеш улдыгым бу әсәремне дә, йауме кәшшаденә бер ядкәр улмак үзрә, матбагаңыза тәкъдим идәрем.

Зөлкагъдә 25, сәнә 1326.
Декабрь 4, сәнә 1908.
Оренбург.

җәридә – газета
мәҗәллә – журнал
тәэсис – оештыру
кәшшад – ачу
әүляде милләт – милләт балалары, әһәле
голум – гыйлемнәр
интишар – таралу
хадим уларак – хезмәтче буларак
мөддәт – вакыт
тәмәнни идәрем – телим
тәэлиф – иҗат
улдыгым – булган
йауме кәшшад – ачылу көне
үзрә – өчен


وَمَا اَرْسَلْنَاكَ اِلَّا رَحْمَةً لِلْعَالَمِينَ

محمد

فخر كائنات افندمز رسول اكرم صلى الله عليه وسلم حضرتلرينك
مبارك شجره‌سى، نسل ونسبلرى و بعض احوالى يازلمش بر رساله‌در

اثر:

رضاء الدين بن فخر الدين

«وقت» مطبعه‌سى آچلديغنده باشلاب باصلمش برنچى اثردر.
سنه ۱۹۰۹ ينوار

Фәхреддин Ризаэддин. Мөхәммәд галәйһиссәлам: Фәхре кяинат әфәндемез рәсүле әкрәм саллаллаһу галәйһи вәсәлләм хәзрәтләрнең мөбарәк шәҗәрәсе, нәсел вә нәсәбләре вә бәгъзе әхвале язылмыш бер рисаләдер, «Вакыт» матбагасы ачылдыгында башлап беренче әсәрдер – Оренбург: Вакыт, 1909. – Б.3.

Җәүдәт Миңнуллин

Рәмиевләрнең алтын приискалары

Дәрдемәнд... Бу исемне ишетүгә күз алдына мәгърур кыяфәтле, Г.Ибраһимов сүзләре белән әйткәндә, «корыч кебек өслүбле» шигърият шоңкары килеп баса. Күп тапкырлар матбугатта дөнья күргән фоторәсеменнән тыныч, искечәрәк әйткәндә, солтанатлы Шагыйрь карап тора. Әдәбият тарихы белән азмы-күпме таныш булган һәр татар Дәрдемәндне беренче чиратта шагыйрь буларак белә. Һәм бу шулай булырга тиеш тә. Чөнки ул иң беренче чиратта шагыйрь, классик шагыйрь. Әдәбият гыйлемендә дә ул асылда шушы яссылыкта өйрәнелгән дип әйтергә мөмкин. Әмма шагыйрьнең тормышы, 1917 елларда бөтен дөньяны бутап ташлаган вакыйгалар шаһиты булган шагыйрь язмышы, күпкә бай һәм катлаулырак.

Әдәбиятта Дәрдемәнд турында шундый бер фикер урнашкан. Янәсе ул күбрәк вакытын кешеләр белән артык аралашмыйча үзенең кабинетында китапка күмелеп укып-язып кына уздырган. Һәрхәлдә З.Бәширинең истәлекләрендә шуңа басым ясала.

Шулай да бу фикер чынбарлыкка ни дәрәҗәдә туры килә? Кыскасы, Дәрдемәнднең иҗтимагый-сәяси позициясе, хәйриячелек һәм, гомумән, иҗтимагый эшчәнлеге хәзергә кадәр юньләп тикшерелмәгән. Лирон ага Хәмидуллинның 1990 елда дөнья күргән «Офыктагы рәшәләр» исемле тарихи повесте бу бушлыкны берникадәр тутыруга булышса да, тикшерәсе мәсьәләләр күп әле. Мәсәлән, Дәрдемәнд заманының күренекле эшкуары да булган һәм бу хакта әдәбиятта әлегә кадәр

мәгълүматлар бик аз. Бу уңайдан халык шагыйре Г.Тукайның 1908 елларда язылган мәгълүм юллары искә төшә:

> Безнең урам аркылы ага суның салкыны;
> Тарта Казанның яшьләрен Рәмиевләр алтыны.

Каян килгән ул алтын? Нинди алтын, кайларда табылган? Бу эштә Дәрдемәнд һәм абыйсы Шакирның өлеше нинди? Бу һәм башка күп кенә сорауларга әдәбият һәм тарих фәнендә төпле җавап бирелмәгән әле.

Соңгы елларга кадәр тикшеренүчеләр игътибарыннан читтә калып килгән чыганаклар* классик әдибебез тормышының һәм гомумән Рәмиевләр гаиләсенең алтын казыту өлкәсендәге эшчәнлекләрен яктыртуга кайбер яңалыклар өстиләр.

Мәгълүм булганча, алтын казу эшен аларның әтиләре Мөхәммәдсадыйк XIX йөзнең 60 елларында башлап җибәрә. Эшне оста оештыруымы, әллә тиз арада алтынлы катламга юлыгуы беләнме ул чагыштырмача тиз тернәкләнеп китә. Ул вафат булганда ике улына берничә алтын приискасы мирас булып кала. Уллары да «алма агачыннан ерак төшми» дигәндәй, әтиләренә охшаган, мирас малын кайберәүләр кебек җилгә очырмыйлар, киресенчә, эшне киңәйткәннән-киңәйтә баралар. Шунысы игътибарга лаек, Рәмиевләр фирмасын тикшергән тау инженеры аларда бухгалтериянең үрнәк тәртиптә алып барылуын билгеләп узган. Эшләренең уңышлы баруында ике кардәш арасындагы чын туганлык хисләре генә түгел, самими дуслык урнашуы да зур роль уйнаганын ассызыклап үтәргә кирәк.

Рәмиевләрнең алтын приискаларын характерлаучы мәгълүматларга күчкәнче шуны искәртеп үтү тиеш: киләчәктә тикшеренүләргә уңайлырак булсын өчен таблицаларда приискаларның исемнәре русча калдырылды һәм тау эшләренә караган кайбер терминнар һәм аларның кыскартылмалары, татарча эквивалентлары урнашып җитмәгәнгә күрә, шулай

* Карагыз: Список золото- и платино-промышленных фирм в России. – СПб., 1906, с.259-263.

ук русча бирелде. Мәсәлән, рз. – рассыпное, жл. – жильное, држ. – дражное, п. – пуд, ф. – фунт, з. – золотник.

Мөхәммәдшакир Рәмиевнең фирмасы рәсми рәвештә 1868 елда эшли башлый. Аның милкендәге һәм исемендәге алтын приискалары Урал тау өлкәсенең Верхнеуральск, Оренбург һәм Миасс тау округында урнашкан була. Верхнеуральск тау округында 1902-1904 елларда түбәндәге приискалар эшләп килгән:

Приискаларның исеме	Нинди алтын	1902			1903			1904		
		п.	ф.	з.	п.	ф.	з.	п.	ф.	з.
Азиатский	рз.	-	25	19	-	21	34	-	8	22
Араратский	««	1	3	48	-	18	56	-	39	83
Балканский	««	-	10	95	-	6	17	1	5	38
Благословенный	««	1	6	83	-	30	7	-	-	55
Богатый	««	2	29	63	5	20	42	2	25	77
Бухарский	««	-	-	-	-	1	38	-	-	90
Золотой Кряж	««	-	-	-	-	-	-	-	6	8
Казанский	««	-	-	-	-	-	-	-	-	14
Каспий	««	-	-	-	-	-	-	-	-	33
Крутологский	««	-	-	-	-	-	16	-	29	42
Мидхатский	««	2	17	51	4	12	7	-	-	1
Мимоходный	««	-	-	-	-	-	53	-	-	-
Мубаряковский	««	-	-	-	-	3	12	-	-	-
Неожиданный	жл.	-	-	88	-	52	-	-	-	-
Несъеденный-Габитовский	рз.	-	-	-	-	-	-	-	1	64
Равгатский	««	-	1	11	-	-	-	-	3	58
Сахара	««	2	10	35	2	10	91	1	3	19
Смиренный	««	-	-	-	-	-	19	-	-	19
Солнечный	««	-	-	-	-	14	90	-	9	12
Соседний	««	-	-	26	-	1	88	-	-	-
Трудовой	««	-	17	22	-	33	66	-	8	34

Хадыевский	««	-	1	15	-	-	29	2	-	28
Хивинский	««	-	2	93	-	14	38	-	-	-
Храбрый	««	-	14	28	-	15	8	-	-	27
Южный	««	-	-	-	-	-	-	-	-	23
Барлыгы	««	11	22	5	17	17	39	9	23	75

Эше туктатылган приискалар: Дачный, Довольный, Золотой Кряж, Китайский, Михайловский, Мубаряковский, Надневский, Несъеденный-Габитовский, Персидский, Равготский, Сартовский, Солодняка, Ханский һәм Южный. Күренә ки, кайбер приискалар Несъеденный-Габитовский, Равгатский (Равготский) исемлектә ике тапкыр теркәлгән.

Оренбург тау округында исә түбәндәге приискаларда алтын чыгарылган:

Приискаларның исеме	Нинди алтын	1902			1903			1904		
		п.	ф.	з.	п.	ф.	з.	п.	ф.	з.
Прииск близ Гадильшиной	рз.	2	27	71	3	-	30	2	11	33
Прииск по рр. Среднему и Малому Худолазу	««	-	8	14	-	12	48	-	6	26
Прииск в местн. трех Бурзянских волостей	««	-	2	21	-	-	-	-	-	-
Местность по системе р. Султанки	««	6	4	59	2	17	33	-	34	53
От грани Больш. Худолаза	««	-	-	-	-	4	7	-	8	74
Барлыгы	рз.	9	2	69	5	34	22	3	20	90

Түбәндәге прииска Миасс тау округында урнашкан:

Приискаларның исеме	Нинди алтын	1902			1903			1904		
		п.	ф.	з.	п.	ф.	з.	п.	ф.	з.
Александровский	рз.	-	-	-	-	-	25	-	-	-
Барлыгы	рз.	20	24	74	23	11	86	13	4	69

Эшләми торган прииск – Владимирский.

Бу саналган приискаларның эше белән Оренбург губернасындагы Верхнеуральск шәһәре тирәсендәге Балкан приискасында яшәгән управляющий Мөхәммәдхарис Бикмөхәммәд улы Габитов идарә иткән.

Шакир Рәмиевнең хатыны Бибигәүһәр Исмәгыйль кызы исемендәге фирма 1896 елның 3 гыйнварында эшли башлаган. Урал тау өлкәсенең Верхнеуральск тау округында бу фирманың түбәндәге приискалары булган:

Приискаларның исеме	Нинди алтын	1902			1903			1904		
		п.	ф.	з.	п.	ф.	з.	п.	ф.	з.
Гористый	рз.	-	-	-	-	-	37	-	-	-
Лесной	««	-	-	-	-	-	-	-	17	90
Фуадский	««	-	1	-	-	2	-	-	10	63
Барлыгы	рз.	-	1	-	-	2	37	-	28	57

Бу приискаларда да шул ук Мөхәммәдхарис Бикмөхәммәд улы Габитов хезмәт иткән.

Мөхәммәдзакир Рәмиев, ягъни Дәрдемәнд милкендәге фирмага 1870 елның 1 гыйнварында нигез салынган. Урал тау өлкәсенең Верхнеуральск һәм Оренбург тау округы территориясендә эш алып барган бу фирмага түбәндәге приискалар кергән.

Верхнеуральск тау округында:

Приискаларның исеме	Нинди алтын	1902			1903			1904		
		п.	ф.	з.	п.	ф.	з.	п.	ф.	з.
Галеевский	рз.	-	-	-	-	-	-	-	12	40
Гарифский	««	-	-	12	1	32	31	4	10	24
Искандеровский	««	7	5	4	3	16	5	4	10	24
Куянтавский	««	-	16	6	-	13	25	-	5	91
Магденбарский	««	-	-	-	-	-	-	-	-	59
Муратовский	««	-	-	-	-	-	17	-	20	92
Незавидный	««	-	-	-	-	-	60	-	9	43
Симеоно-Верхотурский	««	-	-	-	-	-	-	-	-	94
Барлыгы	рз.	7	21	22	5	22	42	6	1	65

Эше туктатылган приискалар: Александровский, Заширотный, Крестовоздвиженский, Нагорный, Неважный, Петровский һәм Тогузакский.

Оренбург тау округында:

Приискаларның исеме	Нинди алтын	1902			1903			1904		
		п.	ф.	з.	п.	ф.	з.	п.	ф.	з.
Владимирский	рз.	-	-	-	-	-	61	-	3	-
Дашкинский	««	-	-	-	-	9	87	-	1	-
Ломоносовский	жл.	-	-	-	-	6	9	-	-	-
Итого		-	-	-	-	16	61	-	4	-
Барлыгы		7	21	22	5	39	7	6	5	65

Эше туктатылган приискалар: Андреевский, Безимянный, Валерин, Веселый, Евгениевский, Елизаветинский, Золотой, Иоанно-Крестительский, Казанский, Неожиданный, Нечаянный, Никольский, Ольгинский, Петербургский, Пограничный, Сунарский һәм Цареградский.

Оренбург губернасы Верхнеуральск өязендәге Искәндәр приискасында яшәүче Гайнелислам Әбубәкер улы Дашкин Дәрдемәнд фирмасында управляющий булып торган.

Дәрдемәнднең хәләл җефете Мәһүбҗамал Рәмиева милкендәге фирма 1896 елның 3 гыйнварында теркәлгән. Фирманың приискалары шул ук территориядә, ягъни Урал тау өлкәсенең Верхнеуральск һәм Оренбург тау округларында урнашкан. Камалетдин Нургата улы Әдһәмов (Адигамов) управляющий булып хезмәт иткән.

Верхнеуральск тау округында:

Приискаларның исеме	Нинди алтын	1902			1903			1904		
		п.	ф.	з.	п.	ф.	з.	п.	ф.	з.
Златорудный	рз.	-	13	-	-	27	56	-	11	51
Пекинский	««	-	-	-	-	13	30	-	11	77
Барлыгы	рз.	-	13	-	1	-	86	-	23	32

Казанский, Небогатый һәм Оренбург тау округындагы Сувундукский (Сөендек) приискаларында эш туктатылган була.

Шулай итеп, Шакир һәм Закир Рәмиевләр үзләренең хәләл җефетләре исеменә берәр фирманы бер үк көндә – 1896 елның 3 гыйнварында теркәткәннәр.

Югарыда санап үтелгәннәрдән тыш, Мөхәммәдшакир Рәмиев Ситдыйк Йосыф улы Мортазин белән бергә 1896 елның 19 февралендә ачылган фирмага да ия булган. Мөхәммәдҗан Хәсәнев исә управляющий вазифасын башкарган. Урал тау өлкәсе Верхнеуральск тау округында фирма түбәндәге приискаларда алтын казыткан:

Приискаларның исеме	Нинди алтын	1902			1903			1904		
		п.	ф.	з.	п.	ф.	з.	п.	ф.	з.
Араратский	рз.	1	4	-	-	-	-	-	-	-
Ачебутакский	««	-	1	88	-	-	-	-	2	10
Успенский	««	-	-	-	-	-	-	-	-	4
Хасяновский	««	-	24	68	-	27	45	-	11	22
Шафиковский	««	1	3	78	-	27	59	-	8	2
Барлыгы	рз.	2	34	42	1	15	8	-	21	38

Фирманың Антынбарский приискасында бу елларда эш туктатылган була. 1891 елның 2 апрелендә кул куелган килешү нигезендә Мөхәммәдзакир (Дәрдемәнд), Мөхәммәдшакир Рәмиевләр һәм Мөхәммәдлатыйф Әбүбәкерев тагын бер фирмага хуҗа булганнар. Бу фирманың управляющие – Шашбәк Әбүбәкер улы Дамкин (Дашкин булырга тиеш – *Җ.М.*). Бу фирманың приискалары да шул ук Верхнеуральск тау округында урнашкан.

Приискаларның исеме	Нинди алтын	1902			1903			1904		
		п.	ф.	з.	п.	ф.	з.	п.	ф.	з.
Аргайлинский	рз.	-	3	48	-	6	45	-	-	-
Благополучный	««	-	1	76	3	36	15	1	2	69
Магденбарский	««	-	-	-	-	-	-	-	1	42
Прииск по р. Куртмак	««	-	3	10	-	-	-	-	-	-
Счастливый	««	-	-	-	-	-	-	-	-	10
Барлыгы	рз.	-	8	38	4	2	60	1	4	25

Добрый приискасы эше туктатылганнардан исәпләнгән.

Шулай итеп, XX йөз башында, төгәлрәге, 1902-1904 елларда, Рәмиевләр гаиләсе кулында җәмгысы 79 прииска бул-

ган, шуларның 42 се ябылган. Моннан тыш алар М.Әбүбәкерев һәм С.Мортазин белән бергәләп уртакка эшләүче тагын 12 приискага өлешчә хуҗа булганнар.

Югарыда аталган приискаларда тупланган алтын һәм, гомумән, мал-мөлкәт нәрсәгә сарыф ителгән? Мәһабәт йортлар салдыру, яхшы атлар җиктерү, бал-май эчендә йөзү өченме, әллә башка максатларгамы? Дәрдемәнд белән озак еллар таныш булган, бергә кулга-кул тотышып диярлек эшләгән һәм шагыйрьнең беренче биографларыннан исәпләнергә хаклы Фатыйх Кәримигә сүз бирик: «Артык җомарт (юмарт – *Җ.М.*) бер кеше булмаса да, ул вакыттагы ысул буенча җәмәгать, халык файдасына иганә бирүдән тартынмый. Җәмгыяте хәйриядә, рус мәктәпләрендә укучыларга һәрвакыт матди ярдәм итеп торды. Чит мәмләкәт мәктәпләрендә үз хисабыннан берничә шәкерт укытты. Ул мондый эшләрен гәзиткә язарга түгел, телгә алып сөйләргә дә яратмый иде.»* Шагыйрьнең хәйриячелек өлкәсендәге эшчәнлегенә асылда дөрес бәя бирелсә дә, Ф.Кәрими язганнарга төгәллек, тулылык җитенкерәми. Хәер, сыйнфый көрәш мәсьәләсе беренче планга куелган 20-30 елларда артыгын әйтеп тә булмагандыр.

Шакир Рәмиев XIX йөз азакларында ук Верхнеуральск төбәгендәге бер приискасында җәдиди мәктәп ачып җибәрә. Алар Казан, Оренбург, С.-Петербург, Троицк, Ялта, Уфа мөселман хәйрия җәмгыятьләренең мактаулы яки гомерлек әгъзалары булып торганнар. 1912 елның 11 маенда ачылган «Укучы мөселманнарга ярдәм өчен Оренбург җәмгыяте»н оештыручыларның берсе һәм рәисе Дәрдемәнд була. Дөрес, ул моңа хәтле үк җәмәгать эшләрендә катнаша башлый. 1899 елдан Дәрдемәнд Оренбург гыйльми архив комиссиясендә әгъза булып тора һәм урта гасырларга караган кайбер татар кульязмаларын фәнни хәрәкәткә кертеп җибәрүгә булыша. 1906 елда ул Оренбург губернасы мөселманнары тарафыннан беренче Дәүләт Думасына депутат итеп сайлана. Утырышлары С.-Петербургның Таврия сараенда узган бу дәүләт орга-

---

* Дәрдемәнд әсәрләре. – Казан, 1928, Б.17.

нында эш күрсәтергә өлгермәсә дә, Дума составында булу аның иҗтимагый-сәяси карашларына тәэсир итүе, иҗтимагый-сәяси эшчәнлек тәҗрибәсе туплауга булышлык итүе шиксез, әлбәттә.

Дәрдемәнд «Иттифак әл-мөслимин» партиясе әгъзасы була һәм 1906 елның гыйнварында С.-Петербургта узган икенче корылтайда катнаша.

Самодержавиене бәреп төшергән 1917 елгы Февраль революциясеннән соң ул сәяси эшчәнлеккә әйләнеп кайта. 1917 елның июлендә Казанда Бөтенроссия мөселманнарының икенче корылтаенда ул эчке Русия һәм Себер төрки-татарларының 22 июльдә игълан ителгән милли-мәдәни мохтариятен тормышка ашыру өчен төзелгән Милли идарәнең малия (финанс) нәзарәте әгъзалыгына кандидат итеп сайлана.

Ике бертуганның хатыннары һәм кызлары Бибигәүһәр, Мәхүбҗамал, Зәйнәп һәм Раузалар да җәмәгать эшләрендә актив катнашалар: Оренбург һәм Уфа мөселман ханымнарының хәйрия җәмгыятьләрен оештыручылар һәм аларның эшлекле әгъзалары булалар. Мәктәп-мәдрәсәләр ачып, яшь буынга белем бирүгә үзләреннән зур өлеш кертәләр.

Шагыйрь алтын казытучы эшкуарлар съездыннан Оренбург казна палатасында вәкил булып торган. 1913 елларда аның фирмасы Оренбург казак гаскәренең Гаскәри хуҗалыгына 15 365 сум 14 тиенлек дәгъвасын җайга салу өчен юрист чакырырга ризалык белдерә. 1917 елның августында Уралдагы алтын казытучы эшкуарлар съездын чакыру буенча Оештыру бюросы эшчәнлегендә дә ул актив катнаша. Кыскасы, Дәрдемәндне кабинет шагыйре дип атау хакыйкатькә хилафлык булыр иде. Ул шагыйрь дә, уңган эшкуар да, җәмәгать эшлеклесе дә.

Югарыда санап үтелгәннәр белән генә чикләнмичә, Дәрдемәнднең, һәм, гомумән, Рәмиевләр гаиләсенең иҗтимагый-сәяси һәм икътисад өлкәсендәге эшчәнлеген тәфсиллерәк өйрәнү киләчәктәге бурычларның берсе булып кала.

Ризаэтдин Фәхретдин

Мөхәммәдшакир әфәнде Рәмиев

Мөхәммәдшакир әфәнденең вафатына ошбу унбишенче мартта бер ел тула. Бүгенгә кадәр тәрҗемәи хәле язылмады. Инде аны якын күргән дуст-ишләренең арзуларына бинаән һәм дә вафатына ел тулу мөнәсәбәте белән мәрхүмнең кыскача тәрҗемәи хәлен язамыз.

Мөхәммәдшакир әфәнде Уфа губернасы, Эстәрлетамак өязе, Җиргән авылында 1857 ел март аеның бишендә вөҗүдкә килмеш. Атасы Мөхәммәдсадыйк хаҗиның туып үскән вә бабасы Габделкәрим бине Исмәгыйльнең ватаны булган бу карья Эстәрлетамак шәһәреннән бераз үрдәрәк, Ак Идел суы буендадыр. Мәрхүм биш яшенә кадәр Җиргәндә торып, 1862 нче сәнәдә атасы бөтен гаиләсе берлә Җиргәннән Оренбург губернасы, Орск өязендәге Йулык карьясенә һиҗрәт кылганнан соң, калмыш сабыйлык чаклары вә егетлек дәверенең дә бераз өлеше Йулыкта кичмештер. Йулык исә Урал тауларының Сакмар суы авышында, Бөрҗан, Төнгәвер башкортларының уртасында, моннан тәхминән 150 сәнәләр мокаддәм килеп урнашкан, ялгыз бер татар карьяседер.

арзуларына бинаән – теләкләрен
вөҗүдкә – дөньяга
карья – авыл
һиҗрәт – күчү
тәхминән – якынча
мокаддәм – элек

Тәхсыйле

Мәрхүм ибтидаи тәхсыйльне шул Йулык карьясендә алмыш. Бәгъдәһә Орск шәһәрендә дамелла Мөхәммәдгариф хәзрәт Мәгазый мәдрәсәсендә ике кыш калганнан соң, Сакмар суы буенда Муллакай авылында Габдулла бине Сәед хәзрәт хозурында укып, 1874 нче сәнәдә укудан туктамыштыр. Мәдрәсә тәхсыйле нәхү гарәби, мантыйк вә бераз гыйльме кәлямнән гыйбарәт иде. Русчаны Орск өязе, Тәмәч карьясендә авыл учителеннән хосусый сурәттә җәй айларында гына укымыш исә дә, укудан туктап тиҗарәт вә алтынчылык эшләренә үгрәнмәгә башлаганнан соң, прииска мөдирләре вә контор хадимнәре руслар булганлыктан вә прииска мөгамәләләре дә русча йөртелгәнлектән, русчаны гамәли уларак яхшы арттырмыш иде.

Торган җирләре

Яшь чакларында даимирәк торган урыны Йулык карьясе булып, 1883 нче елдан 1900 нче елга кадәр гаиләсе берлә Орск өязендә, Урал тауларының бер тармагы булган агачлыклы, агымсулары күп, матур Ирәндек таулары буенда «Солтанский» вә «Гаделшаһ» приискаларында гомер итмеш иде. 1900 нче елдан соң, җәй айларында Верхнеуральск өязендә «Балканский» приискасында, кыш айларында исә Оренбург шәһәрендә тереклек итте.

тәхсыйле – укуы

ибтидаи тәхсыйлә – башлангыч белем

бәгъдәһә – аннан соң

калганнан – торып укыганнан

нәхү гарәби – гарәп теле синтаксисы

тиҗарәт – сәүдә

үгрәнмәгә – өйрәнергә

хадим – хезмәткәр

уларак – буларак

Атасы вә анасы

Мөхәммәдшакир әфәнденең атасы Мөхәммәдсадыйк бине Габделкәрим Җиргән карьясендә торып, яшьлегеннән вафатына кадәр тиҗарәт берлә мәшгуль булмыш. Йулык карьясенә һиҗрәтеннән соң, 1869 нчы сәнәдән башлап алтын приискалары эшләтмеш. Вафатыннан берничә ел мокаддәм әдаи хаҗ кылып, 1892 сәнәсендә апрельнең 22 сендә 63 яшендә вафат итмештер. Йулык карьясе зиратында мәдфүндер.

Анасы Хәнифә Эстәрлетамак өязе, Яуш авылының Алмакай (Әлмөхәммәд) бине Ибраһим Дашков нам кешенең кызыдыр. 1825 нче ел декабрь 27 сендә туып, 1850 нче ел, 10 нчы мартта Мөхәммәдсадыйк хаҗи никахына кермеш вә 1896 сәнәсе март башында «Солтанский» приискада фәүт булып, Йулык карьясе зиратына китерелеп дәфен ителмештер. Укымышлы, гамәлле вә шәфкатьлелекләре аркасында танышлары арасында чын хөрмәт күреп гомер итмеш хатындыр.

Нәсел вә нәсәбе

Беренче бабасы Габделкәрим бине Исмәгыйль Эстәрлетамак сәүдәгәрләре сыйныфына мәнсүб. Торган урыны Җиргән карьясе. Мәгыйшәте тиҗарәт вә игенчелек. Вафаты 1851 нче сәнәдә вә кабере Җиргәндәдер. Икенче бабасы булган Исмәгыйль, бөрадәре Сәлим ахун илә берлектә Зәй суы буендагы Тайсуган карьясеннән һиҗрәт кылып Эстәрлетамакта урнашкан (Сәлим ахунның зөрияте бу көндә Эстәрлетамакта

мәдфүн – җирләнгән

нам – исемле

мәнсүб – нисбәтле

мәгыйшәт – көнкүреш гамәле

бөрадәр – ир туганы

зөрият – нәсел

күптер). Исмәгыйльнең атасы Рәхимкол бине Урман мирза бине Кабкай мирза бине Түләй мирза бине Колай мирза бине Сөләйман мирза бине Тимери мирза бине Рәми бине Ихсан бине Миргалидер. Габделкәримнән элгәреге бабаларының мәгыйшәт вә мәшгулиятләре хакында тәхкыйклы мәгълүмат юк. Ватаннары бу көндә Минзәлә өязе даирәсенә кергән Зәй суы буенда булган. Карьяләренең исеме дә мәгълүм түгел. Шәҗәрәләрендә олуг бабалары Миргалинең, шәһре Болгар хәраб булганнан соң иттибагы берлә Болгардан һиҗрәт кылып Зәй тамагында ватан тотканы зикер ителәдер.

Әхлак вә табигате

Мәрхүм Шакир әфәнде гүзәл әхлаклы вә хәлим табигатьле улып, башкаларга файда тидерү вә һәркемгә хәерхаһлык итүдән ләззәт ала; кешенең косур вә гаепләреннән бәхәс итәргә һич яратмый, ул тугърыда сүз ачылганда сүзне бик тиз кисә иде.

Шакир әфәнде табган җумарт улып, кирәк хосусый игәнәләргә вә кирәк дин вә милләт юлына гаид гомуми хәйрат урыннарына үз гомерендә күп акчалар сарыф итте һәм үзеннән соң да калдырды. Ләкин ул исем вә шөһрәт чыгарудан ләззәт алмаганга күрә, бонларның күбесе башкаларга мәгълүм булмый кала иде.

Мәрхүм Шакир әфәнденең Оренбург, Тозтүбә, Петербург, Тройски, Ялта җәмгыяте хәйрияләре кебек берничә җәмгыятьләрдә фәхри вә гомерлек әгъза булынуы, вакыты илә

тәхкыйклы – тулы
зикер ителә – әйтелә
зикер ителә – әйтелә
косур – кимчелек
табган – табигый
гаид – кагылышлы
хәйрат – хәйрия
фәхри – почетлы

Оренбург губернасындагы имам вә мөәзиннәр өчен тәгавын төзетүе, аңа баш сәрмайә итеп хәйли бик мөһим акча тәгаен итүе, бер чук мәктәп вә мәсҗид биналарына акча бирүе, ислам вә рус мәктәпләрендә үз хисабыннан шәкертләр укытуы, берничә мөхәррирләремезнең әсәрләрен нәшер итәргә иганә кылуы – бонлар барысы да аның хәйрат юлында никадәр киң куллы икәнлегене һәм дә ихтыяҗаты миллиянең һәр нәүгысенә җитешергә хәзер идекене күрсәтергә кяфидерләр.

Шакир әфәнде хуш табигатьле вә тәкәллефсез бер зат улдыгыннан, мәҗлесе гүзәл, сохбәте җиңел иде. Ул һәрвакыт һәркем илә бик самими сурәттә сөйләшә, башкаларның сүзләрен игътибар илә тыңлый. Һәркемнең фикер вә гакыйдәсенә хөрмәт илә карый, каршысындагы адәмнең әхвале рухиясен бик тиз аңлый, мохатәбләренең рухларын күтәрәчәк, күңелләренә нәшат бирәчәк сүзләр табуда аслан көчлек чикми, мәга мафиһи, үз фикренчә тугры тапкан сүз вә фикерләрен ачык әйтүдән һичвакыт тартынмый иде. Мәрхүм Шакир әфәнденең шаян дикъкать сыйфатларыннан берсе дә – андагы фикер тәшәббесенең вәсгатедер. Ул даимән яңа бер нәрсә исәпләп таба, яңа бер эшләр мәйданга китерергә фикер йө-

---

тәгавын – ярдәм, иганә

бер чук – шактый

ислам – мөселман

ихтыяҗаты миллия – милли ихтыяҗлар

нәүгысе – төрлесе

кяфидер – җитәдер

мәҗлесе – аралашуы

сохбәт – әңгәмәләшү

мохатәбләр – тыңлаучылары

нәшат – сөенеч

мәга мафиһи – шуның белән бергә

шаян дикъкать – аеруча дикъкатькә лаек

фикер тәшәббесе – тапкырлык

вәсгать – киңлек

ретә, бер эшнең даимән тәҗәддед вә ислахат юлында алга баруын тиеш таба иде. Шуның өчен дә ул вакыты илә сабын пешерергә өйрәнеп алган. Яңа ысул бер нәүгъ иләк иҗат иткән. Тире иләү ысулын ислах кылган вә, ниһаять, алтынчылык эшендә бик мөһим ислахат вөҗүдкә китерергә муаффәкъ булган.

Мәсләк вә әфкяре

Үзенең заманында татарлар арасында никадәр тәрәккый тарафдары булырга мөмкин исә, мәрхүм Шакир әфәнде һичшөбһәсез шуның иң гали ноктасында улмыштыр.

Шакир әфәнденең бундан тәмам 32 ел мокаддәм, ягъни Русия мөселманнарының таң йолдызы булган «Тәрҗеман»ның яңа нәшер ителә башлаган бер заманнарында нинди фикердә улдыгыны, ниләргә һәвәс иттегене вә ниләр эшләргә теләдегене күрү, бу сүземезнең дөреслегенә дәлил булырга яраса кирәк.

Үзенең дәст булып, түбәндә клишесы басылган хат*, мәрхүм Шакир әфәнденең бундан 32 сәнә мокаддәм, Истанбулда тәхсыйльдә булган борадәре Закир әфәндегә яздыгы мәктүбедер. Ул бу мәктүбендә, «Тәрҗемане хакыйкать»* газетасы-

---

тәҗәддед – яңару
ислахат – реформа
нәүгъ – төр
муаффәкъ булу – ирешү
гали – югары
һәвәс иттеге – һәвәс итүе
дәст – кулы белән язган
* «Шура» журналында бу мәкалә ахырында «Шакир әфәнденең бундан 32 сәнә мокаддәм язмыш мәктүбенең сурәтедер» исеме астында Ш.Рәмиевнең 1881 ел, 16 мартта язган бер хатының факсимилесе урнаштырылган (*Төз. иск.*).
тәхсыйль – укуда
* «Тәрҗемане хакыйкать» — Төркиядә нәшер ителгән газета (*Төз. иск.*).

ны фәүкыль-хидд рәхәтләнеп укыганлыгын бәйан итә. Аны һаман да җибәртергә куша, дәхи дә атналык берәр журнал вә газета сорый. Типография вә газеталар хакында мәгълүмат язарга үтенә. «Безем бу тарафта азлап-азлап кузгалып, тәгълиме мәгариф өчен чалышмакчы булалар. Хайван да тәгълимне кабил , бара-бара инсафка килерләр» ди. Әхвальне аңлатмак өчен вак-төяк китаплар вә мәҗмугалар уку зарур икәнлекне бәян итә. Фәһем алырдай әнвагъ китаптан вә гомранияте күстәрән романнардан монда күбрәк алып кайтырга куша, типография хәрефләре хакында мәгълүмат сорый, аның бәһаләрен белергә тели, алып кайту мөмкинме икәнлеген сораша. Китаплар бастырудан бәхәс итә.

Моннан утыз еллар элек язылган сүзләр мәрхүм Шакир әфәнденең башында нинди фикерләр булганлыкны күрсәтергә кяфидер. Соңра, заманнар кичдекчә милләт тәрәккый тарафына йөз тотты. Шакир әфәнденең фикер вә теләкләре дә үзенең әүвәлге алдалыгы нисбәттә заман илә бергә тәрәккый итте. Ул рус вә төрек матбугатын бик ныклап моталәга итәргә кереште. Башка милләтләрнең тәрәккый вә тәмәдден юлына керү ысулларын үземезнең милләткә татбикъ итәргә һәвәсләнде. Милләтләрнең тәмәдден вә тәрәккыйләренә иң

фәүкыль-хидд – чиктән тыш

дәхи дә – тагын да

тәгълим – өйрәтү

чалышмакчы – эшләмәкче

кабил – кабул итү, аңлау

мәҗмуга – җыентык, журнал

әнвагъ – төрле

гомраниять – тәрәккый

күстәрән – күрсәткән

кяфи – җитә

кичдекчә – кичеп

моталәга – уку

тәмәдден – мәдәнилек, цивилизация

татбикъ – куллану, файдалану

беренче васита әдәбият, матбугат икәнлегенә киткән саен аның иманы куәтләнә барды. Шуның өчен дә ул бер матбага ачып, газета-журнал чыгаруны, әдәбият вә фөнунгә гаид рисалә вә китаплар нәшер итүне үзенә иң беренче максат итеп тотты. Матбага вә матбугат хәлләрен дәхи дә якыннанрак үгрәнергә кереште.

Мәрхүм Шакир әфәнде 1899 нчы елда Яурупага сәфәр иткән вакытында да Петербургта матбага вә матбугат әхвален үгрәнүгә байтак зиһен сарыф иткән. Бораганский матбагасын вә рус матбагаларыннан һәм редакцияләреннән бәгъзеләрен кереп карап йөрегән вә ул дөнья берлән мөмкин кадәр якыннанрак танышырга тырышкан. Буңа аның шул вакыт Петербургтан бөрадәре Закир әфәндегә язган мәктүбләре шаһиттер.

Шакир әфәнде киткән саен эшкә якынлаша бара иде: мәрхүм Гыйльман ахун 1900 нче елда Оренбургта матбага ачарга һәвәсләнгәч, ул буңа матди ярдәм итеп, матбаганы ачарга сәбәп булды. Мөселман кулыннан матбагачылык хезмәте килеп-килмәгәнне бер тәҗрибә итеп күрү вә әгәр килә торган булса, аны тәдриҗән тәрәккый иттерү аның әхасс әмалләре идеке аңлашылмакта иде. Мөселманнарның да матбагачылык итүе мөмкин икәнлеге аңлашылгач, Шакир әфәнденең һәвәсе дәхи дә артты. 1902-1903 нче елларда булса кирәк, бөрадәре Закир әфәнде илә бергә татар телендә бер газета чыгарыр өчен рөхсәт сорап Петербургка мөрәҗәгать итеп тә карадылар. Фәкать ул вакытлардагы идарәнең икътизасынча мөселманнарга үз телләрендә газета чыгарырга рөхсәт алу мөм-

---

васита – арадашчы

фөнун – фән

гаид – бәйле

бәгъзе – кайбер

мәктүб – хат

тәдриҗән – әкренләп

әхасс әмалләре идеке – иң беренче максатларыннан икәнлеге

икътиза – тәртип

кин түгел диярлек дәрәҗәдә мөшкел иде. Рөхсәт бирелмәячәге аңлашылды. Шул сәбәпле эстәр-эстәмәс анлар үзләренең гаййәи хыялларын дәхи бер мөддәт кичектереп торырга мәҗбүр булдылар.

Ниһаять, Русия халкы өчен азмы-күпме якты көннәр килде. Беркадәр сулыш алырга ирек булды. Падишаһ хәзрәтләренең мәшһүр фәрмане галиләре илә әүвәлге кысынкылыклар бер дәрәҗә күтәрелеп, һәр кавемгә үз телендә матбугат вә әдәбият вөҗүдкә китерергә имкян хасил булды. Бу нигъмәттән истифадә итеп бөрадәран Рәмиевләр дә «Вакыт» газетасыны вә соңра «Шура» мәҗмугасене тәэсис иттеләр .

Мәрхүм Шакир әфәнденең фикере газета вә мәҗмугане киттекчә ислах итмәк вә тәрәккый иттермәк, мөфид әсәрләр нәшер итмәк иде. Инде бу вазыйфа аның фикер вә мәтлабларын бик газиз вә мөкаддәс саный торган бөрадәре Закир әфәндегә вә мөхтәрәм гаиләсенә калды. Мәрхүм Шакир әфәнденең нәфесен югалтырга бунларның һичберсе разый булмаячагына без бик әминмез.

Мәрхүм Шакир әфәнде бихаккыйн милләтпәрвәр вә хөббел-мәгалә тарафдары улмак илә бәрабәр, мәгарифе җәдидә

эстәр-эстәмәс – теләр-теләмәс

гаййәи хыял – хыялдагы максат

дәхи – тагын

бер мөддәт – беркадәр

вөҗүдкә китерү – булдыру

имкян – мөмкинлек

истифадә – файдалану

бөрадәран – бертуган

тәэсис итү – оештыру

киттекчә – тора-бара

мөфид – файдалы

мәтлаб – теләк

нәфес – рух

бихаккыйн – кирәгенчә

хөббел-мәгалә – олы күңеллелек

вә мәдәнияте хазирәнең бик зиядә тәкъдир итүчеләрдән иде. Шакир әфәнде үзе бай, миллионер вә алтыннар эчендә яшәүче бер зат булса да, байлыкны акча вә алтында гына дип белми, алтын шикелле үк кыйммәтле булган инсаният, гыйлем вә фикер байлыгыны да тәмам чын мәгънәсе илә тәкъдир итә иде. Шакир әфәнде бихаккыйн яшәде вә үзеннән соң мәңгелек яхшы исем калдырды. Бәхтиярдыр мондый кешеләр!

(«Шура» журналы.-1913.-№6.-Б.186 –188.)

хөббел-мәгалә – олы күңеллелек

мәдәнияте хазирә – замана цивилизациясенең

зиядә – күп

инсаният – кешелеклелек

бәхтияр – бәхетле

Фатыйх Кәрими

Дәрдемәнд

Идел буе татарларының әдәбият дөньясында үзенең тирән мәгънәле матур шигырьләре белән танылган Дәрдемәнд – Закир Садыйк улы Рәмиев Оренбург губернасы, Эстәрлетамак өязе, Җиргән авылында 1859 елда дөньяга килгән. Балалык вакыты шунда үткән. Үзеннән ике яшь чамасы зур булган туганы Шакир белән икесе бергә шул ук Оренбург губернасы Орск өязе Муллакай авылында мөдәррис Габдулла Сәед угылының мәдрәсәсендә укыганнар. Ул вакытларда укыла торган гарәп теленең сарыф, нәхүен үткәч, башка дәресләрне дәвам итеп, «Шәрхе гакаид»кә кадәр җиткәннәр. Мәдрәсәдән чыккач, Закир Рәмиев Истанбулга барып, ике ел чамасында булса кирәк, торган. Ул анда билгеле бер мәктәпкә кермичә, хосусый рәвештә төрек теле вә әдәбияты өйрәнгән. Шагыйрьләр, әдипләр белән катнашкан. Соңра Русиягә кайтып, язу вә тәрҗемәләр белән шөгыльләнә башлаган.

Шул ук вакытларда ул шигырь белән дә шөгыльләнгән булса кирәк. «Каргалының Сибгатулла хаҗига мәктүб» исеме белән «госманлы ләһҗәсендә» 1884 елда Юлык авылыннан язган бер шигыре шуны күрсәтә.

Аның русча өйрәнүе кай вакытларда булгандыр, һәрхәлдә ул русчаны мәктәптә, школада укымаган, хосусый рәвештә генә өйрәнгән. Ул вакытларда рус теле өязләрдә, авылларда хәзерге шикелле нык таралмаган, русча өйрәнүнең юллары да хәзерге шикелле җиңел булмаган, хәтта русча телгә төрле җирәнү, дошманлык күзе белән каралган. Шулай була торып та, Закир Рәмиев үзлегеннән русча телне сарыф, нәхүләре белән, дөрес язарлык, дөрес сөйләрлек, яхшы укып аңларлык өйрәнеп алган.

Кайбер кешеләр яшь вакытларында русчаны яки башка чит телләрне өйрәнәләр дә, әгәр тормышлары шуңар баглы булмаса, аннан файдаланмыйлар, ул телләрне әкренләп оныталар. Закир Рәмиев исә яшьлегендә өйрәнгән төрекчә, русча телләрне генә түгел, хәтта мәдрәсәләрдә начар гына өйрәтелә торган гарәп телен дә онытмаган, бәлки күп мәртәбә алга җибәргән. Төрекчә, русча телләрдә язылган әсәрләрне укып торган, төрек, рус матбугаты дөньясындагы яңалыкларны эзәрләп, әдәбият вә матбугат дөньясындагы кешеләр, фикерләр, мәсләкләр белән таныш булып барган.

Ул Шәрык дөньясындагы Газзали, Фәхерразый, Ибне Рөшд, Гомәр Хәййам, Сәгъди, Нәваи, Фөзули, Габделхак Хәмит, Әкрам, Тәүфикъ Риза, Габдулла Җәүдәтләр белән таныш булган шикелле, Гареб дөньясындагы Гегель, Кант, Вольтер, Лютер, Шиллер, Гейне, Дарвин, Спенсер, Толстой, Горький, Пушкин вә башкалар белән дә бик төпле генә таныш иде. Шул дәрәҗә таныш ки, шундый кешеләрнең фикер вә мәсләкләре турында аның белән сөйләшеп утырганда үзеңнең ялгышыңны күрсәтмәс өчен байтак сакланып, исәпләп сөйләргә туры килә иде.

Боларны язудан максат – шундый бер кешедән ничек итеп өметсез (пессимист), моңсу шагыйрь Дәрдемәнд килеп чыгуын өйрәнүгә юл ачудыр.

Дәрдемәнд – алтынчы

Үзенең искиткеч нечкә тойгылы, тирән мәгънәле шигырьләре белән танылган шагыйрь Дәрдемәнд Урал тауларында алтын казытучы бер промышленник, яхшы ук бай бер капиталист иде. Мәдрәсәдә укыган, Истанбулга барып әдәбият, шигырь белән шөгыльләнгән, шул якларга күңел куйган кеше ничек итеп алтынчы булып китте?

Ул үзе бервакыт болай дигән иде: «Истанбулдан кайткач, үтә-биру нәрсәләр язгаладым, шигырь кебек нәрсәләр сызгаладым, боларны бастыру дәрте кузгалды. Бастырып булмый. Үземдә акча юк. Башкалар алып бастырмыйлар (ул вакытлар-

да наширләр булдымы икән?), язган нәрсәләрне кайсы кешеләргә биреп укыткаларга туры килде, язылган нәрсәләр муллалар-хәзрәтләр колагына барып керде, дингә-әхлакка җиңел караучылык белән безгә каршы сүзләр сөйләнә башлады, хәтта тәкфир итәргә дә дәртләре барлыгы сизелде. Ярлылык, мохтаҗлык белән бер нәрсә дә эшләп булмаячагына ышандым, үзең теләгәнчә сөйли, язар өчен, төшенчәңне, фикереңне акчага карап үзгәртмәү, акча бәрабәренә сатмау өчен матди яктан мөстәкыйль булу кирәклегенә канәгать хасил иттем, элек кәсеп итеп акча табыйм, шуннан соң үз күңелемдәгеν сөйләрмен, язармын, дидем».

Закир Рәмиев, элек туганы Шакир белән бергә, бәлки аталары кул астындадыр, Юлыкта, Орскидә кызыл мал белән сәүдә иткәннәр. Соңра Урал тауларында алтын казыта башлаганнар. 1917 ел революциясенә хәтле ул шул эштә булып, җәйләрен Верхнеурал, Орски өязләрендәге алтын учакларында (приискаларда) тора, кыш Оренбургка килеп яши иде.

Рәмиевләрнең алтын казыту эшләре уңышлы чыккан. Аларның егермедән артык приискалары булган. Анда яхшы йортлар салдырганнар, яхшы атлар җиккәннәр, байлыкка, рәхәткә чумганнар. Ләкин алтынчы, бай Закир Рәмиев китап сөюче, күп укучы, белемнән тәм табучы, нечкә тойгылы, моңсу шигырьләр сөйләүче «Дәрдемәнд» булып калган. Ул башта ук үзенә Дәрдемәнд (кайгылы, моңлы) дигән бер исем сайлап ала. Ахырга кадәр шул имза, шул исем белән яза. Ул моңлы, ул кайгылы – менә бу да шагыйрь Дәрдемәнднең үзенә хас сыйфатлардан берседер.

Дәрдемәнд матбугат дөньясында

Закир Рәмиев алтынчы булып баеса да, әүвәлге идеалыннан аерылмый: аның әдәбият, матбугатка һәвәсе кимеми. Ул озын кыш кичләрен карта уйнап түгел, китап, гәзит укып үткәрергә ярата. Кайда булса да, кая барса да, вакытының әдипләре, язучылары белән таныш була. «Тәрҗеман» гәзитен беренче санынннан укый башлый. Ләкин Дәрдемәнд турында

язганда, аның агасы Шакир турында да берничә сүз әйтми үтү мөмкин түгел. Чөнки Дәрдемәндкә аның зур тәэсире вә ярдәме булган.

Шакир Рәмиев тә туганы Закир төсле яшьлегендә русча телне яхшы өйрәнгән. Соңра туктаусыз китап, әдәбият укып, аны алга җибәргән. Шулай ук төрек китапларын да күп укый торган булган. Гарәпчәсе дә ярарлык кына булып, гарәп телендәге китаплар, гәзит вә журналларын да укып, яхшы аңлый иде. Гомумият белән авылда туган, авыл мәдрәсәсендә укыган, элек авылда яки кечкенә шәһәрләрдә (Юлыкта, Орскидә) сату иткән, соңра күбесенчә Урал тауларындагы приискаларында (кырда) вакыт үткәргән бу ике кешенең ул вакытларда рус телен шулай яхшы өйрәнеп алулары, аннан гыйльми, әдәби яклардан файдаланулары, төрекчә әдәбият вә матбугат белән танышулары дикъкатькә алынмаслык бер хәл түгелдер.

Шул ук Орскидә Борнаевлар, Казанда Галикәевләр, Мөэминевләр кебек, ул вакытларда күп татар сәүдәгәрләре бар иде. Бөтен гомерләре буенча русчаны дөрес сөйләргә өйрәнә алмаганнар, рус телендәге әдәбият вә матбугаттан файдалана алмаганнар, дөньяга карашлары бик тар рәвештә булып, коры бер дини фанатик булып яшәгәннәр. Әмма Шакир, Закир Рәмиевләр боларга бер дә охшамый торган кешеләр булып чыкканнар. Боларның фикерләре нык ачылган, дөньяга карашлары нык киңәйгән. Моның, әлбәттә, иҗтимагый сәбәпләре булгандыр.

Шакир туганы Закирнең гыйльми, әдәби нәрсәләр белән шөгыльләнүенә кырын карау, каршы килү бер якта торсын, ул һәрвакыт аны шуңар юнәлтеп (тәшвикъ итеп) торган. Укылган китаплар, яңа әсәрләр турында бергәләшеп мөхакәмә йөрткәннәр, «Тәрҗеман» гәзитендә кузгатылган мәсьәләләрне бергәләшеп тикшерә торган булганнар. Моннан башка алтын казыту эшенең сәнәгать, техника якларын карауны Шакир үзенең өстенә күбрәк алып, Закирнең әдәби, гыйльми якка күбрәк күңел куюына сәбәп булган.

Шушы ике туган берләшеп, 1902 елларда ук Эчке Русиядә татар телендә гәзит чыгарырга ниятләнәләр. Ләкин ул вакыттагы патша хөкүмәте моңар рөхсәт бирми. Ахырында алар бу максатларына 1906 елда ирешәләр. Шул елны Оренбургта «Вакыт» атлы гәзит, «Шура» исемендә журнал чыгара башлыйлар. Шуннан соң Дәрдемәнд матбугат, әдәбиятка бигрәк якын торып яши башлый.

Сирәк-сирәк кенә ул үзенең шигырьләрен «Шура» журналында, кайчакта «Вакыт» гәзитендә бастыра. Шул шигырьләре белән ул татар әдәбияты дөньясында таныла.

Дәрдемәнднең шигырьләре

Дәрдемәнднең шигырьләренә килгәндә, түбәндәге берничә моментка тукталып үтәргә тиеш булабыз.

1. Дәрдемәнд шигырьне әз яза, язган шигырьләрен ул тиз генә матбугатка чыгармый. Шигырь язганда сүзләрне сайлауга, җөмләләрне төзүгә, чыгышсыз тәгъбирләр, гарип тәркибләр булмауга, сүз белән тәнасиб, ойгынлык булуга вә башка шуның кебек нәрсәләргә соң дәрәҗәдә дикъкать итә.

2. Дәрдемәнд шигырьне бастыру, сатып акча табу, кешедән макталу өчен язмый. Аның язган шигырьләре һичкемнең теләве, кушуы буенча яки кайбер кешеләргә ярау, кайбер кешеләрдән ачу алу өчен түгел. Дәрдемәнд мондый сыйфатлардан бөтенләй ерак. Ул шигырьгә югары бер нәфис сәнгать дип карый, шуннан тәм таба, шуңар күрә вакыт-вакыт аның белән шөгыльләнә иде. Рәсем, музыка сөючеләрнең шул нәрсәләргә карашы ничек булса, Дәрдемәнднең шигырьгә карашы шулай иде.

3. Дәрдемәнднең яза башлаган вакытына кадәр тоткан юлы, тормышка карашы бер генә төсле: анда һичбер үзгәреш юк. Ул бер вакыт динче булып мөнәҗәт әйтми, икенче вакыт динсез булып күренми, байны мактамый, ярлыны яманламый яки моның киресен эшләми. Матур сурәтне күреп, тәмле бер исне иснәп ләззәтләнгән кеше шикелле, ул да матур сүзләрне

тезеп, тирән мәгънәләргә чумудан ләззәтләнә, аның башка нәрсәдә эше юк.

4. Дәрдемәнд шигырьләренең һәммәсендә дә баштан ахырына хәтле кызыл җеп булып сузылып барган нәрсә – моңсулык, өметсезлек, дөньяның фанилыгы, тормыш дигән нәрсәнең мәгънәсезлеге. Ул биш-ун еллар тирәсендә йөрми: ул йөз, мең, бәлки миллион елларны күз алдына китерә дә, һәммә нәрсәнең берсе артыннан икенчесе үзгәреп, бетеп барганын күрә. Ул вакыты белән дөньяга дәһшәт биргән фиргавеннәрнең, дөньяга хаким булган Сөләйманнарның, Юлий Цезарьларның ничек юк булып китүләрен, яшьлек, гыйшык, мәхәббәт дигән нәрсәләрнең нинди кыска гомерле булуларын күрә; вакыты белән һичбер бетмәслек күренгән зур дәүләтләрнең, көчле милләтләрнең җирләрендә бүгенге көндә җилләр искәнен күреп хәйран кала, киткән саен үзенең кечкенәлеген ныграк сизә дә моңлана, шуларны җырлый.

5. Дәрдемәнд һөҗү итәргә, нидән дә булса көләргә ратмый. Һөҗүви шигырь язуны ул бер мутлык итү, гөнаһ эшләү дип карый. Моны әллә кайда бер сирәк кенә эшләп куйса да, соңыннан аның вөҗданы газаплана. Хәтта соңга да калмый, шигырьнең ахырында ук үзенең күңеле яхшылык теләгәнлеген аңлатып куя. Мәсәлән, Тукайга җавап итеп язган һөҗүенең ахырында ул:

> Матур гөлләргә бул былбыл,
> Нәзакәт багына сакчы,–

дип, аның шулай булырга теләвен белдереп куя.

6. Дәрдемәнд нык милләтче. Ул аны үзенең шигырьләрендә берничә җирдә аңлата. Ләкин тар милләтче түгел. Гарби Европаның либераль, киң карашлы, киң исәпләүче милләтчесе. Ул ватанга күп әһәмият бирми: ватан бетәр, милләт калыр, дип җырлый. Чөнки ватаннары бетеп, үзләре калган дистәләрчә милләтләр аның күз алдында торалар.

Дәрдемәнд үзенең шигырьләрендә дөньяга гел фанилык күзе белән караса да, эштә андый пессимист түгел иде. Ул та-

тар теленең имлясы, сарыф, нәхүләре хакында байтак фикер йөртеп, иҗади нәрсәләр эшләде. Ул гарәп хәрефләренең басма өчен уңайсызлыгын күреп, гарәп хәрефләренең шәкелләрен үзгәртте. Бу мәсьәлә өстендә берничә еллар эшләп, шул хәрефләрнең төрле кегльдәге үрнәкләрен бастырып чыгарды. Гомумият белән сәяси, иҗтимагый эшләргә дә катнаша, ихлас күңел белән эшли иде. Беренче Дәүләт Думасына Оренбург губернасыннан әгъза булып сайланды. Икенче, өченче Дәүләт Думаларына сайлау вакытында выборщик булды. Оренбург шәһәр идарәсендә берничә еллар әгъзалык итте. Оренбургта ачылган мөселман җәмгыяте хәйриясендә, рус мәктәпләрендә укучыларга ярдәм җәмгыятендә, ачлар туйдыру, ятимнәр тәрбияләү комитетларында рәис яки эшлекле әгъза булып эшли иде.

Дәрдемәнд революция вакытында качып китмәде, бөтен гаиләсе белән Оренбургта калды. Соңра Орскигә (элекке ватаннарына) барып тордылар. Шул Орскидә торган вакытында кызы, кияве белән күрешү өчен Оренбургка килеп-киткәли торган иде. 1921 елның октябрь аенда Оренбургтан кайткан вакытта тимер юлда суык тигереп, 9 октябрьдә Орски шәһәрендә вафат булган һәм шунда дәфен ителгән. Үлгәндә яше 62 дә булган.

Дәрдемәндне бик якыннан белгән вә аның белән егерме биш ел таныш булып торган бер кеше сыйфаты белән мин аның шәхесе вә кешелеге турында берничә сүз әйтеп үтәргә тиеш табам.

Дәрдемәнднең кешелек ягы бик югары булып, ул гади татар байларына бер дә охшамый иде. Ул алдау, хәйлә, риялану, икейөзлелек итү шикелле нәрсәләргә дошман. Аның үзендә андый сыйфатлар юк. Һәр нәрсәне туры әйтергә ярата. Сүзендә, мөгамәләсендә соң дәрәҗәдә туры. Аның әйткән сүзе, биргән вәгъдәсе һәртөрле документлардан, вексельләрдән нык.

Артык юмарт кеше булмаса да, ул вакыттагы ысул буенча җәмәгать, халык файдасына иганә бирүдән тартынмый. Җәмгыяте хәйриягә, рус мәктәпләрендә укучыларга һәрвакыт

матди ярдәм итеп торды. Чит мәмләкәт мәктәпләрендә үз хисабыннан берничә шәкерт укытты. Ул мондый эшләрен гәзиткә язарга түгел, телгә алып сөйләргә дә яратмый иде.

«Вакыт» вә «Шура»га ул вакытларның Риза хәзрәт, Йосыф Акчурин, Габдрахман Фәхретдинов, Борһан Шәрәф, Җәмалетдин Вәлиди, Шәриф Камал, Кәбир Бәкер, Нургали Надиев кебек көчле гыйлем ияләре катнашуга, «Вакыт»ның буржуазный милли газеталар арасында иң киң мәсләкле бер гәзитә булуына, гәзитә вә журналның наширләре булган Шакир вә Закир Рәмиевләрнең киң караулары сәбәп булды.

«Вакыт»та хатыннарга хокук бирү тиешлек, мәдрәсәләр ислахы, татар театрын күтәреп язу шикелле нәрсәләр басылып чыкканда, муллалар вә мөтәгассыйб байлар тарафыннан наширләренә күп игътиразлар, һөҗүмнәр булса да, алар мондый турыларда гәзитәгә тәэсир итәргә тырышмыйлар, һичбер сүз әйтмиләр иде. «Вакыт»ның унике еллык дәвамында баш мөхәррирнең нашир Дәрдемәндтән ишеткән берничә тәнбиһләре булса, алар да: гәзитәгә «сарт» сүзе истигъмаль ителмәсен, «төркестанлы», «төрек», «үзбәк» сүзләре истигъмаль ителсен иде. Казакъ, башкорт кебек халыклар турында һичбер көлү, кимсетү сүзләре язылмасын иде. Хива, Бохараның ул вакытта Русиягә кушылып губернага әйләндерелү фикерләре йөри иде. Безнең гәзитә шул фикергә кушылмаса иде... кебек нәрсәләрдән гыйбарәттер.

Мәскәү, 20 декабрь, 1927 ел.
(Дәрдемәнд әсәрләре /Төз. – И.Рәми.
– Казан: Яңалиф, 1928, – Б. 8 – 18.)

БЕРТУГАН РӘМИЕВЛӘР ТУРЫНДА XX ЙӨЗ БАШЫ МАТБУГАТЫ

Мөхәммәдзакир Мөхәммәдсадыйк угылы Рәмиев*

Эстәрлетамак өязе Җиргән авылында туган, ләкин атасы Урал тауларында алтын казытмак илә мәшгуль булганлыктан Закир әфәнденең яшьлек вакыты Юлык авылында үтмештер. Хәзерендә 46 яшьләрендәдер. Мөселманча беренче белем алуы Орски өязендә Муллакай авылында Габдулла хәзрәт мәдрәсәсендәдер. Русчаны хосусый мөгаллимнәрдән өйрәнгән вә 1882 нче елларда Истанбулга китеп, бер ел микъдары калып, төгәл фәннәрне өйрәнү илә мәшгуль булган.

Кирәк мөселманча вә кирәк русча язарга һәм сөйләргә яхшы беләдер. Гүзәл генә табигате шигъриясе дә бар.

Асыл мәшгулияте Оренбург губернасында алтын казытмактан гыйбарәттер.

Кыш көннәре Оренбургта вә яз көннәре үзләренең алтын приискаларында торадыр иде.

Мөселманнарның дини идарәләре хакында проект төземәк өчен 1905 елда мөфти тарафыннан Уфада ясалган голәма вә зыялылар җәмгыятенә Закир әфәнде Рәмиев тә чакырылган иде. Шул вакыт зыялылар мөмкин мәртәбә голәма фикеренә муафыйк итеп авыр фикерләр бәйан итеп русча бер ләихә төзеделәр.

---

* Мәкаләнең теле җиңеләйтелде (*Төз. иск.*).

Шунда Закир әфәнденең фикере байтак катышкан. 1906 елда Петербургтагы гомуми мөселманнар җәмгыятенә дә Оренбург мөселманнары тарафыннан вәкил булып барды. 1906 ел февральдән башлап ошбу «Вакыт» газетасын нәшер итәргә башлады. Бу көндә өч угылы Оренбург гимназиясендә укыйлар.

Закир әфәнде гаять назик табигатьле, соң дәрәҗә намуслы вә күркәм холыклы бер зат булып, гыйлем вә мәгърифәткә бик һәвәсле, дин вә милләтенә мәхәббәтле, шуның илә бәрабәр, гаять кешелекле бер ватанпәрвәрдер.

«Русия мөселманнары иттифакы» партиясенә нисбәтле булып, сәяси мәсләге хөрриятпәрвәрлектер.

(«Вакыт» газетасы. – 1906. – 23 апрель.)

Шакир әфәнде Рәмиев*

Идарәбезгә телеграф илә хәбәр бирүләренә караганда мәрхүм Шакир әфәнде Рәмиев җәнабләре соңгы сәфәрендә Мәскәү шәһәрендә вафат итмештер. Җеназасы Оренбургка китерелеп, бүген йә иртәгә җирләнәчәк. Мәрхүм Русиядә фикере иң элек ачылмыш зыялы байлардан иде. Русиядә моннан кырык сәнә элек фикерле голәмадан Мәрҗани, Насыйри вә Баязитов кына булган заманда, фикерле байлардан ул ялгызы иде. Сөйләүләренә караганда, Русия мөселманнары эчендә иң элек мөселман мәмләкәтләреннән төрки вә гарәби китап вә газеталар алып укучы мәрхүм Шакир әфәнде булмыштыр.

Шакир әфәнде әдәбият илә берлектә фәнни китаплар да укыр иде. Хосусан, физика, химия вә механика аның яраткан фәннәре иде. Мәрхүмнең алтын эшләрендә тәрәкъкые коры бер очраклылык түгел, фән вә күп фәннәрдән хәбәрдарлык нәтиҗәсе иде. Тарту көче фәнендә мәрхүмнең үзенә махсус берничә уйлап табуы буенча ясалган машиналар үзенең мәгъдән заводында эшләмәктә иделәр. Патент илә үзенә билгеләнгән машиналары да булуын сөйлиләр.

Тәфсыйльле мәгълүмат җыелганнан соң тулы тәрҗемәи хәле «Йолдыз»ның номерларында янә бер басылыр.

(«Йолдыз» газетасы. – 1912. – 20 март.)

---

* Мәкаләнең теле җиңеләйтелде (*Төз. иск.*).

Шакир Рәмиевнең вафаты*

«Вакыт» идарәсеннән телеграф: *«Шакир Рәмиев вафат итте».*

Шушы 17 март көнне Оренбургтагы «Вакыт» газетасы идарәсеннән бирелгән бу кыска гына телеграф хәбәре идарәбезгә кайгылы бер хәбәрне ирештерде. Ул татар галәме эченнән Шакир Рәмиев кебек бер гали затның җисмән мәңгегә аерылганын белдерде.

– «Шакир Рәмиев вафат итте...» – диде.

– «Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун!..»

Бу кайгылы хәбәргә күңелебезнең бик тә көенүеннән телебезнең берни әйтергә дә хәле юк; фәкать вөҗүдемез:

– Аллаһ рухын рәхәт әйләсен! – дигән догабыз илә генә юанадыр.

Шакир Рәмиев кем иде соң?

Аның тәрҗемәи хәле бик озындыр. Без үз укучыларыбызга аның кем булганын кыскача гына итеп аңлатыйк.

Ул Оренбург губернасының Орски, Верхний Урал өязләрендә Урал таулары итәкләрендәге алтын гына торган җирләрнең (бик күп алтын приискларының) хуҗасы булып, татар галәмендә Шакир вә Закир Рәмиевләр дип мәшһүр, зур дәүләт ияләре ике бөрадәрнең зурысы иде.

Закир Рәмиев бүген дә сәламәттер, Алла аның сәламәтлеген даим әйләсен.

Мәрхүм Шакир Рәмиев бөтен гомере буенча гыйлем вә мәгариф яратучы булып, галим-голәманы сөяр вә үзе һәм үз зирәклеге вә үз сәләте илә һәр фәннән мәгълүматлы, гаять зур гакыл иясе, алдан күрер, татар галәме эчендә тиңдәшсез галим диярлек бер зат иде.

Ул – мөселманнар арасында уку, язу вә белү дигән нәрсәләрнең кадерләре беленмәгән үк заманнан, татарлар вә баш-

---

* Мәкаләнең теле җиңеләйтелде (төз.иск.).

кортлар арасына зыя, гыйлем вә мәгариф тарату юлында дәүләте илә хезмәт итә килә иде. Оренбург губернасындагы бик күп өязләрнең вә хисапсыз күп авылларның мәсҗид вә мәктәпләре — бар да аның салдырган мәсҗид вә мәктәпләредер.

Уфа, Эстәрлетамак вә Тройский калаларына иткән изгелек вә хәйраты вә Петербург җамигысенә иткән зур иганәләр – болар барысы да аны изгелек белән искә алына торган һиммәтләреннәндер. Болар өстенә ул кайда гына бер мөселман «Җәмгыяте хәйрия»се ачылырга уйланса, аңарга башлап ул әгъза була вә башлап ул ярдәмгә җитә иде. Казан вә Оренбург калаларының «Җәмгыяте хәйрия»ләрендә дә фәхри әгъза иде. Аның татар милләтенә иткән изге хезмәтләрен санаганда күптән түгел генә Оренбург «Мәдрәсәи Хөсәения»сенә гыйльме хикмәткә кирәкле нәрсәләр һәдия итеп, анда бер гыйльме хикмәт кабинасы ясап биргәнен дә санамый китеп булмый. Шул милләтенә тагы да зуррак вә күбрәк хезмәт итү максаты илә ул үзенең энесе – мөхтәрәм Закир Рәмиев белән бергә моннан биш-алты ел элек Оренбургта матбага ачып, «Вакыт» газетасын нәшер итә башлады. «Вакыт» бүген дә алтынчы ел дәвам итеп килә, дәвамы тәэмин ителгән вә Русия мөселманнарының матбугат галәмендә «Вакыт» иң зур вә алдынгы газетадыр. Шакир Рәмиев татарларның мәгариф юлына җиңелрәк керүләренә буа булып торган һәммә киртәләрне – барысын да арчып ташларга тырышып, шул җөмләдән безнең уңайсыз булган әлифбабызны да ислах максаты илә ул бөрадәре Закир Рәмиев белән бергә татар матбугаты өчен яңа хәрефләр уйлап чыгарып, аны матурлап эшләп бирде. Аның бу эше өчен Төркиядә вә бөтен ислам галәмендә мактау вә афәриннәр укылды.

Татар галәменең Шакир Рәмиев кебек гали һиммәтле, тырыш вә гакыллы бер кешедән аерылуы, аның татар галәменнән мәңгегә җисмән югалуы татар галәме өчен никадәр зур кайгы булса да, үзе бәхетле иде, бәхетле булып яшәде һәм мәңге бәхетле булып искә алыначактыр.

Үзләре өчен генә түгел, бөтен татар галәме өчен мөхтәрәм, кадерле вә сөекле булган аталарыннан аерылып калган

гаиләсен, борадәре Закир әфәнденең вә җөмлә туганнарын юатып аларга аның мәңгелек изге исеме юанырга тәүсыя илә үзебезнең матәмгә катнашыбызны белдерәбез.

Үз исемемнән хосусан вә «Идел» исеменнән гомумән
Сәгыйть Рәмиев.

(«Идел» газетасы – 1912. – 20 март.)

Зур югалту

Хөрмәтле Мөхәммәдшакир әфәнде Рәмиевнең вафаты илә эчке Русия мөселманнарының иң алгы сафындагы бер кешеләре, милләтнең уяну вә тәрәккыяте дәверенә бәйле тарихларында яхшы исеме мәңгегә калачак бер җәмәгать хадимнәре арабыздан гаиб булды. Русия мөселманнары арасында дин вә милләт юлында хәйрия вә хезмәт әһелләре азмы-күпме электән бирле булып килгән, Ходага шөкер, хәзерендә дә бар. Ләкин бармак белән санарлык дәрәҗәдә аз вә, шул сәбәпле, милләт каршында аларның кадер вә хөрмәтләре үзләренең дәрәҗәләренә мөнасыйп рәвештә бик зурдыр. Мондый адәмнәребезнең вафатлары бөтен халкыбыз өчен диярлек кайгылы вакыйгалардан саналып килде. Шулар җөмләсеннән Мөхәммәдшакир әфәнденең вафаты да милләтебез өчен зур югалтудыр.

Аның дин юлында җиткән хәйрия милләтнең уяну вә тәрәккыят юлында күрсәткән файда вә хезмәтләрен хәзер тәфсыйлән бәян итеп торуның вакыты вә урыны түгелдер. Болар вакыты белән аңлашылыр. Аның ярдәме илә салынган яки тәрбия ителмәктә булган мәчет-мәктәпләр, ислам вә рус мәктәпләрендә укып чыккан яки укымакта булган егетләр, берничә әдипләребезнең басылып таралган әсәрләре вә ошбу «Вакыт» газетасы илә «Шура» журналы мәрхүмнең кем икәнлегенә вә нинди бөек максатларга хезмәт иткәнлегенә шаһитлардыр.

Мәрхүм Мөхәммәдшакир әфәнденең башка хәйрия әһелләреннән аермасы вә иң мөһим хосусияте дә – аның әтрафлылыгыдыр. Милли хезмәттә ул аңа җитешмәгән, ул аны төшенмәгән вә исем өчен түгел, бәлки саф хезмәт итү вә башкаларга файда иттерү максаты илә аны эшләмәгән һичбер җәһәт юк иде! Ул исем-шөһрәт тантаналарыннан кача, яхшылыкларын шауламаенча гына эшләргә ярата иде.

Нәзакәт вә хөсет табигать җәһәтләренчә дә ул бик бөек бер урын тотып, һичбер вакыт һичкемнең хәтерен калдырмаска, һәркемне разый вә канәгать итәргә тырышты. Төрекчә

вә русча әдәбияттан, шигърият вә фәлсәфәдән яхшы хәбәрдар булып вә болардан бөек ләззәт алып әдәбият вә матбугатыбызны күзәтә, шуның эчендә, табигый булган зиһене вә сәләте өстенә бик киң мәгълүматы бар, мәҗлес вә әңгәмәсе гаять хуш бер зат иде. Мәрхүм кыска гомерендә күп эш эшләде. Ләкин заман вә әхваль мөмкинлек бирмәве сәбәпле тормышка ашыра алмый калган тагын да бөегрәк планнарын вә фикерләрен үзе илә бергә алып китте. Җәнабе хакның мәңгелек рәхмәтендә булса иде. Мәрхүмнең зур кайгыга дучар булган мөхтәрәм гаиләсенә вә газиз энесенә – Мөхәммәдзакир әфәндегә, барлык якыннары вә дусларына Ходайдан күркәм сабырлык теләп, хәсрәтләрен уртаклашабыз вә бөек бер тәэсир илә кайгыларын уртаклашамыз.

«Вакыт» вә «Шура» редакциясе.

(«Вакыт» газетасы. – 1912. – 23 март.)

Шакир әфәнде Рәмиевнең вафаты*

«Вакыт» идарәсеннән Шакир әфәнде Рәмиевнең вафаты хакында ошбу телеграмны бирәләр:

«Чәршәнбе көн 21 нче мартта Оренбургта «Вакыт» газетасы илә «Шура» журналының наширләреннән Шакир әфәнде ибне Мөхәммәдсадыйк Рәмиев җирләнде.

Шакир әфәнде соңгы заманнарда неврастения хасталыгы илә авырый иде. Авыруыннан дәвалау өчен аны Мәскәүгә җибәргәннәр иде. Янында энесе, хатыны һәм берничә карендәшләре бар иде. Юлда барганда Шакир әфәнде Мәскәүгә җитәр алдыннан «Воскресенский» станциясе янында ялгышлык илә поездан егылып төшеп вафат булды. Җәсәде Оренбургка кайтарылып, Оренбургның яңа зиратына дәфен ителде. Җеназасына Оренбург шәһәренең һәм Каргалы бистәсенең бөтен имамнары илә бик күп халык катнашкан иде».

(«Йолдыз» газетасы. – 1912. – 25 март.)

---

* Мәкаләнең теле җиңеләйтелде (*Төз. иск.*).

Фатыйх Кәрими

Кем иде Шакир әфәнде?*

(Мәрхүмне искә төшерү)

Аны «алтынчы» диләр, «миллионер» диләр иде. Әмма миңа калса, мин аны гыйлемле, игелекле, кешелекле дип кенә атар идем һәм шулай дип кенә беләм. Минем аның белән танышуыма 13 ел булган. Беренче мәртәбә мин аны 1899 нчы ел, 7 февральдә Оренбургта күрдем. Шуннан бирле без аның илә бик күп күрештек. Һәр нәрсәдән бәхәс иттек. Әмма һичбер вакыт мин аннан үзенең алтынчы икәнен белдерә, байлыгын аңлата вә шуларга бер әһәмият бирә торган бер сүз булсын – ишетмәдем. Ул әдәбияттан бәхәс итәргә бик ярата, яңа чыккан китапларны һич калдырмый диярлек, укып килә, яшь әдип вә шагыйрьләребезнең әсәрләрен укып чыгып, алар хакында фикер алышудан бик ләззәт ала; Толстой, Кант, Ницшеләрнең фәлсәфәләреннән, аларның тормышка карашларыннан бәхәс итә, аларның тормышка фикерләрен Мөхеддин Гарәбиләр, Газалиларныкы илә чагыштырып карый; фикер үсеше вә һәртөрле яңалыклардан бәхәс итә, дин ислахына караган киң бәхәсләргә керешә, Яуропа вә Азия мәдәниятләреннән, техниканың тәрәккыйсеннән, кыскасы, һәр нәрсәдән бик рәхәтләнеп сөйләшә, бик нигезле фикерләр бәйан итә, башкаларныкын бик сөеп тыңлый, әмма һичбер вакыт үзенең алтынчылыгын, үзенең байлыгын, үзенең бер нәрсә эшләгәнлеген яки эшләячәген искә төшерми иде. Мин аның визит карточкаларында һичбер вакыт «золотопромышленник» (алтынчы) дип язылган сүз күрмәдем. Чит кешеләр берлән танышкан вакытында үзен шулай дип тәкъдим иткәнен ишетмәдем, менә шуның өчен дә мин аңа «алтынчы» димим, гыйлем иясе, изге җан димен. Ул алтын өчен яшәмәде. Алтынны зур максатларга ирешү өчен корал дип белде һәм шуңа кулланды.

* Мәкаләнең теле җиңеләйтелде (*Төз. иск.*).

Моннан тәмам унөч ел элек, ошбу мартның унында иде, мәрхүм Шакир әфәнде илә берлектә Берлинның «Парезерплац» исемле мәйданы янындагы «Бранденбург капкасы»ннан чыктык. «Пьер Гартен» исемле бакча янына бардык. Кышның тәэсире һаман бетеп җитмәгән, агачлар яфрак ярмаган, яңа бөреләнә башлаганнар иде. Бакчаның мәйданга караган ягында рәттән гүзәл мәрмәр һәйкәлләр тезелеп киткән. Арба илә акрын гына шулар яныннан үтеп барганда нимес шагыйрьләреннән мәшһүр Гётеның һәйкәле тугрысына җиткәч Шакир әфәнде арбаны туктатты. «Шуның каршысындагы эскәмиягә төшеп утырыйк әле», – диде. Утырдык. Шакир әфәнде Гётеның мәрмәр һәйкәленә бераз вакыт карап торды. Дәшмәде. «Ни исәпләдегез, Шакир әфәнде?» – дидем.

«Үлем,үлем, диләр, Фатыйх әфәнде, ләкин бу сүз бик төрле мәгънәдә бит, кайбер кешеләр дөньяда яшиләр, үләләр, аларның исемнәре бөтенләй онытыла да китә, әмма кайберләре үлгәннән соң тагын да ныграк яшәргә башлыйлар, менә бу кешенең исеме хәзер бөтен мәдәният дөньясына мәгълүм, моның әсәрләрен Яуропаның мәктәп балаларына кадәр беләләр, моның исемен 60 миллион нимес халкы изгеләштерә. Менә бу һәйкәл хозурына килеп, һәрбер мәдәниятле кеше сәлам бирә вә күңелендә әллә нинди хисләр уяна, моны ничек итеп үлгән дияргә кирәк, диде».

Шушы рухта байтак сөйләшеп утырдык. Белмим, ни өчендер, Шакир әфәнде бу һәйкәл янында хыялый, мөтәәссир булды. Зиһенен байтак еракларга җибәреп, кеше ялгыз үзе өчен генә яшәсә дә, аның тормышы да, үлеме дә үзе берлә бетүен, хакыйкый яшәешнең гомум өчен вә гомум илә бергә яшәүдән гыйбарәт икәнлеген, ул вакыт кешенең җәсәде бу дөньядан күчсә дә, исеме мәңгегә калып тормышы һаман дәвам итүен сөйләде, вә шундый кешеләр бәхтияр диде.

Шакир әфәнде пессимист-мәэюслардән түгел, киләчәктән өметле, тормышка тәмам тулы мәгънәсе илә карый, теләгән тәкъдирдә, бик түбән кешеләрнең дә бик югары китә алырына тәмам ышана иде.

Шакир әфәнде илә Петербург Фәннәр академиясе бинасындагы Азиатский музейга бардык. Бераз карагач, көтепханәсенә кердек. Китаплар каталогын сорап алдык. Кулъязма каталог китереп бирделәр, басылган юк, диделәр. Укый башладык, һич ишетелмәгән, күрелмәгән ят мөселман китап исемнәре тулып ята. Боларны күргәч, Шакир әфәнденең күзе кызды: «Тукта әле, Фатыйх әфәнде, мин болардан берничәсенең исемнәрен язып алыйм, – диде». Яза башлады. Ләкин рәттән диярлек язып барырга туры килә. Чөнки тарих, шигърият, сәяхәт, әдәбият вә башкаларга караган әллә никадәр әсәрләр бар. Шакир әфәнде боларның барысының да исемнәрен вә авторларын кемнәр икәнлеген язып аласы килә. Язып алуга мөдиреннән рөхсәт сорадык. Бирде. Мин дә язышырга тотындым, ләкин кая ул, һич бетәрлек түгел. Ул көн музейханә ябылганчы шунда тордык. Шакир әфәнде шул көтепханәне тәмам ләззәт алып карады, актарды. Ләкин моның илә генә канәгатьләнмәде. Иртәгесен янәдән шунда барып утырдык. Шакир әфәнде тагын карады, тагын язып алды. Менә шуның өчен дә мин аны алтынчы димимен, гыйлем иясе, игелекле зат, әдәбиятчы димен. Ләкин аны китап вә әдәбият сөюче генә дию дә дөрес түгелдер. Германиянең Бохем шәһәрендә Артур Купалның локомобиль вә металл эшләү машиналары ясый торган фабрикасын һәм шул машиналар илә эшләнә торган, шул шәһәр янындагы җир күмере учакларын карап йөргән вакыттагы аның дикъкать вә һәвәсе дә Азиатский музейны карап йөргән вакытындагы һәвәсеннән ким түгел, бәлки артык иде.

Машина фабрикасын күрсәтеп йөрүче инженер Шакир әфәнденең техникадан бик яхшы хәбәрдар икәнлеген шунда ук сизеп алды. Аның биргән сорауларына каршы җавапларны бик сөенеп сөйли башлады. Чөнки каршысындагы кешенең боларның нечкәлекләрен аеруына ышана иде. Чынлыкта Шакир әфәнде алтын чыгару вә юу эшендә күп яңалык вә үзгәрешләр кертеп, кайбер ачышларына алган хокукы да бардыр. Соң вакытларда паровой машиналарны ягып җылытуны яңартуга караган, ягъни ягылачак нәрсәне аз кулланырга вә

җылылыкны әрәм итмәенчә, аннан күбрәк файдаланырга чаралар эзләү илә мәшгуль һәм бу хосуста күп уңышы барлыгы да мәгълүм иде.

Ихтимал ки, соң көннәрдән Шакир әфәндене нерв вә рухына төшкән хасталыгына сәбәп тә үзенең зиһен көче вә бик куәтле булган баш мие эшчәнлеге булмыштыр. Аның зиһен вә фикере бер җиргә юнәлсә, аны бөтен тәфсыйләте илә колачлый, ул мәсьәләне үтәп чыгарга тырыша иде. Бу, әлбәттә, нервларга зур тәэсир итәдер.

Шакир әфәнденең нәзакәт вә әхлагы бик сирәк очрый торган дәрәҗәдә югары иде. Унөч еллык танышлыгымда вә байтак вакытлар аның берлә бергә булган сәфәремдә мин аның сүз вә әңгәмәләрендә һичкем хакында бер каты сүз яки тупас мөгамәлә күрмәдем. Хосусан, гайбәт дигән нәрсә аның тирәсендә катгыян юк, мөмкин мәртәбә һәркемгә яхшы фикер тарафында иде. Шакир әфәнде үлде, ләкин яшәп үлде. Дусларының вә үзен хөрмәт иткән кешеләрнең күңелләрен юатачак яхшы исем, изге гамәлләр калдырып үлде. Яшьләй үлүенә бик хәсрәтлебез. Фәкать, гүзәл хатирәсен күңелләрдә мәңгегә сакланачак яхшы исеме, яхшы гамәлләре илә кайгырабыз.

Җисемең арабыздан югалды, фәкать исемең вә хатирәң безнең илә вә бездән соңгылар илә даимидер, мәңгелектер, газиз Шакир әфәнде! Кабереӊ якты, туфрагың йомшак булсын. Син шуңа лаексың. Алланың мәңгелек рәхмәтенә кавыш!

(«Вакыт» газетасы. – 1912. – 25 март.)

Кадь хаттатна лил-мәгали мөзәҗҗиган* Вә дәфинән әл-фазыл вәд-дөнья мәга

Мөхәммәтшакир әфәнде илә булган мәҗлесләремнең иң беренчесе төрек шагыйре Галишир Нәваи хакында сөйләшмәктән гыйбарәт булып, иң ахыргысы да Ибне Гарәби хәзрәтләре хосусында булды.

Уфа шәһәрендә Телеграфный урам, Бережковский өендә торганда Мөхәммәтшакир әфәнде өебезгә килде, янымда Закир әфәнде Ишмөхәммәдев бар иде. Бер-ике минут үтәрүтмәстә ни мөнәсәбәт беләндер әмирләр шагыйре вә шагыйрьләр әмире булган Галишир хакында сүз ачылды. Шакир әфәнде бераздан соң миннән әлеге шагыйрьнең «Мөхакәмәтел-лөгатәйн» исемле әсәрен сорап алды вә шул мәҗлестә күп урыннарын укыды һәм дә ошбу әсәрдә булган кайбер кагыйдәләр хакында изах вә тәфсирләр сөйләде. Бүгенгедәй хәтеремдәдер ки, Мөхәммәтшакир әфәнде чыгып киткәннән соң Закир әфәнде: «Хәзрәт, бу адәмнең олуг байлардан икәнен ишеткән идек. Мәгәр дә, хакыйкый мәгънәсе илә әдәбият мөгаллиме булырга лаек бер адәм икән, бу хакта мин хәйран калдым!» рәвешендә бер сүз сөйләп, үзенең гаҗәпләнүен ачып салды.

Ибне Гарәби хакында сөйләшүебез Оренбургта үз йортында үзенең иң якыннары хозурында булды.

Мөхәммәтшакир әфәнде Ибне Гарәби тәрҗемәсен (биографиясен) никадәр тугры белсә, Галишир тәрҗемәсен дә шул дәрәҗәдә тугры белә иде. Галишир мәсләге илә ни дәрәҗәдә якын хәбәрдар булса, Ибне Гарәби мәсләге илә дә шул дәрәҗәдә мәгълүматлы иде. Хәтта ошбу иң соңгы мәҗлестә дә «Әл-фөсус»тан кайбер сүзләрне тәрҗемә итеп сөйләде.

* «Чынлап та, дәрәҗәле урынга яткырдык һәм аның белән олуг мәртәбәне дә күмдек» мәгънәсендә (гарәп телендәге шигырьдән өзек). Мәкаләнең теле җиңеләйтелде (төз.иск.).

Галишир Нәваи илә башланып, Ибне Гарәби илә төгәлләнгән әңгәмәләр арасындагы мәҗлесләр вә кич утырулар аз булмаса да, күбесе шулар кебек гыйльми вә әдәби нәрсәләр хакында иде. Хәзер аларны тәфсилләп язарга кодрәтебез юк.

Каберенә озатып баручылар: «Мөхәммәтшакир әфәндене дәфен иттек, Ходa рәхмәт кылсын!» – дип сөйләп кайттылар. Аллаһы Тәгалә бу догаларны кабул итсә иде, ләкин тугрысы – без Мөхәммәтшакир әфәнде каберенә яхшы холык, фәзыйләт, тәрбия вә әдәп дәфен итеп кайттык.

Аллаһы Тәгаләнең мәңгелек рәхмәте илә мөшәррәф булсын!

27 март, 1912 сәнә.
(«Шура» журналы. – 1912. – №7. – Б.224.)

Рәмиевнең үлүе мөнәсәбәте илә*

«Вакыт»ның 23 нче мартта чыккан номерында язылуына күрә, Шакир Рәмиев Мәскәүгә барганда, «Воскресенский» станциясе янында ялгыш поездддан егылып төшеп, һәлак булган икән. Моны бәгъзе рус газеталарының хәбәрчеләре үзен-үзе поезд астына ташлаган дип язганнар иде. Бу хәбәр дөрес түгелдер. Бу мөнәсәбәте илә Рәмиевнең гаиләсенә һәм «Вакыт» газетасы идарәсенә бик күп кайгы уртаклашу телеграммалары килгән. Гәрчә наширләреннән булган Шакир әфәнде Рәмиев вафат булса да, «Вакыт» газетасы әүвәлгечә дәвам итәчәктер.

(«Йолдыз» газетасы. – 1912. – 29 март.)

* Мәкаләнең теле җиңеләйтелде (*Төз. иск.*).

Шакир әфәнде Рәмиев*

«Вакыт» газетасында язылган тәфсыйлатка караганда, мәрхүм Шакир әфәнде Рәмиев җәнабләре соңгы вакытларда бер төрле гасаби вә рухи хасталык илә кәефсезләнә башлаган икән. Мәскәү табибларына күренеп киңәшкәннән соң Кырымга яки чит мәмләкәткә китеп дәвалану өчен үзенең җәмәгате Гәүһәр ханым, энесе Мөхәммәтзакир Рәмиев, баҗасы Мөхәммәтһади әфәнде Нигъмәтуллин һәм башка берничә якыннары илә мартның 13 ендә Оренбургтан сәфәргә чыккан икән. Мәскәүгә җитәр алдыннан «Воскресенский» дигән станция янында Алла тәкъдире илә бөек бер каза чыгып, Мөхәммәтшакир әфәнде поезддан егылып, 15 нче мартта өйләдән соң сәгать 2 ләрдә вафат итмештер.

Рәсми рөхсәтләр алганнан соң мәрхүмнең җеназасы 20 нче мартта Оренбурга кайтарылып, йортына китерелмештер.

21 нче мартта өйләдән соң сәгать 4 ләрдә һәммә Оренбург вә Каргалы голәмасы, бик күп шәкертләр, могътәбәр затлар, дус вә әшнәләре вә башка күп халык хозурында Оренбург шәһәренең яңа зиратына җирләнгән. (Аңа Алланың рәхмәтләре булсын!) Мәрхүмнең вафаты хәбәре мәгълүм булганнан соң, төрле тарафлардан варисларына кайгы уртаклашу хатлары вә телеграммалар** бик күп килгән. Җеназа мәрасиме хакында «Вакыт» газетасы ошбу сүзләрне яза:

---

* Мәкаләнең теле җиңеләйтелде (*Төз. иск.*).

** «Вакыт» газетасының 23 март, 5 апрель саннарында (№№ 943, 949) Казан, Оренбург, Уфа, Мәскәү, Әстерхан, Троицк, Орск, Верхнеуральск, Бакчасарай, Тозтүбә, Бохара, Баку, Екатеринослав, Бөгелмә, Бәләбәй, Одесса, Екатеринбург, Омск, Самара, Петропавловск, Хуканд, Харьков, Ростов, Алмата, Эстәрлетамак һ.б. урыннардан килгән күпсанлы кайгы уртаклашу телеграммалары һәм хатлары басылган (*Төз. иск.*).

Җеназа мәрасиме

Мәрхүм Мөхәммәдшакир әфәнде Рәмиев гомум Оренбург мөселманнары каршында бик хөрмәтле бер зат, Оренбург мөселман җәмгыятенең мактаулы әгъзасы, бөек милләтебез нигезләрен ныгытучылардан булган мәрхүм Әхмәд бай вәкыфының мөтәвәллиләреннән һәм газетабызның наширләреннән берсе булганлыгыннан, аның сәфәрдә вафат булу хәбәре Оренбургта ишетелү белән һәркемгә бик кайгылы сурәттә тәэсир итте. Хосусан, Мәскәү газеталарында аның хәбәре кайбер ялгыш гыйбарәләр илә язылуы аеруча хәсрәтне тирәнәйтте. Аның вафат хәбәре ишетелү берлән матәм йөзеннән матбага хезмәтләребез тукталып, газетабыз нәшер ителми торса да, бу кайгылы хәбәр Оренбург мөселманнарына тиз арада таралып җитеп вә һәркем хәсрәт илә бер-берсе белән кайгы уртаклашырга башладылар. Гаилә, якыннары вә дус әшнәләренең кайгыларын аңлатып булмый иде. Вафат хәбәренең дөрес булуы аңлашылу берлән Оренбургның һәммә мәчетләрендә мәрхүмнең рухына тәһлил укылып багышланды вә каза чыккан җиргә Закир әфәнде исеменә бик күп кайгы уртаклашу телеграммалары җибәрелде.

Ниһаять, мәрхүмнең җеназасы Оренбургка кайтарылып җирләнәчәге турында хәбәр алынды. Моның өчен Әхмәд бай вәкыфы мөтәвәллиләренең һәм Оренбург мөселман җәмгыяте советының махсус мәҗлесе булып, җеназаны каршылау өчен махсус әһелләр җибәрергә карар бирделәр. Мөтәвәллиләр исеменнән Хөсәен хаҗи Хөсәенев илә Ихсанбик Казаков, Оренбург мөселман җәмгыяте исеменнән Габделгазиз хәзрәт Габделкәримев Самарага барырга тәгаен ителделәр. Мәрхүмнең җеназасы кайтарылган вә җирләнгән көннәрдә «Хөсәения» мәдрәсәсендә дәресләр тукталып, мәдрәсәдә һәм мәчеттә мәрхүмнең рухына Коръән укылды һәм мәрхүмнең җеназасы кайтарылган көнне иртә берлән газетабызның идарәханәсендә, кич берлән мөселман җәмгыятенең махсус ясалган мәҗлесендә мәрхүмнең рухына Коръән укылды. Газетабызның мөхәррирләреннән Фатыйх Кәримев каршы алу өчен

Габделгазиз хәзрәт берлән 18 нче мартта кич берлән Самарага киттеләр. Мөтәвәллиләр һәйәте тарафыннан сайланган һәйәт кайбер сәбәпләр аркасында Самарага барып өлгерә алмаенча, Новосергеевкага каршы барып тордылар. Мәрхүмнең җеназасы энесе Закир әфәнде вә берничә якыннары һәм каршы барган һәйәт юлдашлыгында булган хәлдә 20 нче март, сишәмбе көн, көндез сәгать 12 ләрдә махсус вагон илә Оренбургка кайтты. Каршы алу өчен вокзалга күп халык төшкән, һәркем кайгылы вә күзләре яшьле иде. Закир әфәнде вә мәрхүмнең якыннарының кайгыларын уртаклашканнан соң җеназа зур бер ихтирам илә йортларына китерелде.

Шул көн сәгать өч ярымда өйдә Оренбург вә Каргалы хәзрәтләре тарафыннан мәрхүмнең рухына Коръән укылды.

15 мартта, мәгълүм каза чыкканнан соң, мәрхүмнең җәмәгате Гәүһәр ханымның бу кайгыны күтәрә алуы бик мөшкил булачагы аңлашылуыннан җеназаны күчерү мәсьәләсе хәл ителгәнгә кадәр, якыннарының киңәше илә, аның Петербургка кызы Камилә ханым Максутова янына барып кайтуы һәм аны да кадәри хәл юату муафыйк күрелгәннән, үзенең бер якыны илә Петербургка киткән икән. Ул Оренбургка шуннан килде. Садреддин әфәнде Максудов илә кайттылар. Ләкин аларның кайтып җитүләре чәршәмбе көн генә мөмкин булачагы хәбәр алынганлыктан җеназа бер көн кичектерелеп, алар кайтып җиткәч үтәлергә тиеш булды. Ниһаять, 21 март, чәршәнбе көн, алар да кайтып җиткәнлектән өйлә намазыннан соң җеназа беренче мәхәллә мәсҗиде ихатасына чыгарылып намаз укылды, соңра яңа зиратка илтеп җирләнде. Җеназага килүче халык бик күп иде. Мәрасим бик тәртипле үтте. Мәрхүм Мөхәммәдшакир әфәнде әле 55 яшендә генә булып, тәмам рәхәт күрер чагында дөньядан үтте. Гаилә рәисе булып калган олы угылы Сөләйман әфәнде Рәмиев Оренбургта иде. Петербург гимназиясен быел тәмамлый торган угылы Габдеррәүф әфәнде илә Бельгиянең Льеж шәһәрендә югары электрик вә техник мәктәбендә укучы угылы Әхмәдмидхәт әфәнде җеназага кайтып җитешә алмадылар. Шакир әфәнденең үзе сәламәт вакытында язып калдырган васыятьнамәсе

һәм дин вә милләт юлына калдырган беркадәр хәйраты барлыгы аңлашылды. Васый итеп угылы Сөләйман әфәндене, энесе Мөхәммәдзакир әфәнде Рәмиевне, кияүләре Мөхәммәд әфәнде Яушев һәм Садреддин әфәнде Максудовны вә приискаларындагы мөдирләре Ислам әфәнде Дашкин илә Харис әфәнде Габидовларны тәгаен итеп калдырмыштыр.

(«Йолдыз» газетасы. – 1912. – 29 март.)

васый – васыятьне тормышка ашырырга тиешле вәкил.

Борһан Шәрәф

Киңрәк нәзарлы кеше...*
(Искә төшерү)

Мәрхүм Шакир әфәндене иң элек тануым әлеге сыйфат илә булды.

Ул моннан ун ел чамасы элек Казанга сәфәрендә «мәдрәсәи Мөхәммәдия»гә кергән иде. Монда дәрес программаларын җиңелчә сорашып, мәдрәсәнең эчен дикъкать илә карап йөрде. Иң соң күрсәтелгән ашау бүлмәсенә бик игътибар илә туктап, якынча шундый бер сүз сөйләде:

«–Кешенең тереклеге ашау-эчү илә генә булганлыктан, аның рухына иң нык тәэсир итә торган нәрсәләрнең бере – ашаган нәрсәсе һәм ашау бүлмәседер. Ашау бүлмәсенең якты вә матур булуы, ашау әсбабларының чисталыгы кешенең рухына, хосусан, яшьләрнең тәрбиясенә тәэсирсез калмый. Ашау вакытында күңелнең шат булучылыгы адәмнең җанына куәт бирә, яшәүнең ләззәтен арттыра, шуңа кешене тормышка ныграк багълый, эш эшләүгә күңелен күтәрә. Ашавы ләззәтсез кешенең эше теләксез булачагы мәгълүмдер. Кайдадыр укыганым дөрес булса, японнарның мәктәп вә мәдрәсәләрендә иң әһәмият бирелгән матур бүлмә – ашау бүлмәсе була икән. Ул вакытта японнар Русиядә бик танылмаган иде әле.

Ауропада үзләрен бик тәрбия итә торган кешеләрнең музыка тавышы астында ашарга яратулары, аш сеңдерү өчен музыка тыңлаулары башта бәлки бер фәлсәфәгә нигезләнгән булса, гаҗәп түгел...»

Шакир әфәнде, шул сүзләрне сөйләп бетергәч, гомумән, мәдрәсәнең хәленнән канәгать булганлыгын, хосусый иганәләр илә генә бер мәдрәсәнең шул хәлгә килүе мөдирнең тырышлыгына дәлил кылганлыгын сөйләде дә, «мәдрәсә расходлары өчен тотарга» дип, мөдирнең кулына 500 сум тап-

---

* Мәкаләнең теле җиңеләйтелде (*Төз. иск.*).

шырды. Аннан тыш шәкертләр өчен дип биргән иганәсе (күпмелеге хәтеремдә калмаган) шәкертләрнең теләве илә көтепханә суммасына кушылган иде.

Шакир әфәнде чыгып киткәч аның хакында шәкертләр вә мөгаллимнәр арасында күп фикер алышу булды. Фикерләшүебез мәдрәсәгә килгән олуг иганә хакында түгел, бәлки Рәмиевнең онытылмаслык сүзләре хакында күбрәк иде. Чөнки шәкертләр мәдрәсәне карарга кергән бик күп сәүдәгәрләр, муллалар вә зыялылардан тырышлык, тәүфыйкъ, итагать кеби гомуми мәсьәләләр хакында чиксез үгет вә нәсыйхәтләр, йә кергән кешеләрнең үзләренең мактануларын кат-кат ишеткән булсалар да, ашау бүлмәсенең әһәмияте кеби яшәешкә бәйле мәсьәлә аларга ят күренде. Верхнеурал кеби, күбесенә ишетелмәгән караңгы өяздән килгән «бер бай»ның яңа сүз сөйләп калдыруы гаҗәп тоелды. Шәкертләр вә мөгаллимнәр ул кешенең мәдрәсәгә кергәч ни өчен бүтән байлар шикелле сөйләнмәвенә сәбәпләр эзләделәр. Шул хакта сүз булгач, мәдрәсә мөдире мөхтәрәм Галимҗан хәзрәт шәкертләрнең аптырау вә гаҗәпләнүләрен басу өчен:

– Шакир әфәнде башка сәүдәгәрләргә күрә күбрәк хәбәрдар, киңрәк карашлы кеше шул. Ул шуңа күрә мәдрәсәнең дә башкалар күрмәгән урынына әһәмият бирә, – диде.

Без дә хәзрәтнең бу аңлатуына канәгатьләндек. Шакир әфәнденең киңрәк карашлы кеше булуы да шул чакта күңелгә урнашып калды. Ул вакытта «Франция» номерларындагы бер-ике әңгәмәбез миндә бу фикерне ныгытты.

Соңгы елларда аның мәҗлесендә ешрак булырга туры килеп, Шакир әфәндене болай аңлауга дәлилләр янә артты. Ул сүзнең мәгънәсе дә элеккә күрә бик күп киңәйде.

Шакир әфәнденең бер хасияте – аның мәҗлесендә сүзнең мөһим мәсьәләләр өстендә йөрүе иде. Болар булучылык бер ясанудан, үзен шулай күрсәтүгә теләүдән түгел, бәлки аның фикере, башы зиһене шундаен мәсьәләләр илә мәшгуль булганлыктан сүз шуңа тартыла. Мөһим мәсьәләләрдә материалы күп булганлыктан фикер алышу ялыктырмыйча, озын дәвам итә иде.

Аның мин очраган мәҗлесләрендә, күбесенчә, диннән, фәлсәфәдән, әдәбияттан, техникадан, сәнгатьтән, милли эшләрдән, галәмдәге яңалыклардан яки «Вакыт» вә «Шура» эшләреннән бәхәс ителә. Һичбер вак сүзләр сөйләнми иде. Әңгәмә дини мәсьәләләргә кереп китсә, һәр мәзһәбтән дин гыйлемендә иң олуг кешеләрнең исемнәре искә алына, аларның фикер вә сүзләре мөнәсәбәт илә бер-бер артлы тезелә вә омтылыш, яратылыш, вәхи, динне аңлаудагы үзгәреш мәсьәләләре, мәңгелек бәхәсләре сөйләнә; шуннан фәлсәфәгә керешеп кителә. Юкса, кайберәүләр каршында дин мәсьәләсе буларак сөйләнә торган вак-төяк өлеше хакында дини җәһәттән бәхәс ителми иде.

Бер мәҗлестә вә яратылыш мәсьәләсендә әңгәмә булып, төрле сүзләр сөйләнгәннән соң, Шакир әфәнде суфыйлардан берничәләрнең фикерләрен вә тәфсыйлле буларак Кятиб Чәләбинең моңа карашын бәйан итте. «Мөхәммәдия»нең берничә урыныннан нәзымнар укыды. Аларны тәхлил итте. Аның бәйанын тыңлагач, мин: «Мөхәммәдия»не шулай тәхлил кылырга күптән ихтыяҗ бар икән, матбугатта бер кимчелек – шуның юклыгы булса кирәк», – дип фикер йөрттем.

Аның бер мәҗлесендә әдәбиятка мөнәсәбәтле берничә кешеләр җыелган иде. Телебезнең кагыйдәләрен булдыру вә шуңа мөнәсәбәтле китаплар нәшер кылыну мәсьәләсе сөйләнде. Һәркем бер төрле нәрсәләр сөйләде вә фикерләр бәйан итте. Иң соң сөйләгән вә мәҗлесне йомгаклаган кеше – Шакир әфәнде булып, һәммәбезне хәйран калдырды. Чөнки аның сүзләре тикшереп, үлчәнеп ясалган бер доклад кебек нигезле булып, күптәнге фикер, 15-20 ел буталчыклык нәтиҗәсе булуында шөбһәсез калмады. Бу мәсьәләдә ул күрсәткән чыганак илә танышырга тиешлекне аңлап таралдык.

Мәҗлестә техника вә машина эшләреннән сүз кузгалса, мәшһүр тәгъбирчә – ул йөзә иде инде. Чөнки Шакир әфәнде машина эшләре илә бик сөеп шөгыльләнгән, ул хакта тәҗрибә вә белеме күп; машина эшендә элек булмаган берничә ачыш вә яңалыклары бар. Кайсыларына имтияз (привилегия) алган, кайсыларына алырга өлгермәгән. Әгәр дә аның башка

бер эше дә булган булмаса, ул шул машина эшендәге ачыш вә яңалыклары илә генә дә дөньяга бер күрекле кеше иде.

Үткән ел бервакыт Шакир әфәнде илә Беловка бакчасында очраштык. Яр буендагы эскәмиягә утырып, берничә минутлар Урал суын, аның аръягындагы дача агачлыкларын ерактан тамаша итеп тордык. Шакир әфәнде Җаекның агымына бер сузып Азия ягындагы инеш далага күзен салды да:

– Борһан әфәнде! Күрәмсең, монда бик күп көч әрәм була бит. Менә бу Урал суы, әнә тегендә генә кушыла торган Сакмар суы ничә йөз еллардан бирле әрәмгә агалар, без шуннан файдалана белмибез. Безнең кул астында миллионнар ята, шуларны җыеп алырга кеше юк. Менә Урал, Сакмар буенда ничәмә елларда ягъмурлар җитешми, игеннәр уңмый. Әгәр дә шушы Урал, Сакмар сулары илә ун мең дисәтинә генә җирне сулап торгызсаң да, никадәр эш булыр иде. Менә без, татарлар, гомер буена Уралны, Сакмарны беләмез, шуны эшли белмибез бит! «Иген булмый» диләр. Сүзмени ул! Төркестанлылар ягъмур көтеп торсалар, күптән ачка үлгән булырлар иде. Алар агым сулардан никадәр байлык чыгаралар...

Соңра Шакир әфәнде, бу суларны ничек күтәртергә, ничек агызырга планнар сөйләде, якынча күпме чыгым кирәклеген бәйан кылды. Моннан минем зиһенем югары авыл хуҗалыгы мәктәбендә бер мөһим лекция тыңлаган кадәрле эш булды.

Шакир әфәнденең су йөртү эшендә аерым осталыгы бар иде. Суны теләгәнчә агызып, аның көченнән кат-кат файдалану эшендә Шакир әфәнденең берәр приискасы Шәркый Русиядә тиңсез дәрәҗәдәдер.

Шакир әфәнде эш кешесе иде. Ул гомерендә бик күп эш эшләгән. Эштән, һөнәрдән гадәттән тыш буларак күп игелек күргән. Пәйгамбәребезнең «Ризыкны җир эченнән эзләгез!» дигән хәдисен иң тугры аңлап, шуны иң муаффәкыятьле рәвештә гамәлгә куйган аз мөселманнарның берсе – шөбһәсез, ул иде.

Фәлсәфә, дин, әдәбият мәсьәләләре илә күп шөгыльләнгән кешеләрнең мәгыйшәт эшеннән ераклашулары, кара гакыл илә мәгълүм нәрсәләрне дә аңламый башлаулары гадәт

кеби булган хәлдә, Шакир әфәнде тормыш эшен яхшы белүчеләрдән иде.

Ул үзенең тормышында дөньядан никадәр файдаланырга мөмкин булса, шул кадәр файдаланып, дөньяга никадәр файда тидерергә мөмкин булса, шул кадәр файда тидереп яшәде. Дөньядан зарланып, башкаларның эшен тәнкыйть илә гомер кичерү аның фигыленнән түгел иде.

Шакир әфәнде уңайлылык ясый торган, иҗат итә торган табигатьтә иде. Тискәрелек, инкяр, вату, җимерү, кеше эшенә аяк чалу аның табигатеннән булмаенча, ислахәт вә яңарту тарафдарлары өчен дә иң газиз бер сыйфатка ия иде. Мәгыйшәт эшендә күтәрелүе дә һөнәре вә алдан күрүчәнлеге нәтиҗәсендә булып, юкса кешенең зарарыннан мәнфәгать күрү, адәм сөякләреннән үзенә тәхет ясау «осталыгы» Шакир әфәндегә ят булып, мөселманнан гына түгел, гомумән, миллионерлар эчендә мондыйлар сирәк табылуы мәгълүмдер.

Шакир әфәнденең вафат булуы илә дәүләт ияләре үз араларыннан бер белекле, әхлаклы, инсафлы, һәр эштән хәбәрдар кешене югалттылар.

Яңалык тарафдарлары исә урталыкта була торган уңайлы чаралары мөстәкыйль вә хөр фикерле, тырыш, кодрәтле бер кешедән мәхрүм калдылар.

Шакир әфәнде ике фирка өчен дә «киңрәк карашлы кеше» иде.

Тәңребез аның каберен киң кылсын! Киң рәхмәтендә аңа киң урын бирсен! Киң карашлы, киң күңелле, киң куллы мәрхүмнең рухына бер фатыйха!

(«Вакыт» газетасы. – 1912. – 30 март.)

Закир әфәнде Рәмиев

Шималь төрек газеталарының иң мөһиме улган «Вакыт» җәридәсенең сахибе Закир әфәнде Рәмиев хәзрәтләре кәримәләре Зәйнәп ханым әфәнде илә берлектә Истанбулга килделәр. Кәндиләренә кәмаль самимият илә: «Сафа килдеңез, хуш килдеңез!» – диюрез.

(«Төрек йорды» журналы. Истанбул. – 1914. – №5. – Б.2174.)

шималь төрек – төньяк төркиләр, ягъни татарлар

улган – булган

җәридә – газета

кәримәләре – җәмәгате

кәндиләренә – үзләренә

кәмаль – камил

диюрез – дибез

Оренбург мөселман студентлар кайда?

Льеж дарелфөнүнендә укучы русияле шәкертләрдән 300 кадәр кешенең әсир сыйфатилә кулга алынып, Германиянең Аахен каласына китерелдекләре беленде. Льеждагы русияле мөселман студентлар һәммәсе шул җөмләдә булсалар кирәк.

(«Вакыт» газетасы. – 1914 ел. – 24 август.)

Льеждагы мөселман студентлары

Льеждагы студентларының оренбурглы Мидхәт вә Гариф әфәнде Рәмиевләрнең урау юллар илә барып, Истанбулга җитешдекләреннән хәбәр алынды. Оренбурглы Бәдретдин әфәнде Сәйфелмөлеков илә «Вакыт» мөхәррирләреннән Галимҗан әл-Идриси һәм анлар илә бергә булсалар кирәк.

(«Вакыт» газетасы. – 1914 ел. – 27 август.)

Дәрдемәнд*

Дәрдемәнд – «Вакыт» вә «Шура» наширләреннән мәшһүр миллионер Закир әфәнде Рәмиевнең псевдонимы.

Мөселманчаны мәктәп вә мәдрәсәдә укыган. Русчаны һичбер мәктәпкә йөреп укымаган. Бәлки хосусый учительдән бераз укып, үз тырышлыгы белән рус әдәбиятыннан, заман гыйлемнәренең төрле фәннәреннән күп мәгълүмат алган.

Закир әфәнде үзе кебек татар байларына һичбер җәһәттән охшамый. Алар, бер төрлесе төн-көн мал вә дәүләт кайгысы артыннан чапкан, икенче бер төрлесе аталарының маңгай тирләрен агызып тапкан малын җыен хәерсез урыннарга таратып типтерү галәмендә гомер уздырган хәлдә, Закир әфәнде вакытының күбесен уку вә белем алу юлында үткәрә вә «Дәрдемәнд» исеме илә яңа әдәбиятыбызга матур-матур шигырьләр дә бирәдер.

Закир әфәнде хәзер 55 яшьләрендә булганлыктан, аның яшь вакытында безнең үз әдәбиятыбыз иң яшь, хәтта юк иде. Ул фән вә әдәбиятка бәйле мәгълүматының күбрәген госманлыча язылган китаплар аркылы алганлыктан, татарча язарга тырышса да, тел җәһәтеннән дә, мәгънә җәһәтеннән дә госманлы әдәбиятының тәэсиреннән котыла алмыйдыр. Ул моны үзе дә таный («Шура», 1908 ел. – №1).

Закир әфәнде «Вакыт» вә «Шура»дан башка берничә мөһим китаплар да нәшер итте. Үзенең шигырьләре җыентык сурәтендә нәшер ителгәне юк, алар югарыда әйтелгән газета вә журналларда нәшер ителә.

(Дәрдемәнд // «Заман» календаре. 1915 ел өчен.
– Казан, 1914. –Б.55.)

---

* Мәкаләнең теле җиңеләйтелде (*Төз. иск.*).

Зариф Бәшири

Рәмиевләр турында истәлекләр

[...] 1905 ел революциясеннән соң Фатыйх Кәрими мәктәп-мәдрәсәләр салдыруы белән дан тоткан Әхмәт бай Хөсәеневнең энесе Гани бай Хөсәеневкә татар телендә берәр газета чыгару турында киңәш сала. Гани бай аның бу киңәшен мәслихәт күрү белән генә калмый, оештыру эшенә дә керешә. Ул, туганы Мәхмүт байны, Закир һәм Шакир Рәмиевләрне дә шул эшкә тартып, күндереп, әлеге «Гыйльман ахун Кәримев матбагасы»н берләштергән хәлдә, «Кәримев, Хөсәенев вә шөрякәсе» дигән зур бер матбагачылык ширкәтен барлыкка китерә. Фатыйх Кәриминең теләве буенча, аның кияве булган Тимерша Соловьев директор итеп билгеләнә.

Фатыйх Кәриминең сөйләвенә караганда, Гани бай Хөсәенев тә матбугат һәм матбагачылык эшен нык ярата торган булган. Бу юлда ярдәмне дә кызганмаган. Ләкин аның зур улы Вәли мулла, аерата иске фикерле, реакцион бер кеше булганлыктан, атасының бу эшенә үч итеп, карагруһ дин башлыклары органын – «Дин вә мәгыйшәт» журналын оештыра.

«Кәримев, Хөсәенев вә шөрякәсе» матбагасы төзелгәннән соң, Шакир һәм Закир Рәмиевләр Фатыйх Кәрими редакциясендә «Вакыт» газетасын, аннан соң Риза казый Фәхретдинов редакциясендә «Шура» журналын чыгара башлыйлар. Тимерша Соловьев «Чүкеч» журналын нигезли. Алар «Кәримев, Хөсәенев вә шөрякәсе» матбагасында басылалар.

Ләкин күпләрнең зур өмет белән, шактый суммалар салып төзелгән бу ширкәтләре үсә дә, уңыш та күрә алмады. Төп

сәбәбе – башында Тимерша Соловьевның утыруында, аның чиксез дәрәҗәдә вакчыл булуында, үзенә байлык тупларга омтылуда иде. Ул үзенчә бик хәйләкәр һәм артык дәрәҗәдә экономлы булырга тырыша, шул юл белән ширкәтне дә, үземне дә баетам, дип уйлый иде. Ләкин аның бу экономлыгы һәрвакытта «биш тиенлек куян, ун тиенлек зыян» булып бетә иде.

Мин шушы ширкәткә эшкә барган чагында матбага менә шундый бер хәлдә иде: машиналар һәм хәрефләр тәмам искергән, күбесе сынып, кителеп беткән. Матур клишеләр юк. Арзанлы тонык буяу, кәгазьләр чүбекләнеп, сәлперәп торалар. Тимерша, экономия ясыйм дип, яңа машиналар, хәрефләр, яхшы буяулар, кәгазьләр алдырмый. Әнә шул чүп-чарлар белән эш итә, газета, журнал һәм китаплар бастыра. Басылган нәрсәләр тонык булып чыгалар, бик күп хәрефләр бөтенләйгә танылмыйлар иде. Эшчеләрне аларның белемнәренә, тәҗрибәләренә карап түгел, аз хакка да риза булуларына, үзенә ялагайлануларына карап ала. Төрле юллар белән эшчеләрнең эш хакларын басып калырга тырыша иде. Менә шуның өчен дә яхшы матбага эшчесе килми, килгәне дә күңел биреп эшләми иде.

«Вакыт» газетасы белән «Шура» журналын шул матбагада бастыручы Рәмиевләр, бигрәк тә Закиры, матбугат вә әдәбият эшенә зур мәхәббәт белән караганлыктан, матбугат эшенә сәүдә-табыш ягыннан килмәделәр. Матбугатның эчтәлеге белән дә, күләме, тышкы күренеше һәм техника ягыннан да нәфис, матур, күркәм булуын телиләр иде. Менә шуның өчен дә алар үзләре дә пайчы булган ширкәт матбагасының техника ягыннан түбән булуына, бигрәк тә «Вакыт» белән «Шура»ның кеше күзенә күрсәтергә оят дәрәҗәдә пычранып чыгуына рәнҗеп, сыкранып карыйлар, ләкин, Фатыйх Кәриминең кияве булганлыктан, аның хәтерен саклап, Тимерша Соловьевның юньсезлекләренә каршы чара да күрмиләр иде.

Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: Рәмиевләр, бу ширкәтнең, аңа шактый зур сумма керткән әгъзасы булуларына да карамастан, ширкәтнең исемендә үз фамилияләрен күрсәтүдән баш тарттылар, шунлыктан ул «Кәримев, Хөсәенев вә шөрякәсе» исеме белән йөртелә, Рәмиевләр фамилиясе «шөрякәсе» дигән сүз эченә яшерелә иде. Хәтта үзләренең шушы ширкәттә булганлыкларын да белдермәскә тырышалар иде.

1909 елның башларында Закир Рәмиев, үзенең акчасына үз ишегалдындагы бер өйдә, «Вакыт» газетасы белән «Шура» журналларын бастыру өчен, «Вакыт» матбагасы ачты, шуңа чаклы атнасына өч тапкыр чыгып килгән газета көндәлеккә әйләндерелде.

Закир Рәмиев газета белән журналның техника ягыннан матур булып чыгуына шул кадәр нык әһәмият бирә иде, хәтта машинадан өч тапкыр үткән хәрефләрне яңадан керттерми, алар белән әйбер бастырмый иде. Ул «Кәримев, Хөсәенев вә шөрякәсе» матбагасында чагында чүбекләнеп, ертылырга торган кәгазьләргә басылучы газета белән журнал өчен шытырдап, ялтырап торган нык кәгазьләр, чем-кара буяулар китертте.

«Минем матбагамда басыла торган газета, журналлар белән китаплар гына түгел, афишалар белән гади листовкалар да шундый кәгазьдә басылсыннар, бер кырыйларыннан тотып торган чагында, алар калай такта шикелле ялтырап, катып торсыннар, бөгелмәсеннәр, сынмасын, сәлперәп-сизерәп төшмәсеннәр!» – ди торган иде.

Үзләренә аерым матбага оештырудан элек «Вакыт» газетасының исеме дә, үтмәс балта белән юынып ясалгандай, тупас, ыржайган рәвештә күзгә ташлана иде. Закир Рәмиев, аны да алып ташлатып, гарәп хәрефе кулланыла торган барлык илләрдә иң югары урын тоткан нәсех язуы белән клише ясатты.

Аерым матбага оештырудан элек «Вакыт» газетасы редакциясендә бар булган ике кеше – Фатыйх Кәрими белән Габдрахман Фәхретдинев кенә эшли иде. Аерым матбага оешты-

рылганнан соң, аның редакция составы да киңәйтелә башлады. Төрле шәһәрләрдән тәҗрибәле журналистлар белән шагыйрь, язучылар чакыртылды. Казаннан Борһан Шәрәф килде, Рәкыйб Рәкыйби, соңрак Заһид Шәркый, Шәриф Камаллар алынды. Тик «Шура» журналында бар булган бер кеше – Риза казый үзе генә торып калды. Ул – үзе редактор, үзе секретарь, үзе әдәби сотрудник, хәтта редакциягә килгән хат һәм материалларны да күчереп чыгучы иде. Тик соңга таба гына әдәби нәрсәләрне миңа тапшыра торган булды.

Үз вакытында «Сәлимә» шикелле шактый матур әдәби нәрсәләр язган Риза казый нәрсә өчендер:

– Мин әдәби нәрсәләрне матур иттереп эшли дә, төзәтә дә алмыйм, әдәбияттан, бигрәк тә шигырьдән хәбәрем дә аз! – дип, әдәби нәрсәләргә кул салмый иде.

Закир Рәмиев, редакция эшчеләренең тормыш ягыннан яхшы тәэмин ителүләре, тышкы күренештә дә культуралы яшәүләре ягына нык күз сала, шуның өчен дә аларга, ул чорларда һичбер җирдә күрелмәгәнчә, зур жалование бирә иде. Мисал өчен шуны гына искә алып үтү дә җитсә кирәк: ул чагында, татар дөньясында түгел, хәтта Мәскәү, Петербург шәһәрләрендә чыга торган иң зур, популяр рус газеталарының редакторлары да аена 70-80 сумнан артык жалование алмыйлар иде. «Вакыт» газетасы редакторы Фатыйх Кәрими белән «Шура» журналы редакторы Риза казый аена 130 сум алдылар. Моны күпләр «министрлар жалованиесе» дип йөртә торган иде.

Шуның өстенә Риза казый Закир Рәмиевнең үз ишегалдындагы зур гына бер өендә түләүсез тора, аның яктырту, ягу расходлары да Закир Рәмиев өстендә иде.

1909 ел башларында, «Вакыт» газетасының чыга башлавына өч ел тулу уңае белән, кечкенә генә бер җыелыш үткәрелде. Шунда Закир Рәмиев мондыйрак мәгънәдә сөйләгән иде:

– Үткән елларда «Вакыт» белән «Шура» һәр елны, алтын хисабы белән, ун мең сумга якын зарар күреп килделәр. Бу

зарар укучыларның, алдыручыларның аз булуыннан килгән хәл түгел. Безнең укучылар, шактый зур табыш күргән башка газеталарныкына караганда, ике өлеш диярлек күп. Бу зарар безнең газета белән журналны эчтәлеге ягыннан да, техникасы ягыннан да матур иттереп чыгару өчен акчаны кызганмавыбыздан килә.

Аннан соң, ул тантаналы рәвештә шуны белдерде:

– Моннан соң без бу юлда ел саен 15 мең сумга чаклы зарар күрергә дә хәзербез! – диде.

Закир Рәмиевнең чын мәгънәсе белән аристократ шагыйрь, әдәбиятка «сәнгать – сәнгать өчен» ноктасыннан караучылардан булганлыгы барыбызга да билгеле инде. Шулай булуына да карамастан, башка язучылар белән шагыйрьләрнең иҗатлары, әгәр дә сәнгать ягыннан югары, көчле булса, аларның фикер, идея ягыннан нинди нигездә булуына да карамастан, бастыра бирә иде, аларга гонорарны да түбән түләми торган иде. Мәсәлән, ул Тукай шигырьләренә юлына 50 тиенгә чаклы гонорар бирү шарты белән, аны үзләренә эшкә чакыра. (Бу чагында бер генә җирдә дә шигырьнең юлына 5 тиеннән артык гонорар түләнми иде.) Ул Закир Рәмиев, пролетариат язучысы Шәриф Камалны да үзләренә эшкә чакырып китерде һәм аның иҗатларын гел үзе генә бастырды. Аңа бер генә җирдә булмаган рәвештә зур гонорар түләде. Бер вакытны ул Шәриф Камалга болай ди:

– Синең «Акчарлаклар» хикәясендә, бер генә дә благородный тип булмаса да, гаҗәп дәрәҗәдә художестволы язылганга күрә, мин аны бастырам, – ди һәм аңа уйламаган дәрәҗәдә зур гонорар түли. Закир Рәмиевләрчә, эшче, крестьян типлары благородный тип саналмый була инде!

Закир Рәмиевнең үзе чыгара торган газета-журнал редакцияләренә килеп-кереп йөргән чагын мин бик аз беләм. Мин шул тирәдә ике елга якын эшләп йөреп тә, аның «Вакыт» редакциясенә килгәнлеген тик бары бер тапкыр гына күрдем. Шул ике ел эчендә аны күрүем бар булганы өч тапкыр булды.

Закир Рәмиев, редакцияләрдә генә түгел, башка җирләрдә бик сирәк күренә, үз өеннән рәтләп чыгып йөрми, кеше белән аралашмый торган иде. Әлеге бергә эшли торган ширкәт әгъзалары еш кына үзара киңәшләр үткәрәләр, ә ул аларга бер вакытта да килми, тик аның агасы Шакир Рәмиев кенә килә иде.

Мин Фатыйх Кәрими һәм Риза казыйлардан берничә тапкыр аның турында шундый сүзләрне ишеткәнем бар:

– Ул яшьтән үк чиксез дәрәҗәдә өметсезлеккә бирелгән кеше. Шуның өчен дә аның барлык юанычы – үзенең көтепханәсендә матур әдәбият укып, язып көнен үткәрүдән тора...

(Аның яшьтән үк өметсезлеккә бирелүенең сәбәпләре турында гаҗәп вакыйгалар сөйләнсә дә мин, аларны монда язып торуны кирәк тапмадым.)

Мин аның белән тик бер тапкыр гына редакциядә очрашып, ун минутлап сөйләшеп утырдым. Ул әкрен, салмак тавыш белән бик аз сөйли, әйтергә теләгән нәрсәсен кыска гына итеп, ике-өч сүз белән генә әйтеп, аңлатып куя торган иде.

Ул, миңа, бердән шушы сорауны бирде:

– Ничек соң, язган нәрсәләрең өчен яхшы түлиләрме, гонорар белән тормышны тәэмин итеп буламы?

– Анысы инде аның, Закир абзый...

Мин, шулай дип сүз башлаган гына идем, ул, минем нәрсә әйтергә теләгәнемне бердән аңлап алды булса кирәк, миңа әйтеп бетерүгә дә юл куймады:

–Алай карарга ярамый ул, – диде. – Язучы, шагыйрьнең тормышы тәэмин ителми икән, аның иҗаты да тәэмин ителми!

Аннан соң ул:

– Мин синең «Шура» журналында басылган шигырьләреңне укып барам. Сез, художество ягыннан шактый үсеп барасыз, – диде. – Кайбер шигырьләрегездә минем школага иярү дә күренә!..

Мин аның бу соңгы: «минем школага да иярү күренә» дигән сүзләрен, ул аны үз школасына иярүне хуплап әйтәме,

әллә аны мәгъкуль күреп бетермәгәнлектән әйтәме, анысына төшенә алмадым.

Аның сүзләреннән мине беркадәр аптырауда калдырганы: «Шура» журналында басылган шигырьләрне укып барам», – дигән сүзләр булды. Чөнки мин ул чыгара торган журналда эшләгәч һәм шулай ук үзе шагыйрь дә булгач, анда басыла торган шигырьләрне ул үзе карап, үз күзеннән үткәреп бастыра торгандыр, дип уйлый идем. Шунлыктан мин аңа түбәндәге сорауны бирергә ашыктым:

– Соң, Закир абзый, Сез аларны журналга кермәс борын укымыйсызмыни?

Ул миңа болай дип җавап бирде:

– Журналның җаваплы кешесе бар бит аның! Аңа мин нишләп кысылыйм? Мин дә шулай, башкалар шикелле, аны басылып чыккач кына укыйм...

Ул «Шура» журналының үз акчасына чыгарылуына да карамастан, аның редакция эшләренә һичбер тыгылмау гына түгел, хәтта үз нәрсәләрен Риза казыйга: «Яраклык итеп тапсагыз, журналга кертерсез», – дип кенә бирә икән.

Шул чорларда «Шура» үзенең укучыларына түбәндәге мөрәҗәгатьне бастырып чыгарган иде:

– Сезнеңчә, иң алдынгы шагыйрьләр кемнәр? Шулардан ике шагыйрьне күрсәтеп язуыгызны үтенәбез.

Моңа каршы Габдрахман Сәгъди:

– Габдулла Тукаев белән Зариф Бәшири, – дип яза.

Закир Рәмиев шул турыда миңа сорау бирде:

– Моңа Сез ничек карыйсыз? – диде.

Ләкин мин аның бу соравын аңлап җиткерә алмадым: «Г.Сәгъдинең җавабына ничек карыйсыз?», әллә «Үзегез кемнәрне алдынгы шагыйрьләрдән саныйсыз?» ди идеме?

Шунлыктан мин, тисә тиенгә, тимәсә ботакка дигәндәй, боларның икесенә дә җавап була алырдайрак иттереп:

– Мин булсам, Тукай белән Дәрдемәнд дип җавап бирер идем, – дидем.

Ул бераз гына сүзсез торды да:

– Минемчә, Сәгыйть Рәмиев булса кирәк! – диде.

Ул Сәгыйть Рәмиевне Тукай урынына куеп әйтәме, әллә үз урынына, ягъни Дәрдемәнд урынына куеп әйтәме – мин төшенә алмадым. Ләкин һәрхәлдә шунысы ачык: ул Сәгыйть Рәмиевкә зур бәя бирә иде.

Закир Рәмиевнең үзе чыгара торган газета-журналларының редакция эшләренә, аларның эчтәлекле мәсьәләсенә «мин хуҗа, мин теләгәнчә булсын!» рәвешендә тыкшынып йөрмәгәнлеген, шулай ук аның кайбер сәбәпләрен дә мин Риза казыйның кайбер сүзләреннән яхшы гына аңладым. Закир Рәмиев белән сөйләшеп утырудан соң берничә көн үткәч, Риза казый мине үз өенә чакырды. («Шура» журналының аерым редакциясе юк, аның бөтен эшләрен Риза казый үзенең өендә алып бара торган иде.)

Ул миңа болай диде:

– Редакциядә бик күп шигырьләр җыелды. Аларның барысын да журналга кертеп бетереп булмый, әлбәттә. Шуның өчен дә, без Закир әфәнде белән сөйләштек тә, аларның яхшыракларын сайлап, аерым бер җыентык чыгарырга булдык. Син менә шуларның барын да карап, журнал өчен муафыйк булганнарын сайлап ал әле.

Шуннан мин аңа да Закир абзыйга биргән сорауны бирдем:

– Нигә Закир абзый үзе карап, сайлап алмыймыни? – дидем. – Ул сайласа, белебрәк тә сайлар иде, шуның белән бергә – журналның хуҗасы да бит ул!

Риза казый үзе дә уңайсызланган рәвештәрәк итеп:

– Закир әфәнденең гадәте дә, карашы да кызык аның, – дип куйды. – Закир әфәнде болай ди ул: «Һәрбер әдипнең, һәрбер шагыйрьнең үзенә бер өслүбе, тоткан юлы була. Бигрәк тә яшь язучылар белән шагыйрьләр шул үзләре алган юл белән алга баралар, үрлиләр һәм алар шулай шома гына, аксамый гына барырга тиешләр. Ә мин, аларның шигырьләрен төзәтәм дип, үземә табан борып җибәрермен дә аларда икеләнү тудырырмын»,– ди. Менә шуның өчен дә ул кеше иҗатына тыгылмауны артыграк күрә.

Аннан соң Риза казый, үзеннән өстәп, шуны да әйтеп куйды:

– Ул үз өслүбенә, үз мәзһәбенә артык бирелгән мөтәгассиб булса да, башкаларга аны йөкләү ягында түгел. «Һәрбер шагыйрь, һәрбер әдип бу мәсьәләдә ирекле булырга тиешле!» – ди ул.

Менә шушы көннән башлап «Шура»ның әдәби бүлеген мин алып бара торган булдым.

Әлеге утырышыбызда Галиәсгар абзый белән шушы турыда байтак кына сөйләшеп утырганнан соң, ул Тукайның Оренбургка килүдән баш тартуына үзенең бик үк риза булып бетмәгәнлеген әйтеп куйды.

– Минемчә, Г.Тукай бу мәсьәләдә бераз гына ялгышкан, – диде. – Бәлкем ул – мәсләк, фикер ягыннан Закир Рәмиев белән килешә алмам дип уйлый торгандыр. Ләкин мин мәсьәләгә болай карыйм, иң элек Тукай өчен Казан мохите бик үк шәптән түгел. Тагын да бер кабат әйтәм: «Тукай өчен», – дим, чөнки Тукай һич [...][*]

– Артыграк үзсүзле, Тукайга аңлатуы да кыен! – диде, – кызганам мин аны...

Шушы чорларда мин Рәмиевләр белән Фатыйх Кәриминең бер әдәби журнал чыгару фикерендә булуларын да аңлаган идем. Бу турыда Галиәсгар абзыйдан сорагач, ул:

– Минем белүемә караганда да, шулайрак аңлашыла, ләкин аңа муафыйк кешесен таба алмыйлар икән. Шәриф Камал белән Галимҗан Ибраһимовны чакырырга уйлыйлар, имеш, – диде.

Бу чагында мин Галимҗанга чын ихлас, өмет белән карау дәрәҗәсенә килгән булсам да, Шәриф Камалның «Шура» журналында чыккан һәм миңа бик ошаган «Уяну» дигән хикәясеннән башка нәрсәсен күрмәгәнлегемнән, аның турында бертөрле дә төпле карашка ия түгел идем.

мөтәгассиб – фанатик

[*] Кулъязманың бу өлеше сакланмаган (*Төз. иск.*).

– Нинди кеше соң ул Шәриф Камал? Шундый бер журнални алып барырлык өмет күрсәткәне юк ич әле аның, – дидем.

Башта Галиәсгар абзый шаяруга тартып:

– Кем булсын, Пенза мишәрләреннән берәү, – диде. Аннан соң җитди төс алып:

– Мишәрен мишәр дә бит, – диде, – ул кеше шул беренче хикәясе белән үк үзенең буш бер мишәр булмаганлыгын күрсәтә. Аның «Вакыт»ка вә «Шура»га тагын да берничә нәрсәсе килгән. Шуларны укыгач, Закир Рәмиев тә аңа зур өмет бәйләгән. Үз тирәбезгә тартырга, үстерергә кирәк бу егетне, дигән. Аның бер кулъязмасын мин дә укып чыктым...

Шул соңгы сүзләрне әйткәндә, Галиәсгар абзый канәгатьләнгән төстә башын да чайкап куйды.[...]

***

1907-1908 елларда Казанның берничә язучы һәм журналисты, Оренбург шәһәрендә алтын промышленниклары Закир һәм Шакир Рәмиевләр акчасына чыгарыла торган «Вакыт» газетасы белән «Шура» журналына эшкә киттеләр. Шулар арасында мин дә бар идем. Мин «Чүкеч» журналында һәм типографиядә эшли башладым. Шул уңай белән Тукай «Яшен» журналында «Тарта Казанның яшьләрен Рәмиевләр алтыны», – дигән бер җыр бастырып чыгарды. Шуннан бераз вакыт үткәч, Рәмиевләр белән Фатыйх Кәримиләр Тукайга да хат язып, аны үзләренә эшкә чакырдылар*. Алар Г.Тукайга, аена 40 сум жалованиедән тыш татар матбугаты тарихында гына түгел, хәтта рус матбугаты тарихында да күрелмәгән рәвештә яхшы шартларны тәкъдим итәләр. Мәсәлән, аның

* Хакыйкатьтә Фатыйх Кәриминең Рәмиевләр һәм үзе исеменнән Г.Тукайны Оренбургка чакырып хат язуы вакыйгасы башкачарак сәбәпләрдән булган. 1908 елда Казаннан Хәбибрахман Зәбири Г.Тукайның язмышы өчен тирәнтен борчылып Ф.Кәримигә шагыйрьне үз даирәләренә җәлеп итүләрен сорап хат язган. Ф.Кәриминең Тукайны Оренбургка чакырып хат юллавының төп сәбәбе шул. Ә инде Тукайның бу чакыруга нинди мөнәсәбәт белдерүе – башка мәсьәлә (*Төз. иск.*).

шигырьләренә юлына 50 тиен кадәр гонорар бирергә вәгъдә итәләр. Ул чакта татар матбугатында шигырьгә бирелгән гонорарның иң зурысы юлына 3 тиен иде.

Ләкин Тукай, бу чакта үзенең шактый авыр хәлдә яшәвенә дә карамастан, анда бармады. Ул үзенең рәсми җавабында: «Мин Казанны ташлап китә алмыйм!» – дип кенә язган булган. Ләкин төбендә ул алай түгел иде. Казанга кайтканнан соң, мин аннан:

– Дөресен генә әйт әле, Тукай, синең Оренбургка бармавыңның төп сәбәбе нәрсә иде? – дип сорадым.

Моңа каршы ул:

– Гәрчә син минем шул чакыруга каршы язган хатымнан, «Чүкеч» журналында: «Саклый Казанның яшьләрен Печән базары шакшысы!» – дип төрткән булсаң да, минем Оренбургка бармавымның сәбәбе Казаннан китәсем килмәвемдә генә түгел иде, әлбәттә, – диде. – Аның икенче сәбәпләре дә бар: элек минем белән чәкәләшеп алган Закир Рәмиев аны бервакыт онытмый, әлбәттә. Аларның мине чакырулары күбрәк әнә шуннан иде. Алар шуның белән башкалар алдында да: «Алтын кайда – чынлык шунда!» дигәнне исбат итәргә телиләр, янәсе: «Алтынга каршы шигырьләр язып, үзен мәсләгендә ныклы күрсәткән Тукай да бездән уза алмады, алтын артыннан килде!» – дияргә уйлыйлар иде.

Аннан соң, син үзең дә беләсең һәм әйтәсең: «Мин, ике ел Оренбургта торып, шуларның нәшриятларында эшләп тә, Рәмиевне бар булганы ике тапкыр күрдем», дип. Менә бу Закир Рәмиевнең үзен артык дәрәҗәдә югары аристократларча, артык светский тотканлыгын күрсәтә. Әнә шундый кешеләр белән мин бергә була да, эшли дә алмыйм!.. Минем гадәтем шул! Миңа кеше килгәндә ишегем дә, чыраем да ачык булсын, башкаларныкы да миңа шулай булсын!

«Аннан соң, – диде Тукай, шушы сүзләреннән соң, – мин үземнең чакырылуымнан элек үк: «Тарта Казанның яшьләрен Рәмиевләр алтыны!» дигән җырымны язып чыккан идем... моның мәгънәсе «алтынга сатылалар!» дигән сүз икәнлеген

һәркем аңларга тиеш. Шулай булгач, мин үземне дә әнә шул алтынга сатылучылар катарына эшем белән кертеп куя аламмы?..»

Мин Тукайга Закир Рәмиевнең, гәрчә ул капиталист һәм шул идеяне нык саклаучы кеше булса да, түбәндә яхшы табигатьле булуын, үч алу, кешене үзенә табындыру гадәте юклыгын сөйләп:

– Аның сине чакыруы, һичшиксез, синең иҗатыңны хөрмәт итү һәм дә яхшы бәя бирүдән башка нәрсә түгел иде, — дидем.

– Ул турыда да миңа әйтүчеләр булган иде. Галиәсгар Камал да шулайрак язды, – диде Тукай моңа каршы. – Хәтта мин баштарак шуңа таянып, барырга да уйлаган идем. Ләкин соңыннан тагын да бармау ягы җиңде.

(Зариф Бәшири. Замандашларым белән очрашулар. – 1968 ел. Өзек автор кульъязмасыннан алынды. Татарстан Милли китапханәсенең Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге. – «758-т» шифрлы кульъязма)

Раиф Мәрданов

«Шура» журналы һәм Рәмиевләр

Әдәби, фәнни вә сәяси «Шура» (Киңәш) журналы Оренбург шәһәрендә мәшһүр галим Ризаэтдин Фәхретдин мөхәррирлегендә һәм бертуган Шакир вә Закир Рәмиевләр наширлегендә 1908 елның гыйнварыннан 1917 елның декабрь аена кадәр тәртипле рәвештә, һәр айның 1 һәм 15 көннәрендә басылып чыккан. Шул рәвешле, бер елга 24 саны чыгып килгән. Ун ел дәвамында нәшер ителгән «Шура» журналының барлыгы 240 саны дөнья күргән.

«Шура» журналы чыккан чорда «Оренбургны татарның төп кайнаган җире, Казан белән ярышучы, хәтта үзенә мәркәзлек төсе алып баручы бер култык хәлендә»[*] булганлыгын инкяр итеп булмый. «Вакыт» газетасы һәм «Шура» журналының матбугат мәйданына чыгу факты үзе дә татар мәдәнияте әһелләренең Оренбургка тупланауына зур бер сәбәп була.[**] Шул рәвешчә, XX йөз башында, «Шура» журналы нәшер ителгән чорда, Оренбург каласы татар милли-мәдәни үзәкләренең берсе булган.

«Шура» журналы мәшһүр татар промышленниклары – бертуган Мөхәммәтшакир (1857-1912) һәм Мөхәммәтзакир (1859-1921) Рәмиевләр тарафыннан нәшер ителгән. Бертуган Рәмиевләр XX йөз башы татар иҗтимагый тормышында күренекле эз калдырган, татар дөньясының тәрәккые, мәгари-

---

[*] Ш.К. Оренбургта татар матбугаты // «Сабан» (Оренбург). – 1925. – 3 гыйнвар (№28).

[**] Мәхмүтов Һ., Ильясова И., Гыйззәт Б. Октябрьгә кадәрге татар театры: Очерклар. –Казан: Татар. китап нәшр., 1988. – Б.266.

фе, мәдәнияте вә әдәбияты үсеше өчен җан аткан, абруйлы милләтпәрвәр шәхесләр.

Рәмиевләрнең матбугат, басмаханә эшләре белән кызыксынулары 1880 нче елларда ук башланган. «Милләтләрнең тәмәдден вә тәрәккъкыйләренә иң беренче васита әдәбият, матбугат икәнлегенә киткән саен аның (Шакир Рәмиевнең – *Р.М.*) иманы куәтләнә барды. Шуның өчен дә ул бер матбага ачып, газета-журнал чыгаруны, әдәбият вә фөнунгә гаид рисалә вә китаплар нәшер итүне үзенә иң беренче максат итеп тотты. Матбага вә матбугат хәлләрен дәхи дә якыннанрак үгрәнергә кереште. Мәрхүм Шакир әфәнде 1899 нчы елда Яурупага сәфәр иткән вакытында да Петербургта матбага вә матбугат әхвален үгрәнүгә байтак зиһен сарыф иткән. Бораганский матбагасына вә рус матбагаларыннан һәм редакцияләреннән бәгъзеләрен кереп карап йөрегән вә ул дөнья берлән мөмкин кадәр якыннанрак танышырга тырышкан. Буңа аның шул вакыт Петербургтан бөрадәре Закир әфәндегә язган мәктүбләре шаһиттер... 1902-1903 нче елларда булса кирәк, бөрадәре Закир әфәнде илә бергә татар телендә бер газета чыгарыр өчен рөхсәт сорап Петербургка мөрәҗәгать итеп тә карадылар. Фәкать ул вакытлардагы идарәнең икътизасынча мөселманнарга үз телләрендә газета чыгарырга рөхсәт алу, мөмкин түгел диярлек дәрәҗәдә, мөшкел иде. Рөхсәт бирелмәячәге аңлашылды. Шул сәбәпле, эстәр-эстәмәс анлар үзләренең гайиәи хыялларын дәхи бер мөддәт кичектереп торырга мәҗбүр булдылар».* Аларга изге хыялларын фәкать 1905 ел инкыйлабыннан соң гына тормышка ашыру мөмкинлекләре ачылган.

тәмәдден – мәдәниләшү

икътиза – тәртип

эстәр-эстәмәс –теләр-теләмәс

гайиәи хыял – хыялдагы максат

бер мөддәт – беркадәр

* [Фәхреддин Ризаэддин]. Мөхәммәдшакир әфәнде Рәмиев // Шура. 1913. – №6.-Б.188.

1906 елның 16 февралендә Рәмиевләр Оренбург каласында «Вакыт» исемле татар газетасы[*], 1907 елның 13 декабрендә «Шура» исемле татар журналы нәшер[**] итүгә рөхсәт алалар.

Рәмиевләр 1909 елның 2 гыйнварында «Вакыт» исемендә үз матбагаларын ачарга Оренбург губерна идарәсеннән 4 нче номерлы таныклык алып[***] «Вакыт» газетасын һәм «Шура» журналын үз басмаханәләрендә бастыра башлыйлар.

«Шура» журналының наширләре – бертуган Рәмиевләрнең әдәбият буенча белемнәре тирән булган. Р.Фәхретдиннең бер хатирәсендә Шакир Рәмиевнең «хакыйкый мәгънәсе илә әдәбият мөгаллиме улырга лаек» икәнлеге турында язылган[****]. Наширләрнең икенчесе – Закир Рәмиев-Дәрдемәнд үзе мәшһүр фәлсәфи, лирик шагыйрь, татар классик шигъриятенең иң күренекле вәкилләреннән берсе. З.Бәширинең 1968 елда чыккан «Замандашларым белән очрашулар» исемле китабына керми калган, ягъни автор кулъязмасының редактор тарафыннан сызылган юллары Дәрдемәнднең әдәби эшчәнлеккә аеруча игътибарлыгын һәм зур әһәмият бирүен күрсәтә. Гонорар мөнәсәбәте белән икесе арасында булган әңгәмәне З.Бәшири болай дип искә алган:

«– Ничек соң, язган әсәрләрең өчен яхшы түлиләрме, гонорар белән тормышны тәэмин итеп буламы?

– Анысы инде аның, Закир абзый...

Мин шулай дип сүзгә башлаган гына идем, ул, минем нәрсә әйтергә теләгәнемне бердән аңлап алды булса кирәк, миңа әйтеп бетерүгә дә юл куймады:

– Алай карарга ярамый ул,– диде. – Язучы, шагыйрьнең тормышы тәэмин ителми икән, аның иҗаты да тәэмин ителми!»[*****]

---

[*] ТМА. 1370 ф., 1 тасв., 2 эш, 1 кгз.

[**] ТМА. 1370 ф., 1 тасв., 4 эш, 3 кгз.

[***] ТМА. 1370 ф. 1 тасв., 4 эш, 6 кгз.

[****] Фәхреддин Ризаэддин. [Хатирә]//Шура. – 1912. – №7. – Б.224.

[*****] «758т» шифрлы кулъязма. Татарстан Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге. 107-108 кгз. (Алга таба: ТМК. – «758т.»);

Закир Рәмиевнең «Дәрдемәнд» псевдонимы белән шагыйрь буларак шөһрәт казануы да «Шура» журналы сәхифәләре аша була. Мөхәммәтшакир Рәмиев 1912 елның 15 мартында фаҗигале төстә вафат булгач, агасы белән бергә башлаган барлык эшләрне дәвам итү һәм «Шура» журналын нәшер итү дә Закир Рәмиевкә йөкләнә.

Рәмиевләр һәм «Шура»ның мөхәррире Р.Фәхретдин үзара зур ихтирам саклап килгәннәр. Алар арасындагы җылы мөгамәлә турында Әсма Шәрәф истәлекләрендә бик тәфсыйльле тасвирланган.*

Журналның наширләре «Шура»га бик зур әһәмият биргәннәр, күп чыгымнар таләп итсә дә, акчаларын кызганмаганнар, даими кайгыртучанлык күрсәткәннәр. З. Бәшири хатирәләре моны бик яхшы дәлилли. Ул З.Рәмиевнең 1909 елдагы «Әлегә чаклы үткән елларда «Вакыт» газетасы белән «Шура» журналы һәр елны, алтын хисабы белән, ун мең сумга якын зарар күреп килделәр. Бу зарар аларны укучыларның, алдыручыларның аз булуыннан килгән эш түгел. Безнең газета белән журналның укучылары шактый зур табыш күргән башка газеталарныкына караганда ике өлеш диярлек күбрәк. Бу зарар безнең газета белән журналны эчтәлеге ягыннан да, техника ягыннан да матур, нәфис иттереп чыгару өчен акчаны кызганмавыбыздан килә... Моннан соң без бу юлда ел саен 15 мең сумга чаклы зарар күрергә дә хәзербез» дигән сүзләрен язган.* Шул ук истәлекләрдәге мондый факт та наширләрнең журналга карата аеруча җитди мөнәсәбәт һәм ихласлыкларына мисал. «Закир Рәмиев редакция эшчеләренең тормыш ягыннан яхшы тәэмин ителүләре, тышкы

Шагыйрь һәм журналист, язучы Зариф Бәширинең 1968 елда Татарстан китап нәшриятында «Замандашларым белән очрашулар» исемле истәлеге басылган. Татарстан Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә китапның автор кулъязмасы саклана. Өзек автор кулъязмасыннан алынды.

* Шәрәф Ә. Әткәем турында истәлекләр // Ризаэтдин Фәхретдин: Фәнни-биографик җыентык=Ризаэтдин Фахретдинов: Научно-биографический сборник. – Казан: Рухият, 1999. – Б.39-80.

* ТМК. – «758т.» – 105 кгз.

күренештә дә, культуралы яшәүләре ягына да нык күз сала, шуның өчен дә аларга ул чорларда һичбер җирдә күрелмәгән рәвештә зур жалование бирә иде. Мисал өчен шуны гына искә алып үтү дә җитсә кирәк: ул чагында татар дөньясында түгел, хәтта Мәскәү, Петербург шәһәрләрендә чыга торган иң зур, популяр рус газеталарының редакторлары да аена 70-80 сумнан артык жалование алмыйлар иде. Закир Рәмиев «Вакыт» газетасы редакторы Фатыйх Кәримев белән «Шура» журналы редакторы Риза Казыйга 130 сум жалование бирә иде. Моны күпләр «министрлар жалованиесе» дип йөртә торганнар иде.*

Милли матбугат өчен җан аткан һәм ихлас тырышкан бертуган Рәмиевләрнең «Шура» журналын матди җәһәттән тәэмин итеп торулары сокландыргыч.

Әлбәттә, журналны нәшер итү җиңел генә бармаган. «Шура» наширләре һәм мөхәрриренә рус шовинистлары тарафыннан, татар карагруһчылары һәм кадимчеләрдән тискәре мөнәсәбәт тә булып торган. Төрле сәяси һәм башкача кысынкылыклар булуга карамастан, журналның наширләре һәм мөхәррире өзлексез, тотрыклы чыгуын тәэмин итүгә барлык көчләрен куйганнар.

Ун ел дәвамында чыккан журналның 240 санында барлыгы 4000 нән артык исемдәге публикация, ягъни мәкаләләр, әдәби әсәрләр, хатлар һ.б. төрле язмалар дөнья күргән. Журнал битләрендә дөнья күргән материалларның күпчелеге тарих, әдәбият, иҗтимагый мәсьәләләр, мәгариф, тел белеме өлкәләренә караган.

«Шура» сәхифәләрендә уку-укытуга багышланган материаллар күп бирелгән.

Әдәбиятка һәм мәдәнияткә гаять югары дәрәҗәдә игътибар һәм әһәмият биргән шәхесләр тарафыннан мөхәррирлек вә нәшер ителгән журналда, әлбәттә, әдәби әсәрләргә һәм әдәбият мәсьәләләренә зур урын бирелгән.

---

* ТМК. – «757т.» – 104кгз.

Бизәлеше һәм техник эшләнеше ягыннан «Шура» журналы елдан-ел камилләшеп барган. Беренче елында (ягъни 1908 елда) «Шура» журналы Оренбургтагы «Кәримев, Хөсәенев вә шөрякәсе» матбагасында басылган. Журнал кечкенәрәк форматта булып, бер бите 19х27 см зурлыкта булган. Текстлар һәр биттә ике багана итеп урнаштырылганнар. Тышлыклары төрле: яшел, зәңгәр, сары, кызыл һ.б. төсләрдәге яхшырак сыйфатлы кәгазьдә басылган. Журналның аерым саны, тышлыклары белән бергә, 36 битле булып чыккан.

1909 елның 2 гыйнварында Закир Рәмиев исеменә Оренбург губернасы идарәсеннән «Шура» журналын үзләренең «Вакыт» исемле типо-литографияләрендә бастырырга рөхсәт алына.* 1909 ел башыннан журнал «Вакыт» матбагасында басыла башлый һәм иң соңгы санына кадәр шунда чыгып килә. «Вакыт» матбагасы ачылган елында ук зур абруй казанган, замандашлары тарафыннан югары бәяләнгән. Шиһаб Әхмәрев 1909 елда «Басып чыгардыгы әсәрләр гаять нәфис вә пөхтә булып, бу матбагадан киләчәктә матбугатымызның нәзакәт вә нәфасәтенә күп хезмәт өмид итмәк мөмкиндер», – дип язган.** Татар китабы тарихын нигезле рәвештә өйрәнгән галим Әбрар Кәримуллин хезмәтләрендә дә «Вакыт» басмаханәсенең нәфис һәм матур китаплары белән үз чорында зур шөһрәткә ия булганлыгы искәртелә.***

Яңа матбагада чыккан беренче саныннан ук журнал яхшы сыйфатлы ак кәгазьдә, нәфис һәм матур хәрефләр белән басыла башлый. Форматы 1908 елдагыча ук калса да, техник эшләнеше ягыннан зур үзгәрешләр күзәтелә. Рубрика-баб исемнәре матурлап язылып, бизәк-нәкышле рәсемнәр эченә урнаштырыла, текстлар кысалар һәм рәсемнәр белән зиннәтләнә.

---

* ТМА.1370 ф., 1 тасв., 4 эш. 6 кгз.

** Әхмәр Ш. Матбагатчылык тарихы. – Казан: И.Н. Харитонов матбагасы, 1909. – Б.70.

*** Каримуллин А.Г.Татарская книга начала XX века. -Казань: Татар. кн. изд-во, 1974. – С.152-155.

«Вакыт» газетасында «Шура»ның чыгу көннәре турында даими белдерелеп, эчтәлеге хәбәр ителә торган булган. Гомумән, «Шура» үзе дә «Вакыт»ның кушымтасы буларак тәгаенләнгән. Журналның иң беренче саны үрнәк, реклама рәвешендә «Вакыт»ны алдыручыларга бушка җибәрелгән.* «Шура»ның 1910 елгы 19 санынннан башлап 4 нче тышлык битендә рус телендә «Приложение к газете «Вакт» дигән язма урын алган.

«Шура» журналы 1913 елның беренче санынннан Төркия матбагаларында актив кулланылган «госманлы хоруфаты» дип аталган нәфис нәсех шрифты белән басыла башлаган.

Журналның эчтәлек җәһәте, тулаем, мөхәррире Р.Фәхретдин җаваплылыгында булса, бизәлешендә наширләренең югары зәвыгы да чагылган. «Закир Рәмиев газета белән журналның техника ягыннан нәфис, матур булып чыгуына шулкадәр нык әһәмият бирә иде, хәтта машинадан өч тапкыр үткән хәрефләрне яңадан машинага керттерми, алар белән әйбер бастырмый иде. «Кәримев, Хөсәенев вә шөрякәсе» матбагасында чагында чүбекләнеп, ертылырга торган кәгазьләргә басылучы газета белән журналлар өчен шытырдап, ялтырап торган, ныклы, чыдамлы кәгазьләр, ялтырап торган чемкара буяулар китертте. «Минем матбагамда басыла торган газета, журналлар белән китаплар гына түгел, афишалар белән гади листовкалар да шундый кәгазьдә басылсыннар, бер кырыйларыннан тотып торган чагында алар, калай такта шикелле, ялтырап, катып торсыннар, бөгелмәсеннәр, сынмасын, сәлперәп-сизерәп төшмәсеннәр!» ди торган иде»,** – дип искә ала З.Бәшири.

Матбугат тарихы белгече Исмәгыйль Рәмиев «Шура» турында «техникасы ягыннан, һичшиксез, беренче урынны тотты дияргә мөмкин» дип язган.***

---

* Идарәдән// Шура. 1908. – №1. – 3 т.б.

** ТМК. – «758т». – 102-103 кгз.

*** Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты. (Альбом). 1905-1925. – Казан: «Гәжур»,1926-Б.44.

«Шура» журналы эчтәлеге ягыннан гаять тә бай һәм күпкырлы, бизәлеше һәм техник эшләнеше җәһәтеннән XX йөз башы татар журналларының иң күркәме һәм нәфисе булган.

Матбугат мәйданында ун ел дәвамында балкыган «Шура» битләрендә барлыгы 880 авторның төрле публикацияләре дөнья күргән. Мәкаләләрнең зур бер өлеше, шулай ук редакциягә килгән хатларга, бихисап сорауларга җаваплар журналның мөхәррире Р.Фәхретдин тарафыннан язылган. Рәмиевләр тарафыннан нәшер ителгән «Шура» журналы һәм «Вакыт» газетасының идарә-редакциясе, нигездә, бер үк кешеләр тарафыннан чыгарылган. «Шура» редакциясендә төрле елларда Ф.Кәрими, Ш.Камал, З.Бәшири, Җ.Вәлиди, Я.Вәли, К.Бәкерләр эшләгән. Г.Тукайның да «Шура» редакциясенә эшкә чакырылганлыгы билгеле.*

«Шура»да иң күп язган авторлардан Дәрдемәнд, Шәехзадә Бабич, Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Камал, Сәгыйть Сүнчәләй, Зыя Ярмәки, Вакыйф Җәлал, Галәветдин Ходаяров, Һади Атласый, Муса Бигиев, Зәки Вәлиди, Габдрахман Сәгъди, Нәүширван Яушев, Хәсән Гали, Галимҗан Идриси, Мөхәммәткәмал Мозаффаров, Сабирҗан Кормаши, Мөхәммәтсәлах Жданов исемнәрен күрсәтергә кирәк. Журналда хатын-кыз авторлардан М.Акчурина, З.Сәгыйдә, Гайнелхәят Илкинова һ.б. мәкаләләре, әсәрләре дә басылган.

«Шура» авторлары төрле катлау-сыйныф вәкилләре булган. Анда миллионер да, мөфти дә, философ, галим, сәүдәгәр, мулла, мөгаллим, мөгаллимә, солдат, балаларның да мәкаләләре, хикәяләре, шигырьләре, хатлары басылып чыккан. Авторлар арасында күренекле шәркыять белгече А.Вамбери кебек шәхесләр дә, студент, имамнар, шәкертләр, мөгаллимнәр, табиб һ.б. да булган.

---

* Бәшири З. Замандашларым белән очрашулар: (Язучы истәлекләре). – Казан: Татар. китап нәшр., 1968. – Б.216-217; Тукай Г. Әсәрләр. Биш томда. Т.5: Истәлекләр, юлъязмалар, хатлар, мәсәлләр һәм балалар өчен хикәяләр (1902-1913). – Казан: Татар. китап нәшр., 1986. – Б.84.

Россиянең югары дәүләт органы булган Дәүләт Думасы китапханәсенә 1911 елда 2 татар журналы – «Шура» һәм «Мәгълүмате җәдидә»[*] алдырылганлыгы мәгълүм.[**] Россия мөселманнарының рәсми үзәк идарәсе органы вазыйфаларын башкарган «Мәгълүмате җәдидә» журналының Мөселман фракциясе, махсус Дин эшләре буенча комиссия булган Дәүләт Думасы китапханәсенә алдырылуы гадәттән тыш хәл түгел. Ә «Шура»ның анда алдырылуы исә, фикеребезчә, укучылары күп булуы, абруй һәм мәртәбәсеннәндер. Дума китапханәсенә «Шура» журналы һәм «Вакыт» газетасы, сатып алынган башка матбугат органнарыннан аермалы буларак, Дәүләт Думасының стенографик хисапларына алмашып алынган.[***] «Шура» журналы белән Россия патшасының якын даирәсе да таныш булган. Бу факт «Тәрҗеман» газетасыннан алынып «Шура»да басылган бер хәбәр[****] белән раслана. Россия шәркыять җәмгыятенең химаячесе княгиня Милесса Николаевнаның 12 июньдә Исмәгыйль Гаспринскийны кабул иткәнлеге һәм княгиняның «Шура»да басылган Мәхмүдхуҗа Бәһбүдов мәкаләсендәге[*****] фарсыча шигырьләргә игътибар бирүе хәбәр ителә.

Шәрекъне өйрәнүче галимнәр дә «Шура»ны укып барганнар. Журнал хәбәрчесе Гариф Кәримевкә профессор

---

[*] «Мәгълүмате җәдидә» – Мәхкәмәи шәргыя органы «Мәгълүмат» журналы (Уфа, 1908-1910, 1916-1917) чыгудан тукталып торган чорда аның вазыйфаларын беркадәр үз өстенә алган, Уфада «һәфтәдә бер мәртәбә нәшер улынан мәҗәлләи исламия». Нашире һәм мөхәррире Локман Хәким Канзафаров булган «Мәгълүмате җәдидә»нең 1911-1912 елларда барлыгы 16 саны дөнья күргән.

[**] Усманова Д. Мусульманская фракция и проблемы «свободы совести» в Государственной Думе России (1906-1917). – Казань: Мастер Лайн, 1999. – С.62.

[***] Шунда ук.

[****] Олуг княгиня кулында «Шура» мәҗмугасы // Шура. – 1912. – №14. – Б.426.

[*****] Бәһбүдов М. Мөхтәрәм Муса әфәнде шәрәфенә // Шура. – 1912. – №11. – Б.351-352.

В.А.Гордлевский үзе бу хакта белдерә,* «Шура» журналы Россиянең иң зур матбугат каталогларында да урын алган.

Географик җәһәттән караганда да «Шура»да Казан, Әстерхан, Петербург, Мәскәү, Уфа, Алма-Ата, Ташкент, Бохара, Каһирә, Истанбул, Бәйрут, Мәдинә, Париж, Льеж, Вальпараисо һ.б. шәһәрләрдән, Кырым, Кавказ, Урта Азия, Төркестан, Себер, Ерак Көнчыгыш тарафларыннан язылган мәкаләләр басылган. Димәк, журнал шул төбәкләрдә алдырып, зыялылар, мөгаллим һәм шәкертләр, руханилар арасында укылган. «Шура» редакциясе үзе дә гарәп, төрек, фарсы, рус һәм Европа телләрендә башка матбугатны алдырып, танышып барган. Журналның редакторы Р.Фәхретдин һәм редакциянең башка хезмәткәрләре гарәп, фарсы, төрек, рус телләрен нигезле белгәннәр. Шулай ук Европа телләрендә дә аңлашучылар булган. Журнал идарәсенә килгән бер япон журналы уңаеннан «Шура»да журнал мөндәриҗәсе илә ашна улмак дәгел, хәтта исемен улсын – белмәдек. Япон лисаныны белүчеләр шимди Оренбургта улмадыкларыннан тәрҗемә иттермәк насыйп улмады. ...Аурупа лисаннарының вә язуларының кангыйсында улса да улсын, газеталары вә журналлары килдегендә мөндәриҗәләре илә ашна улыр өчен идарәдән чыгарга мәҗбүрият» юклыгын белдергән** юллар да моңа ачык бер дәлил. XX йөз башындагы мондый соклангыч факт уңаеннан хәзерге, ягъни XIX йөз башындагы татар газета һәм

* Кәримев Г. Яңа госманлы әдәбияты: (Профессор Гордлевский лекциясе) // Шура. – 1911. – №2.-Б.50.

лисан – тел

шимди – хәзер

кангый – кайсы

мөндәриҗә – эчтәлек

ашна улмак – танышу

** Японияда асаре кадимә вә тарихи вакыйгалар // Шура. – 1909. – №12. – Б.371.

журналлары редакцияләрендә бу мәсьәлә ничегрәк тора икән дигән уй килә.

«Шура» татар халкына хезмәт итүдән тыш, гомумтөрки бер журнал сыйфатын да алган. «Гомумтөрки» гыйбарәсе астында, бу очракта, нигездә, Россия империясендәге мөселман төрки халыклары күздә тотыла.

Журналны укучылар даирәсе татар җәмәгатьчелеге белән генә чикләнмәгәнлектән, «Шура» битләрендә татар авторлары белән беррәттән төрек, казакъ, әзәрбәйҗан, үзбәк, уйгур һ.б. төрки халык вәкилләренең 150 исемнән артык мәкалә һәм язмалары басылып чыккан.

«Шура» журналы 1918 елның гыйнварында Халык Комиссарлары Советының «Матбугат турында декрет»ы (1917, 27 октябрь) нигезендә рәсми рәвештә ябылган. «Шура» журналы һәм «Вакыт» газетасы совет дәүләт органнары тарафыннан иң беренче ябылган татар матбугаты органнары.

Шура журналының еллык төпләмнәре хәзерге вакытта Казан, Мәскәү, Петербург, Уфа, Ташкент, Алма-Ата шәһәрләренең иң эре китапханәләрендә, шулай ук Нью-Йорк публик китапханәсендә, Хельсинки университеты китапханәсендә, Төркия китапханәсендә саклануы мәгълүм. Бу да журналның үз чорында киң таралганлыгын раслый.

Раиф Мәрданов

«Вакыт» газетасы

Көндәлек сәяси вә әдәби татар газетасы – «Вакыт» Оренбург шәһәрендә бертуган Рәмиевләр наширлегендә һәм Фатыйх Кәрими мөхәррирлегендә 1906 елның 21 февралендә нәшер ителә башлаган. Газета атнага 2-3 мәртәбә, ә 1913 ел башыннан көндәлек булып чыккан. «Вакыт»ның барлыгы 2308 саны дөньяга чыгып, 1918 елның 26 гыйнварында большевиклар хөкүмәте тарафыннан ябылган.

«Вакыт» газетасы үз чорының матди яктан иң яхшы тәэмин ителгән, күп таралган, абруйлы, эчтәлеккә бай татар милли газеталарыннан берсе. Замандашлары тарафыннан «Вакыт» иң алдынгы татар матбугаты органы буларак беренче урынны тота дип бәяләгән. Лондонда чыккан «Таймс» газетасында «Вакыт» турында мәгълүмат биреп һәм аны уңай Шәркыять галиме Армени Вамбери 1906 елда ук яңа татар газетасына якты киләчәк юрый.

Газета редакциясендә күренекле әдипләр, җәмәгать эшлеклеләре һәм журналистлардан Фатыйх Кәрими, Ризаэтдин Фәхретдин, Шәриф Камал, Габдрахман Фәхретдинев, Борһан Шәрәф, Габделбари Баттал, Ярулла Вәли, Рәкыйб Рәкыйби, Госман Акчокраклы һ.б. эшләгәннәр. Алардан тыш, газета сәхифәләрендә Галимҗан Ибраһимов, Йосыф Акчура, Муса Бигиев, Һади Атласи, Зәки Вәлиди кебек күренекле затларның мәкаләләре еш басылган. «Вакыт» газетасының Россиядәге күп кенә шәһәрләрдә һәм төбәкләрдә, шулай ук чит илләрдә дә үзенең махсус хәбәрче-корреспондентлары булган. «Вакыт» Россия империясенең Петербургтан алып Ерак Көнчыгышка кадәр татарлар яшәгән барлык төбәкләрендә таралу

белән берлектә башка төрки халыклар – казакъ, башкорт, төрек, кырым татарлары, Кавказ, Урта Азия халыклары, Шәркый Төркестанда да яратып укылган. Россиядәге һәм чит илләрдәге Шәрыкне өйрәнүче галимнәр дә «Вакыт»ны күзәтеп барганнар. Россия Дәүләт Думасы һәм чит илләрдәге китапханәләргә дә «Вакыт» газетасы алдырылган булуы билгеле.

Тематика ягыннан «Вакыт» газетасы бик киң булган. Анда үзәк мәсьәләләрдән – милләтнең тәрәккъые, тарихы, милли мәгариф, тел, әдәбият һәм сәнгать, дини вә иҗтимагый мәсьәләләр һ.б. үз вакытының барлык актуаль җәһәтләре яктыртылган. Газета кирәгеннән артык ваклыклар белән булышмыйча, һәр мәсьәләне киң колач белән җентекләп, принципиаль хәл итүгә омтылган. Габдрахман Сәгъди бәяләвенчә, «Вакыт» чын-чынлап татар вакытлы матбугаты органнары арасында «мәгънәви юлбашчылыкны» тоткан.

Газетада актуаль мәсьәләләр бик кыю һәм хөр фикер белән язылганлыктан, «Вакыт»та бастыруга әзерләнгән үткен мәкаләләр цензура тарафыннан рөхсәт бирелмичә, дөньяга чыгудан тыелган, аерым саннары конфискацияләнгән, газета идарәсе штрафлар түләргә мәҗбүр ителгән, мөхәррире Фатыйх Кәрими хөкемгә дә тартылган. Алай да редакция хезмәткәрләре һәм типография эшчеләре бу кыенлыклардан чыгу юлларын да эзләгәннәр. Бу уңайдан Салих Фәхретдинов истәлекләре кызыклы.*

Техник эшләнеше һәм бизәлеше ягыннан да «Вакыт» газетасы татар милли газеталары арасында иң нәфисе, күркәме буларак беренчелек тоткан.

1906-1907 елларда «Вакыт»ның әдәбият капчыгы» исеме белән газетага кушымта рәвешендә махсус әдәби китапчыклар сериясе нәшер ителгән. Газетада чыкмый калган шигырьләр, әдәби парчалар һәм мәкаләләр тупланган әлеге китапчыкларның 13 кисәге дөнья күргән.

---

* Фатыйх Кәрими: Фәнни-биографик җыентык=Фатых Карими: Научно-биографический сборник. – Казан: Рухият, 2000. – Б. 96-98.

«Вакыт» газетасы битләрендә Россия, шулай ук чит илләрдә яшәгән татарлар, башка төрки халыклар һәм, гомумән, мөселманнарның XX йөз башындагы тарихи, иҗтимагый тормышы, мәдәни үсеше, әдәбияты буенча гаять бай материал тупланган.

ДӘРДЕМӘНД ШИГЫРЬЛӘРЕ

Үткән көннәр

Әй, кая ул көн ки бездә –
Шәп торулар бар иде;
Әмма дошманнарда гамьнәр,
Эч пошулар бар иде.

Бер заман чыгар идек без
Кырга дуст-ишләр илә;
Анда уеннар, көлүләр,
Сикерүләр бар иде.

Һай, гомерләр... үтте китте...
Кая китте ул заман!
Кайда ул шәп һае-һулар!
Гөфтегүләр бар иде...

Бер вакыт бунча рәхимсез
Дәгел иде кызлары;
Анда туташларда ымнар,
Күз кысулар бар иде.

гамь – көнчелек мәгънәсендә
һае-һу – шау-гөр килү
гөфтегү – сөйләшү, әңгәмә

Ничә еллар үтте, әмма
Күрмәдек кызлар йөзен!
Янымызда әүвәле
Кандай сылулар бар иде.

Шигърене күргәч Закирең,
Диде өлкәннәр дә: «Һай!
Яшь чагында бездә һәм
Андай йөрүләр бар иде!»

кандай – нинди

Каләмгә хитаб

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Түгеп күз яшьләреңне бу кәгазьгә,
Ни моңлы уйларың бар – сөйлә безгә!
Бабалар кабре янында күңел зар,
Аталар рухының армандәсе бар...
Кара тупрак тулы мәзлум нидасы
Алар кемдер?.. Алар кемнәр фидасы?..
Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Түгеп күз яшьләреңне бу кәгазьгә,
Ни моңлы уйларың бар – сөйлә безгә!..

хитаб – эндәшү, мөрәҗәгать
кальб (калеб) – күңел, йөрәк
гаян итү – ачып салу, белдерү
бәян итү – сөйләп бирү
армандә – теләк, өмет
мәзлум – җәберләнгән, рәнҗетелгән
нида – зар-ыңгырашу

Кыйтга

Ни гамь – бөлсәм? Әгәр үлсәм – ни ваем?
Эчеп, дустлык шәрабеннән исерсәм;
Булып дустлар белән берлектә даим,
Гомернең тиз үтәр язын кичерсәм.

кыйтга – кыска шигырь

***

Көн кызды!.. Кызды һава монарланып,
Сагымлап, кыр белән дала чобарланып.
Һава тымык, шылт итми!.. кысылды тын:
Ягъмур көтә җирнең йөзе комарланып...

Күренде күк йөзендә кара болыт,
Болганып, гайрәт белән ужарланып,
Йөгертеп өермәләр, истереп җил,
Ачулы килә атлып, йомарланып!

Ялт итте яз кылычы кыеп күкне,
Бушанды күк – ягъмурны коеп түкте.
Күк селкенеп укырана, җир сыгыла,
Нәзер әйтеп Ходаемга халык сыгъна.

Мал, чулашып уртагалып балаларын,
Баш иyләр, куеп арка җил ягына.

Күк ярылып чатырлый, тау шаңгырый,
Шифалы ява коеп яз ягъмуры.
Җан-җәнлек, су тавышы тулды җиһан,
Шаулый-гөрли җирнең йөзе, күк яңгырый!

монарлану – куеру, зәңгәрләнү

сагым – мираж, рәшә

чулашу – куркышу

Кыйтга

(Тимерле тирәзә үтәсендә күзе елтыраган танышка тартым)

Ятимнәр күңлене кырдың, җимердең,
Көчең җитсә – бу зindан ишеген ват!
Туган, алдауда мин синнән калышмам,
Күрим сине – йә, бу солдатны алдат!

***

(Урам егетләренә тартамын)

Чамасы гыйльме шәп матур егетнең,
Кай эчке кайда – барыннан хәбәрдар.
Эчендәген белә шешә тышындан –
Өнәр бар ирдә, бакчы, зур өнәр бар!

чамасы гыйльме – гыйлем дәрәҗәсе мәгънәсендә
эчке – эчемлек, аракы

Шагыйрьгә

Ничөн бу хиддәт, и шагыйрь,
Нәдер бу ярганың ярма?
Эчендә бармы йә бер чир,
Вә йә синдә күңел тарма?

Әдиплек шаныңы саклап,
Әдәпле сирәт эзләп тап;
Бигүк түрләргә уздырма,
Катаңны да хата мактап.

Бирелмә ул кадәр зарга,
Сиңа көндәш түгел карга;
Вәли бик калкынып очма –
Сакын тап булма шоңкарга!

Яңылма, и яңа былбыл,
Тикәннән гөлне айрып бел;
Телеңдә хар вә хөсса булса,
Вафаи васләт итмәс гөл.

хиддәт – ачу
сирәт (сиярәт) – гадәт, холык
вәли – ләкин
сакын – салкын
хар вә хөсса – чәнчү һәм дошманлык хисе
вафаи васләт – турылыклы аралашу

Ала кошларга бакмакчы,
Газизем, булма такмакчы;
Матур гөлләргә бул былбыл,
Нәзакәт багына сакчы.

Без

Гасырлар кичте, китте... кичте еллар!
Нәбиләр падишаһлар сөрде дәүран...
Гомерләрдер күчеп кәрван вә кәрван,
Килеп кичте җиһаннан канча илләр!..

Сүнеп, вәйран булып мәгъмур тиякләр,
Җир астында тезелде ку сөякләр!..
Исә җилләр, күчә комнар... бетә эз...
Дәригъ, мәхзүн күңел, без дә бетәбез!

Мөсафир, кем, җиһанга басты ботны,
Биетте ажгырып аны замана...
Өеп чергән өмидне... төртте утны –
Йотып утларны... китте... яна... яна...

нәби – пәйгамбәр

дәүран (дәверан) – гомер, чор

вәйран булу – җимерелү, юкка чыгу

мәгъмур – төзек

дәрийгъ (дәригъ) – үкенеч

мәхзүн – аянычлы, кайгылы

Кораб

*

Шаулый диңгез...
Җил өрәдер:
    Җилкәнен киргән кораб!
Төн вә көндез
Ул йөрәдер:
    Юл бара ят ил карап...

*

Чыкты җилләр,
Купты тулкын –
    Ил корабын җил сөрә!..
Кайсы юллар,
Нинди упкын
    Тарта безне җан сорап?!.

Рәсем

(Нәваидән)

Тәнкәен ак, түшкәйләрен киң яраткан,
Биткәенең иң очында миң яраткан;
Саклар өчен зифа буен яман күздән,
Чәчкәйләрен аяк белән тиң яраткан!

Игътизар

Ачыдыр күз яше табган, газизем,
Ходаның хөкеме бу – юктыр гөнаһым!
Гомерләрдер яна кальбемдә утлар...
Кичә күр, бер сине көйдерсә аһым!

игътизар – гафу үтенү
табган – табигый
кальб (калеб) – күңел

Бүзләрем маналмадым

Гәрчә мин дә бар саналдым,
Ил катар сан алмадым;
Илдә йөрдем, хазлар алдым,
Уйласам – сан алмадым.
Янды Мәҗнүн, янды Фәрһад,–
Бер янып ат алдылар.
Мин, гариб, мең кат янып та,
Яндыга саналмадым.
    Уйлагыз: мәгъшука меңнәр!..
    Мин гашыйк саналмадым!
Кемгә васләт, кемгә өмид
Нигъмәтен бирде фәләк.
Мин өмиднең сул кулыннан
Бер сынык нан алмадым.
    Кемгә васләт, кемгә өмид!..
    Мин сынык нан алмадым!
Әйттеләр, кем, бер бәхетсез
Илгә гашыйксың, фәкыйрь.
Бер кызардым, бер бузардым...
Ни таныйм – таналмадым.
    Ни таныйм?.. Таналмадым!

ил катар – ил буйлап
хаз – өлеш
нигъмәт – муллык
нан – икмәк
васләт – кавышу
бузару – агару

Сезне, милләт кызлары, аһ!
И өмид йолдызлары!
Таң-сәхәрләр эзләп-эзләп,
Бер күреп каналмадым!
    И өмид йолдызлары!..
    Бер күреп каналмадым!

Исте җилләр ил эченнән,
Иртә-кич салдым колак.
Җил-җиләсләрнең моңыннан
Зәүкы әлхан алмадым.
Кайда бер тау, кайда мәэмүл
Чишмәи абелхәят!
Тез йөгендем, яшь тамыздым,–
Дәрткә дәрман алмадым.
    ...Дәрткә дәрман алмадым!
Биэре милләт, маэи зәмзәм
Күзләдем еллар буе.
Җитте дәфнем вакыты,
Кәфнем бүзләрен маналмадым!..
    Вәйля!..
    Дәри-и-й-гъ!
    Бүзләрем маналмадым!..

зәүкы әлхан – көй ләззәте
мәэмул чишмәи абелхәят – мәңгелек чишмәсе
биэре милләт – милләт коесы
маэи зәмзәм – зәмзәм суы
дәфен – күмү, җирләү
вәйля! – ни үкенеч!
дәрийгъ – ни кызганыч!

Кыш көннәре

Картайды җиһан...
Гөлләр дә бетте!
Кичмәктә заман –
Кышлар да җитте!
    Иелде ботаклар,
    Карлар асылды;
    Тагълар, болаклар –
    Бар да басылды.
Күк бозлар катып,
Оешып ятып,
Чишмәкәй шымды –
Бар җиһан тынды!
    Җил генә яман
    Сызгыра, өрәдер,
    Һәм күктә йөрәдер
    Бәс белән томан!

Нәсихәт

Гәрчә күрсәң ата-анаңнан җәфалар күп заман,
Син җәфа итмә аларга, бәлки – хөрмәт, и угълан!
Син нидер иттең исә атаң өчен, анаң өчен,
Син дә угълыңнан алырсың аны, әлбәт, и угълан!

***

Килсә кулдан, шат кыйл һәр җанны,
Кем, ханлык будыр,
Тәхет кыйл кырмысканың күңлен –
Сөләйманлык будыр!

Абдул Абдуличкә

«Угылым, сиңа әйтәм,
киленем, син тыңла!»

Татармы, армы син – белмим үзеңне,
Гаҗәп, тел боткасын тансык итеп син,
Качаннан бирледер ык-мык итеп син,
Көчәндең – көчкә аңлаттың сүзеңне!

***

Кил ки, зарым!
Юк язарым,
    Чөн кабул итми базар...
Үтми акчаң,
Кайда букчаң –
    Тиз алып үкчәң күтәр!

Өмидләр

*

Кил, и башчы! Агачны юнма юкка,
Кирәк булмас – угыңны як, кил утка!
Ачып хәйрат белән гыйбрәт күзеңне,
Кара читләргә: туплар китте хутка!

*

Ничә багълар күңелләрдә төзелде,
Сары юллар булып гамьнәр сызылды.
Өмидләр, кем, менеп башка тезелде,
Агарган кыл кебек... бер-бер өзелде.

*

Кил, и башчы! Агачны юнма юкка,
Кирәк булмас – угыңны як, кил утка.
Агарды чәч,
Куарды баш,
Сары юллар сызылды.
Өмидләр, кем...
Өмидләр, кем...
Дәригъ, бер-бер өзелде...

***

Рәнеҗ хәтер булганын илнең суыктан белде яз,
Кем, чәчеп нур, йөргезеп җилләр шифалы, килде яз.
Кар эреп, кырлар ачылды, таудан исте хуш җиләс,
Тау вә сәхраларга яңы җан биреп, сирпелде яз.

Кырны, тугайларны алды язгы сулар ташкыны,
Кем, чәчеп нурлар шифалы, йөргезеп җил, килде яз.

*

Яз үтеп, көннәр бетеп, булды тәмам гомрем кышы,
Агъла, и бичара Закир, кем синеңчөн үлде яз.

рәнҗе хәтер – күңеле рәнҗүе мәгънәсендә

***

Исәрме җил тугай буйлап,
Җырлармы кыз моңын сөйләп,
Көләрме шатланып, көйләп,–
    Агач, таш эчләре шаңрап,
    Киләдер бер нида яңрап!..

нида – зар-ыңгырашу

***

Ятам кай чаклары моңлап,
Һаваның тынлыгын тыңлап.
Килә өннәр, колак чыңлап.
Диямен:
– Ни бу? Нидәндер бу?
Җавап урынында – гөрли су,
Тирәклек тирбәнә, шаулый!..

***

Тиң булырмы йолдыз тулган айга –
Ул буйга-сынга, ачык чырайга!
Омтылган иләк кебек йөрешләре,
Ул моңлы, матур күз сөзешләре!
    Ялвару кирәкмәс, кирәк наз гына,
    Ул да – урыны белән, аз-аз гына!

***

Нидер, и сөйгәнем, бу яшь күзеңдә,
Ничөн хәсрәт күренде гөл йөзеңдә?

Борынгы шатлыгың юктыр сүзеңдә,
Ничөн хәсрәт күренде гөл йөзеңдә?

Күтәр чәчкәйләрең, күтәр кабагың,
Күренсен күзләрең, көрпә яңагың.

Шифа җилабе бар матур күзеңдә,
Сагышларга дәва ширин сүзең дә.

Үзеңдә бар икән тирйак күзеңдә,
Ничөн хәсрәт күренде гөл йөзеңдә?..

*

Фида җаным синең юлыңда, яр,
Берүк сау бул, берүк уйланма, зинһар.
Белалмим, ниндәен гизле моңың бар,
Ничөн хәсрәт күренде гөл йөзеңдә?

шифа җилабе – шифалы ялтыравык
ширин – татлы
тирйак – агулануга каршы дару
гизле – яшерен

***

Куанды ил, канат какты мәләкләр,
Шашып, аң-таң булып шайтан төкерде!..
Җитәр, җилкенмә, йолкынма, күңел, син,
Кияү булсаң да, ул туйга түгел син!
Җиһан тормыш туен иткән чагында,
Синең урның – үлекләр аймагында.

Видагъ

Тәгәрәп-аунап
Буй үскән,
    Туган илем, исән бул!
Чәч кузгатып
Җай искән,
    Таңгы җилем, исән бул!
Йөгереп-йөгереп
Туктаган...
Яулык болгап
Сыктаган,
    Нәзкәй билем, исән бул!

видагъ – аерылышу

***

Әгәр барсаң, саба җил, безнең илгә,
Сәламнәр әйт, сәлам ул нечкә билгә!
Төшендә юл өчен чәчкәен тарасын,
Гарибнең кайтырыннан фал карасын,
Ходаеннан кавышмаклык сорасын.
    Сәламнәр әйт, сәлам ул нечкә билгә!

Дәрийгъ, бер гомер икән сөргән элек без,
Йөрер бергә, көлер-уйнар идек без.
Бу көндә Сак белән Соклар кебек без...
    Сәламнәр әйт, сәлам ул нечкә билгә!

саба җил – таң җиле

гариб – туган-үскән иленнән аерылып, читтә яшәүче

***

Гөрләгән сулар башында,
Тыңлагыз, шунда үтәр –
Йөрсә сыктап таң-сәхәрләр
Моң-сагышлардан хыял.
И туган илнең һавасы,
    Рәнҗемим, зинһар, күтәр!
    Рәнҗемим, зинһар, күтәр!

Ни газизрәк – бу ватанмы?
Аһ, туган каумем газиз!
Ул мөкаддәс кан белән ул
Изге сөткә ни җитәр!..
    Сөт калыр, ватан китәр!
    Сөт калыр, ватан китәр!

***

Җәй үтте...
Кар-яңгырлы көз урнашты,
Күк тугайның баурына боз урнашты...
Гөл кипте,
Сабагында кинә калды.
Былбыл!
Сиңа бер бөртек инә калды.

***

Урамнан һәм базардан чүплә сүзне,
Алар бетмәс борын – барма еракка!
Тупас та булса тел – илнең колагы,
Уеңны уйдырып сал шул колакка.

***

Урысча күп сүзең, азы татарча,
Белалмыйм, кем син – урысмы, татармы?
Ничектер белмәдек исме шәрифең:
Хәсәнме, юкса Иванмы, Макармы?..

***

Кил, өйрән, и туган, бер башка телне,
Бүтән телләр белү яхшы һөнәрдер.
Катыштырма вәләкин телгә телне,
Тел уйнатмак наданлыктан әсәрдер.

***

Атам-анам йорты өчен
Булса мең җаным фида,
Туган-үскән җирем өчен
Соң тамчы каным фида.

***

Татарлыктан татар һич гарь итәрме,
Кеше үз исмене инкяр итәрме.
Татарлыкта татар угылы татармын,
Татар түгел димә – башың ватармын!

***

Әгәрчә дәүләтем юктыр җитәрлек,
Ишәктәй һәм йөк астында түгелмен.
Үзем башмын, үзем түш һәр эшемдә –
Тынычлыкта торамын, хуш күңелмен!

***

Зәгыйфь кырмыскамын мин юлда яткан,
Түгел бал корты мин – чагып елаткан.
Ни зур бу дәүләт, кем, шөкер итәм чук,–
Минем беркемгә җәбер итәр көчем юк.

1968
چوقوکلاغان آق اتشکی تولپار توگل

***

Мөгзе бар куйның бары да кучкар түгел,
Очкан кошның барысы да шоңкар түгел.
Кемнәр әйтмәс шигырьне, әйтер берүк,
Чукаңлаган аксак ишәк толпар түгел.

Лəтыйфə

Йə китсен суфи мəктəптəн аманлык белəн,
Йə – ку кəҗəне бакчадан яманлык белəн.
Яманлык кирəк, һəм дə мул кирəк –
Ул «урыска» күптəн шул кирəк!

лəтыйфə – мəзəк (шигырь)
аманлык – иминлек

***

Кил, җитеш тиз, кил, җитеш,
И сөйгәнем, зармын сиңа.
Сак белән Соклар кебек,
Күптән өмиддармын сиңа.

***

Булат такмый кәмәрләгән конан бил,
Тази атлар җалын какмый биә̇ җил.
Өшәнләнде даланың толпар аты,
Урал шоңкарының сынды канаты.

конан – нәзек
тази – йөгерек
биә – бии

***

Гомерләрдер... Өелмәктә сагышлар...
Дәвам итмәктәдер шиддәтле кышлар...
Һавалар тын... кыен очкан һома юк...
Азан иштелсә дә, кыйбла-нөма юк!..

шиддәтле – бәла-казалы
һома – бәхет кошы
нөма – компас

***

Җитәр инде, Дәрдемәнд, сүзне озатма,
Катып кунган күңелләргә боз атма!
Дилең өчен телең булсын тозаклы,
Йөз аклыгың өчен – аузың йозаклы!

дил – күңел

1968

***

Сөләйманны җиңә Бәлкыйс аягы,
Мисырның тәңресен – Муса таягы.

***

Илдә бер дуст булмаса гәр,
Ил бөтен – дошман түгел!

***

Күңелемнең әзрәк кенә кинәсе бар,
Телемнең дә зәһәр очлы инәсе бар.

***

Көләрсең, көлдерер, шатландырырсың,
Сөярсең, сөйгәнем, һәм сөйдерерсең.

***

Энҗе-алмаслар югалмас
Һәм ятып калмас – үтәр.

***

Кил, и дустым, хафа булма – бетәр бу;
Килер бер көн – китәр хәсрәт, үтәр бу!

***

Табып ләззәт матур дөнья сүзеннән,
Гомерләрдер җилеп йөрдем эзеннән.

Истәлек-парчалар

*

Эшләрнең җае, кәсепләрнең уңае, бер заманнар бу кәминәне Урал тауларының эчләренә аткан иде. Эшләремнән бушанган чакларымда тауларның хуш мәнзараларын, күркәм җирләрен сәйяр вә тамаша кылмактан бушанмый идем.

Урал тавының кай тирәләре гаять тә хуштыр. Бәлзәм исле нарат урманнарының эчендә – таштан ташка атылып чыккан агым сулар; төш-төш ачык җирләрдә – төрле чәчәкләр белән бизәлгән күркәм тугайчыклар.

кәминә – түбән дәрәҗәле (кеше); бу бәндә мәгънәсендә

*

Җылы һава, тынык... Тау-ташлар, агачлар – бөтен җиһан комарга талган, һәр нәрсәне көчле маркым алган иде. Күләнкәдәй буй аткан талчыбыкларны – ярымның зиба буена, агым суларның гөрләүләрен моңлы көенә биңзәтә идем; көрпә чәчәкләрнең күркәм килешен матуркаемның матур көлешенә охшата идем. Агым суларның гөрләп агышында гизле сагышлар бары, җиләс җил белән шаулап тибрәнгән агачларның моңлы зары күңлемә әсәр итте.

биңзәтү – охшату
гизле – яшерен

*

Үлән өстенә сузылып яттым. Җил шаулый, колак чыңлый иде. Бу искән җилләрдә кичкән елларның моңлы агышы белән, үткән гомерләрнең хәсрәтле сагышы тоела иде. Алда киләчәк адәмнәрнең тупарлашып баскан аяк тавышлары ишетелгәндәй була иде.

*

Мәзлум, мәгъсүм күз яшьләре кебек мөлдери, имәнгән күңелләр кебек тилбери иде. И Җаекъ! Син кай илләрнең күз яше, нинди хәсрәт силләренең юлдашысың!..

мәзлум – рәнҗетелгән

мәгъсүм – гөнаһсыз, керсез

Җаекъ – Урал елгасы

сил – ташкын

Галимҗан Ибраһимов

Дәрдемәнд

Исә җилләр... күчә комнар... бетә эз...
*Дәрийгъ, мәхзүн күңел, без дә бетәбез.**

I

...Менә бакча... Әнә, киң яфраклы ботаклары белән бөтен җир йөзен каплап алырга теләгән сыман, як-ягына җәелгән зур карт имәннәр; әнә, каһарман егеттәй, башларын күккә күтәреп, күкрәген киереп, мөтәкәббиранә утырган биек нарат-лар һәм дә, монда без дә бар, дигән шикелле шаулашмакта улган салынкы киемле карамалар... Әнә шуларның янәшәсендә үк буйга кече, ләкин җимеше бәрәкәтле алма агачлары... Әнә шуларның тирәсенә түшәлгән яшел үләннәр арасыннан, гүя кояшка яисә кичәнең матур йолдызларына таба сузылган, киң яфраклы түгәрәк зур кызыл чәчәкләр... Һәйбәт гөлләр... Шул чирәмне икегә ярып, шул агачлар астыннан тар, ләкин салкын һәм тирән елга ага... Ул күгелҗем ак төсле булып, күккә каршы көмештәй ялтырый. Аның бер артына, бер як-ягына карап барган сыман борылып-борылып агышы, аның бөтен бакчага, биек агачлар илә кызыл гөлләргә матур вә бераз киберле елмаешы гүя: һәммәгезне мин тәрбиялим, минем аркамда бу дәрәҗәгә җитәсез, ди. Зур карт имәннәр, олугъ кызыл чәчәкле гөлләр:

дәрийгъ – аяныч

мәхзүн – кайгылы

* Дәрдемәнднең «Без» (1908) шигыреннән.

киберле – эре

– Әйе!!. Әйе!!. Син булмасаң, без саргаер, кибәр идек! – дип баш ияләр.

Әнә шул җәмальләргә, шул тәэссөратка чыдый алмый, сандугач та ят илләрдә, могъҗиз музыкалар белән хәссас йөрәгендәге аһларын сөйли башлый.

...Мөкаддәс Кәгъбә эченә кергән изге җан кебек, бу бакчаның ишеген ачып, гөнаһлы аягың белән эчкә таба бер генә мәртәбә атлау белән, күңелең илә ниндидер самими вә кодси бер тәэсир эчендә каласың. Табигать җанлана, агачлар телгә киләләр, олугъ карт имәннең мәһабәт торышы, киң карамаларның шаулавы – боларның зур куәтләре хакында сөйли; агар су табигатьнең бу дәрәҗәгә ирешкән күркенә хәйран итә; киң яфраклы зур кызыл чәчәкләр, үзләренең гүзәллекләре белән, аяк баскан урыныңның җир йөзендә идекен оныттырырлык бер хәлгә китерәләр. Сандугач... сандугач... аһ, Тәңренең бу илаһи моңы үзенең гаҗәеп музыкасы илә тәмамтәмам игъҗаз кыйла. Һәрнәрсәдә аерым бер ләтафәт, мөмтаз бер матурлык. Ләкин, ләкин бөтен шул бакчада, табигать үзенең соңгы мәһарәтен сарыф итеп вөҗүдкә китердеге шул биек вә мөтәкәббир агачлар, агар сулар, карап туя алмаслык гөлләр, моңлы сандугачлар уртасында, боларның һәммәсеннән мөмтаз, һәммәсеннән гүзәл булган бер чәчәк утыра ки, үзенең гаҗәеп исе, нәфис сабагы, янып торган ал, кызыл йөзе белән сиңа бөтен бакчаны югалта – зур карт имәннәр күренмәс була, олугъ чәчәкләр каядыр яшеренә... Тик агар су, мәләкчә елмаеп:

– Мин аның өчен яратылдым, – ди.

хәссас – сизгер

кодси – пакь, саф, изге

игъҗаз кыйлу – гаҗәпкә калдыру

ләтафәт – гүзәллек

мөмтаз – үзгә

мәһарәт – осталык

вөҗүдкә китерү – барлыкка китерү

мәләкчә – фәрештәдәй

Сандугач:

– Мин аңа гашыйкмын, монда тик аның өчен киләм, гомерем буена аның гүзәллеген сайрыйм, – ди.

Син дә үзе кечек улдыгы хәлдә мондый мөмтаз урын алган чәчәк алдында:

– Әлбәттә, әлбәттә! – дип баш иясең.

Беләсең, аның гомере дә кыскадыр; ул теге зур имәннәр кебек калын бүрәнәләр, ягарга утыннар да, алмагач кебек җимешләр дә бирми; син сокланганләтафәте дә бәлки зәвальледер. Ләкин боларның һичберсе синең мәфтүниятеңне киметә алмый.

– Чөнки ул табигый булган чын матурлык!

Әдәбиятымыз һәйәте табигый талантларның эшчән каләмнәреннән, нәзек вә хәссас җаннарның нәфис сәнгатьләреннән вөҗүдкә киләчәк бер бакча исә, аның, үзенә күрә, башларын күккә мөтәкәббиранә күтәргән олугъ карт имәннәре, буйга кечкенәрәк булса да, җимеше илә болардан файдалырак һәйбәт алмагачлары, кызыл чәчәкле үләннәре вә боларның барына хәят бирә торган агар суы, боларның җәмаленнән мөтәәссир уларак сайрамакта булган сандугачлары булса вә боларның һәммәсе безнең җанымызга азмы-күпме азык бирмәктә, үзләренең шифалыклары илә язмышның каһәрле кулыннан эчерелгән тарихи агуларны бераз җумакта вә, һәрхәлдә, безгә бер җәһәт илә тәэсир итмәктәләр исә – бу бакчада, шул агачлар, гөлләр эчендә, кечек улдыгы хәлдә, үзенең матурлыгы вә берничә җәһәттән мөмтазлыгы илә башкалардан тәмам үз алдына тора торган кайбер සималар була ки, татар әдәбияты бакчасында йөреп, ана телебездә чын каләм сәнгате нәфисәсе эзләп тә, аларның алдында хәй-

зәвальле – бетәчәк

мәфтүният – соклану, мөкиббән китү

һәйәте – күренеше

сима – шәхес

сәнгате нәфисә – матур әдәбият

рәт илә озак-озак туктамау – бик зур зәвекъсезлек, бәлки әдәби сукырлык хисапланырга мөмкиндер...

II

Дәрдемәндне Сәгыйть Рәмиев илә янәшә куям. Чөнки бу ике санигымызның әүвәлгесе үзенең тирән уе, авыр тәэссөраты, куәтле ялкыны белән бөтен татар матбугатында ялгыз булган кебек, соңгысы да тик үзенә генә бирелгән берничә сыйфаты илә һәммә әдип вә шагыйрьләремездән аерым бер биеклектә торадыр.

Дәрдемәнд татар әдәбияты дөньясына сигезенче елның башында куәтле тавышлар илә шауламакта улган диңгезнең дулкыннарын ярып барган могъҗиз «Кораб» өстендә заһир булды. Аның әдәби йөзе мөмтаз дәрәҗәдә матур улмак илә бәрабәр, күзләрендә бер өмидсезлек катыш хәзин һәм ниндидер авыр тәфәккер әсәре ялтырый иде.

Аның бу сыйфаты кайберәүләр тарафыннан бик тиз күрелде һәм тәкъдир дә ителде.

Шулай булмый мөмкин түгел.

Бездә язалар, күп язалар, күпләр яза. Язуларында фикер дә бар кебек, фәлсәфә дә кушалар төсле, тормышны да тасвир кылалар шикелле. Ләкин төрлене тели, бигрәк тә күңелләре белән матурлык сөя торган зәвык вә тәмәйез ияләрен күп язулар үзләренең кабалыгы белән туйдыралар; сәнгатьсез һәм мәдәниятсез улучылыклары белән җанны сыгалар. Безем матбугатның кайсы ягына кагылсаң да, мәдрәсә исе килә, шәкертлек вә хәлфәлек күләгәләре күренә... Татар каләменең һәр җирдә тупас эзләр калдыруы үзенең укучыларын «матур

хәйрәт илә – хәйранга калып

санигъ – сәнгатьче, әдип

заһир булу – килеп чыгу

хәзин – хәсрәтле

тәфәккер – фикерләү, уйга калу

тәмәйез – үзенчәлек

каба – начар, ямьсез

сүз» илә «гүзәл сәнгать» ләззәтләрен милли даирәдә табудан мәхрүм итә. Һәр җирдән аңкыган мәдрәсә исе белән тел кабалыгы, өслүб тупаслыгы шул дәрәҗәдә туйдыра ки, татар телен сөеп, аның эчендә аз булса да матур яза, нәзек хис итә, хыял вә тойгыларын яңа галәмнән алып, аны нәфис өслүбтә ала торган бер куәтне җанның табигый ихтыяҗы кебек эзли башлыйсың. Менә шундый халәттә булганнар «Шура»да Дәрдемәнднең «Кораб», «Без» вә башка әсәрен күреп, һич шөбһәсез:

– Менә татар сәнгате әдәбиясе күгендә яңа бер йолдыз заһир булды! – димешләрдер.

Чөнки аңарда чынлап та яңа рух сизелә – мәдрәсә исе дә аңкымый, тупас та түгел, бәлки ниндидер әдәби мәдәнилек, чын каләм сәнгате, матур өслүб, җыйнак вә кыска тәгъбирләр; җиңел вә шома йөри торган каләм һәм хөзен катыш тәфәккер илә самими вә шигъри тойгы...

III

Дәрдемәнд фәсыйх яза – бу бер.

Анда әдәби зәвыклеләрнең колагына ят вә ямьсез тоелачак бер сүз очрау мөмкин булмадыгы кебек, чыгышсыз бер лөгать, артык бер хәреф күрергә дә имкян юктыр. Дөрест, анда кайбер вакыт гарәби йә фарси сүзләр булгалый, ләкин бу нәзым ясарга көчләнүдән-фәләннән түгел, аның бөек мәгънәсен ифадә кыйлырга ярлы татар теле җитә алмаудан вә шуның кебек мәшругъ бер сәбәбе әдәбидәндер. Сүзләрне сайлауда ул шундый бер тәмәйез табигый күрсәтә ки, анлар гүя маһир җәүһәрченең энҗеләре булалар. Бу энҗеләрне те-

---

сәнгате әдәбия – әдәбият

хөзен – кайгы, көенеч

фәсыйх – матур, килешле

имкян – мөмкинлек

ифадә кыйлу – аңлатып бирү

мәшругъ бер сәбәбе әдәбидәндер – әдәбият кануннарына туры килүдән

зеп – сүзләрне тәркиб итеп бер җөмлә ясауда да ул мөстәсна бер урында тора. Зарурәте шигърия бәласен ул гүя белми дә. Вәзен яисә кафия өчен сүзне үзенең табигый урыныннан күчерү аңарда бик вә бик сирәк очрый. Аңарда, гарип тәркибләр булмадыгы кебек, чыгышсыз тәгъбирләр дә аслан юк. Дәхи анда тел белән мәфһүм арасындагы тәнасеб искиткеч мәртәбәдәдер.

Бу ике җәһәттән карала:

1) Бездә бик күп каләмнәр сүз боткасы пешерә, бер сүз белән аңлатырлык мәгънәдә ун сүз истигъмаль итә . Яисә артыклар, тәкрарлар, табигыйсезлекләр тула да, үзенең мәгънәсенә караганда, тел вә ифадә аркасына капчыклар тагылган, билендә җепләр бәйләнгән сәләмә киемле ертык хәерче кебек булып чыга. Анлардан бер мәгънә аңлау өчен туктарга, араларга, тикшеренергә кирәк; төзәтергә уйласаң, әллә ни хәлгә әвереләчәк була. Ә Дәрдемәндтә ул юк; юк, булганда да искиткеч дәрәҗәдә. Аның мәгънәсе илә тәгъбир вә ифадәсе арасында шул дәрәҗәдә тәнасеб була ки, сүзләреннән, Ходай хакы өчен, берсен төшерергә, алмаштырырга, урынын үзгәртергә аслан мөмкин булмый. Гүя, Шәрекънең барлык табигый гүзәллекләрен җыйнап, Гаребнең иң соңгы нәфасәте илә артык зәвык вә тәмәйез үзәренә киенмеш бер хуры ки, карыйсың да, садәлек илә катышкан гүзәллекне күреп,

---

тәркиб итү – бер рәттән кую; кушу, җыйнау (сүз тезмәсе)
мөстәсна – аерым
вәзен – шигырь үлчәме
кафия – рифма
аслан – бөтенләй
дәхи – тагын
мәфһүм – эчтәлек
тәнасеб – ярашу, тәңгәл килү
истигъмаль итү – куллану
гареб – көнбатыш
нәфасәт – матурлык
хур – хур кызы

хәйран каласың. Дәрдемәнднең шигырьләре сүзне сайлау, төзү, матлубны мөкәммәл аңлатып та, һичбер хәреф артык кертмәүдән шул дәрәҗәдә мөкәммәл ки, аларны укыганда сүзләр ничектер күзеңә дә чалынмый. Гүя ул, ниндидер бер сихерле куәт белән, әйтергә теләгән мәгънәсен йөрәгеңә турыдан-туры яра да сала... Алыйк «Кораб»ны, «Без»не, «Өмидләр»не һәм башкаларны.

2) Мәгънәләрдә улган интизаме табигыйнең һәрвакыт диярлек тәгъбир вә ифадәдә ригайә ителүе . Аның каләме гүя табигатьнең хәрәкәте уңгаена баруны лязем таба. Хәлбуки, буны нәзымда түгел, нәсердә дә күп каләмчеләр ригайә кыйла алмыйдыр.

Мисал:

Чыкты җилләр,
Купты дулкын –
Ил корабын җил сөрә!..
Кайсы юллар,
Нинди упкын
Тарта безне җан сорап?!*

Дәхи:

Исә җилләр... күчә комнар... бетә эз,
Дәрийгъ, мәхзүн күңел, без дә бетәбез.

Ачык күренә ки, аның каләме табигатьтәге хадисәләрнең тәгакыбе тәртибен бик нәзек аера һәм нәсердә мөшкил улырлык мәртәбәдә ифадә дә кыйла ала – җөмләләрнең төзе-

---

матлуб – максат

мөкәммәл – тулы

интизаме табигый – табигый тәртип

ригайә ителү – исәпкә алыну, истә тотылу

лязем – тиеш

* «Кораб» (1908) шигыреннән.

хадисәләрнең тәгакыбе тәртибе – вакыйгаларның килү тәртибе

леше мәгънәләрнең төзелешенә тәмам-тәмам мөтәнасиб рәвештә бара. Бик аз сүзләр илә бик бөек мәгънәләрне бирә алу кебек бер имтиязда Дәрдемәндне хаклы иткән бу тәнасеб (бу табигыять, бу тәнкыйх, бу вөзух) өстенә, аның өслүбендә бу имтиязга ярдәм иткән дәхи шундый хасиятләр бар ки, һич булмаса, бер-икесен әйтеп китми мөмкин түгел. Иң әүвәл хәтергә килә аның тәшбиһләре. Бу аңарда бик еш очрый. Ләкин шул дәрәҗәдә мәһарәт илә йөртелә ки, дикъкатьләп карамасаң, тиз генә анда тәшбиһ барын да сизмисең. Ул һәркайчан диярлек тәшбиһнең адатен төшереп калдыра. «Шуның кебек», «тегенең», «моның сынлы», «шикелле», «-дай», «сыман»нарны ул кертми, һәм шул аның мәгънәсенә зур куәт тә бирә, өслүбендәге матурлыкны тагы бер мәртәбә арттыра да.

Мисал өчен югарыда китерелгән мисрагъларның үзләрен үк алырга ярый. «Бәллү»дә буңа гаид дәхи байтак нәрсә бар. Дәрдемәнднең тәшбиһләре безем әдәбиятымыз дөньясында «ихтирагъ диярлек мәртәбәдә мөмтазигъ һәм муаффәкыятьледерләр. Шулай ук Дәрдемәнднең өслүбендәге мусыйкыять илә эшләнүе аз булган татар теле өчен хәйрәттә калдырачак мәртәбәгә ирешкән табигый аһәңе хакында да сөкүт үзәренә кичәргә мөмкин түгел.

Кыйгач кашым,
Асыл ташым!

мөтәнасиб – ярашлы
табигыять – табигыйлек
тәнкыйх – кыскалык
вөзүх – аныклык
тәшбиһ – охшату, чагыштыру, метафора
адат – сыйфатланмыш, ярдәмче сүзләр
ихтирагъ – яңалык, ачыш
мөмтазигъ – үзенчәлекле
мусыйкыять – музыкальлек, аһәңлелек
сөкүт үзәренә кичәргә – дәшми калдырырга

Йоклаек икәү...
Йокла, иркә,
Йокла, бәбкә,
Бәүкәй, бәллү, бәү!
Хублар хубы,
Алма тубы –
Пешкән, тулгансың!
Бу чагында
Син тагын да
Чибәр булгансың.
Алмакаем,
Аппаккаем,
Йоклаек икәү...
Йокла, иркә,
Йокла, бәбкә,
Бәүкәй, бәллү, бәү!
Җилбер, җилбер,
Син бик тилбер –
Күбрәк уйныйсың!
Ал гөлләрне,
Сөнбелләрне
Өзми куймыйсың!
Кил, гөлкәем,
Сөнбелкәем,
Йоклаек икәү.
Йокла, иркә,
Йокла, бәбкә,
Бәүкәй, бәллү, бәү![*]
. . . . . .иләх.

«Бәллү» югарыда сөйләп килгән һәммә кәмальләрне үзендә җыйдыгы кебек, өслүбенең матурлыгы, нәзымының му-

---

хублар хубы – яхшыларның яхшысы
тилбер – тиктормас
[*] «Бәллү» (1909) шигыреннән.
иләх – һәм башкалар

сыйкыяте, гаҗәеп аһәңе илә дә бөтен матбугатымызда беренче урынны аладыр. Аның, укып килгәндә мәгънәнең ачыклыгы, ифадәнең мәфһүмгә мөтәнасиб вә табигыйлеге, сүз вә тәркибләрнең башка һичкемдә күрелә алмаган мәртәбәдә саф вә матур төзелеше өстенә, аһәң вә гармониясе илә шул дәрәҗәдә сихерләнәсең ки, вакыт-вакыт: «Әллә мин маһир музыкант каршысындамы?» – дип шөбһәгә төшәсең.

Дәрдемәнднең һәммә әшгаре диярлек шул тәүсыйфларны күтәрәчәктер. Тик арага «Козгын», «Тәвәккәл» кебек берничә нәрсәне кертергә генә ярамый. Болар бик түбән, начар һәм муаффәкыятьсез улып, кайбер мисрагълары «Кораб» илә «Без» һәм «Бәллү»ләр мәртәбәсендә югары булган Дәрдемәнд каләме ничек боларга тәнәззел итте икән дип аптыратырлык мәртәбәдәдер.

IV

Дәрдемәнднең тәфәккерате хәзин улмак илә бәрабәр, ихатасы гаять киң, шагыйранә тәхыйяләте ерактан һәм югарыдан әйләнмәктәдер... Ул «Бәллү»дә яшь вә фәрештәдәй мәгъсум сабыйның илаһи тәҗәллиләре белән бик аз гына җуанган төсле күренде. Аның каршысында ниндидер бер күңеллелек тапты. Шулай ук Нәваидан алынган «Рәсем»ендә дә:

Тәнкәен ак, түшкәйләрен киң яраткан,
Биткәенең иң очында миң яраткан;
Саклар өчен зифа буен яман күздән,
Чәчкәйләрен аяк белән тиң яраткан! –

әшгар – шигырьләр

тәнәззел итү – түбән төшү

тәфәккерат – фикерләү

хәзин – кайгы, хәсрәт, көенеч

ихатасы – чикләре

тәхыйяләте – фантазиясе

мәгъсум – гөнаһсыз

илаһи тәҗәллиләре – илаһи көчләрнең күңелдә чагылышы

дип, ниндидер бер самими мөляемәт һәм соклану әсәре күрсәтте. Ләкин боларда ул бөтен җанын күтәрерлек шатланып та китә алмады, рәхәтләнеп көлә дә алмады – гүя авыр җәрәхәтле адәм үзенең сызлануын тик бер генә минутка озайтты гына. Минут үтте, аңа тагы үзенең авыр вә хәзин кыяфәте кайтты. Ул берничә мәртәбә:

Югарыга таш ыргыткан җүләрләр
Үз аңкау башларын тишеп үләрләр.
Тишек тапсаң сиңа япкан ишектән,
Үзеңнең ертык аузыңнан көләрләр*,–

кебек һөҗү ясап караган иде. Теге халәте рухия тәэсир итеп, аның һөҗүе мәсхәрә кыйлып көлү булмады, бәлки үзенә бер төрле ачу катыш илтифатсызлык, түбәнсетүчелек килеп чыкты. Һөҗүләрендә дә, соклануларында да Дәрдемәнднең муаффәкыяте ачык күренә. Ләкин болар аңа минутка гына килеп китә торган халәтләр. Ә гомумән ул авыр уйлары, хәзин тойгылары дәрьясындадыр.

Дәрдемәндне укый башласаң, матур язлар, яшел чирәмнәр, агар сулар, нурлы кичәләр каядыр югала да, хыял күгең караңгыланып, каршыңа кызганычсыз табигатьнең үзгәрмәс агымы гәүдәләнеп килеп баса... Ул үзенең каты, салкын вә усал барышына бөтен бәни адәмне шул җөмләдән сине дә эләктереп ала да, куәтле диңгез дулкынына ташланган йомычка кебек сөреп, картлыкка, өметсезлеккә... таба алып китә... Соңра үлемнең мөдһиш тырнагына ыргыта...

Аның тасвиратында бәндә хәят юлында үз теләгәненчә бара торган падишаһ түгел, бәлки язмыш агымының кызга-

---

мөляемәт – ягымлылык

аңкау – ахмак

* «Беренче апрельдә зиярәт портретын җибәргән «дустыма» (Аталар сүзе)» (1910) шигыреннән.

бәни адәм – кешелек дөньясы

мөдһиш – куркыныч, хәтәр

ныч колы... Адәм хәят вә рәхәт эзли, ә табигать-язмыш аңа картлык, үлем хәзерли:

Ничә багълар күңелләрдә тезелде,
Сары юллар булып гамнәр сызылды,
Өмидләр, кем, менеп башка тезелде,
Агарган кыл кебек бер-бер өзелде*.

Бичара адәм, юкка мәшәкать чигеп, «агачны юнма», «кирәк булмас, угыңны як, кил утка», чөнки сине алда икенче нәрсә көтә:

Агарды чәч,
Куарды баш,
Сары юллар сызылды.
Өмидләр, кем...
Өмидләр, кем...
Дәрийгъ бер-бер өзелде...

«Бүзләрем маналмадым»да бу рух тагы киңрәк ачыла. Дәрдемәнд монда бигрәк тә үзе: күңел хәят вә рәхәт эсти, ә фәләк аның һәммә теләгенә каршы бара... Ниһаять, үлемгә китерә...

«Бүзләрем маналмадым». Бунда хәят өстеннән кичеп чыккан мөтәхәссир күңел фәләктән фөрьяд итәдер:

Янды Мәҗнүн, янды Фәрһад – бер янып, ат алдылар;
Мин гариб, мең кат янып та, «янды»га саналмадым;
Уйлаңыз: мәгъшука мең нәр!..

гамнәр – сагышлар

* «Өмидләр» (1912) шигыреннән.

куарды – агарды

дәрийгъ – кызганыч

мөтәхәссир – хәсрәт чигүче

гариб – ят, чит күренгән кеше

Мин гашыйк саналмадым!
Кемгә васләт, кемгә өмид нигъмәтен бирде фәләк,
Мин өмиднең сул кулыннан бер сынык нан алмадым.
Кемгә васләт, кемгә өмид!..
Мин сынык нан алмадым;
Сезне, милләт кызлары, аһ! И өмид йолдызлары!
Таң-сәхәр эзләп-эзләп тә, бер күреп каналмадым;
...И өмид йолдызлары!..
Бер күреп каналмадым!
Кайда бер тау, кайда мәэмүл: чишмәи абелхәят,
Тиз йөгердем, яшь тамыздым – дәрткә дәрман алмадым.
Дәрткә дәрман алмадым!
Биэре милләт маэизәмзәм күзләдем еллар буе,
Җитте дәфнем вакты, кәфнем бүзләрен маналмадым.
...Вәйлә !..
Дәр-и-й-гъ !
Бүзләрем маналмадым!!!

Бу урында кайбер парчаларын китердекем «Бүзләрем маналмадым»ны сәнгате әдәбия вә сәнгате каләм* эзләүчеләр иртә-кичә вирд итсәләр , яңлышкан булмасалар. Мондагы ихатаның киңлеге, киная вә мәҗазларның артык муаффәкыятьлелеге, һәрбер мәгънә вә һәрбер фикерне бирү өчен нинди

васләт – кавышу
нан – икмәк
абелхәят – мәңгелек су чишмәсе
биэре милләт – милләт коесы
маизәмзәм – зәмзәм суы
дәфнем (дәфенем) – (үлеп) җиргә күмелүем
маналмадым – мана алмадым
вәйля! – ни үкенеч!
дәрийгъ! – кызганыч!
* Әдәбият һәм каләм сәнгате.
вирд итү – дога урынына кабатлау
мәҗаз – метафора

сурәтләр алынып та, тел вә өслүбнең рухыңны кол итәрлек дәрәҗәдә булулары – һәрбер әһле каләм өчен гыйбрәт алырлыктыр. «Әдәби вә сәнгате әдәбия» белән гади язмалар арасын аеру өчен бездә Дәрдемәнд илә башка берәүне тәфсилләп чагыштыру зарар итмәс иде.

Дәрдемәнд монда үзенең укучысын шул дәрәҗәдә җиңә ки, син ахыргы сүзләрне үлемнең үз тавышы кебек хис итеп, аның белән бергә:

Вәйлә!..
Дәри-и-йгъ!.. –

дип, фөрьяд итеп җибәрер хәлгә киләсең.

V

Дәрдемәнднең аз сүз вә садә тәркибләр белән нинди бөек мәгънә вә нинди зур куәт аңлата алганлыгын чамалау һәм аның әхвале рухиясенә азмы-күпме якынлашу өчен түбәндәге мисрагълар да ярдәм итсә кирәк:

Ачыдыр күз яше табган, газизем,
Ходаның хөкме бу – юктыр гөнаһым!
Гомерләрдер, яна кальбемдә утлар...
Кичә күр, бер сине көйдерсә аһым![*]

Укыйсың да хәйрән буласың: ничаклы гына сүз, нинди садә кебек тәркибләр – ә бирелгән мәфһүм ни дәрәҗәдә бөек, ачык һәм куәтле...

әһле каләм – каләм иясе
тәркибләр – сүз тезмәләре
табган – табигый
кальбемдә – күңелемдә, йөрәгемдә
[*] Дәрдемәнднең «Игътизар» шигыре.
мәфһүм – мәгънә

Дәрдемәнд хәяткә авыр карый. Вакыйгъдә үлем белән хәятнең һәр икесен дә эченә алган җиһан аңа бигрәк үлем ягы белән күренә, күбрәк каберстанны аңдыра. Дөньяга киләләр, яшиләр... Соңра фәна килә...

Әүвәле хәят, гыймарәт ... Соңра хәрабәлек... Ә Дәрдемәндкә бу ике яклы тормышның әүвәлге ягы ничектер яшерен – аңа соңгылары күренә: үлемнәр, фәналәр, хәрабә, зарлыклар... Бәни адәмнең алгы көннәре вә андагы өмидләре Дәрдемәндкә зәвальгә мөстәгыйд улмак җәһәтләре илә генә күренәләр... Әмма мазый вәйран: анда хәрабәләр, мәкъбәрәләр.

Гасырлар кичте китте... кичте еллар!
Нәбиләр, падишаһлар сөрде дәүран.
Гомерләрдер күчеп кәрван вә кәрван,
Килеп кичте җиһаннан канча илләр.

Ул бөек җанлы нәбиләр, ул куәт вә солтанәтләре белән дөньяны зир вә зәбәр итәрлек падишаһлар, ул үзенең шан вә шәрәфе илә башын гарешләргәчә күтәрдем занында булган олугъ кавемнәр нинди бөек эшләр кыйлмаганнардыр да, ниләр уйламаган вә ниләр өмид итмәгәндерләр... Ләкин... Лә-

---

вакыйгъдә – чынында
фәна – бетү, юкка чыгу
гыймарәт – төзелү, туу
зәвальгә мөстәгыйд улмак – бетә торган
мазый вәйран – үткән-кичкән җимереклек хәлендә
мәкъбәрә – каберлекләр
нәби – пәйгамбәр
дәүран – рәхәт
канча – күпме
зир вә зәбәр итәрлек – астын өскә китерерлек
шәрәф – затлылык
гарше (гареш) – күк
занында булу – дип уйлау

кин адәм зәвал корбаны... Куәт вә шаннары кай мәртәбәгә генә җитсә дә, үлемнән котыла алмаганнар һәм һичкем котылмый:

Сүнеп, вәйран булып мәгъмур тиякләр,
Җир астында тезелде ку сөякләр!..

Исә җилләр... күчә комнар... бетә эз...
Дәрийгъ, мәхзүн күңел, без дә бетәбез!

Көч бездә түгел. Хәятнең падишаһысы да без имәсмез. Без табигать агымының, дөнья китешенең кызганыч коллары гына:

Мөсафир, кем, җиһанга басты ботны,
Биетте ажгырып аны замана...
Өеп чергән өмидне... төртте утны –
Җотып утларны, китте... яна-яна.

«Без» – Дәрдемәнднең беренче диеләчәк шигырьләреннән. Мондагы тәфәккер галәменең ни дәрәҗәдә киң ихаталыгына хәйран булмый мөмкин түгел. Монда бәни адәмнең хәяте мазиясе табигатьнең аңа мөнәсәбәте, гакыйбәтләр, кадәр вә ихтыяре нәзарияләре*, безем дә шул дулкындагы агышымыз, адәмнең хәятендәге муаффәкыятьсезлек трагедияләре – һәрбере әллә ничаклы сәхифәләр, хәтта җилдләр тели торган бик күп тирән нәзарияләр Дәрдемәнднең сихерле куә-

---

мәгъмур – төзек
ку – коры, итсез
тәфәккер галәме – фикер дөньясы
хәяте мазия – «борынгы кешенең башлангыч тормышы»
гакыйбәт – «(шуның) нәтиҗәсе булган хәл» мәгънәсендә
кадәр – такъдир
* Язмыш һәм ирек турында фикер йөртүе.
җилд – том

те белән әллә нинди садә бер шәкелгә әйләндерелгәннәр дә, аның могъҗиз каләме астында берничә юллык шигъри вә мөәссир сүзләр белән мөкәммәл рәвештә тасвир кыйлына алганнар.

Хосусан,

Исә җилләр... күчә комнар... бетә эз,
Дәрийгъ, мәхзүн күңел, без дә бетәбез,–

белән:

Өеп чергән өмидне... төртте утны –
Җотып утларны, китте... яна-яна...–

кебиләр, теләсә бөек вә чуалчык мәфһүмне шул дәрәҗә садә калыпка коеп бирә алу җәһәтеннән булсын, теләсә шул бөек вә мөшкил мәфһүмне бик садә берничә сүз белән матур вә шагыйранә бәян итә алу ягыннан каралсын – һәрхәлдә, андый гаҗәеп тәфәккере алдында да, ул өслүбе кашында да баш имәү мөмкин дәгелдер. Аңларга кирәк ки, шагыйрь тел вә каләм генә түгел – ул баш та, йөрәк тә. Ләкин аның уйлавы, бигрәк тә уйлаганын әйтүе «бу болай, теге тегеләй» дип кенә булмасын, бәлки хыялый яисә табигый сурәтләр, охшатулар аркылы булсын.

Буңа дөрест мисал өчен Дәрдемәнднең «Без»еннән дә муафыйкны табу читен булыр.

Һәр нәрсәне тар рамкаларның беренә кертергә яратучылар Дәрдемәндтә бәлки төзәлмәс бер «пессимист» күрерләр. Аның янына «фаталист», ягъни «җәбрия» идекене дә кушалар. Вакыйган, буңа сәбәпләр дә юк түгел; ләкин мин андый бер тәгаеннән еракмын.

Тик шуны гына әйтә аламын ки, Дәрдемәнднең каләме кая гына барса да, аның эзеннән кызыл өстендә карага охшашлы бер җеп сузылып бара. Ул да шуннан гыйбарәт:

шәкел – форма
мөәссир – тәэсирле
хосусан – бигрәк тә

– Җиһан фани!!! Һәр нәрсә зәвальле!!!

Мәгънәвият гәүдәләнә алса иде, аның хәзин катыш мөтәфәккир кыяфәте әдәбиясендә* шул ике җөмлә эре хәрефләр илә язылмыш булыр иде. Рухындагы шул хосусият тәэсиреннән булса кирәк, Дәрдемәнднең матур вә хәятле язлар, мәсгудиятле якты кичәләр хакында сайрадыгы ишетелми. Дүрт фасылдан тик «Кыш көннәре»н генә тасвир итүе – бу уйны дәхи куәтләмәктәдер. Чөнки кыш чыннан да фәна вә зәвальне иң авыр тәхаттыр иттерә торган күренешләрнең бередер.

Бер-ике юл:

Картайды җиһан!
Гөлләр дә бетте...
Кичмәктә заман –
Кышлар да җитте!
...иләх.

VI

Әнә дәрья... Ялгыз... Тын... Бөек һәм сакит ...

Чыга җил... Күтәрелә давыл... Менә бер вакыт ул үзенең ниһаясез зур саны белән бик акрын гына кузгала башлый... Аның тигез, шома өсте иңеннән-иңенә селкенеп, киң күкрәгендә бөек таулар биергә, дулкыннар йөгерергә тотына... Җил дәвам итә... Көчәя... Дәрья ниндидер куркыныч тавыш белән шаулый, үкерә башлый... Язмышны кем алдан белсен, табигатьнең шундый ачулы вакытында әллә ничаклы кораблар туры киләләр... Җил туктамый... Диңгезнең зур дулкын-

---

мәгънәвият – күренеп тормаган, аң белән генә беленгән эшләр

* Кайгы-хәсрәт катыш уйчан әдиплек кыяфәтендә.

мәсгудиятле – бәхетле, рәхәт

тәхаттыр иттерү – хәтергә төшерү

сакит – тыныч

ниһаясез – чиксез

сан – гәүдә

нары һаман шаулашып йөгерешәләр... Ләкин корабларга башка чара юк: анлар төне-көне баралар.

Анларны ни көтә? Корыга ирешүме? Әллә әҗәлме?

– Анысы караңгы!

Язмышлары табигать вә әхваль агымы кулына тапшырылган бичара бәни адәмнең хәяте дә бик күп җәһәтләрдә шул куәтле дулкыннар илә шауламакта булган дәрьядагы «кораб»ларга охшыйдыр. Дәрдемәнд тә үзенең «Кораб»ы белән шул бөек мәгънәне бирергә уйлый һәм, шөбһә юк, муаффәкъ тә буладыр :

Шаулый диңгез...
Җил өрәдер...
Җилкәнен киргән кораб!
Төн вә көндез
Ул йөрәдер;
Юл бара, ят ил карап...

Бу – табигать диңгезе. Мондагы корабның алгы минуты караңгы: ул, бәлки корыга ирешер, ихтимал, дулкын астына китәр. Җир йөзендә яшәмәктә улган милләтләр, дәүләтләр, илләр дә шундый бер хәлдәдер. Анлар хәят диңгезенә төшерелеп җибәрелгәннәр. Каза вә кадәрнең куәтле җилләре туктаусыз исә, хәят дәрьясындагы «ил» кораблары шул киң сахәдә уйнамакта булган дулкыннар арасында үзләренең хәятләрен саклап килергә мәҗбүрләр. Ләкин бу җиңел эш түгел. Бунда «ил»ләр тәмам ихтыярлы да түгел. Бу минут бер ил бар, иртәгә, кем белә, бәлки, әҗәл кочагына китәр. Һәм гамәлдә шул тәкрар ителеп тә тора... Бар иде бабилләр, куәтле асуриләр! Бар иде дулкыннар өстендә уйный торган финика-

---

муаффәкъ булу – ирешү
каза вә кадәр – бәла, афәт һәм тәкъдир
сахә – ачык урын, мәйдан
тәкрар ителү – кабатлану
бабилләр – Вавилония халкы

лылар ... Бар иде бәни Исраил, Нәмруд һәм фиргавеннәр... Бүген каялар? – һәммәсе шул хәят диңгезендәге куәтле дулкыннар сугуы илә су төбенә сәфәр итмешләр түгелме? Яшәде шәүкәт вә куәтле җиһанны тетрәткән мәдәниятле, сайланмыш юнаннар, бөек Рум дәүләтләре... Вакытында җир йөзендә дәһшәт бирде бу бөек илләр? Һәммәсе дә шул хәят диңгезенең кызганмас дулкыннары эчендә әҗәлләренә йотылмышлар түгелме?

Заман тагы үзгәрде. Хәят диңгезенең хәрәкәте мөдһиш бер хәлгә килде. Корбаннар, фаҗигаләр гадигә әйләнде.

Безне көтә җанмы, әҗәлме – анысы караңгы:

Чыкты җилләр,
Купты дулкын –
Ил корабын җил сөрә!..
Кайсы юллар,
Нинди упкын
Тарта безне җан сорап?!

Дәрдемәнднең әшгаре бүгенгәчә бер мәҗмуга рәвешендә басылып чykканы күренми. Буңа бик вакыт иде.

(Г.Ибраһимов. Татар шагыйрьләре. Беренче бүлем:
Сәгыйть Рәмиев, Дәрдемәнд, Габдулла Тукаев.
– Оренбург: Вакыт, 1913. – Б. 29-48.)

финикалылар – Финикия халкы
бәни Исраил – Исраил халкы, ягъни яһүдләр
юнан – грек
рум – Рим

Җәмал Вәлиди

«Татар шагыйрьләре»

(Әдәби мөсахәбәләр)

...Бездә байтак шагыйрьләр бар, алар үзләренең гомум әсәрләре илә яки күбрәк әсәрләре илә яшиләр һәм моннан соң да яшәячәкләренә күңел ышана. Бу шагыйрьләрне, әлбәттә, әлегә бөтенләй санап чыгып булмый, шулай да әһле фикер вә зәвыктан «бу шагыйрьләр кемнәр?» дип соралса, боларның күбрәге иң элек ошбу өч исемне әйтәчәкләренә күңел ышана: Габдулла Тукаев, Дәрдемәнд, Сәгыйть Рәмиев. Һәм боларны ошбу без язган тәртип белән әйтерләр төсле тоела.

Иштә Галимҗан әфәнде дә гомумияттән еракка китмәгән, үзенең «Татар шагыйрьләре» исеме илә яза башладыгы тәнкыйтенең хәзер басылып чыккан беренче җөзьэ өчен шул өч шагыйрьне алган вә тик алар арасындагы тәнасебне гына әфкяре гомумиянең тәмамилә гакесенә йөрткән: китап Сәгыйть Рәмиев илә башлана, Габдулла Тукаев илә тәмам була. Дәрдемәнд уртада тора. Мондагы тәкаддеме зикринең тәкаддеме хакыйкыйны мөстәлзим булганын, әсәрнең үзен яки безнең ошбу мәкаләне ахырына кадәр укып чыккан кешеләр күрерләр.

әһле фикер вә зәвык – фикерле һәм зәвыклы кешеләр
тәнасеб – бер-берсенә охшау, туры килү
гакесе – киресенчә
тәкаддеме зикри – элек әйтеп үтелгән
тәкаддеме хакыйкый – алда булган хаклык, чынбарлык
мөстәлзим – сәбәпче, тудыручы

...Сәгыйть Рәмиевтән соң Галимҗан әфәнде Дәрдемәндкә күчә вә әдәбиятымызны бер бакча рәвешендә тасвир итеп, Дәрдемәндне ул бакчадагы, үзенең гаҗәеп исе, нәфис сабагы, янып торган ал, кызыл йөзе илә мөмтаз булган бер чәчәккә охшата. Соңра ул ошбу сүзләрне яза: «Бездә язалар, күп язалар, күпләр яза. Язуларында фикер дә бар кебек, фәлсәфә дә кушалар төсле, тормышны да тасвир кылалар шикелле. Ләкин төрлене тели, бигрәк тә күңелләре белән матурлык сөя торган зәүкы тәмәйез ияләрен, күп язулар үзләренең кабалыгы белән туйдыралар. Сәнгатьсез һәм мәдәниятсез улучылыклары белән җанны сыгалар; безем матбугатның кайсы ягына кагылсаң да, мәдрәсә исе килә, шәкертлек вә хәлфәлек күләгәләре күренә. Татар каләменең һәр җирдә тупас эзләр калдыруы үзенең укучыларын «матур сүз» илә гүзәл сәнгать ләззәтләрен милли даирәдә табудан мәхрүм итә. Һәр җирдә аңкыган, мәдрәсә исе белән тел кабалыгы, өслүб тупаслыгы шул дәрәҗәдә туйдыра ки, татар телен сөеп, аның эчендә аз булса да матур яза, нәзек хис итә, хыял вә тойгыларын яңа галәмнән алып, аны нәфис өслүбтә әйтә ала торган бер куәтне, җанның табигый ихтыяҗы кебек эзли башлыйсың. Менә шундый хәләттә булганнар «Шура»да Дәрдемәнднең «Кораб», «Без» вә башка асарен күреп һич шөбһәсез: «Менә татар сәнгате әдәбиясе күгендә яңа бер йолдыз заһир булды!» – димешләрдер».

Безнең матбугатның кайсы гына ягына карасаң да мәдрәсә исе килүе ихтимал ки, хәзерге халәтемездә бик табигый вә заруриі бер хәлдер, чөнки хәятемезнең кайсы гына ягына карасак та, анда мәдрәсә исе аңкый. Без хәятемезне никадәр идеализировать итик дисәк тә, әтрафымызда шул ис аңкып торганда аннан мөтәәссир булмыйча мөмкин түгел. Безнең язучыларның күбесе халык эчендә һәм мәдрәсәдә житешкәннәр, шуның өчен алар йә хиссән вә йә фикрән азмы-күпме

зәүкы тәмәйез – югары зәвыклы
мөтәәссир – тәэсирләнгән
хиссән – хис белән
фикрән – фикере белән

халыкчы. Матбугатымызга, әдәбиятымызга бу тупаслык, бу простойлык халыкчылык илә бергә гайре ихтыяри сурәттә килеп керә. Аполлон өчен шигырь сөйләүче сәнаигы нәфисә каһарманнары күбрәк халык эченнән чыкмый, аларны сонуфе мөмтазә җитештерә. Бездә исә сонуфе мөмтазә юк. Аннан соң хәзерге көндә русларда әдәбият таҗының Пушкиннарда түгел, Толстойлар, Горькийларда булуы да безнең каләмнәрне сәнгатьтән бигрәк халыкка яисә фикергә хезмәткә чакыра. Бу сүзләрдән Дәрдемәнд хакында сәлби фикердә булуымыз аңлашылмасын. Мин Галимҗан әфәнденең аның хакында язганнарына кушылам. Вә Дәрдемәндне мөмтаз бер шагыйремез дип беләм. Ләкин мөнтәкыйд әфәнденең тасвир итдеке бакчада теге гаҗәеп исле, нәфис сабаклы, мөмтаз чәчәк ни дәрәҗә мөһим вә кыйммәтле булса, аңа караганда күп калын вә тупас булган имәннәр, карамалар да үз урыннарында кыйммәтле вә мөһимдерләр. Ярый, тагы мөнтәкыйд әфәндене тыңлыйк:

«Дәрдемәнд фәсыйх яза. Анда әдәби зәвыклеләрнең колагына ят вә ямьсез тоелачак бер сүз очрау мөмкин булмадыгы кебек, чыгышсыз бер лөгать, артык бер хәреф күрергә дә имкян юктыр. Дөрест, анда кайбер вакыт гарәби йә фарси сүзләр булгалый, ләкин бу, нәзым ясарга көчләнүдән фәләннән түгел, аның – бөек мәгънәсен ифадә кылырга ярлы татар теле җитә алмаудан вә шуның кебек мәшруг бер сәбәбе әдәбидәндер. Сүзләрне сайлауда ул шундый бер тәмәйезе табигый күрсәтә ки, алар гүя маһир җәүһәрченең энҗеләре булалар. Бу энҗеләрне тезеп, сүзләрне тәркиб итеп бер җөмлә ясауда ул мөстасна бер урында тора».

Галимҗан әфәнденең бу сүзләрендә без бик зур исабәте тәкъдир күрәмез. Дәрдемәнд өслүб вә тарзы ифадәчә бө-

---

сонуфе мөмтазә – аерым сыйныфлар
сәлби – каршы, тискәре
фәсыйх – матур һәм килешле тел
мәшруг – тыелмаган
тәркиб итеп – тезеп
исабәте тәкъдир – дөрес бәя бирү

тенләй мөстәкыйль вә аерым бер сима. Аның язганнарында татарлыктан килмәгән, үзенә бер төреклек аһәңе бар, ләкин бу төреклек, татарлык булмаган кебек, госманлылык, кыргызлык яки сартлык та түгел, бу Дәрдемәндкә махсус бер төреклек.

Чәчеп сүз дөрләрен, и кил ки мәгъмүм,
Күңел-җан жирләрен ачып, тохым күм!
Агыз яшьләрне, кыйл төшләрне ирваэ,
Бетеп, бер-бер буй атсын нәхле сәүдаэ!
Караңгы төн исә якын ераклар,
Хәзин кальбемне вакла – як чыраклар.

Фәкать моны аның бөтен әсәренә тәгъмим кылып булмый, ул үзенең бөек иҗаты булган «Кораб»та һәм башка байтак әсәрләрендә чын татар. Ләкин теләсә генә ничек язсын, аның билгомум әсәрләрендә кирәк тәгъбир вә ифадәчә, кирәк тәфәккерчә безнең бишенче ел җиле илә килеп чыккан яшь татарлык юк. Ул бу яктан безнең бөтен шагыйрьләрдән аерым тора.

Галимҗан әфәнде Дәрдемәнднең тәфәккер вә ихтисасате хакында әйтә: «Дәрдемәнднең каләме кая гына барса да, аның эзеннән кызыл өстендә карага охшашлы бер җеп сузылып бара. Ул да шуннан гыйбарәт: Җиһан фани!! Һәр нәрсә зәвальле!! Мәгънәвият гәүдәләнә алса иде, аның хәзин катыш мөтәфәккир кыяфәте әдәбиясендә шул ике җөмлә эре хәрефләр илә язылмыш булыр иде».

тарзы ифадә – аңлатып бирү ысулы
дөр – энҗе бөртеге
кил ки мәгъмүм – сагышлы камыш каләм
тохым – орлык
ирва кыйлу – сугару
нәхле сәүдаэ – шашкын гыйшык уты күбәләге
ихтисасат – хис итүләре, сизү, тоюлары
зәваль – китү, бетү, юкка чыгу
мәгънәвият – рухи хәләт
хәзин – кайгы, хәсрәт

Дәрдемәнднең асаре илә таныш булган кешеләр, әлбәттә, монда шөбһә итмәсләр.

Дәрдемәнд һәрбер сурәт мәфтүне вә нәфасәт гашыйкы бер сәнгатькәр түгел. Ул бер шагыйрь булудан бигрәк бер мөтәфәккир. Аның һичбер шигыре юк ки, сине үзе илә әллә нинди фикер вә тасвират дәрьясына өстерәп алып китмәсен. Аның «Кораб»ы фил-хакыйкати тасвире табигать түгел, бәлки үзенең дәрья кеби тәфәккератенә, ихтисасатенә бер символдыр. Ул гаять маһир бер символист. Ул үзенең рәмезләрене шулкадәр муаффәкыятьле вә ихаталы тәрсим итә ки, син аның һәрбер сүзендә хисапсыз мәгънә вә һәрбер ноктасында ниһаясез нөктә күрәсең*.

(«Вакыт» газетасы. – 1913. – 24-26 июль.)

асар – әсәрләре, иҗаты
мәфтүн – үз-үзен онытып сокланучы, гашыйк
фил-хакыйкать – чынлыкта
рәмез – символ
нөктә – сүзнең яшерен, үткен, серле мәгънәсе
* Мәкалә газетада «Җәләй» имзасы белән басылган (төз. иск.).

Габдрахман Сәгъди

Дәрдемәнд

Бу шагыйрьнең лирикалары үзендә тирәнлек белән нечкәлек сыйфаты бергә җыйналган куәтле бер минең татар әдәбиятында беренче иҗаты иде. Аның шигырьләре хистән бигрәк фикер тирәнлеге эченә чумылып, озак төшенүнең җимеше булдылар. Ул әүвәл хис итмәде, төшенде: төшенгәнен хискә әйләндерде. Яисә аның хисләре аркылы фикере түгел, фикере аркылы хисләре туды. Хисләрен ул фикеренә, төшенүенә ияртте. Тукай кебек ул әүвәл хис итеп, шуннан соң уйламады. Әүвәл уйлап, аннан соң хис итте. Сәгыйть Рәми кебек шашкынлы бер хис, дөньяга кискен бер нәфрәт уты эчендә дә чолганып калмады. Шулай ук Сәгыйтьтәге кебек шау-шулы язгы ташкынга охшау да анда юк. Ул бик әкерен, тирән, киң алымлы, бормалы дулкыннар белән аккан бер дәрья шикелле тавышсыз, ләкин гаять кайгылы бер тын белән акты. Аның кайгысы да реакция соңында татар өстенә әүвәлге җәберләрнең кайту хәвефе иде.

Дәрдемәнд Яурупа мәгънәсе белән чын либераль буржуа лиригы иде. Аның шигырьләрендә гыйлемле, мәгълүматлы һәм мәдәнилек тә үсеп җиткән. Ләкин тарихи, мәҗбүри бер һәлакәтне алдан төшенеп өлгергән бер минең ялтыравы күренде.

Шулай да ул моның өчен шашынып, акылыннан язып, аһ ормады. Өзелә-өзелә, сыгыла-сыгыла моңайды. Аның күз яшьләре уйлый-уйлый, төшенә-төшенә түгелделәр. Бу күз яшьләрендә алдагы өмет нуры сүнгән бер сыйныфның – буржуазия сыйныфының күз яшьләре дип аңларга кирәк.

Дәрдемәндтә тагы менә шундый бер хосусият бар: ул фикер-хисләренә, моң-зарларына гомумилек, җиһанилык сыйфатын бирергә тырыша. Гүя ул үзе өчен түгел, «милләт», «ил» өчен һәм аннан да аша китеп, гүя ул бөтен кешелек хәяте өчен, бөтен илләрнең, бөтен кешелекнең юк булып китүе өчен әрнүче булып күренә. Аның өмидсезлеге дә гүя бөтен җиһанның, бөтен «ил»нең өмидсезлеге, аның «Без» шигырендәге:

Гасырлар кичте, китте... кичте еллар!
Нәбиләр, падишаһлар сөрде дәүран...
Гомерләрдер күчеп кәрван вә кәрван,
Килеп кичте җиһаннан канча илләр.
Сүнеп, вәйран булып мәгъмүр тиякләр,
Җир астында тезелде ку сөякләр...
Исә җилләр... күчә комнар, бетә эз...
Дәрийгъ, мәхзүн күңел, без дә бетәбез!!
Мөсафир кем, җиһанга басты ботны,
Биетте ажгырып аны замана...
Өеп черегән өмидне, төртте утны,
Йотып утларны... китте... яна... яна... –

мисрагълары өстенә «Бүзләрем маналмадым» шигыре баштанаяк шуны аңдырды.

Гәрчә мин дә бар саналдым, ил катар сан алмадым;
Илдә йөрдем, хазлар алдым, уйласам – сан алмадым.
Янды Мәҗнүн, янды Фәрһад, – бер янып ат алдылар,
Мин, гариб, мең кат янып та, яндыга саналмадым.
Уйлагыз: мәгъшука меңнәр!..
Мин гашыйк саналмадым!
һәм:
Әйттеләр, кем, бер бәхетсез илгә гашыйксың, фәкыйрь.

ку – корыган, кипкән мәгънәсендә
хаз – гарәпчә сүз булып, өлеш, хисса мәгънәсендә

Бер кызардым, бер бузардым... ни таныйм... таналмадым.
Ни таныйм? Таналмадым...
Сезне, милләт кызлары, аһ, әй өмид йолдызлары!
Таң-сәхәрләр эзләп-эзләп, бер күреп каналмадым!
Әй, өмид йолдызлары!
Бер күреп каналмадым.
Иште җилләр ил эченнән, иртә-кич салдым колак.
Җил-җиләсләрнең моңыннан зәүкы әлхан алмадым, –

дигән мисрагълары мәгълүм бер «ил», «милләт» кайгысы белән сугарылганын аңлаттылар. Болар барысы да аның Сәгыйть кебек индивидуалист түгел, идеализм нигезендә объективист булып һәм җәмәгатьчелек рухында моңланганын, яисә шулай моңланырга тырышканын күрсәтәләр. Аның «Хәят» дигән шигыре дә гүя бөтен кешелек тормышының, бөтен мәдәният хәятенең музыка уеннары күрсәтелгән бер картинасы.

Шулай итеп бу шагыйрь үзенең үзлеген «Зәүкы хәят киткән гасырлар», «калын ил» моңнары, «Хәят» уеннары эчендә яшерен, үзен шулар аркылы күрсәтергә тырыша. Аның мәшһүр «Кораб»ы да шундый ук бер рухта. Анда:

Чыкты җилләр, купты тулкын –
Ил корабын җил сөрә!..
Кайсы юллар, нинди упкын
Тарта безне җан сорап?!. –

дигән мисрагы шуны ачык сиздерә.

Дәрдемәнд реакция заманының романтик-пессимист шагыйре.

Ул татар лирикасында романтизмны, көчле бер пессимизм рухы белән тирәнәйтүче. Ләкин Сәгыйть кебек эзлекле пессимизм белән түгел, иҗтимагый пессимизм рухы белән. Анда без шәхси бәхетсезлектән бигрәк иҗтимагый бәхетсезлектән, «ил» бәхетсезлегеннән зарланганны күрәбез.

Шуның өстенә ул татар лирикасында тирән бер фәлсәфи тамыр үстерде. Икенче төрле әйткәндә, ул фәйләсүф бер лирик һәм фикер шагыйре булды. Аның югарыдагы шигырьләрен алмыйча, тик:

Ул калын ил кем гадәмнән сил булып килмәктәдер,
Шәүкымнар бирмәктә аннан бу вөҗүд ырмагына, –

дигән ике мисрагын алып күрсәтү – үзе генә дә моның өчен җитә.

Дәрдемәнд татар лирикасында көчле символизм һәм декадентлык чаткысын күтәрүче шагыйрьнең берсе, бәлки беренчесе. Бу сыйфат анда Сәгыйтьтәгедән дә ачык күренә. Аның югарыда әйтелеп үтелгән «Кораб»ы белән «Хәят»е моның өчен ачык мисал. «Кораб»та татар халкының авыр тормыш көрәшендә югалу куркынычын тасвир итә.

Дәрдемәнд шигырьләрен тикшергәндә үзенә игътибарны аерып караткан тагы бер як менә шушы: ул Мәҗитләр, Сәгыйть Рәмиевләр кебек «алла», «тәңре», «рабб»лар белән дә чуалмый*. Аның төп иҗатларында болар һич йад ителмиләр. Ул андый бер куәткә сыгынмый да. Бу ягы белән ул үзендә югары дәрәҗәдә бер буржуазиялелеген күрсәтә; юаш булса да, бер дәһрилек рухын сиздертә.

Татар буржуазиясе үзе өчен ике типлы сәнгатьче җитештерде. Чәчмәдә, хикәя, романнарда Ф.Әмирхан булса, тезмәдә Дәрдемәнд булды.

Дәрдемәнд тезмәдә чынлап та татар либераль буржуазиясенең сүз сәнгатьчесе. Ул үзе җырлап, шул ук вакытта үзе музыка уйнап торучы бер сәнгатьчегә охшый. Ләкин аның кулында кыллы музыка юк. Ул музыка тавышы белән үз тавышының җитешсезлеген дә каплаучы түгел. Шуның белән бергә коры сүз уены да ясамый. Ул фикер, хисләрендәге бик

---

* Анда тик:
Ачыдыр күз яше, тәбган, газизем;
Ходаның хөкеме бу – юктыр гөнаһым, –
дигән бер шигырендә, бер мисрагында гына «Хода» сүзен очратабыз.

назик бер музыкавилекне сүз музыкасы белән чынлап та иҗади бер юлда искиткеч бер рәвештә сәнгатьчелек күрсәтеп аралаштыра ала. Аның шигырьләрендә фикер белән сүз, форма белән мәгънә һәм мөндәриҗә бер-берсеннән, гүя, һич аерыла алмый торган бер нәрсә; андагы тулы аһәң дә шул икенең нык берләшә алуыннан туган эчке, самими бер музыкавилек булып чыга. Кыскасы, форма белән мәгънәнең мөндәриҗәнең берләшүе анда һичкем инкяр итмәслек бер дәрәҗәдә матурлык күрсәтә. «Сәнгать сәнгать өчен» нәзариясе нигезендә шигырь иҗат итүдә татар әдәбиятының тезмә бүлемендә Дәрдемәнд шигырьләре иң ачык бер мисал була алалар.

Дәрдемәнд иҗатында сүзләр шул дәрәҗәдә бер осталык белән сайланган була ки, аның сүзләрен икенче сүзләр белән алыштыру һич мөмкин булмый. Сүз һәм җөмләләрнең корылыш һәм төзелешләрендә гаҗәеп бер эчке багланыш күренә, бер сүз яисә бер җөмләнең үз урынын алмаштыру дигән сүз – ул Дәрдемәнд шигыренең бөтен бинасын җимерү дигән сүз булачак. Кыскасы, ул тел-өслүб, вәзен техникасында зур бер оста, олы бер специалист булып чыкты.

Ләкин бу техника, бу осталык югарыда, үз урынында, әйтеп үткәнебезчә, нәгыз татар теле рухында түгел иде. Гарәп сүзләре, фарсы теле өслүбенчә сүз оештырулар аның шигырьләренең тамырында ята. Тик шунысы бар: болар башка шагыйрьләрнең шигырьләрендәге шикелле, коры вәзен, бетем (кафия) ясау өчен генә китерелми. Алар, гүя, шагыйрьнең фикер һәм хисләрен үзе теләгәнчә тулы һәм аһәңле итеп аңлату өчен зур бер шигъри хезмәт үтиләр. Шуның белән алар Дәрдемәнд шигырьләре өчен бик табигый рәвештә матур тезеләләр.

Кыскасы: «Үзенең коелган корыч кебек өслүбе, тирән мәгънәсе, һичбер шагыйребездә булмаган аһәңе-музыкасы белән татар әдәбиятында бөтенләй аерым ялгыз торган шагыйрь – Дәрдемәнд»* булды. Ул һәр ягы белән октябрьгәчә

* Г. Ибраһимовның «Татарстан» гәзитендә 1922 елда Дәрдемәнд вафат булгач язган «Еллык хисаб»ыннан.

булган ун ел эчендә татар классикларының да иң көчлесе булып калды.

Дәрдемәнд татар лирикасында үзенә аерым бер мәктәп, аерым бер агым тудырды. Аның шәкертләре, иярченнәре дә булды. Фиракый һәм беренче адымнарында Кәрим Әмири*, тагы башкалар шул мәктәпкә мәнсуб иделәр.

Ләкин Дәрдемәнд үзенең шушы җитешлекләре белән бергә, шөбһәсез, татарның массасыннан, укымышлыларыннан, эшче-крәстияннән, аның теләк һәм кирәкләреннән тәмам читтә торган бер сәнгатьче иде. Идеологиясе, мөндәриҗәсе, рухы, теле-өслүбе белән дә ул аңа һич якын түгел. Шуның өчен дә татар массасы аның шигырьләрен турыдан-туры үзе аңлап укып таный алмады. Аның танылуы тар бер түгәрәктә, әдәбиятчылар, укымышлылар арасында гына калды. Әле дә эшче-крәстиян массасы аны таныса да, тик тәнкыйтьләр, аңлатулар аша гына таный алачак.

Ул шәп шагыйрь, классик шагыйрь, ләкин эшче-крәстияннеке түгел; буржуа сыйныфыныкы. Ул бөтен мәгънәсе белән буржуа тупрагыннан, шуның «үзәге»ннән ярып чыгып үскән; шуның һавасы эчендә тәрбияләнеп, шуңа яраклы җимеш биргән бер шагыйрь. Шуңа күрә ул һәм аның шигырьләре

---

* Кәрим Әмири башта үзенең Дәрдемәнд шикелле үк нечкә уйлап караучылык һәм аның өслүбендә язучылык тәҗрибәсе заманында:

«Очар кош! Оч, канат как! Үрлә күккә,
Сәгадәт талларын күктән табарсың...
Үләксә тупрагы җир гөлләрендә...
Бәхет юк, анда тик кортлар табарсың.»

вә:

«Заманага аяк баскан мөсафир
Тирән сазга кереп батып адашса,
Юлын тапмак насыйпмы ул гарибкә,
Сүнәр шәм берлә эзләргә маташса», –

дигән фәлсәфи шигырьләре өстенә, хәтта 1921 елда да әле:

«Әй, ләтыйф җил, ни сөйлисең бөдрә тал яфрагына?
Шатланыпмы җилферди ул – баш орып як-ягына.
Сөйлә җил, ач эч сереңне,
Сүз бирәм сакларыма», –

рәвешендә, Дәрдемәнд телендә, аның өслүбендә язуны ташламаган иде.

хәзерге өчен үзенең идеологиясе, мөндәриҗәсе, теле-өслүбе белән файдалы бер иҗат булып түгел, бәлки тик тарихи хадисә, тарихи бер факт булып кына тикшерелә ала.

Аның теле дә, техникасы да турыдан-туры татар хәятенә ашарлык түгел; хәзер инде аның теле тормыш теле булудан бигрәк тә ерак тора. Аның шигырьләренең хәзер дә безнең өчен әһәмияте тик ике яктан гына. Берсе – алар татар әдәбиятында чын сәнгатьчә эшләнгән иң аһәңле, иң икътисадлы бер өслүб өчен ачык бер үрнәк, икенчесе – фикер, фәлсәфә лирикасыннан, алар, Яурупа мәгънәсе белән матур, тирән мөндәриҗәле бер иҗат булып торалар. Дәрдемәнд лирикасының татар әдәбиятында, татар әдәбият тарихында гомере әнә шушы ике ягы белән тәэмин ителә. Нечкә, матур, тирән фикернең музыкалы бер тел аркылы бик зур бер осталык белән бирелә алуы – менә Дәрдемәнд лирикасының татар әдәбиятында бөтен кыйммәте шуннан гыйбарәт. Аңа шуннан башка кыска бер тәгъриф тә юк.

(Габдрахман Сәгъди. Татар әдәбияты тарихы:
дәреслек-кулланма. – Казан: Татар. дәүләт нәшр., 1926.
– Б.231-236.)

Гали Халит

Шагыйрь иҗатында дөнья һәм тарих концепциясе

1

XX йөз башы татар поэзиясендә Дәрдемәнд (Закир Рәмиев) үзенең иҗат юнәлеше белән дә, иҗтимагый хәле белән дә үзенчәлекле шагыйрьләрнең берсе. Г.Тукай, М.Гафури, С.Рәмиев, Н.Думави, З.Бәшириләр кебек, яңа гасыр башында азатлык өчен барган көрәшләргә таң калып һәм шуңа булган шатлыкларын шау-гөр килеп җырларга ашкынган әдипләрдән ул нык аерылып торды. Аның үз шигъри кушаматын Дәрдемәнд – «Хәсрәт чигеп яшәүче» дип алуы ук шундый давыллы чорда шактый сәер тоела иде.

Ул алтын приискалары тоткан Рәмиевләрнең берсе булып, алар «яхшы йортлар салдырганнар, яхшы атлар җиккәннәр, байлыкка, рәхәткә чумганнар»[*]. Шуңа күрә шагыйрь үз сыйнфый дәрәҗәсен һәм зур материаль көчкә ия булуын шактый тирән аңлап, аны шигырь белән төгәл итеп әйтүдән һич тә тартынмаган:

Әгәрчә дәүләтем юктыр җитәрлек,
Ишәктәй һәм йөк астында түгелмен.
Үзем башмын, үзем түш һәр эшемдә,
Тынычлыкта торамын, хуш күңелмен[**].

---

[*] Ф.Кәрими истәлегеннән // Дәрдемәнд әсәрләре. – Казан, 1928. – Б.11.
[**] Дәрдемәнд. Сайланма әсәрләр.– Казан, 1959. – Б. 89.

Үзен әнә шундый югарылыкта торучы асыл зат дип хис иткән һәм яшәвеннән тәмам канәгать шагыйрьнең сәнгатькә карата да беренче таләбе –«Матур гөлләргә бул былбыл, нәзакәт багына сакчы» («Шагыйрьгә», 1907) рәвешендә булды һәм бик ачык төстә «түбән чынбарлык» белән бәйле поэзиягә каршы куелды. XIX йөзнең икенче яртысы рус поэзиясендәге шикелле (монда Тютчев, Фет һәм Некрасов иҗатлары күздә тотыла), XX йөз башы татар поэзиясендә дә «матурлык поэзиясе» (яки «саф» поэзия) һәм «тормыш (яки гражданлык) поэзиясе» концепцияләре мәйданга чыкты. Шагыйрьнең тормышка һәм халыкка мөнәсәбәте мәсьәләсе төп критерий булып әверелде.

Дәрдемәнд тормыш ваклыгыннан, аның көндәлек бурычларыннан саф һәм югары булган сәнгатьне күпме генә якламасын, – тарихка, үз заманына, тормышка һәм кешегә мөнәсәбәт күрсәтүдән читтә кала алмады. Чөнки ул да, бик күпләр шикелле үк, үз чорының гаять катлаулы, каршылыклы тарихи-иҗтимагый шартларында яшәгән һәм үз язмышы өчен көрәшкән конкрет бер сыйныф идеологы булудан ваз кичә алмый иде. Шулай итеп, татар поэзиясенә өстен сыйныфлар, аеруча буржуаз даирәләр белән турыдан-туры һәм тыгыз бәйләнештә торган шагыйрь килде.

Нинди яңалык алып килде соң ул безнең поэзиягә? Бу сорауга җавап бирү юлында татар әдәбият белеме кайбер уңышлы тәҗрибәләр ясап карады инде. Шулай да Дәрдемәнд поэзиясенең «серләре» тулысынча ачылган һәм аларның төз системасы табылган дип булмый әле. Бу «серләрне» беренче мәртәбә күпмедер күләмдә кыю итеп ачарга теләгән тәнкыйтьче Г.Ибраһимов булды. Аның 1913 елда басылган «Татар шагыйрьләре» исемле хезмәтендә Тукай, С.Рәмиев һәм Дәрдемәнд кебек өч зур шагыйрьнең үзенчәлекләрен күрсәтү нияте белән кызыклы гына фикерләр әйтелгән иде. Бу әсәрнең Дәрдемәндкә караган өлешендә:

«Аның тасвирында бәндә, – ди тәнкыйтьче, – хәят юлында үз теләгенчә бара торган падишаһ түгел, бәлки язмыш агышының кызганыч колы...» «Дәрдемәнд хәяткә авыр ка-

рый. Вакыйгъдә үлем белән хәятнең һәр икесен дә эченә алган җиһан аңа бигрәк үлем ягы белән күренә, күбрәк каберстанны аңдыра»*.

Шагыйрьнең дөньяга карашын тулысынча өметсезлек караңгылыгында калган итебрәк сурәтләү белән килешү, бәлки, мөмкин дә түгелдер, әмма китерелгән өзектә Г.Ибраһимовның Дәрдемәнд поэзиясе үзәгеннән фәлсәфи караш һәм лирик настроениене шактый төгәл формалаштыру бәхәссез. Бу настроение үзенең төп юнәлеше белән дөнья әдәбиятларында булып үткән романтизмны искә төшерә. Чыннан да, шагыйрьнең иң беренче әсәрләреннән саналган «Үткән көннәрдә» шигырендә әнә шундый настроение бар. Монда, үткәннең матурлыгын сагынып, аны бүгенгегә куеп үкенү шикелле элегик мотивлар өстенлек итә. Шуңа күрә бу шигырьне романтик поэзиягә бик характерлы элегиянең бер үрнәге дип атарга мөмкин. Дәрдемәнд лирикасында элегиянең фәлсәфи һәм идиллик төрләре зур урын тота. Аның да лирик герое дөнья, тормыш, тарихи барыш һәм кеше турында тирән сагыш, хәсрәт тойгыларына дучар.

Заман яшәргәндә, яңарганда һәм күп әдипләр шуңа сөенгәндә, чынбарлыкны тамырыннан үзгәртүгә ышанып иҗат иткәндә, Дәрдемәнд бөтенләй киресен җырлады:

Нә алтын, бәлки балчык бу замана,
Беләлмим, кемгә тансык бу замана.
Уенчык, яшь иде яшьлек көнемдә,
Бүген карт, бәлки карчык бу замана**.

(«Замана», 1906)

Шулай итеп, үткән заманнарның матурлыгын сагынып, яңа, яшь заманны картайган санап, шагыйрь революцион чынбарлык белән каршылыкка керде. Мондый хәлнең нигезендә, барыннан да элек, тарихи пессимизм ята иде.

---

* Г.Ибраһимов. Әсәрләр: сигез томда. 5 т. – Казан, 1978. – Б.103, 105.
** «Вакыт». – 1906 ел. – 13 апрель.

Дәрдемәнд – үзенең иҗтимагый хәле белән зур тарихи катастрофалар кичергән шагыйрь. Ләкин ул үз сыйныфының сукыр колы гына түгел, ә күпмедер дәрәҗәдә аңардан югары торган һәм тарихи катастрофалардан үз сыйныфының да котылгысыз икәнлеген аңлаган художник-идеолог буларак, тарихи трагедияне һәм зур чынбарлыкны аңларга теләүдә активлык күрсәтүче дә иде.

XX йөз башы татар поэзиясен кеше һәм дөнья проблемасы биләп алды. Бу проблеманы инде хәзер тарих, ил һәм халык мәсьәләләреннән читтә күз алдына китерү һич тә мөмкин түгел иде. Шул проблема һәм мәсьәләләр Дәрдемәнд иҗатының да үзәгендә. Әмма шагыйрь аларны бик үзенчәлекле һәм үтә каршылыклы хәл итте.

Иң әүвәл аның 1908 елда, ил тарихындагы һәм халык тормышындагы бик авыр бер чорда – Столыпин реакциясе котырган вакытларда язылган «Кораб» һәм «Без» кебек шигырьләрен искә төшерик. Бу шигырьләрне кайсы гына якка борып карасаң да, аларның үзәгеннән үтә торган бер фикер – тарихны, заманны ничек аңлау, бәяләү шактый ачык. Дөрес, бигрәк тә «Кораб» шигыренә карата әдәбият белгечләре арасында төрлечәрәк фикерләр күренгәләде; ихтимал, тагын да күренер әле. Хәтта кайберәүләр аннан Россия өстенә «якынлашып килә торган яшенле күкрәү» тавышын ишетергә һәм Горькийның «Давыл хәбәрчесе» белән тиңләштерергә дә теләгәннәр иде (мәсәлән, П.Коган мәкаләләре). Әмма шагыйрь үзе үк нәкъ 1908 елда «Бүзләрем маналмадым» шигырендә:

Мин өмиднең сул кулыннан
Бер сынык нан алмадым...–

дип икърар иткән иде. Димәк, Россия эченнән узган революцион җил-давыллардан ул өметләнмәгән дә, ләззәтләнмәгән дә икән. Әйе, Дәрдемәнд Россияне тетрәткән иҗтимагый үзгәрешләр турында сөйли һәм революцион давылларның дәһ-

---

нан – икмәк, ризык

шәтле көч икәнен бик яхшы аңлый. Әмма шуннан чыга торган нәтиҗә нидән гыйбарәт? Бу сорауга: «Ил корабын җил сөрә!.. Нинди упкын тарта безне җан сорап?!» дигән аптыраулы җавап бирелә «Кораб» шигырендә. Җил, давыл, дулкынланган диңгез, әлбәттә, тарих стихиясен гәүдәләндергәндер, һәм ул бигрәк тә романтик әдәбиятларда күп кулланылган шартлы-традицион сурәтләр. Алар романтик поэтиканың аерылмас атрибутлары булып килде. Дәрдемәнд тә аны шундый сыйфаты белән файдалана.

Дәрдемәнд фәлсәфәсенең сурәтле формасы – табигать символикасы. Дөнья, тарих, тормыш – бер дәрья, океан, диңгез ул. Шуның шикелле, дөнья да котырына, дулкынлана. Тарих диңгезе дә мәрхәмәтсез – беркемне дә, бернәрсәне дә кызганмый.

Әнә шул котырган стихия корабны, илне, гомумән, тарихны кая алып бара? –шагыйрьне шундый сорау борчый. «Без» шигырендь тагын да конкретрак итеп:

Исә җилләр, күчә комнар... бетә эз...
Дәрийгъ, мәхзүн күңел, без дә бетәбез, –

диелә. Шулай итеп, искә алынган шигырьләрдән чыга торган төп идея – тарих барышы илләр, халыклар һәм кешеләр язмышын рәхимсезлек белән хәл итә – мәңгелек комы белән күмә диюдән гыйбарәт. Мондый караш, әлбәттә, тарихи барышка өметсезлек белдерә, язмышка каршы тору мөмкин түгеллеген раслый. Анда фатализм, язмыш, тәкъдир фәлсәфәсе өстенлек итә.

Әлбәттә, Дәрдемәнд пессимизмының аеруча кискен булып чагылышында Беренче рус революциясеннән соңгы реакция чынбарлыгының ролен дә истә тотарга кирәк. Аның әнә шулай артык куе төстә гәүдәләнешенә Россияне буйданбуйга баскан, буган, аскан-кискән Столыпин вәхшәте үзенең билгеле тәэсирен ясамый калмагандыр. Шуңа күрә

дәрийгъ, мәхзүн – аяныч, кайгылы

Дәрдемәнд фәлсәфәсендәге, аның тарихка мөнәсәбәтендәге өметсезлек, гомумән, реакция елларындагы татар әдәбиятында сизелгән төшенкелек настроениеләре белән уртак күренеш иде. Әмма Дәрдемәнд пессимизмының эчтәлеген реакция елларына мөнәсәбәт белән генә, шул җирлеккә кайтарып калдыру белән генә чикләп булмый. Тулаем алганда, бу фәлсәфәнең асыл мәгънәсе – аерым милләт, кеше, ил язмышы гына түгел, ә бөтен кешелек язмышы тарихының мәрхәмәтсез стихиясе алдында көчсез булуын күрсәтергә теләгән космик пессимизмга кайтып кала. Бу пессимизмның төп мәгънәсе – бөтен дөньяның һәм шуның белән бергә җәмгыятьнең бер һәлакәттән икенчесенә котылгысыз рәвештә барырга тиешлеге хак дип өметсезлеккә бирелүдә. Дәрдемәндкә карата үз вакытында Г.Сәгъди бу фикерне түбәндәгечә формалаштырган иде: «...Ул фикер-хисләренә, моң-зарларына гомумилек, җиһанилек сыйфатын бирергә тырыша. Гүя ул үзе өчен түгел, «милләт», «ил» һәм аннан да китеп, гүя ул бөтен кешелек хәяте өчен, бөтен илләрнең, бөтен кешелекнең юк булып китүе өчен әрнүче булып күренә. Аның өмидсезлеге дә – гүя бөтен җиһанның, бөтен «илнең өмидсезлеге»*. Шуңа күрә дә шагыйрь үзенең бүгенге тыныч, матур тормышыннан, рәхәтеннән күпме генә канәгать һәм материаль өстенлегеннән никадәр генә риза булмасын, ахыр чиктә, ул үзе дә, бөтен дөнья, галәм, тарихның фаҗигале барышы белән чыгыштырганда, бик мескен, кызганыч җан иясе булып калуын икърар итәргә мәҗбүр:

Зәгыйфь кырмыскамын мин юлда яткан,
Түгел бал корты мин чагып елаткан.

Галәмгә традицион-фаталистик фәлсәфә ноктасыннан караучылар гадәттә кешене бик кечерәйтеп күрсәттеләр. Көнчыгыш әдәбиятында да бу караш гасырлардан гасырларгача кабатлана килде. Дәрдемәнднең дә кешене кырмыскага ча-

* Г.Сәгъди. Татар әдәбияты тарихы. – Казан, 1926. – Б.232.

гыштыруында шул рухтагы космизм бар: кешенең шундый дәрәҗәгә төшерелүе, әлбәттә, галәмнең зурлыгына, очсыз-кырыйсызлыгына һәм һичбер көчкә буйсынмас булуына нисбәтән күз алдына китерелә. «Галәм һәм кеше» фәлсәфәсе бер Дәрдемәнднең генә түгел, башка татар әдипләренең дә игътибарын биләде. Мәсәлән, М.Гафуриның: «Чиге юк бу галәмнән бер кисәкмен», – диюендә шул фәлсәфә чагылды («Кояш баеганда», 1909). Шул рәвешчә, татар поэзиясендә космик лиризм урын алды. Дәрдемәнднең әле генә искә алынган шигырендә шагыйрь шәхесенең реаль тормыштагы хәле белән аның рухи дөньясы кичерешләре, фәлсәфәсе арасында гаять тирән чоңгыл, аралык барлыкка килә. Әнә шул чоңгылда инде котылгысыз бер каршылык та ятса кирәк. Тукай, Гафури, Рәмиевләрнең лирик геройлары белән чагыштырганда, Дәрдемәнд героеның тавышы һәм горурлыгы шактый тонык булып калачак. Беренче төркем шагыйрьләр тудырган лирик геройларның барысына да:

Баш имә, зур син, – бу әдна җанлылар дөньясына
Падишаһ син! Бик кирәксә, баш исен дөнья сиңа, –
(Г.Тукай. «...гә (Ядкәр)», 1908)

кебек горурлык, ягъни кешенең явыз чынбарлыкка баш имичә яшәү һәм иҗат итү хисе уртак. Димәк, алар кеше горурлыгын һәм язмышын яклап көрәшкә күтәрелгән трагик герой образын пьедесталга бастырдылар. Мәсәлән, С.Рәмиев герое ләгънәтләнгән дөнья белән котылгысыз конфликтка керә, әмма ул үзен һич тә язмыш колы итеп санамый, кечкенә бер җан иясе дәрәҗәсенә дә төшми, ә үзендә һичбер явызлыкка буйсынмас демонизм сизә. Ул кызганыч түгел, ә үз идеалы, үз азатлыгы өчен көрәш юлында һәлак булудан курыкмаган актив трагик герой. Беренчел романтик сыйфаты да аның менә шунда. Ә Дәрдемәнднең лирик герое – мелодраматик герой. Аңарда явызлык белән бәрелештә туган трагизм юк. Ул

әдна – түбән

пассив, ягъни язмыш каршында баш ияргә өнди. Шуңа күрә дә шәхес трагедиясенә шагыйрьнең югары бәя бирүе хакында сөйләү өчен Дәрдемәнд поэзиясеннән җирлек табу шактый читен. Тукай яки С.Рәмиев лирикасында аерым шәхес трагедиясе турында сөйләргә мөмкин. Аларның икесендә дә трагик настроение Беренче рус революциясе җиңелгәннән соңгы авыр иҗтимагый-политик шартларны газаплы кичерү белән бәйләнгән иде. Бу яктан алар икесе дә билгеле тарихи чор трагедиясен кичергән конкрет шәхес буларак алга басалар, шул яктан бер-берсенә якын торалар. Чор трагедиясен поэтик шәхес, лирик герой нинди позициядән аңлады һәм кичерде? – дигән сорауны куйганда инде, Тукай белән Рәмиев арасындагы аерма турында сөйләү таләп ителәчәк, әлбәттә. Кыскача гына әйткәндә, беренче шагыйрьдә чынбарлыкны аңлау һәм хис итүнең тарихи-объектив колачы киң, иҗтимагый пафосы көчле булса, икенчесендә исә чынбарлыкка субъектив мөнәсәбәт өстенлек ала. Әмма ике очракта да, әйтелгәнчә, шәхес трагизмының конкрет тарихи шартлар һәм сәбәпләр белән бәйләнеше ачык иде. Ә Дәрдемәндкә карата мондый фикер бик абстракт һәм дәлилсез булып кына калачак. Әйе, кешелек кичергән һәм кичерәчәк тарихи процессның котылгысыз икәнлеген ул аңлый. Әмма аны тоташ фаҗига һәм кешедә аңа каршы торырлык көч юк дип карый.

2

Тормыш һәм тарих серләренең фатальлеге, халыктан, кешедән өстен һәм көчле булуы турындагы фәлсәфәнең тамырлары бик борынгы заманнарга китә. Дәрдемәнд, бер яктан, Көнчыгыш әдәбиятларында күп гасырлар буе кабатланып килгән традицион фәлсәфәгә теләктәшлек итә:

Галәм өчен, әйтче, кеше, син кем генә?
Синең яшәү – барлы-юклы төтен генә.

Үлем һаман упкын әле, төпсез упкын,
Төштең киттең һәм мәңгегә беттең генә*, –

(Х.Туфан тәрҗемәсе)

дигән урта гасыр Көнчыгышының даһи шагыйре Гомәр Хәйям (1048-1132), һәм мондый фәлсәфә бөтен дөнья әдәбиятларында урын алган. XVIII йөз рус поэзиясе вәкиле Херасков кына түгел, аннан соң, ягъни XIX йөздән инде Герцен, Белинский, Чернышевский кебек сугышчан материалист әдипләрнең, философларның эшчәнлекләре киң колач алган заманда, Фет һәм Тютчев кебек күренекле шагыйрьләр шул рухтагы фатализмны, язмыш фәлсәфәсен тагын да нечкәртелгән төстә җырладылар. Алар кешенең табигать һәм тарих законнары каршында көчсезлеген әйтергә теләде. Гомумән, романтик әдәбиятта һәм аның геройлары тормышында язмыш зур роль уйный торган серле көч итеп каралды. Язмыш образы Лермонтов поэзиясенә дә чит түгел. XX йөз башы татар поэзиясендә дә аның тирән эзләре калган.

Мондый фактларны истә тотканда, Дәрдемәнд җырлаган традицион-фәлсәфи идеяләр аны Көнбатыш әдәбияты, бу очракта, конкретрак алганда, Фет һәм Тютчев белән билгеле күләмдә якын куеп, чагыштырып фикер йөртергә дә мөмкинлек бирә. Дәрдемәнд белән, мәсәлән, Тютчев арасында дөньяны һәм тарихны аңлау ноктасыннан зур якынлык бар. Тютчев иҗатында «гүяки тарихи акланышы булмаган котылгысызлык, язмыш, илаһи кодрәт төшенчәләре беренче планга этәрелде»**.

Тарихи фатализм концепциясе – XX йөз башында да шактый таралган күренешләрнең берсе. Шуңа күрә Дәрдемәнд аның чагылышын тик борынгы, традицион бер идеяне кабат тергезү, яңарту дип кенә карау тулы булмас. Тарихи язмышның котылгысызлыгына ышану, әйтелгәнчә, романтизм әдә-

* «Көнчыгыш шагыйрьләре»: җыентык.– Казан, 1959. – Б.171-172.
** Л.К. Долгополов. Тютчев и Блок // «Русская литература». – 1967, – №2. – С.66.

биятында еш очрый. Бу идеяне символистлар да үзләренчә дәвам иттерделәр, аңа үз фәлсәфәсен салдылар. Мәсәлән, Вл. Соловьев бөтен дөнья тарихының соңы турындагы теорияне тәкъдим итте. Бу төр пессимизм астында тарихны яңарта торган революцион көчләрнең килүен аңламау яки күрмәү генә түгел, бәлки инкяр итү ята иде. Символизм идеологлары трактовкасында тарихи язмыш фатализм концепциясе мистик, реакцион эчтәлек алды.

Шул ук вакытта символизмның А.Блок шикелле вәкилләре, тарихи катастрофа, һәлакәт теориясен һәм пессимизмын кабул итмичә, кешелек тарихының яңадан корылачагына, моны түбәннән күтәрелүче көчләр тормышка ашырачагына һәм дөнья тарихи процессының гармониясе булуына өмет белдерделәр. Блок фикеренчә, «тарих көчләрендә фаталь характер бар. Тарихны тыеп булмый. Тарих кешелекне яңа эпохага китереп җиткерде. Кеше инде аңа каршы торырлык хәлдә түгел...»*

Дәрдемәнднең дә тарихи котылгысызлык концепциясендә Блок белән билгеле төстә аваздашлык, якынлык шиксез кебек. Аңарда да тарихның барышын, үзгәрешен, яңарышын инкяр итү түгел, ә зарури, котылгысыз дип ышану сизелә. Аның бигрәк тә табигать лирикасыннан шундый тойгы тибеп тора. Блоктагы кебек үк Дәрдемәндтә дә табигать дөньясындагы гармонияне табарга омтылыш бар. Бу тенденция исә шагыйрьнең чынбарлыкка мөнәсәбәтендә оптимистик башлангычка да юл калдыра.

Чыннан да, егерменче еллар азагында ук инде Г.Нигъмәти кебек тәнкыйтьчеләр Дәрдемәндкә гел өметсезлек кенә хас булмавын, аңарда үзенчәлекле оптимизм барлыгын да күрсәтеп киткәннәр иде: «Өмитсезлек дөньяга карашы Дәрдемәнд иҗатында беренче урынны алган мотив түгел»,** – дип расларга батырчылык итте Г.Нигъмәти һәм шушы фикеренә дәлил итеп «Хәят» шигырен китерде. Тәнкыйтьче бу мисалда

* Л.К. Долгополов. Поэмы Блока и русская поэма конца XIX – начала XX веков. – М., Л., 1964. – С.110.
** Дәрдемәнд әсәрләре. – Казан, 1929. – Б.22.

шагырьнең тормышка «зур мактаулар яудыруын, аны мактавын» һәм «тибеп, ашкынып торган оптимизмын» күрде. Әмма озак еллар өстенлек иткән фикер Дәрдемәнд поэзиясен тоташ пессимизм итеп бәяләргә тырышудан гыйбарәт булды. Соңгы елларда исә Дәрдемәнд дөньяга карашының ике ягын – аның пессимизмын да, оптимизмын да күрергә, боларның нидән гыйбарәт икәнлеген аерып аңлатырга омтылыш алга чыкты[*].

Дәрдемәнднең дөньяга карашында урын алган ике капма-каршы башлангычның – пессимизм һәм оптимизмның барлыгына, аларның янәшә, бергә яшәвенә игътибар итү нигезсез булмаса кирәк. Әмма бу ике башлангычның, идея-философик тенденцияләрнең бер-берсе белән сыешуын ничек аңларга? Әйе, Дәрдемәнд – тарихи барышка фәлсәфи карашы белән пессимист, әмма шагыйрь-художник буларак, чынбарлыкка мөнәсәбәтендә, аны хис итүендә шул фәлсәфә кысаларында гына бикләнеп кала алмый. Аның реаль чынбарлыкка эстетик, сәнгатьчә мөнәсәбәте субъектив-сыйнфый аңыннан көчлерәк һәм киңрәк.

Дәрдемәнд пессимистик фәлсәфәсенең бик борынгыдан килүен һәм бөтен дөньяга билгеле икәнлеген әйткән идек инде. Тагын да борынгыны искә төшереп, башлыча оптимист, көр күңелле шагыйрь буларак дан казанган һәм шул ук вакытта дөньяның фанилыгын, язмышның мәрхәмәтсезлеген җырлаган Гомәр Хәйямгә мөрәҗәгать итик:

От стрел, что мечет смерть, нам не найти щита:
И с нищими и с царем она равно крута.
Чтоб с наслажденьем жить, живи для наслажденья,
Все прочее – поверь! – одна лишь суета.[**]

(О.Румер тәрҗемәсе)

---

[*] Нуруллин И.З. Путь к зрелости. – Казань, 1971. – С. 172.
[**] Омар Хайям. Четверостишия. Библиотека журнала «Азия и Африка сегодня». Вып. II. – 1971. – С. 6.

Әйе, Дәрдемәнд поэзиясендә дә әнә шундый ике яклы фәлсәфә – язмыш алдында барысы да көчсез, әмма шулай да яшәүнең тәмен, рәхәтен татып дөньядан китәргә кирәк дигән фәлсәфә әледән-әле лейтмотив булып сызылып бара.

Ни гамь – бөлсәм, әгәр үлсәм – ни ваем,
Эчеп дуслык шәрабыннан исерсәм,
Булып дуслар белән берлектә даим,
Гомернең тиз үтәр язын кичерсәм, –

(«Ни гамь бөлсәм...»)

ди шагыйрь һәм аңа икенче бер шигырендә («Нәсихәт») дөнья атын йөгәнләп, аңа атланып яшәү һөнәрен белергә, тапталып яшәмәскә чакыра. Әлбәттә, Г.Хәйям фәлсәфәсе белән Дәрдемәнд фәлсәфәсе арасында туры сызык куеп кына сүз алып барырга ярамый. Чөнки Дәрдемәнд фәлсәфәсенең ижтимагый-тарихи сәбәпләре һәм идея-эстетик йөге, ихтыяҗы башка инде. Шагыйрь үз заманыннан аерылган хәлдә күктә асылынып тормый яки ал гөлләр, сөмбелләр арасында гына яшәми. Мәхәббәткә ул күпме генә мөкиббән китмәсен, мәҗнүннәр шикелле баш имәсен, барыбер аның да җирдән аерылгысыз булуын раслый һәм шуның белән традицион-идеаль мәхәббәтнең иллюзия, хыял икәнлеген күрсәтә:

Йөреп, бер-бер карап чык һәр каберне,
Алып туфракны учка, иснә җирне;
Ни җирдә гашыйк вә сәүдәләр исе бар,
Аның шул җирдә кабре... шунда ул яр!..

(«Хикәяи гыйшык», 1908)

Дәрдемәнд оптимизмын гомумән яшәешкә, көндәлек тормышка мөнәсәбәт яки интим хисләр кысасында гына калды-

---

даим – һәрвакыт

сәүдә – мәхәббәт, сөешү

ру бу мәсьәләгә берьяклы карау булыр иде. Шагыйрьнең дөньяны танып-белүдәге фәлсәфи һәм эстетик концепциясе буларак, оптимизм идеясе аның киң мәгънәсендәге дөньяга һәм тарихка мөнәсәбәтен дә сугара барды. Менә шул урында Дәрдемәнд борынгы Көнчыгыш поэзиясеннән килгән бик билгеле бер караштан – мәхәббәт һәм шәраб (мәй) дөньясында онытылып, кәеф-сафа чигеп яшәүне мактаудан югары күтәрелде дә инде. Нәкъ шул урында аның оптимизмы заманга, тарихка мөнәсәбәт шикелле әһәмиятле, актуаль, зур идеягә якын килде. Моның үзәгендә заманның тарихи логикасын, үткәннең һәм киләчәкнең табигый гәүдәләнеше булуын инкяр итүдән бигрәк, аны кабул итү тойгысы өскә чыкты.

Дәрдемәнд иҗатының традицияләр белән бәйләнешен һәм бигрәк тә оптимизмын караганда, Көнчыгыш поэзиясендә шактый таралган пантеизм идеяләренең заман рухында яңартылып кабатлануын, дәвам иттерелүен дә истә тотарга кирәк. Пантеистик концепция XIX йөз ахырындагы рус әдәбиятында да урын алган иде. Тулаем бу концепция «дөнья серен» сизәргә, ачарга, табигать белән кеше арасындагы бәйләнешне аңларга омтылды. Шушы мәгънәсендә ул Дәрдемәнд карашларында да үзенең эзен калдырды. Әгәр дә С. Рәмиевтә пантеизм кешене аллалаштырудан, шәхесне шул рухта идеаллаштырудан гыйбарәт булса, Дәрдемәндтә исә тарих белән табигать һәм кеше арасындагы мөнәсәбәтләр фатальләштерелде, серле итеп каралды. Аларның икесендә дә пантеистик идеаллар «югары көч – табигать – кеше» мөнәсәбәтләре яктылыгында төрле аспектта хәл ителде. Дәрдемәндтәге пантеизмның характерлы бер ягы табигатьне идеаллаштыруга, табигать культына барып тоташа: «Куй, табигать хөкмен итсен – шул тәкамел, шунда ямь», – ди шагыйрь («И мөхәррир», 1908). Нәкъ шушы караште инде аның тарихка, тормышка һәм кешегә оптимистик мөнәсәбәтенең сере дә яшеренгән шикелле. Монда сүз барысы да табигать законнарына таянып, шулар яктылыгында хөкем ителергә тиешлеге хакында

тәкамел – камилләшкән, җитлеккән, өлгергән

бара, һәм бу идея, ышаныч – романтизмның асылташларыннан берсе булып, антропологик концепция нигезендә ята. Чыннан да, Дәрдемәнд фәлсәфи карашларының сәнгатьчә конкрет эчтәлеге бигрәк тә табигать белән бәйләнештә үзенең нечкә лирик психологик сыйфатларын күрсәтте. Татар поэзиясендә гаять үзенчәлекле булып аның иҗатында табигать лирикасы формалашты.

Табигать пейзажына шактый игътибар иткән шагыйрьләрнең күренеклесе тагын Тукай булды. Дәрдемәнд тә, Тукай да милли лириканың бу тематикасында бик характерлы ике тенденцияне – реалистик һәм романтик тенденцияләрне башлап җибәрделәр һәм нигезләделәр.

Дәрдемәнд табигать лирикасында күзгә ташланган нәрсә – аның дөньяга карашы үзәген билгән фәлсәфәсе, бигрәк тә пантеистик идеяләре белән бәйләнешнең калку булуы. Аның лирик герое табигатьнең ниндидер серле көчкә ия булуы, табигать стихиясенең магик, могҗиз кодрәте турында сөйли. Шагыйрь игътибарын барыннан да бигрәк әнә шул тарта:

Яратам кайчакларын моңлап,
Һаваның тынлыгын тыңлап,
Килә өннәр колак чыңлап.

Диямен:

– Ни бу? Нидәндер бу?
Җавап урнында гөрли су,
Тирәклек тирбәнә, шаулый[*].

Тагын бер мисал:

Исәрме җил тугай буйлап,
Еларме кыз моңын сөйләп,
Көләрме шатланып көйләп,
Агач, таш эчләре шаңрап,
Киләдер бер нида яңрап[**]!

---

[*] Дәрдемәнд. Сайланма әсәрләр. – 1959. – Б.82. (Курсив безнеке. – *Г.Х.*)
[**] Дәрдемәнд әсәрләре. – 1929. – Б.96. (Курсив безнеке. – *Г.Х.*)

Бу шигырьләрдә табигать аша гомумән дөнья һәм яшәү серен аңларга, хәтта ул сернең тавышын (өнен, нидасын) ишетергә теләү бар. Шагыйрь иҗатында әледән-әле яңгырап торган шундый мотивларның ачыграк чагылышына мисал итеп тагын да, мәсәлән, аның бер нәсереннән өзек китерик: «Үлән өстенә сузылып яттым. Җил шаулый, колак чыңлый иде. Бу искән җилләрдә кичкән елларның моңлы агышы белән, үткән гомерләрнең хәсрәтле сагышы тоела иде. *Алда киләчәк адәмнәрнең тупарлашып баскан аяк тавышлары ишетелгәндәй була иде»*[*].

Китерелгән мисаллар Дәрдемәнднең фәлсәфи карашларына икенче бер мотивны өстиләр: шагыйрь табигать стихиясе эченнән икенче хакыйкать тавышын ишетә. Аннан «кичкән елларның моңлы агышы», «үткән гомерләрнең хәсрәтле сагышы» гына килми, ә алдагы тарихның да, киләчәк буыннарның да хәбәре, аяк тавышы яңгырагандай. Димәк, шагыйрь кешелек җәмгыятенең күчемлелек, дәвам итү зарурлыгын раслый, һәм бу раслауны аның пантеистик оптимизмыннан аерып булмый. Мондый оптимизм исә кешелек барышының закончалыгына, тарихның дәвамлылыгына, гомумән, табигый үсеше һәм яшәеш матурлыгына ышанычны Дәрдемәнднең тарихи пессимизмны һич тә кире какмавы турында сөйли. Менә шуннан инде аның поэзиясендә табигатьнең эчке рухи рәхәтен, ләззәтен һәм гүзәллеген сурәтләү осталыгы үсеп чыкты. Нәкъ шушы моментта шагыйрь романтик идеалының тагын бер сыйфаты ачылып китсә кирәк. Ул сыйфат романтизмның табигать культына һәм дөнья гармониясен белдергән музыкаль концепциягә барып тоташа.

Аеруча унынчы елларда, татар әдәбиятында романтизм шактый куәт алгач һәм үзенең милли үзәненә төшкәч, күп кенә әдипләр музыка, мәхәббәт һәм табигать культы белән мавыгу шаукымын кичерделәр. Гомумән алганда, бу культта яшәүнең рухи гармониясен эзләү сизелеп торды. Әмма Дәрдемәнд поэзиясендәге музыка культын туры мәгънәсендә

---

[*] Шунда ук. – Б. 86. (Курсив безнеке. – *Г.Х.*)

музыканы илаһилаштырудан, аны дөньяның рухы, җаны итеп аңлаудан гыйбарәт дип карарга кирәкми. Аңарда ул, беренчедән, поэзияне, шигырь сәнгатен идеаллаштыруда һәм шуңа нисбәтән шигъри сүзнең нечкәлеген, нәфислеген, гүзәллеген табарга тырышуда күренә; икенчедән, дөнья, табигать гармониясен, аның фәлсәфи, рухи һәм шигъри серен ачарга теләү рәвешендә гәүдәләнә. Шулай итеп, музыка культы Дәрдемәндтә тотрыклы идея-эстетик концепциягә әверелде. Бу яктан ул рус романтик поэзиясендә шактый зур урын алган музыка культына якынайды.

«Музыка дөньяны иҗат итә», – дигән Блок, һәм моның белән «дөнья гармониясе» концепциясенең мәгънәсен әйтергә теләгән. Тютчевның табигатькә мөнәсәбәтендә музыка культы аерата көчле булуын күрсәтәләр. Аның поэзиясендә табигать күренешләре хәтта «җырлый» итеп сурәтләнә*. Табигать, мәхәббәт һәм җыр – өчесе бергә бер-берсеннән аерылмас, гармоник, шигъри, музыкаль дөнья тудыра дип караган Фет. Шагыйрь исә шул гармонияне, музыканы аңлау сәләтенә ия булырга тиеш. Болар һәммәсе романтик концепциядән гыйбарәт. Һәм Дәрдемәнднең дә музыка культын шул мәгънәдәрәк аңлау дөрес булыр.

Аның поэзиядән башка жанрларга игътибар итмәве дә очраклы түгел, ягъни ул барыннан да бигрәк шигырь дөньясында үзенә тирән канәгатьлек, ләззәт һәм матурлык таба. Монда ул сайланма тема һәм мотивларны җырлавы белән дә аерылып тора, ягъни теләсә нинди тема һәм мотивлар белән эш итми. Тютчев һәм Фет шикелле үк, ул да поэзиягә лаек булган һәм булмаган объектлар бар дип карый. Бу караш шулай ук романтизмга хас. Ә реализм әдәбияты барлык күренешләр дә поэзиядә чагылырга мөмкин дип раслый.

Романтизм пейзажга күбесенчә эмоциональ һәм психологик буяуларны салырга омтылды. Табигать күренешләренә «җан пейзажы» («пейзаж души»), рухи тональлек итеп карады. Әйтик, табигатьтәге давыл рухи давыл белән янәшә куел-

* Сб. «Мастерство русских классиков». – М. – 1964. – С. 226.

ды, күк күкрәүдә, диңгез дулкыннарында һ.б. шундый күренешләрдә эчке яшерен көч бар дип саналды. Дәрдемәндтә дә табигать лирикасын «җан пейзажы» итеп сурәтләү шактый сизелә. Һичшиксез, аның иҗатында табигать культы һәм дөнья гармониясе кебек идеяләр күп очракта психологик аспектта булып, шагыйрьнең тарихка, дөньяга, кешегә булган төп фәлсәфи карашыннан аерылгысыз моң, сагыш, элегик настроениеләр белән сугарыла:

Агышың, и агым су, туп-тулы зар,
Синең ни хәсрәтең, ни моңнарың бар?.. –

дип эндәшә шагыйрь агым суга һәм үзенең моң-зарлары белән уртаклаша.

Туган-үскән җирне, аның табигатен сөю, аннан аерылып яшәүнең газабы, аны сагынуның ләззәте, анда гомер итүнең чын бәхет булуы кебек мотивлар Дәрдемәнд лирикасында бик характерлы. Ул мотивлар күп кенә очракларда туган ил табигатенең җил-яңгырларын, гөл-чәчәкләрен һәм, гомумән, аның җанга ягымлы бизәкләрен сурәтләү белән үрелә:

Чыкты кояш, кызарып нурлар очты,
Бизәнде тау, бизәнде кыр, гөлләр үсте.
Һава тымык, шылт итми... үләннәр чык,
Җым-җымылдап уйныйдыр җирнең өсте.

Менә шул дүртьюллыкта табигать сурәтләренең гаять бай бизәкләре һәм төрле күренешләре күз алдына бастырылган, аларның күп сыйдырышлы панорамасы тасвир ителгән. Г.Нигъмәти әйткәнчә, шагыйрь «аз сүз, кыска җөмләләр белән бай картина бирергә тырыша»[*]. Дәрдемәнд лирик стилендә импрессионистик элементлар да шактый гына. Аның табигать лирикасында да шул рухтагы, эмоциональ-психоло-

[*] Дәрдемәнд әсәрләре. – Б. 32.

гик күтәренкелек белән әйтелгән, бик үзенчәлекле, субъектив экспрессивлык белән өретүле сурәтләү еш очрый:

Бу – ул матур, бу – ул күркәм,
Бу – ул,
Бу – ул хуш исле яз!
Бу – ул хуш исле таң җиле...

Дәрдемәнд туры мәгънәсендә гражданлык поэзиясе вәкиле түгел, ә фәлсәфи-әхлакый поэзия традицияләрен дәвам иттерүче һәм яңартучы. Шушы яктан ул гаять дәрәҗәдә эзлеклелек һәм үзенчәлек күрсәтте. Дәрдемәнд поэзиясенең фәлсәфи-әхлакый характеры аңарда хикмәт традицияләренең тотрыклы булуын да таләп итте. Шул сәбәпле ул безнең поэзиядә традицион-афористик стильне дә нык саклаучылардан һәм үстерүчеләрдән булды.

Татар поэзиясендә хикмәт традицияләренең ике чыганагын истә тотарга кирәк: аның берсе бик борынгы язма әдәби традицияләргә барып тоташа, икенчесе халык авыз иҗатыннан азыклана. Соңгысына мисал – бигрәк тә ике гасыр аралыгында Акмулла һәм Гафури кебек шагыйрьләр иҗатында казакъ фольклорыннан килә торган традицияләрнең мул чагылышы. Бу факт хикмәт жанрында шактый гына үзгәреш барлыкка килүе хакында да сөйләргә мөмкин. Әлбәттә, хикмәт традицияләрнең ике чыганагы да бер-берсе белән теге яки бу төстә үзара бәйләнештә булды.

Дәрдемәндтәге хикмәт лирикасы исә югарыда күрсәтелгән тенденциядән шактый аерыла. Аңарда Көнчыгыш поэзиясенә хас хикмәт традицияләре тотрыклырак һәм рациональ башлангыч көчлерәк. Брюсов шикелле, Дәрдемәнд «акыл-хирыс» («мысль-страсть») концепциясенә күбрәк басым ясый. Аның шигырьләрендәге эмоциональлек, хисси башлангыч сурәтләренең шигъри нечкәлеге, пөхтәлеге символик, аллегорик һәм афористик рәсемлелек белән тудырыла. Шагыйрь үз фәлсәфи һәм әхлакый карашларын, шул рухтагы үгет-нәсихәтләрен гаять нечкәртелгән сурәтләргә, символ-

кинаяләргә, афоризмнарга яшереп бирү юлын сайлый. Аңарда хикмәтле сүз, акыл, әхлак үгете шәрә дидактик шигырь булып түгел, ә «ишарә пафосы» һәм «яшерелгән лирика» кебек традицион алымнар ярдәмендә бирелә. Бу алымнарның төрләре һәм диапазоннары Дәрдемәнд поэзиясендә байтак. Шул сәбәпле андагы хикмәт мотивлары да сурәтләрнең төрле структурасында гәүдәләнә. Аларның иң гади, туры формаларына кадәр очратырга мөмкин:

Югарыга ташны аткан юләрләр
Үз аңкау башларын тишеп үләрләр.
Тишек тапсаң сиңа япкан ишектән,
Үзеңнең ертык авызыңнан көләрләр.

(«Беренче апрельдә зыярәт портретын
җибәргән «дустыма», 1910)

Шагыйрь үзе үк, бу шигырен «Аталар сүзе» дип искәртүе белән, аның халык телендәге гыйбрәтле, хикмәтле сүзләрдән–афоризмнардан торуын әйткән. Бу мисалда билгеле мәкаль-әйтемнәрне нигез итеп алган һәм үгет-нәсихәтен бик туры итеп чагылдырган хикмәт поэзиясе үрнәген күрәбез. Шул рухта шагыйрь гаять дәрәҗәдә кыска, үткен, төгәл һәм халыкчан булган шигъри афоризмнар-хикмәтләр иҗат итте:

Күңлемнең әзрәк кенә кинәсе бар,
Телемнең дә зәһәр очлы инәсе бар.

Дәрдемәнд поэзиясендә бик тирәнгә, эчкә яшерелгән, ягъни символик, шартлы сурәтләр артында торган хикмәтле, гыйбрәтле фикер-киңәшләр аз түгел. Хәтта аларның кайберләрендәге символиканың нәрсәгә ишарә икәнлеген төгәл белүе дә читенләшә (мәсәлән, «Яз чәчәге», «Җәй үтте» һ.б.). Мондый очракларда шагыйрь еш кына табигать сурәтләренә мөрәҗәгать итә һәм аларга яшерелгән символикага артык субъектив төсмер бирә.

* * *

Дәрдемәнднең шәхси һәм иҗади язмышында социалистик революциягә мөнәсәбәт – җитди мәсьәләләрнең берсе. Бу мөнәсәбәт шактый катлаулы һәм каршылыклы булды. Чөнки шагыйрьнең өстен сыйныфлар белән нык бәйләнештә булуы һәм халыктан ераклыгы, Россия чынбарлыгын тамырыннан үзгәрткән тарихи борылышны аңа тиз арада гына аңларга мөмкинлек бирмәде. Революциягә аның беренче мөнәсәбәтен белдергән әсәрләреннән «Куанды ил...» дип башланган шигыре – әнә шул гаять каршылыклы һәм катлаулы настроениенең бер күрсәткече.

Шагыйрь, бер яктан, революциянең ил, халык өчен куаныч һәм тормыш туе икәнлеген күрә, – димәк, аның тарихи зарури хәл булуын икърар итә; әмма, икенче яктан, үзе яңа «тормыш туеның кияве» була алмавына, урыны кирәксез кешеләр арасында калганга үкенәчәген белдерә һәм шигырьнең азагын «йөз аклыгың өчен авызың йозаклы булсын» дип тәмамлый. Димәк, Дәрдемәнд, революциянең ил, халык куанычы кебек зур тарихи үзгәреш икәнлеген аңлаган хәлдә, үзенең аңа турыдан-туры хезмәт итәргә кыюлыгы, көче җитмәвен һәм шул сәбәпле битарафлык позициясендә калуын әйтергә тели. Шуңа күрә дә бу – революциягә дошманлык түгел, ә яңа тарихи шартларның мәгънәсен аңламауның бер драматик чагылышы иде. Шулай ук шагыйрьнең революцияне тарихи зарурлык, котылгысызлык дип аңлавы да көтелмәгән нәрсә булмады. Аның бу карашы – дөнья барышындагы, җәмгыять үсешендәге тарихи яңарышны, искенең юкка чыгып, үлеп, аңа алмашка яңаның килүен котылгысыз дип санаган фәлсәфи ышанычларының бер реаль гәүдәләнеше иде. Бу очракта да Дәрдемәнднең Блокка билгеле бер охшашлыгы бар шикелле: Блок дөнья музыкаль концепциясе аша революциянең тарихи зарурлыгы һәм пычрак чынбарлыкны сафландыра торган көч икәнлеген аңлауга килде һәм революция музыкасын тыңларга чакырды. Дәрдемәнднең дә пантеистик карашы дөнья гармониясен эзләүдән аерылгысыз иде. Ул да дөнья гармониясе тарихи катаклизм һәм һәлакәтләрдән азат

була алмый дигән карашны алга сөрде. Шуның нәтиҗәсе буларак, аерым кешеләр һәм сыйныфлар теләсә-теләмәсә дә, үзгәрешләрнең, революциянең котылгысыз икәнен аңлау мәҗбүрияте, ихтыяҗы икърар ителде. Дәрдемәнднең социалистик революциягә мөнәсәбәтендә әнә шундый мәҗбүрият, ихтыяҗ, һичшиксез, өстенлек алды. Бу инде аның үз сыйныфыннан аерылу юлына басуы дигән сүз иде. Шуңа күрә Дәрдемәнд үз шәхси язмышын да үзенчә хәл итте. Ул революциядән качмады. Милли буржуазиянең күп кенә идеологлары совет дошманнары белән бер лагерьга кереп, илен, халкын ташлаганда, шагыйрь үзенең туган-үскән җирендә калды һәм аңа мәхәббәтен җырлады:

Әй, туган илнең һавасы,
Рәнҗемә, зинһар күтәр!
Рәнҗемә, зинһар күтәр! –

дип гафу үтенүе бик тә гыйбрәтле иде.

Дәрдемәнд поэзиясендә туган ил тойгысы тирән драматизм белән сугарылып, үзенең лирик нечкәлеге, сагышлы моңы белән гәүдәләнеп калды. Бу нечкәлек халык поэзиясеннән килгән мотив һәм сурәтләрне искә төшерә:

Тәгәрәп, уйнап
Буй үскән,
Туган илем, исән бул!
Чәч кузгалып,
Җай искән,
Таңгы җилем, исән бул! –

шикелле юллар үзләре генә дә халык җырларына тоташкан аһәң һәм сурәтләрнең гаять тирәнгә үтеп керүләре, шагыйрь кичерешләренең тибешенә тәңгәл килүләре турында сөйләрлек дәлил, үрнәк булырлар. Шундый аһәң һәм сурәтләр арасында нечкә билле сөйгән кыз образының басып торуы туган

илгә мәхәббәтне тагын да күркәмрәк итә, аның халыкчан гүзәллеген һәм җылылыгын көчәйтеп җибәрә.

Революциягә һәм ватанга мөнәсәбәт – яңа тарихи шартларда Дәрдемәнд иҗатының бик әһәмиятле мотивы булды. Бигрәк тә туган ил темасы аша шагыйрьнең яңа чынбарлыкны аларга омтылышындагы кискен тирбәлешләр, каршылыклы уй-тойгылар шактый сизелеп калды:

Ни газизрәк, бу Ватанмы?
Аһ, туган каумем газиз... –

(«Гөрләгән сулар...»)

дигән сорау һәм аңа җавап шагыйрьне бик борчыды. Бәлки бу хәл Дәрдемәнднең драматик кичерешләрендә, тарихи барышка мөнәсәбәтендә һәм үзенең шәхси язмышына карата да кечкенә роль уйнамагандыр. «Ләкин шагыйрьнең бәхетенә, ватан һәм милләт рәвешендәге каршылык тирәнәюгә, трагик чишелешкә таба бармый».*

Чыннан да, Дәрдемәнд иҗатында ватан белән милләт арасындагы каршылыклы мөнәсәбәт мотивы буйдан-буйга сузылып килә диярлек. Октябрьдан соң да билгеле дәрәҗәдә аның шул рухтарак дәвам итүен кире кагып булмас. Әмма, шуның белән бергә, аның бу чорда инде тирәнәюен түгел, ә ватан, милләт һәм шагыйрь арасындагы уртаклык, якынлык, тугандашлык тойгыларының бер ноктагарак килүе, өскә чыгуы турында кыюрак итеп әйтергә мөмкин.

Илдә бер дуст булмаса гәр,
Ил бөтен дошман түгел, –

диде шагыйрь, һәм үзе белән ил арасындагы якынлыкның һич тә өзелмәс изге тойгы булуын җырлады. Тагын да:

кавем – халык, милләт

* Н. Хисамов. Дәрдемәнд поэзиясендә туган ил мотивы // «Совет мәктәбе». – 1969. – № 2. – Б. 28.

Атам-анам йорты өчен
Булса мең җаным фида;
Туган-үскән җирем өчен
Соң тамчы каным фида, –

дигән юлларын революциядән соң язылган дип санасак, Дәрдемәнднең яңа ватанга мөнәсәбәте никадәр тирән үзгәреш алуын күрербез, гуманистик һәм халыкчан эчтәлеге киң колач белән яңгыравын ишетербез.

(«Казан утлары». – 1979. – №12. – Б.146-156.)

Нурмөхәммәт Хисамов

Дәрдемәнд

(Тормышы һәм иҗаты турында очерк)

Дәрдемәнд* иҗаты XX йөз башы татар әдәбияты тарихында аерым урын тота. Бу хәлне, табигый булганча, һәр тикшеренүче диярлек билгеләп үтә.

Шагыйрьнең иҗаты үз чорына хас барлык үзенчәлекләрне: XIX йөз азагы – XX йөз башы арасындагы мәгърифәтчелек идеяләрен, Россиядә беренче революциянең иҗтимагыйсәяси һәм фәлсәфи каршылыкларын, Октябрь революциясе алып килгән борылышны – һәммәсен чагылдыра. Ә сәнгатьчә форма һәм шигъри эшләнеш өлкәсендә Көнчыгыш поэтик традицияләрен дә, рус һәм Көнбатыш Европа шигъри мәктәбе үзенчәлекләрен дә бергә кушты, шушыларны тыгыз рә-

* Шагыйрьнең моңарчы чыккан китапларында «Дәрдмәнд» дип язылган псевдонимын, бер хәреф өстәп, «Дәрдемәнд» дип язу нәрсәгә нигезләнә соң? Барыннан да элек, хәзерге орфография таләпләренә нигезләнә. Мәгълүм ки, гамәлдәге имлябызда ишетелгәнчә язу кагыйдәсе хөкем сөрә. Ә шагыйрьнең исеме телдә һәрвакыт «Дәрдемәнд» дип әйтелә. Монда традиция дә, сүзнең аһәңен саклау теләге дә чагылыш таба; «е» хәрефе төшеп калганда, кушма сүзнең беренче өлеше тартыкка бетсә, азаккы «д» авазы котылгысыз рәвештә саңгыраулаша. Язуга ияреп, хәзерге буын күп очракта шагыйрьне «Дәртмәнд» дип йөртә. Закир Рәмиевнең тәхәллүсенә килгәндә исә, кимчелек гарәп әлифбасыннан яңалифкә күчкәндә тәҗрибә җитмәү аркасында килеп чыккан, гарәптәге тартыкка сузык ялганмый калдырылган. Дөрес, шагыйрьнең үз шигырьләрендә ритм «Дәрдемәнд» дип язуны таләп иткән. Монысында инде гаруз поэтикасы чагыла, чөнки гаруз үлчәмендә иҗекләр тигезлеге, кирәк чакта тартык кына калдырып, икенче очракта сузыкларны саклап хәл ителә. Без, шуларны истә тотып, традициягә ятышлы һәм аһәңне саклый торган «Дәрдемәнд» язылышын яңартырга булдык.

вешкә кертеп трансформацияләде. Кыскасы, ул XX йөз башының Г.Тукай, С.Рәмиев, М.Гафури иҗатларын эченә алган сәнгатьчә закончалыклар кысасында, әмма бу шагыйрьләрдән шактый аермалы, үзгәрәк идеяләр җирлегендә торып иҗат итте.

Дәрдемәнднең күләме ягыннан зур булмаган, әмма фәлсәфи-әхлакый эчтәлеге һәм шигъри осталыгының үзенчәлеге белән гаять зур әһәмияткә ия мирасы совет әдәбиятының бөтен тарихы дәвамында татар шигъриятен тикшерүчеләрдән берәүне дә битараф калдырмады. Берәүләр аңа кискен рәвештә кире бәя генә биреп, икенчеләре бары шигъри осталык җәһәтеннән генә аның әһәмиятен таныса, өченчеләре исә лирикасының җәлеп итү серләрен тулырак төшенергә тырышты. Әмма вульгар социологизм йөге барлык очракта да диярлек мәгълүм стереотип чигеннән чыгарга ирек бирмәде. Шунлыктан аның шигърияте әдәбият белеме өчен асылда һаман чишелеп бетмәгән мәсьәлә булып кала. Аны тулырак аңлыйм дисәң, узган унъеллыкларда урнашып калган схемалардан тәвәккәл рәвештә баш тартырга һәм әсәрләрен җентекләп өйрәнергә кирәк.

Хакыйкатькә бару юлында өзлексез киртә булып яткан берничә схема күрсәтеп үтәргә мөмкин. Беренче схема шагыйрьнең барлык идея һәм образларын примитив төстә гадиләштереп, аның иҗтимагый-икътисади хәленә бәйләүдән гыйбарәт. Икенче схема шагыйрьнең идея-сәнгатьчә үзенчәлеген механик рәвештә XX йөз башы рус шигъри мәктәпләренә, аерым алганда, символизмга кайтарып калдыруда чагыла. Өченче схема исә Дәрдемәнднең шигъри идеяләрендәге пессимистик һәм фаталистик мотивларны абсолютлаштырудан тора. Шагыйрьгә тагылган «декадентлык» ярлыгы укучыларны шактый озак шомландырып килде.

Беренче схема уннарча еллар дәвамында барлык эзләнүләрне өстән басып килә. Анысы – егерменче еллар әдәбият белеме һәм тәнкыйте калдырган мирас. Бу юнәлеш тарафдарларыннан Ф.С.-Казанлыны һәм С.Мортазинны күрсәтергә мөмкин. Икенче схема Г.Сәгъди хезмәтләреннән башлана.

Өченче схема, караш ноктасы буларак, әүвәл Г.Ибраһимовның «Татар шагыйрьләре» очеркында урын алып, аннары Г.Нигъмәти хезмәтендә уздырылды, соңрак Г.Халит хезмәтләрендә яклау тапты.

Дәрдемәнд иҗатының үзенчәлекләрен намуслы рәвештә фәнни аңлатырга омтылучы кеше Г.Нигъмәти булды. Шагыйрьнең мирасын саклау һәм өйрәнүдә игелекле эшне М.Гайнуллин эшләде. Дәрдемәнднең татар шигырен үстерүгә керткән өлешен Х.Госман тикшерде, шагыйрьнең аерым шигырьләрен шәрехләү юнәлешендә тирән һәм ышандыргыч фикерләрне Й.Нигъмәтуллина әйтте. Г.Халитнең соңгы тикшеренүләре шагыйрь иҗатының идея-фәлсәфи эчтәлеген аңлатуда зур адым булды. XX йөз башы татар әдәбиятының идея-сәнгатьчә контекстында шагыйрьнең тоткан урыны И.Нуруллин хезмәтләрендә объектив һәм тулырак чагылыш таба.

Мөхәммәтзакир Мөхәммәтсадыйк улы Рәмиев (Дәрдемәнд) 1859 елның 23 ноябрендә Оренбург губернасы, Эстәрлетамак өязе, Җиргән авылында сәүдәгәр гаиләсендә дөньяга килә. Аның атасы Мөхәммәтсадыйк Габделкәрим улы ул елларда мануфактура белән сәүдә итә. 1862 елда ул шул ук өяздәге Юлык авылына* күчеп килә һәм алтын приискасы ача. Алтын чыгаручы миллионер Рәмиевләр тарихы шуннан башланып китә.

Закир башлангыч белемне авылында ала, аннары абыйсы Шакир белән Орск өязенең Муллакай авылы мәдрәсәсендә укый, анда гарәп һәм фарсы телләре өйрәнә. Ул мөстәкыйль рәвештә кечкенәдән рус телен үзләштерә. Журналист И. Рәми язганча, шагыйрьнең әнисе Хәнифә Эстәрлетамак өязенең Явыш авылыннан Алмакай (Әлмөхәммәд) Дашков кызы бул-

* Риза Фәхретдинев үзенең «Асар» дигән энциклопедик хезмәтендә (14 том) бу авылның «чама белән моннан 200 ел элек» килеп утырган Казан татарлары тарафыннан нигезләнүе хакында әйтә. Хезмәт 1927 елда тәмамланган. Кара: Фәхретдинев Р. Кулъязмалар мәҗмугасы («Асар»ның IV өстәмә кисәге). Т. 14. – Б. 31. Башкортстан Фәннәр академиясе архивында саклана.

ган.[**] Бу исә атаклы морза Дашков нәселе. Алар арасында русча белем алган кешеләр дә аз булмаган. Закирның кечкенәдән рус телен өйрәнүендә әнисе зур роль уйнаган. Шагыйрьнең кызы Зәйнәп Вәлиева сүзләре буенча, Дәрдемәнд әнисе кебек үк саргылт чәчле булып, үзенең тышкы кыяфәте белән, гомумән, аңа охшаган. «Вакыт» газетасы мөхәррире һәм шагыйрьнең биографиясен язып калдырган әдип Ф.Кәрими сүзләренә караганда, Закир Рәмиев русча камил сөйләшә һәм яза алган, рус әдәбиятын күп укыган.[*] Мондый күренеш ул чор татар тормышында киң таралган дип һич әйтеп булмас иде. Шагыйрь соңрак рус һәм төрек телләре аша Көнбатыш Европа әдәбияты, аның иҗтимагый-сәяси һәм фәлсәфи фикере белән тирән танышкан.

Укуын дәвам итү өчен, Закир Рәмиев 1880 елда Төркиягә китә, анда төрек теле һәм әдәбиятын өйрәнә, әдипләр, шагыйрьләр белән аралаша. Шунысына да игътибар итәргә кирәк, ул елларда төрек әдәбиятында төшенкелек хисләре өстенлек итә.

Россиягә әйләнеп кайткач, З.Рәмиев әдәби иҗат белән шөгыльләнә башлый, төрекчәдән хикәяләр тәрҗемә итә, шигырьләр яза. 1902-1903 елларда аның берничә кыска шигыре «Тәрҗеман» газетасында басыла. Бу әле аның өйрәнчек тәҗрибәләре.

Шагыйрьнең чынлап торып күзгә бәрелгән беренче әсәре 1906 елда «Казан мөхбире» газетасында басылган «Каләмгә хитап» шигыре була. Анда ул үзенең эстетик кредосына караган төп принципларын бәян итә: каләмен ихласлыкка, «дөньяга килеп киткәннәр хәлен» язарга, золымга юлыккан, җәберләнгән кешеләр тавышына сизгер булырга чакыра. Ул үзенә «Дәрдемәнд» (сагышлы, моңсу) дигән тәхәллүс сайлаган. Бик күп тикшеренүчеләр бу фактның мәгънәсенә төшенергә тырышканнар, аны шагыйрь иҗатының, алар карашынча, әйдәүче мотивы – моңсулык һәм пессимизм белән бәйләп караганнар.

Безнең карашыбызча, тәхәллүс сайлауда ике момент роль уйнаган: Көнчыгыш поэзиясенең традиция көче, ягъни урта га-

---

[**] Кара: Дәрдемәнд әсәрләре. – Казан, 1929. – Б.9.
[*] Кәримов Ф. Дәрдемәнд // Дәрдемәнд әсәрләре, – 1929. – Б.9.

сыр әдәбиятына хас этикет һәм иҗатының төп аһәң үзенчәлеге. Мәгълүм булганча, урта гасыр Көнчыгыш поэзиясендә шагыйрьнең укучылар алдында үзен тыйнак, кечелекле тотышы әдәп кагыйдәсеннән саналган. Бу исә «Кол» (Кол Әхмәдне, ягъни Әхмәд Ясәвине һәм Кол Галине генә алыгыз), «Мискин», «Фәкыйрь», «Гариб», «Ярлы» кебек псевдонимнарда чагылган. Ә инде тәхәллүснең Дәрдемәнд иҗатындагы аһәң юнәлешенә бәйләнешен мәгълүм искәрмәләр белән генә танырга мөмкин, чөнки аның поэзиясендә яңгыраш һәм моң диапазоны гаять киң. Әйтергә кирәк ки, Тукай да мәхәббәт шигырьләренең берсендә үзен «Дәрдемәнд» дип атаган.

Закир һәм Шакир Рәмиевләрнең хатларыннан һәм Фатыйх Кәрими белән Риза Фәхретдинев истәлекләреннән күренгәнчә, агалы-энеле бу ике тынгысызның төп кайгысы газета һәм журнал чыгаруга ирешү булган. Шакир Рәмиев Истанбулга энесе Закир исеменә язган хатында хәрефләр сатып алу мөмкинлеге белән кызыксына. Соңрак нәшергә хокук алу һәм бу эшне юлга салу өчен аларга Оренбург һәм Петербург хөкемдарлары каршында озак бил бөгәргә туры килә. Биредә Дәрдемәнд 1905 ел революциясенә зур өмет баглый. «Вакыт» газетасының булачак редакторы Фатыйх Кәримигә 1905 елның 29 октябрендә язган хатында ул болай ди: «Гәзитә хосусында һичбер тәшәббестә булганыбыз (эшкә керешкәнебез) юк. Оныткан өчен түгел, бәлки мәркәздә әхвале сәясиянең көн саен тәбдил кылмакда (яхшы якка алмашынуда) вә «явочный порядок» (халык массасының ачыктан-ачык чыгышлары) өмите барган саен куәт алмакда булган өчен. Хода кушып та, тизлектә хөррият там галәбә тапса (тәмам җиңеп чыкса), хәзерге хәлендә кабулына мөстар (кабул ителүенә мәҗбүр) булганыбыз күп «чара юк»лар, мәванигълардан (киртәләрдән) котылыр идек». Шул ук вакытта шагыйрьнең ачылуы ихтимал мөмкинлекләргә реалистларча сак каравы да күзгә ташлана. Һәрхәлдә, ул патша манифестына ул чаклы шаккатмый.

«Вакыт» газетасы Оренбургта – 1906 елның 21 февраленнән, «Шура» (Киңәш) журналы исә 1908 елның 10 гыйнварыннан чыга башлый. Болар – либераль юнәлештәге басма-

лар була. Әлеге басмаларда XX йөз башы татар мәдәниятенең күренекле эшлеклеләре Фатыйх Кәрими һәм энциклопедист галим Риза Фәхретдинев мөхәррирлек итә, Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Камал, Мәҗит Гафури, Шәйхзадә Бабич, Зәйнәп Сәгыйдә, Зариф Бәшири һ.б. шундый демократик әдипләр язышып тора. Габдулла Тукай да басылган. «Вакыт» газетасының демократик эчтәлекле аерым саннарына берничә тапкыр арест, ә наширенә штраф салына. Укучылар дөньясы Дәрдемәнднең шигъри иҗаты белән, нигездә, «Шура» журналы аша таныша. Шушы матбугат үзәкләре һәм шагыйрь тирәсендә көчле әдәби мохит барлыкка килә. Дәрдемәнднең әдәби салонында ул еллардагы иҗат җәмәгатьчелегенең иң мөгътәбәр вәкилләре мәгънәви аралашу, әңгәмә һәм бәхәс өчен һәр җомгада очрашып, узара таныша, иман һәм фикер уртаклыгы таба, әңгәмә кора һәм бәхәсләшә торган булган.

Ф. Кәрими Дәрдемәнднең байлык тупларга керешү максатын ачкан сүзләрен китерә. Аның язуынча, шагыйрь моны «иҗатта матди исәпләргә бәйсез булу, күңелендә булганны иректә әйтә алу» өчен зарур дип санаган.* Тикшеренүчеләр бу сүзләрне артык беркатлы дип бәялиләр һәм әлеге максатының чынлыгына шикләнеп карыйлар. Хәлбуки, Дәрдемәнд – әсәрләренең үтә ихлас булуы белән аерылып тора. Шагыйрь андый максатының дөреслегенә чын күңелдән инанган булырга мөмкин, әмма тормыш, икътисади кануннар яшь кешенең ниятләреннән көчлерәк булып чыккан, аны үзенең шартларына буйсынырга мәҗбүр иткән. Ә инде аның шигырьләрен кайбер муллалар һәм искелек тарафдарлары гаепләп сөйләвеннән зарлануы хак дияргә нигез бар. Шагыйрь соңрак та алар хакында зәһәр-зәһәр һөҗүләрен (сатирик шигырьләрен) язып бастыра.

Дәрдемәнд иҗтимагый актив кеше булган. Ул I Дәүләт Думасына Оренбург губернасыннан депутат итеп сайланган, II һәм III Дәүләт Думасына сайлау вакытында сайлашучы ва-

---

* Кара: Кәримов Ф. Дәрдемәнд. – Б. 10.

зыйфасын үтәгән, Оренбург шәһәр идарәсе әгъзасы булган, мөселман җәмгыяте хәйрияләре, ярлыларга ярдәм, ятимнәрне тәрбияләү комитетларында йә рәис, яисә әгъза булып торган, аларга даими рәвештә матди ярдәм күрсәткән, үз исәбенә чит илләрдә берничә студент укыткан, татар мәктәп һәм мәдрәсәләре өчен күпләп-күпләп дәреслекләр алып биргән.

1912 елда шагыйрьнең агасы һәм нәшер эшендә аның хезмәттәше, якын фикердәше Шакир Рәмиев фаҗигале төстә һәлак булган. Бу вакыйга татар матбугатында киң чагылыш таба. Шунысы кызык, наширнең вафаты мөнәсәбәте уңае белән бирелгән телеграммалар арасында яшь Якуб Чанышевныкы да бар. Анда мәрхүмнең мохтаҗларга игелекле ярдәме санап үтелә.

Бу хәлләрдән соң газета-журнал нәшеренә караган мәшәкатьләр тулысынча Закир Рәмиев өстенә төшә. Шагыйрь ике басманы да, аларның идея һәм эстетик юнәлешләрен саклау шарты белән, берәр рәсми оешма карамагына тапшыруның юридик нигезләрен ачыклау белән шөгыльләнә.

Октябрь революциясе чорында шагыйрь читен хәлдә кала. Бу вакыйгага ул әзерлексез килә.

Шагыйрьдә элек гувернантка булган, соңрак исә Такташның хатынының әнисе Өммегөлсем Мансурова сүзләреннән күренгәнчә, Дәрдемәнд революциядән соң байлар белән аралашырга яратмаган. «Алар янына барсаң, һаман шул югалган байлыклары турында зарлану гына ишетәсең», – ди торган булган. Күп вакытын ул гаилә эчендә һәм зыялылар белән аралашып уздырган.

Шагыйрь гражданнар сугышы беткәч тә газета һәм журнал нәшер итүне яңарту хыялы белән яши. Үлем түшәгендә яткан чагында хәлен белергә килгән Риза Фәхретдиневкә ул үзенең шушы ниятен әйтә һәм әдипнең журналга янә мөхәррирлек итәргә ризалыгын сорый. Тик аңа бу хыялын тормышка ашыру инде насыйп булмый – Оренбургтан кайтканда, поездда салкын тидереп, ул 1921 елның 9 октябрендә Орск шәһәрендә вафат була. Г.Ибраһимов «Татарстан хәбәрләре» газетасына бу мөнәсәбәт белән язган мәкаләсендә ша-

гыйрьне «уяну күгендәге әүвәлге йолдызлардан иде» дип бәяләп үтә.

Дәрдемәнд иҗатын тикшерүне каләмгә эндәшеп язган шигырьләреннән башлау кулай. Аларда аның иҗат мәсләге чагыла. Шагыйрьнең әүвәл басылган шигырьләреннән берсе «Каләмгә хитаб» дип атала. Ул 1906 елда язылган.

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Түгеп күз яшьләреңне бу кәгазьгә,
Ни моңлы уйларың бар – сөйлә безгә!
Бабалар кабре янында күңел зар,
Аталар рухының армандәсе бар...
Кара туфрак тулы мәзлум нидасы.
Алар кемдер?.. Алар кемнәр фидасы ?..

Күренә ки, ихласлык һәм нечкә күңел шагыйрь поэзиясенең иң тирән мотивлары буларак күтәрелә. Төп тема исә «дөньяга килеп киткәннәр хәлен сөйләүгә» кайтып кала. Иҗатының әйдәүче аһәңе буларак моңсулык, сагыш игълан ителә.

XX йөз башында милли тарихка игътибар көчәеп китә. Тукайның «Шүрәле» поэмасына керешендәге уйланулар бу яктан характерлы. «Бабалар кабере янында күңел зар» дигәндә шул ук мотивларны күрәбез. «Кара туфрак тулы җәберләнгән җаннар ыңгырашуы»нда шагыйрьгә якынрак чор вакыйгалары белән тарихта ерак калган вакыйгалар кайтавазы уртак яңгырый. 1906 ел – царизм белән рәхимсез тарткалашу һәм канлы корбаннар чоры. Столыпин реакциясе алды, аның канлы җәзалары якынлашкан чак.

гаян ит – ачып сал

армандә – үтәлмәгән өмет

нида – зар-ыңгырашу

фида – корбан

Каләм образына бәйле икенче бер шигырендә шагыйрь болай ди:

Килки зарым!
Юк язарым,
Чөн кабул итми базар...

Ягъни гавам (толпа) зәвыгына әсәрләр яза алмавын әйтә. Шагыйрь буларак, ул, чыннан да, күбрәк традицияләр өлкәсенә карый.

Шулай да үз халкына карата язмышның рәхимсезлеген күрә торып, аның хөкеме алдында Дәрдемәнднең итагатьле кол булып та каласы килми. Милләтнең аяныч хәлен уйлаганда аңарда көрәшче дәрте кузгала:

Һөҗүм иткән фәләк җир-җир корып дам...
Ишет милләтнең ул фөрьяд вә зарын!
Сине бер хам тимер зан кылган ул хам...
Чыгар кыннан каләм – тел зөлфекарын!

Мәгънәсе болай:

Язмыш җир саен тозак корып һөҗүм иткән...
Милләтнең ул ярдәм сорап ялваруын, зарын ишет!
Сине бер чи тимер дип уйлаган ул хам,
Чыгар кыныннан каләмеңне – телнең изге кылычын!

Дәрдемәнд, шагыйрьлек бурычы турында уйланып, шулай ук каләмгә мөрәҗәгать итә. «Кыйтга» («Өзек») шыгырендә ул үзенең гамьле каләмен сабан белән чагыштыра, аңа җаннарын ачып, сүз энҗеләрен орлык итеп күмәргә куша, шагыйрьне илтеп күмгәч, туфракка чәчкән сүзләрен җан саклагыч тылсым-бөти итеп тагып йөриячәкләренә ышаныч белде-

---

килки зарым – каләмемнең зары

хам – язмышка карата әйтелгән нәфрәт сүзе

рә. Шигъриятнең тагын да киңрәк мәгънәсе турында шагыйрь дөнья поэзиясенең бөек гуманистлары дәрәҗәсендә фикер йөртә. Каләм бу очракта чырапычак рәвешендә метафоралаштырыла.

Караңгы төн исә якын-ераклар,
Хәзин кальбемне вакла – як чыраклар:
Гарибләр, шәмчырак күргәндә юлда,
Дисеннәр: бер заман бар булган ул да...

Икенче төрле әйткәндә, шигъриятнең бурычын шагыйрь кешеләргә юл яктыртып януда күрә. Шул рәвешле, каләм сурәте Дәрдемәнд поэзиясендә кайбер яклары белән Тукай «Пәйгамбәр»енә аваздаш гуманистик мәсләк мәгънәсенә ирешә.

Әле генә күздән кичергәнчә, шагыйрьнең иҗат программасында алгы планга «килеп киткәннәр әхвален бәян итү» куела. Шунысы кызык, яшь Дәрдемәнднең беренче шигырьләрендә үк үткәннәргә күз төбәү күренә. Ихтыярсыздан Ф.Кәрими истәлегендәге сүзләр хәтергә килә. Мин шагыйрьнең байлык туплау максатын күздә тотам. Тормыш уйлаганнан катлаулырак булып чыга һәм шагыйрьнең беркатлырак ниятләрен читкә тибәрә. Җитлегү елларының чынбарлыгын шат һәм кайгысыз үсмер елларына каршы куюын яшьлек идеалларының буржуаз дөнья кырыслыгы һәм катлаулы чынбарлык белән бәрелеш нәтиҗәсе дип кенә аңлап була. Дөрес, яшь кешегә хас булганча, аның тавышы әле көр, сулышы киң, хөкем йөртеше гайрәтле. Әле аның шигырендә конкрет тормыш чынбарлыгы чагыла.

Хәзергесен үткәнгә каршы куеп, узган дәверләргә мөрәҗәгать итүе алга таба тарихтан кырыс һәм дәһшәтле гыйбрәтләр алуга әйләнә, чагыштыру өчен сайлаган янәшәлекләр

хәзин – кайгылы
гариб – чит җирләрдә йөрүче, юлчы
шәмчырак – факел

арасы тарих киңлегенәчә сузыла, һәм моңардан котылгысыз фәна, үлем, юкка чыгу турында нәтиҗә ясала. Нәкъ шуны инде тикшеренүчеләр фатализм дип бәялиләр. Әмма шагыйрьнең сәнгатьчә-фәлсәфи дөньясы, тормышны аңлавы һәм күрүе моның белән генә чикләнми. Без аңарда сәламәт, көр, якты мотивларны да күп табабыз.

Дәрдемәнд үзенең оппозитив фикерләвендә чик төшенчәләр белән эш итә. Кеше язмышының ул капма-каршы иң ерак чикләренә: яшәү һәм үлемгә күз сала. Г.Ибраһимов язганча, «вакыйгъдә үлем белән хәятнең икесен дә эченә алган җиһан аңа үлем ягы белән күренә»*. Биредә ике факторның: якынлашып килүче тарихи зилзиләне тоемлау һәм Шәрекънең фәлсәфи шигърияте, аерым алганда, Гомәр Хәйям традициясенең аерылгысыз булып чагылуын күзәтергә мөмкин. Муса Җәлил, үсмер чагында яратып укыган шагыйрьләрен искә алганда, Дәрдемәндне Г.Хәйям кебек фарсы шагыйрьләре белән тикмәгә янәшә куймаган**. Яшәү һәм үлем темасы бу шагыйрьләр иҗатында үзәк темаларның берсен тәшкил итә. Дәрдемәнд биредә аеруча урта гасыр әзәрбәйҗан шагыйре Хаканига якын тора. Хакани исә үзенең «Мәдаин хәрабәләре» шигырендә «кайчандыр Җәмшидләр сафа сөргән сарайлар урынында Бәһрамнарга күләгә биргән җимерекләр генә калганга» көенә.

Дәрдемәнд тарих һәм галәм күләмендә фикер йөрткәндә, аның күз алдына вәйранлык, үлем һәм юкка чыгу гына килеп баса. «Без» шигыре, мәсәлән, болай башлана:

Гасырлар кичте... китте... кичте еллар!
Нәбиләр, падишаһлар сөрде дәүран ...
Гомерләрдер күчеп кәрван вә кәрван,
Килеп кичте җиһандан канча илләр!

* Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда. 5 т. – Казан, 1978. – Б.105.
** Җәлил М. Сайланма әсәрләр: Өч томда. 1 т., – Казан, 1955. – Б.4.
нәбиләр – пәйгамбәрләр
дәүран – дәверләр

Алга таба шагыйрь болай ди:

Исә җилләр, күчә комнар... бетә эз...
Дәрийгъ, мәхзүн күңел, без дә бетәбез!

Гомернең кыскалыгы, яшәүнең фанилыгы шагыйрьне гаҗизлеккә сала. Ул газап белән үзе һәм милләте өчен «мәңгелек яшәү чишмәсе» (чишмәи әбелхәят) эзли. 1908 елда ул дәфене (күмелер вакыты) җитсә дә, бүзләрен манарга өлгерә алмавын яза («Бүзләрем маналмадым»). Бу үкенечкә сәбәп, әлбәттә, ул чор чынбарлыгында оптимизм өчен нигез булмауда гына түгел, шагыйрьнең аны күреп җиткермәвендә, субъектив факторда һәм гомернең тиз үтүчән кыскалыгында да.

Күренешләрне галәм күләмендә иңләве белән Дәрдемәнд Көнчыгыш шигърияттенә, аерым алганда, Рудаки-Хәйям традицияләренә барып тоташа, Европа поэзиясендә исә Гётегә тартыла. Аның бер шигырендә сүз уенга чумган бала хакында бара, әмма шагыйрь карашы берьюлы аның гомер азагын да күреп ала.

Тыя күрмә уен уйнар мәлендә,
Әҗәл эшләр эшен үз тәңгәлендә!

И. Нуруллинның, иҗтимагый-тарихи юлсызлыктан чыгуны шагыйрь тормыш рәхәтләреннән эзли, дигән фикерендә хаклык бар*. Әмма беркадәр гадиләштерелгән, тулы булмаган хаклык. Тулырак аңлатманы бары шагыйрьнең фәлсәфи-әхлакый концепциясе яссылыгында гына табарга мөмкин.

Дәрдемәнд фаталистик гаҗизлектән котылу юлын мәхәббәт аша рухани-әхлакый үлемсезлеккә ирешүдә таба. Мәхәббәтне ул бу дөньяның кодрәт ияләрен үзенә буйсындырып

дәрийгъ – аһ, үкенеч

мәхзүн – кайгылы

* Нуруллин И. XX йөз башы татар әдәбияты. – Казан, 1966. – Б.67-68.

килгән мәңгелек табигать кануны итеп аңлый. Шушы кануни хискә кушылып, аның лирик каһарманы да үлемсезлеккә ирешә. Атаклы «Хәят» шигыренең мәгънәсе шушындый. Тикшеренүчеләр бу әсәрнең фәлсәфи идеясе һәм аеруча аның исеме хакында бик күп баш ваталар. Шигырьнең метафорик символикасы чыннан да катлаулы, ләкин ул татар шигърияте һәм, гомумән, Көнчыгыш поэзиясе өчен принципиаль яңалык түгел. Шушындый катлаулы метафорик телне без – Низами иҗатында, төрки әдәбиятта исә Котб әсәрендә күрәбез. «Хәят» – Дәрдемәнд иҗатының иң гүзәл әсәрләреннән, XX йөз башы татар поэзиясенең сирәк казанышларыннан берсе булып кала. Аның ритмы үтә музыкаль, аваз бизәме гаять бай, аңардагы психологик сурәт искиткеч нәфис.

Дәрдемәнд XX йөз башы татар шагыйрьләре арасында төрки-татар классик поэзиясе традицияләрен үз иҗатында тулырак чагылдырган сәнгатькәрләрдән санала. Ул классик шигърияткә затлы, гали сүз байлыгыннан, фразеологиясеннән, әдәби этикетыннан бүтәннәргә караганда активрак файдалана. Бу исә чорның шигъри эзләнүләре фонында архаиграк булып та күренә.

Шагыйрьнең «Рәсем» дигән дүртьюллыгында Хәрәзмидән (XIV йөз) алган икеюллык тулысынча файдаланылып, татар халкының әхлакый тәҗрибәсе белән баетылган һәм шагыйрьнең үзенә хас әдәп хисенә өртеп бирелгән. Дәрдемәнд аны «Нәваидән» дип китерә*.

Шагыйрьнең Котб «Хөсрәү вә Ширин»е белән танышлыгына да җитди дәлилләр бар. Моны без «Хәят» шигырендәге метафоралаштыру үзенчәлегендә дә күрәбез.

Дәрдемәнд:

Югарыга ташны ыргыткан җүләрләр
Үз аңкау башларын тишеп үләрләр.

---

* Тикшеренүчеләр Нәваинең «Мөхәкәмәи лөгатәйн» әсәрен чыганак итеп китерәләр. Анда урта гасыр төрки шагыйрьләренең әсәрләреннән үрнәкләр бирелгән. Кара: Татар әдәбияты тарихы. 1 т. – Казан, 1984. – Б. 206.

Котб:

Кеше кем күк таба таш атса, зинһар,
Теләр кем үз башын ук кыйлса азар.

Сәнгатьчә формасы һәм иҗтимагый-фәлсәфи эчтәлегенең үтә тыгызлыгы белән Дәрдемәнднең иң камил шигыре –аның «Кораб»ы. Әсәр «Шура» журналында 1908 елда, ягъни реакция чорында басылган. Тикшеренүчеләр аны Дәрдемәнднең фаталистик лирикасына кертәләр. Г.Халит, мәсәлән, шагыйрь 1905 ел революциясен «илгә һәм кешелеккә һәлакәт китерүче коточкыч стихия итеп саный», дип язды*. Тикшеренүчеләрнең җавап эзләгән төп соравы шундый: «Шагыйрь кораб образында кемне яки нәрсәне күздә тота?» Әлеге шигырьгә булган барлык шәрехләрнең нигезендә Дәрдемәнд шигъриятен артык гадиләштереп аңлау ята, «Кораб» шигырен шул чор шигъри процессыннан метафизик аерып кую чагыла. Бу кимчелектән Г.Халит хезмәтләре генә азат. Югыйсә кораб образы ул чорның күп шагыйрьләрен үзенә җәлеп иткән. Барлык очракта да ул татар милләтенең киләчәк язмышы турында уйлануларга бәйле рәвештә кулланыла. Тукай, мәсәлән, «Милләтчеләр» шигырендә:

Көймә бата; йота торган балык өчен
Корбан булган мөрәүвәтле бер җан кирәк, –

дип яза. Икенче төрле әйткәндә, халык шагыйре, милләтне һәлакәттән саклау өчен корбанга барырга кирәк, дип саный. Г.Камал исә «Милләт корабы» исемле шигырендә (1906 ел) башка кораблар арасында кыю һәм җитез юл яручы милләт корабына якты киләчәк юрый. Дәрдемәнд «ил корабы» гыйбарәсен куллана. «Ил» сүзе аның әсәрләренә еш кына «милләт», «халык» төшенчәсендә йөри. Кораб образы рухы белән Дәрдемәндкә аеруча якын рус шагыйре Фет иҗатында хәвеф тойгысына өртелә. Кешелек язмышы турында уйлаганда

* Халит Г. Габдулла Тукай. – Казань, 1956. – Б.65.

Көнбатыш Европа философиясендә бу образны фаталистик мәгънәдә Шопенгауэр куллана*.

Ни генә булмасын, Дәрдемәнднең «Кораб» шигырендә кешелекнең фаталистик һәлакәте идеясе ятмый. Ф. Кәрими язганча, шагыйрь төгәл сүзне тапмый торып, шигырен тәмамлаган дип санамаган. Тикшеренүчеләр «Кораб» шигырендәге хәвеф мотивына күбрәк игътибар бирәләр, ул хәвефнең асылы турында исә баш ватмыйлар. Ә бит уйлап карасаң, заман һәрьяклап хәвефле. 1905 ел революциясе үзе хәвефле булмаганмы? Монда исә инде реакция котырына. Шагыйрьне корбан кирәклеге борчымый, ә нинди максат һәм нәрсә хакына корбан соралуы борчый:

Нинди юллар,
Кайсы упкын
Тарта безне җан сорап?!

Әлеге метафора нигезендә киң таралган легендадагы корабны һәлакәттән саклау өчен көймәдәгеләрнең берсен мифик балыкка яисә диңгез алласына корбан итү мотивы ята. Андый легенда Г.Ибраһимовның «Диңгездә» хикәясендә дә китерелә. Дәрдемәнд үзен, ихтимал, корбаннар арасында күрә. Әмма шигырьдә куелган сорауның асылы шундый: корабны коткару өчен нинди көчкә корбан бирергә?

«Кораб» реакция елларында язылса да, шагыйрь анда революция һәм реакция чорын берләштереп иңли. Вакыт аралыгы образга камиллеккә ирешкәнче оешып утырырга мөмкинлек биргән. Үзенең образлы сыйдырышы белән, гомумиләштерүе, тәвәккәл-хәвефле аһәңе, новаторларча яңа строфикасы һәм сәнгатьчә-хисси тыгызлыгы ягыннан «Кораб» шигыре XX йөз башы татар шигъриятенең иң көчле әсәрләреннән берсе булып чыккан.

Иҗтимагый гаделлек темасы – Дәрдемәнд иҗатының үзәк темаларыннан. Шагыйрь аны төрле яклап куя һәм хәл итә.

* Шопенгауэр А. Мир как воля и представление. – Изд-во Маркса, 1968. – Б. 129.

Традиция рухында хөкемдар һәм халык проблемасы алына, ягъни хакимиятле өстеннәр һәм мохтаҗ түбән катлау кешеләре мәсьәләсе. Гаделлекнең асылын шагыйрь хөкемдарның һәркемгә тигез игелегендә күрә. Үзенең идеалын ул Тәураттагы мифик гадел патша – Сөләйман образында гәүдәләндерә. Ягъни яһүди, христиан һәм мөселман дөньясының сокланычы булган мисалга мөрәҗәгать итә.

Килсә кулдан, шат кыйл һәр җанны,
Кем ханлык будыр,
Тәхет кыйл кырмысканың күңлен –
Сөләйманлык будыр!

Чын бөеклек һәм гаделлекне шагыйрь кечкенә кеше турында кайгыртуга бәйли.

Аның гуманизмы көчләүне дә кире какмый, мәсәлән, көчләүчеләргә кырыс һәм кинаяле гаепләү белән ул болай мөрәҗәгать итә:

Ятимнәр күңлене кырдың, җимердең,
Көчең җитсә – бу зиндан ишеген ват!
Туган, алдауда мин синнән калышмам,
Күрим сине – йә, бу солдатны алдат!

Үзен ул көчләүче итеп түгел, бәлки гөнаһсыз кырмыска итеп күрә:

Зәгыйфь кырмыскамын мин юлда яткан...

Афоризмга омтылуы һәм тезмәне идея-тематик яктан чәчмә белән тулыландырып баруда Дәрдемәнд Көнчыгыш шигъриятендәге «Гөлстан» авторы Сәгъдигә якын тора. Аның фарсы шагыйреннән турыдан-туры алынмалары да бар. Чәчмә миниатюралар лирик каһарман образын, аның дөньяны күрүен тулырак аңлауга ярдәм итә. Андый әсәрләрдә әдип нечкә һәм киң күңелле шәхес, бүтәннәр бәхетен көнләшүдән

өстен зат булып күз алдына баса («Габдуллабыз борынгы Габдулла түгел иде...» хикәясен генә алыйк). Чәчмәдә һәм шигырьләрендә шагыйрь дуслыкны дөньяның иң зур байлыгы итеп тасвирлый. Байлык, гомер һәм дуслык мотивлары каршылыгына корылган «Ни гамь бөлсәм...» шигыре бу яктан үзенчәлекле:

Ни гамь бөлсәм, әгәр үлсәм, ни ваем,
Эчеп дуслык шәрабеннән исерсәм,
Булып дуслар белән берлектә даим,
Гомернең тиз үтәр язын кичерсәм.

Г. Халит бу шигырьне Г. Хәйямнең «Ләззәтле яшәү өчен, ләззәт хакына яшә. Калганы барысы да – ышан – бары буш ыгы-зыгы», – дигән юллары белән чыгыштырып: «Шулай ук Дәрдемәнд поэзиясендә дә лейтмотив буларак һаман да шул ике яклы фәлсәфә уздырыла – язмыш каршында буш, көчсез, әмма шулай да бу дөньяда яшәү шатлыгын татып калырга кирәк», – дип яза. Дәрдемәнд шигыре бу контекстта уңышсыз китерелгән. Болай шәрехләү шагыйрьне, берни уйламыйча, тормыш рәхәте генә кичереп яшәүче дәрәҗәсенә төшерә. Әлеге шигырь исә, киресенчә, гуманист шагыйрьнең гади эпикурчыдан өстенлеген гәүдәләндерә. Әхлакый кыйммәтләрне ул байлыктан югары куя. Байлык һәм нигъмәтләрнең ышанычлы түгеллеген тоя, әлбәттә. Әмма тормышны дуслар белән кичерү мөмкин чагында мондый ихтимал аны куркытмый. Бу шигырьне һәм шагыйрьнең теләсә кайсы бүтән әсәрен бары аның рухани-әхлакый, киңрәк алганда исә, гуманистик иманы яссылыгында карап кына дөрес бәяләргә мөмкин.

Үзенең мәгърифәтчел идеяләре, фәннең, гыйлемнең куәтен данлавы, кешенең танып белү сәләтенә соклануы, укытудагы торгынлыктан һәм кешенең дәрәҗәсен кимсетүче тәрбия ысулларыннан көлүе белән шагыйрь XIX йөзнең олы шагыйрьләре һәм татар иҗтимагый фикеренең күренекле эшлеклеләре белән аваздашлык таба. Бу өлкәдә, бигрәк тә афо-

ризмнар белән эш итүдә ул Акмуллага якын тора. Шунысы кызык, шигъри форма, ритм һәм аһәң үзенчәлеген төрләндергәндә, шагыйрь төрки эпос тәҗрибәсенә таяна. Хис һәм сурәт бирелешенең аеруча нәфислеге белән күзгә ташланган «Видагъ» шигырендә бу нык сизелә. Дәрдемәнднең афористик тапкырлык өлгесе эзләп, «Идегәй» дастынына мөрәҗәгать итүе игътибарга лаек.

Мөгезе бар куйның бары кучкар түгел,
Очкан кошның бары да шоңкар түгел,
Кемнәр әйтмәс шигырьне, әйтер берүк,
Чукаңлаган аксак ишәк тулпар түгел.

Әлеге шигырьнең барлык афористик фактурасы «Идегәй» текстыннан. Шагыйрь аны шигъри иҗатка кайтарып калдырган. Дастанда әлеге афористик өзек болай яңгырый:

Атның бары тулпар булмас,
Кошның бары шоңкар булмас,
Ишәк дөя булмас,
Сыер бия булмас...
Бинең аты би булыр,
Колның аты кол булыр...

Туктамыш хан Идегәйнең улы Норадынга шулай эндәшә. Биредә иң мөһиме шул: татар халкының борынгы дастаны зур шагыйрьләр колагына чалына килгән һәм алар аның колоритлы кисәкләрен шул рәвешле кәгазьгә терки барганнар. Дәрдемәнд шигыренең тирән байлыгы һәм үзенчәлеге исә татар шигыренең күп гасырлар төрле чыганакларын үзләштереп тыгызлаудан хасил булган.

Дәрдемәнд, табигать гармониясенә кушылып, яшәү мәгънәсенә һәм дөнья серләренә төшенергә омтыла. Бөтен тирә-

---

кучкар – тәкә

чукаңлаган – чатанлаган

лекне панорам иңләве белән дә, реалистик төгәллеге ягыннан да, ритм-аһәң һәм калып-төзелеш төрлелеге белән дә аның табигать лирикасы XX йөз башы татар поэзиясенең кабатланмас күренеше булып кала. Бу лириканың фәлсәфи нигезен Г.Халит «пантеистик оптимизм» дип билгели. Шагыйрьнең табигатькә мөнәсәбәтен һәм лирик героеның табигать белән кушылу үзенчәлеген лирик пантеизм дип атарга мөмкин булыр иде. Бу цикл шигырьләрнең күпчелегендә темага импрессионистларча якын килү сизелә, икенче төрле әйткәндә, сәнгатькәрнең игътибары күренешләрне күбрәк шәхси хиссияте аша үткәреп кабул итүгә юнәлә. Мондый шигырьләр форма ягыннан да традицион поэзия кысаларыннан тулысынча азат дәрәҗәдә диярлек иркен төрләнүчәннәр. Алар йә таныш ритмик тезмәләрнең музыкальлеген саклаган хәлдә яңа строфик рәвеш ала, йә бөтенләй ирекле шигырь төсенә керә. Бу исә шулчаклы табигый һәм гади килеп чыга ки, укучы хәтта форма үзенчәлеген дә сизми кала. Әнә шулай талантлы рәвештә һәм күзгә артык ташланмыйча, шагыйрьдә милли шигырь яңарышы бара.

Менә берничә мисал.

Ятам кайчаклары моңлап,
Һаваның тынлыгын тыңлап,
Килә өннәр колак чыңлап,
Диямен:
– Ни бу? Нидәндер бу?
Җавап урнында гөрли су,
Тирәклек тирбәнә, шаулый!..

Яки:

Бу ул матур, бу ул күркәм,
Бу ул,
Бу ул – хуш исле яз!
Бу ул – хуш исле таң җиле...

Беренче очракта каршыбызда тирән уйлануларның психологик сурәте калыкса, икенче очракта табигать яңарышыннан хозурланучы, тантана итүче шагыйрь җаны күз алдына килә. Мондый үрнәкләр соңрак шигырь формасын яңартуда Һади Такташ ясаган даһи тәҗрибәләргә, һичшиксез, этәргеч биргән булырга тиеш.

«Сеңеп җиргә...» дип башланган шигырь үтә нечкә күзәтү һәм сынландырулары белән импрессионистик төсмер ала. Анда табигатьнең бер халәттән икенче халәткә күчеше, әверелеш нечкәлекләре тасвир кылына. Елганың агуы, суларның ташларга бәрелеп чәчрәве, таулар арасыннан бормаланып, күбекләнә-күбекләнә узуы, яктыда дулкын-дулкын булып бөтерелеп пар-бу күтәрелүе, күз яше бөртегендә кояш нуры чагылып, аны алсу кан төсенә кертүе сурәтләнә, шагыйрь җанындагы киеренке драматизм чагыла.

Дәрдемәнд шигъриятенең үзәгендә туган ил мотивы ята. Аның шәхси иҗади драмасы шушы мотив тирәсендә хәл кылына. Шагыйрь өчен изге булган ватан сүзе гаять киң сыйдырышлы: ул – туган җир төшенчәсен дә, милләт һәм тулаем туган ил мәгънәсен дә үз эченә ала. Ул үзен иле язмышына береккән итеп күрә:

Булырмы яз, исеп җилләр,
Килерме җәй, ачып гөлләр;
Җитәрме кыш, кичеп еллар,–
Диямен, сез, газиз илләр.

Шагыйрьнең шушы темага язылган атаклы икенче бер шигыре икърарының сафлыгы, иҗтимагый аңының югарылыгы белән җәлеп итә:

Атам-анам йорты өчен
Булса мең җаным фида,
Туган-үскән илем өчен
Соң тамчы каным фида.

Дәрдемәнд, аерылгысыз булган «ватан» һәм «туган халык» төшенчәсен дилеммага әйләндереп, үз алдына үтә драматик сорау куя. «Гөрләгән сулар...» дип башлаган шигырендә:

Ни газизрәк, бу ватанмы?
Аһ, туган каумем газиз, –

ди.
Биредә татар халкының милли-тарихи язмыш үзенчәлеге, аның төрле җиргә таралып утырганлыгы, күпчелегенең борынгы милли үзәгеннән аерылган булуы чагылыш тапкан.

Октябрь революциясе шагыйрь алдына: «Син кем ягында?» – дигән сорауны бөтен кискенлеге белән куйды. Бу сорауга ул чорда анык сыйнфый җавап сорала иде. Дәрдемәнд «үз сыйнфыннан» аерылган, «җиңүче сыйныфка» исә кушылып китә алмаган хәлдә, ике уртада торып кала. Ватан мәсьәләсендә ул тар сыйнфый эгоизмнан югары күтәрелә алды. Шушындый драматик шартларда ул үзе өчен бердәнбер дөрес нәтиҗәгә килә:

Илдә бер дус булмаса гәр,
Ил бөтен дошман түгел.

Шагыйрь үз сыйныфына карата тарихның кырыс хөкемен ирләрчә кабул итеп, Октябрь революциясенә мөнәсәбәтен ап-ачык билгели. Социалистик революцияне ул илнең тормыш туе дип атый, яңа тормыш башлануы итеп саный. Алай гына да түгел, ул үзе шушы туйга «кияү» булырга әзерләнгән, әмма туйның үзе өчен уздырылмавын яхшы төшенә. Аның шушы икърарында тирән трагизм чагыла.

Җиһан тормыш туен иткән чагында,
Синең урының үлекләр аймагында.

Тормышның яңа хуҗалыгы белән яманатлы булмас өчен, аның сазы бөтенләйгә тына.

Дилең өчен телең булсын тозаклы –
Йөз аклыгың өчен аузың йозаклы,–

дип киңәш итә ул үз-үзенә.

Сәнгати күренеш буларак, Дәрдемәнд иҗаты төрле шигъри мәктәпләр һәм эстетик башлангыч үрелмәсеннән хасил. Көнчыгыш-Көнбатыш синтезына аяк басканда, ул татар теленең сафлыгын да, фольклорга хас шигъри фикерләүне дә үзләштерә, үзенең шигъри палитрасын халык эпосы ритмнары һәм калыплары белән сафландыра, сөйләмнең интонацион мөмкинлекләреннән файдаланып, шигъри синтаксисны камилләштерә. Форма, эчтәлек һәм мотивлар өлкәсендә, әлбәттә, аның нигез платформасы булып классик төрки шигырь кала. Шушы нигездәге Көнчыгыш башлангычын ул рус һәм Көнбатыш Европа поэзиясенә хас форма, алымнар һәм аһәң белән куша. Татар җанлы сөйләм интонациясенә нигезләнүнең гамәлдәге тәҗрибәсе һәм конкрет үрнәкләре белән ул шигырь төзүнең үзенә кадәрге классик поэзия практикасына таныш булмаган рациональ юлларын күрсәтеп бирә. Мәсәлән, «Бүзләрем маналмадым» әсәрендә шигъри юлларның тулы синтаксик вариантыннан соң аның интонацион кыскартылган вариантын китерә:

Кемгә васлəт, кемгә өмид
Нигъмәтен бирде фәләк.
Мин өмиднең сул кулыннан
Бер сынык нан алмадым.
Кемгә васлəт, кемгә өмид!
Мин сынык нан алмадым.

Дәрдемәнд шигъри тәҗрибәсенең әһәмияте XX йөз башы һәм безнең көннәрдәге татар поэзиясе өчен гаять тирән бул-

---

васлəт – кавышу

фәләк – язмыш, тәкъдир

ды. Лирикасының идея һәм мотивлары ул чор татар зыялыларының фикер һәм кичерешләренә күп яклап аваздаш яңгыраган. Үз чорында аларны Г.Ибраһимов та уртаклашкан. Сәнгатьчә эзләнүләре һәм, гомумән, шигъри культурасы белән Дәрдемәнд еш кына Тукайга якын тора, кайвакыт исә аның белән бәхәскә керә. Шигырьләрнең аваз бизәме, аһәңдәшлеге (ассонанс) һәм эчке рифмалар муллыгы ягыннан бу ике шагыйрь арасында уртаклык шактый. Монда үзара ярыш һәм бер-берсеннән өйрәнү дә чагыла булса кирәк. Менә үзенчәлекле берничә мисал.

Дәрдемәнд:

Ил мөмәййез, аңлар ул тиз,
Син аны сизмәс, димә.

Җитте дәфнем вакты,
Кәфнем бүзләрен маналмадым...

Тукай:

Үзләре сүздән түбәннәр, күзләре тездән түбән...

Монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан, монда нур,
Монда минем нечкә билем, җәннәтем һәм монда хур.

Кыскасы, бу шагыйрьләрнең икесе дә шигырьне аваз ягыннан эшкәртүдә, ягъни инструментовка өлкәсендә үтә нечкә осталыкка ирешәләр.

Дәрдемәнд яшь Исәнбәткә, М.Җәлилгә, Х.Туфанга, С.Хәкимгә бәрәкәтле йогынты ясаган, хәзерге татар поэзиясендә исә аның шигъри мәктәбеннән Р.Фәйзуллин, Р.Харис, Р.Гатауллиннар уңышлы файдалана.

(«Казан утлары». – 1989. – №12. – Б.165-175.)

мөмәййез – сизгер

Тукай-Дәрдемәнд мөнәсәбәтләре

«Аңлашу»

Мөхтәрәм «Вакыт» гәзитәсенең 12 нче номер әдәбият мәҗмугасенең ахыргы сәхифәсендә һич мөнәсәбәтсез вә хаксыз уларак минем «Мөтәшагыйрьгә» дигән шигыремә каршы мине тәхкыйрь юллу язылмыш шигырьләр дәреҗ ителмеш.

Бәнем «Мөтәшагыйрьгә» шигърене язуым аслан «Вакыт» гәзитәсенә юнәлтеп түгелдер. Шул шигырьне язганда «Вакыт» гәзитәсе минем хәтеремә дә килгәне юктыр.

Беләм ки, минем шигыремдә «вакыт» ләфзының мөгътәриза эченә хатамы, йә үземнең синтаксик кагыйдәсенә мөсаһәлә итүемнәнме төшүе мөхтәрәм «Вакыт» мөхәррирләрен шөбһәгә төшермештер. Миңа «Вакыт» гәзитәсен кимсетергә бер дә юл юктыр. Чөнки «Вакыт» гәзитәсе әшгарь мәҗмугасе түгелдер ки, мин аны тәнкыйть итеп, «Мөтәшагыйрь» исемен бирим.

Икенчедән, мин һәммә ислам гәзитәләрен җаным кадәр сөямен. Һичберсенә тел озату минем шаным түгелдер.

тәхкыйрь юллу язылмыш – кимсетү максатында язылган

дәреҗ ителү – басылып чыгу, матбугатка чыгу

аслан – бөтенләй

ләфзы (ләфыз) – сүз

мөгътәриза – җәя

мөсаһәлә итү – игътибарсызлык күрсәтү

әшгарь – шигырьләр

шан – дан, дәрәҗә

Минем бәгъзе вакытта, дөрест, «Борһане тәрәккъый»дә бер дә кирәкмәгәнгә урын алган бәгъзе шигырьләргә эчем пошадыр. «Мөтәшагыйрьгә» шигыре, ихтимал, шундый эч пошулар сәбәпле ихтыярсыз язылган булыр.

Инде «Вакыт»тан түбәнчелек белән үтенәмен ки, Хода хөрмәте өчен бу яңлыш уларак киткән фикерне кайтып алсын. Мин бу кадәр нахак сүзләрне тәхәммел итә алмыйм.

Гаҗиз: Габдулла Тукаев».

«Вакыт» газетасы, үз нәүбәтендә, Г.Тукайның бу ачык хатына каршы «Вакыт»ның 1907 ел, 196 нчы санында шулай ук җавап хаты бастырып чыгара:

«Аңлашу»ның җавабы

«Мөхтәрәм Габдулла әфәнде!

Мәгълүм шигырьләреңездә «вакыт» кәлимәсене мөгътәриза эченә куюыңызга бер сәбәп күрмәдекемездән безне касд итдекеңезне зан әйләмеш идек. Соңра исә ерак вә якын җирләрдән килмеш мәктүбләрдән бер кач әдипләрнең бигайниһи безем кеби бер занда улдыкларыны аңладык.

Ошбу тараф мөселманнарының Мәгарриләре улачак әдип өмидләнеп тордыкымыз бер затның (занымызга күрә) бөйлә салкын мөгамәләсенә вәҗһе тапмадыкымыздан сөкүт илә кичмәк дә бер әдиб хакында рәва улмадыгыннан, тәхкыйрь

тәхәммел итү – күтәрә алу, түзү, чыдау

кәлимә – сүз

касд – ният итү

зан әйләү – уйлау

кач – берничә, төркем

бигайниһи – үзгәрешсез

бөйлә – шулай, шул рәвешчә

вәҗһе – сәбәп

сөкүт илә – дәшмичә

рәва – яраклы, ятышлы

касдилә дәгел, бәлки зарафәт юлында нәсихәт итмәк ниятенә мәбни шөйлә шигырьләр басылды.

Шимди сез үзеңезнең шигырьләреңездә безне ирадә әйләмәдекеңезне сөйләрсез вә сезләрә хитаб ителмеш шигырьләрнең кире алынмасыны эстәрсез. Без дә мәмнүният илә морадыңызга муафыйкъ итеп 12 нче номер «Әдәбият мәҗмугасе»нең соң битендә сезләрә хитаб ителмеш шигырьләрне тәмам алдык. Вә сезнең шигыреңез нә хөкемдә калмыш исә, бездә язылмыш шигырьләр бигайниһи шул хөкемдә калыр.

«Йолдыз» мөгътәбәр гәзитәләрдән улдыгы өчен безем кашымызда һәм мөхтәрәмдер. Шуның өчен мәктүбеңезне аңа вирдегеңезгә бер сүземез юк. Фәкать кәндемезә тугъры юлламыш улса идеңез, дәһа гүзәл вә дәһа самими улачак иде. Һәрхәлдә, вазыйфамыз әүвәлгесе кеби сезә хәер-хаһлыктыр.

«Вакыт» [редакциясе]».

«Борһане тәрәккъый» – 1906-1910 елларда Әстерханда чыккан татар газетасы.

«Йолдыз» – 1906-1918 елларда Казанда Һади Максуди (1868-1941) наширлегендә һәм мөхәррирлегендә чыккан татар газетасы.

(Дәрдемәнд (Закир Рәмиев). Исә җилләр. Шигырьләр / Төз. һәм иск. язучы Р.Даутов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – Б.220-223.)

тәхкыйрә касдилә дәгел – кимсетү нияте белән түгел

зарафәт – нәзакәтлек, тәрбиялелек

мәбни –нигезләнгән

шимби – хәзер

ирадә әйләмәдекеңезне – безне күздә тотмавыгызны мәгънәсендә

хитаб ителмеш – багышланган

мәмнүният илә – шат һәм риза булып

кәндемезә – үзебезгә

ХАТЛАР

1. Мөхәммәтшакир Рәмиевтән Мөхәммәтзакир Рәмиевкә

Биисмиһи тәгалә.

Гыйззәтле Мөхәммәдзакиргә күп сәламнәр укыдык.

Безләр, барчаларымыз да, әлхәмделиллаһи, саг-сәламәтләр идек.

Сезнең гыйнвар башларында язган хатыңызны йулыкып, сәламәтлек вә хәл-әхвалләреңезне белеп, тәскине калеб әйләмеш идек. Ләкин хатыңыз бик кыска язылмыш икән. Без сездән бу озак вакытлар язылмаган хатны да озын вә тәфсыйльрәк көтә идек. Бу хат, күп улса, бер сәгать вә йә ярым сәгать хезмәте кебек күренде. Дәресеңез вә аның һәземендән дә язмагансыз. Вә уйлә бер мөешдә ултырыб укымактан максуда ирелешәчәкме – белмәймез. Французча, немеччә анда укылмаса да ярапр мәгърузате мәйдан вөҗүдә килтереләчәк кабилият тәхсыйль иделәчәкме? Типография вә гәзитәләр хакында бер-ике сүз язмагансыз.

Әмма «Тәрҗемане хакыйкать»[1] безләрә күбдән килә башлады. Укып фәүкыль-хидд рәхәтләнәмез. Әүвәлге хатымда аның килгәнен язарга да онытканмын. Насыйб булса, аны һаман да җибәртеңез һәм, мөмкин булса, «Һәфтә»[2] кеби берәр журналдыр, атнада нәшер иделә торган гәзитәнең яхшырагыннан җибәрсәңез, яхшы улыр иде.

Мөхәммәдрәхим әфәнденең Эстәрлетамакка язган хатының мәфһүмен сезнең хаттан әүвәлрәк белмеш идек. Сезнең



Шакир Рәмиев хаты.
(«Шура». – 1913. – №6. – Б.189.)

хәлеңезе вә сәламәтлегеңези язган икән һәм арада улан бераз мәхәббәт тә күренмеш. Фәләкийәттән тәхсыйль вә истикамәт бик гүзәл вә гайре дийә язмыш. Һәр нә улса, ул хатлар килгәләгәч куаныштык.

Әбрә абзыйның сезгә җибәргә дип язган хатыны җибәрдем, күрерсез. Ул бичара да хөкүмәт хезмәтендән калып, бераз әндишәләрә керешмеш, күрәрсез. Безем бу тарафта да азлап-азлап кузгалышып, байагы тәгъмиме мәгариф дийә чалышмакчы булалар. Ликин нә кадәрә варыр, һич әйтер хәл юк.

Безем халык үрәдник күргәндәгедәй, өстендә чапан, башында чалма улмаган хәлдә сөйләйән адәмнең сүзенә һич игътибар улгандай чамасы юк кебек, Гаспринскийның гәзитендән дә бәгъзе адәмләр өркешеп, ерактан гына таяк илән төртеп «гәзитә-гәзитә, дөнья бозылырга итә» диешәләр. Дөрест, хайван да тәгълим кабил, вара-вара инсафка килә. Заман әхвале күстәрәчәк вак-төяк китаплар, мәҗмугаләр укылмак зарур. Безем милләт өчен исеме китап улсын – гәзитә улмасын. Бу сәбәпле фәһем алырдай әнвагы китапдан вә гомранийәти күстәрән руманлар монда күбрәк алып кайта күр.

Типографияэ шрифтләрен ничек идәрсең, нә бәһаләр илән алмак мөмкин – язарсыз. Вә бу сәфәр алып кайту мөмкинме, яки соңра улса да алдыру яхшы улырмы? Ничек тә улса, бу хосуста гайрәт итмәк кирәк иде. Чөнки әүвәл берничә ел китаплар бастырылса да яраячак һәм китап күп сатылачак файда илән. Вә йәнә Оренбурыхдагы мәгълүмеңез Кәрвансарай биналарыны хәзер хөкүмәтдән мөселманлара тәрек иделмәсен сорай башладылар һәм шуның өчен ничә вулысдан пригавор давиренныслар җыелып иҗтиһад идәләр. Хода насыйп итеп, бирелә калса, мәдрәсәләр улса, безә бер фале хәйр улыр иде. Бер-ике ел безем кулларымыза төшкән бу кеби маддәләр гайре адәмләрә төшә башлавы тәгаҗҗеб итмәңез.

Үзем фибрал башында өйдән чыкыб, Сенбер һәм Мәскәү сәфәре йөреп кайтып киләмез. Товар-чәй кебек нәрсәләр кирәгенчә алып кайттык. Бу ел алтын эшләремезә терәк улыр

ризаларымыз ничек улыр, мәгълүм түгел. Бик кыен кебек күренеп тора. Үзеңез быел Мәкәрҗә ярминкәсенә карап кайта күреңез һәм кайтуыңыздан хат языңыз. Бүгенге хатыңыздан соң әткәйләр 300 тәнкә акча җибәргән иде. Кирәк булындыкда дәхи язарсыз – җибәрермез. Безем табигатьчә, ул җирдә расхутны кысып тотканда, таман килер.

Алган китапларыңнан безгә дә җибәрә алмамсың? Цензорда мәшәкате күп улмаса, җибәреңез. Гәзитәләрне цензорда карап, бәгъзе җирләрен кара буяу илән буяп җибәрәләр.

Әткәй Оренбурыхда икән. Бергә Йулыкка кайтамыз. Ликин сезнең тиз хат язмаганыңыз – кирәк, үзеңезгә, кирәк безгә бик күп зарар. Кыска-кыска гына хатлар язгалап торырга кирәк. Хат көтә-көтә бик тәшвишләнеп, хафаланамыз. Бу фигыленңне сахихән тәкъбих идәрем ки, күп зарарлары, бәстләр һәм улдыкны ахырында үзең дә сизәрсең.

Әддагый Мөхәммәдшакир ибне Мөхәммәдсадыйк.
81 нче сәнә, 16 март.

(«Шура» журналы. – 1913 ел. – № 6. Б.189-191.)

Тәрҗемәсе:

Бөек Алланың исеме белән.

Гыйззәтле Мөхәммәтзакиргә күп сәламнәр укыдык.

Безләр, барчаларыбыз да, әлхәмделиллаһи, сау-сәламәтләр идек.

Сезнең гыйнвар башларында язган хатыгызны алып, сәламәтлек вә хәл-әхвалләрегезне белеп, күңел тынычлыгына ирештек. Ләкин хатыгыз бик кыска язылган. Без сездән бу озак вакыт язылмаган хатны да озын вә тәфсыйльлерәк булыр дип көтә идек. Бу хат, күп булса, бер сәгать йә ярты сәгать хезмәте кебек күренде. Дәресегез вә аны үзләштерүегезне дә язмагансыз. Вә шундый бер почмакта мөешдә утырып укымактан максатка ирелешәчәкме – белмибез. Французча, немеччә анда укылмаса да ярар гамәл мәйданы тормышка ашырылачак сәләт хасил ителәчәкме? Типография вә гәзитәләр хакында бер-ике сүз язмагансыз.

Әмма «Тәрҗемане хакыйкать» безләргә күптән килә башлады. Укып чиктән тыш рәхәтләнәбез. Әүвәлге хатымда аның килгәнен язарга да онытканмын. Насыйп булса, аны һаман да җибәртегез һәм, мөмкин булса, «Һәфтә» кеби берәр журналмы, атналык нәшер ителә торган гәзитәләрнең яхшырагыннан җибәрсәгез, яхшы булыр иде.

Мөхәммәтрәхим әфәнденең Эстәрлетамакка язган хатының эчтәлеген сезнең хаттан әүвәлрәк белгән идек. Сезнең хәлегезне вә сәламәтлегегезне язган икән һәм арада булган бераз хөрмәт тә күренгән. Астрономияне өйрәнү бик яхшы вә башкалар дип язган. Һәр ни булса, ул хатлар килгәләгәч куаныштык.

Әбрә абзыйның сезгә җибәрергә дип язган хатын җибәрдем, күрерсез. Ул бичара да хөкүмәт хезмәтеннән калып, бераз мәшәкатьләргә тарыган, күрерсез? Безнең бу тарафта да азлап-азлап кузгалышып, баягы мәгариф тарату дип эшкә керешмәкче булалар. Ләкин ни кадәргә барыр, һич әйтер хәл юк.

Безнең халык үрәдник күргәндәгедәй, өстендә чапан, башында чалма булмаган хәлдә сөйләгән адәмнең сүзенә һич игътибар булгандай чамасы юк кебек, Гаспринскийның гәзитеннән дә кайбер адәмнәр өркешеп, ерактан гына таяк илән төртеп «гәзитә-гәзитә, дөнья бозылырга итә» диешәләр. Дөрес, хайван да өйрәткәнне кабул итә, бара-бара инсафка килә. Заман әхвален күрсәтә торган вак-төяк китаплар, журналлар укылуы зарур. Безнең милләт өчен исеме китап булсын, гәзитә улмасын. Бу сәбәпле фикер алырдай төрле китаплардан вә мәдәниятне күрсәткән романнар монда күбрәк алып кайта күр.

Типография шрифтларын ничек итәрсең, ни бәһаләр илән алмак мөмкин – язарсыз. Вә бу сәфәрдә алып кайту мөмкинме яки соңрак булса да алдыру яхшы булырмы? Ничек булса да, бу хосуста гайрәт итмәк кирәк иде. Чөнки әүвәл берничә ел китаплар бастырылса да яраячак һәм китап күп сатылачак файда беләэн. Вә йәнә Оренбургтагы үзегезгә мәгълүм Кәрвансарай биналарын хәзер хөкүмәттән мөселманнарга бирү-

не сорый башладылар һәм шуның өчен ничә вулыстан имзалар, довиренныслар җыеп тырышалар. Ходай насыйп итеп, бирелә калса, мәдрәсәләр булса, безгә бер хәерле фал булыр иде. Бер-ике ел безнең кулларыбызга төшкән мондый маддәләр башка адәмнәргә төшә башлавына гаҗәпләнмәгез.

Үзем фибрал башында өйдән чыгып, Сембер һәм Мәскәүгә сәфәр итеп кайтып киләмез. Товар-чәй кебек нәрсәләр кирәгенчә алып кайттык. Быел алтын эшләребезгә терәк булырга ризалашкан кешеләребез ничек булыр, мәгълүм түгел. Бик кыен кебек күренеп тора. Үзегез быел Мәкәрҗә ярминкәсен карап кайта күрегез һәм кайтуыгызны әйтеп хат языгыз. Бүгенге хатыгыздан соң әткәйләр 300 тәңкә акча җибәргән иде. Кирәк булганда тагын язарсыз, җибәрербез. Безнең табигатьчә, ул җирдә расхутны кысып тотканда, таман килер.

Алган китапларыңны безгә дә җибәрә алмассыңмы? Цензорда мәшәкате күп булмаса, җибәрегез. Гәзитәләрне цензорда карап, кайбер җирләрен кара буяу белән буяп җибәрәләр.

Әткәй Оренбургта икән. Бергә Йулыкка кайтабыз. Ләкин сезнең тиз хат язмавыгыз – кирәк үзегезгә, кирәк безгә – бик күп зарар. Кыска-кыска гына хатлар язгалап торырга кирәк. Хат көтә-көтә бик тәшвишләнеп хафаланабыз. Бу фигылеңне хупламыйм, күп зарарлары, сәбәпләре булганын ахырында үзең дә сизәрсең.

Догачы Мөхәммәтшакир Мөхәммәтсадыйк улы.
1881 ел, 16 март.

Искәрмәләр

1. «Тәрҗемане хакыйкать» – Төркиядә нәшер ителгән газета.
2. «Һәфтә» – Төркиядә нәшер ителгән журнал.

2. Закир Рәмиевтән Фатыйх Кәримигә*

Биисмиһи

Мөхтәрәм борадәрем Фатыйх әфәнде!

Җәнабеңезгә ихласлы сәламнәремне күндердем. 7 нче сентябрьдә язмыш мөбарәк мәктүбеңезне алдым.

Мәкәрйә әхваләтен укып, Шакир абзый белән берлектә гаять мөтәләззиз булдык. Бер дәрәҗә гүзәл муаффәкыять вә максатка яхшы гына хезмәт вакыйг булган дип, хисап кылыштык. «Интеллигентный кружок» ляихәсеннән копия күндермәкеңезе үтенәмен – хезмәте күп булмас.

Мөхтәрәм Риза казыйның Оренбурга торуга килү ихтималыны укыгач, мәгълүм газета мәсьәләсене кузгатып сөйләштек. Рөхсәт сорау өчен хәзерге вакыт, иншаллаһ, муафикъ булса кирәк, диештек. Бинаән галә зәликә, Шакир абзый Хәсән җизни Акчурингә[1] хат язды, Петербурга барырга үтенеп, һәм муафыйк җавап килде исә, расходка лязим акчасын тизлектә йибәрермез, дип язды. Һәр ни гәзит иҗтиһадында булачакмыз. Әгәр Акчурин барудан отказаться итсә, сезгә язармыз.

Бу хосуста мәслихәт күрсәгез, Риза казый әфәндене хәбәрдар итәрсез. Әгәр Акчурин бу эшкә алынса, Өфе шәһәрендә мәхале нәшер улачак ихтимал, әгәр алынмаса – мәслихәт вә имкяне кай шәһәрне иҗаб кылыр.

Шакир абзыйның сәламәтлеге, Ходага шөкер, бу ел бик яхшы.

«Шу фәлякәтле хутор» мәсьәләсе хакында Шакир абзыйның фикере ошбу: саткан хәлдә алты, әкалль биш йөз тәңкәдән кимгә булганда, сатмауны мәслихәт күрәдер. Сатмаган хәлдә насосын алдырып, прииска йибәртергә үтенәмез. Оренбурга алдырсаңыз, безнең Габдрахман ямщик табып, төятер Шакир абзыйга. Өен алучы булса, урыныннан, булмаган тәкъдирдә – боздырып, Оренбург китертеп сатарга мөмкин,

---

* Хатта Ф.Кәрими кулы белән 1905 елның 26 сентябрендә алынуы теркәлгән.

ягъни таштан гайре агач нәрсәләрен. Плодовай агачларны, мөмкин булса, бер маклер кушып, биш-ун төпләп саттырып карарга мөмкин – һәр ни өч йөз тәңкәгә биргәннән шулай бозып алган артык булыр дип уйлыйдыр – насосы үзе ике йөзләргә торырлык дип чамалый – насостан гайресеннән йөз тәңкә, әлбәттә, хасил кылып булса кирәк ди – янә сезнең, ничек күрерсез, мәсьәләнең һәр тарафы сезгә мәгълүм.

Госман Нури[2] әфәндегә көч-хәл белән ошбу көн мәктүбҗавап яздым. Җавапны бу кадәр кичектергәнемә ояламын.

Йибәргәнеңез «Нәшрияте Кәрими»ләр[3] килеп тора, тәшәккерләр кылып укыймын. Сәламәт буласыз.

Газиз гомерегезгә бәрәкәт теләп кәминә Закир.

19 сентябрь, 1905 сәнә.
Искәндәрский приискадан.

Татарстан Милли архивы, 1370 ф., 2 тасв., 20 эш, 10, 10б битләр.

борадәрем – туганым
мөтәләззиз булдык – тәм таптык, сөендек
муаффәкыять – яраклылык, туры килү
ляихә – проект
бинаән галә зәликә – шуңа күрә
лязим – тиешле
мәслихәт күрсәгез – кирәк тапсагыз
мәхәле нәшер – нәшер ителү урыны
имкян – мөмкинлек
иҗаб кылыр – уңай күрер
«шу фәлякәтле хутор» – «шул бәлале хутор»
әкалль – иң аз дигәндә мәгънәсендә
тәшәккерләр – рәхмәтләр
кәминә – ким, фәкыйрь

Искәрмәләр

1. Хәсән Акчурин (1866-1916) – мәшһүр татар байларыннан, меценат, коллекционер.

2. Госман Нури – Кырым әдипләреннән Госман Нури Акчокраклы.

3. «Нәшрияте Кәрими»ләр – Кәримиләр тарафыннан серия рәвешендә нәшер ителеп барган китаплар турында сүз бара.

3. Закир Рәмиевтән Фатыйх Кәримигә*

Биисмиһи

Мөхтәрәм борадәрем Фатыйх әфәнде!

Бакча хосусында шөбһәсез җавапка мөнтәзыйрсыз! Әүвәл үзем өйдә булмадым. Икенче – абзый белән мәслихәт кылу зарур булды – көннәр үтте.

Бакчаны хәзергә ул бәһагә сатмау мәслихәт күренде. Насыйп булса, язга чыккач бер мәслихәтен кылып карармыз. Кышлык расход, әлбәттә, безнең өстемездә.

Газета хосусында һичбер тәшәббестә булынганымыз юк. Оныткан өчен түгел, бәлки мәркәздә әхвале сәясийәнең көн саен хөсне тәбәддел кылмакта вә «явочный порядок» өмиде барган саен куәт алмакта булган өчен. Хода кушып та тизлектә «Хөррияте тамм» галәбә тапса, хәзерге хәлдә кабулына мозтар булганымыз күп «чара юк»лар, мәванигъләрдән котылыр идек. Шуңа күрә янә бераз сабыр итсәк микән димез. Сез ни диярсез?**

Думага вәкаләт хосусында Оренбур олугларының мәктүбен алдым. Әлбәттә, андый илтифатка хөсне тәвәҗҗеһкә мәмнун булмамак мөмкин түгел. Шакир абзый белән мәслихәт кылганым юк әле. Мәслихәт кылгач, Нургали җизнәйгә җавабымны әйтәчәкмен. Әмма хәзерге сәгатьтә үз фикеремне сезгә мәхрәманә*** язамын – ул хезмәтне дәргаһедә кыла алмаячакмын. Миндә икътидар юк, милләт нәзедендә мәсьүлияте зур. Һәм безгә, ягъни Оренбур мөселманнарына, үземездән вәкил йибәрмәк мөйәссәр исә ялгыз бер вәкил йибәрү мөмкин булачак. Шундаен газиз форсаттан хөсне истифадәнең зыягына сәбәп буласым килми. Иншаллаһ, лаеграк кеше табылыр.

---

* Хатта Ф.Кәрими кулы белән 1905 елның 5 ноябрендә алынуы теркәлгән (төз. иск.).

** Хатның бу абзацы М.Гайнуллинның «Татар әдипләре» китабында урын алган. Кара: Гайнуллин М.Х. Татар әдипләре. (Иҗат портретлары). – Казан: Тат.кит.нәшр.,1978. – Б.160.

*** Ассызыклар Закир Рәмиевнеке.

Госман Нури әфәнде белән хат язышамыз. Мәгълүм хоруфат тәмам булган икән. Өч-дүрт сәхифәлек куйдырып, Оренбурга сезнең исемгә йибәрергә үтендем. Шайәд, килә калса, җәнабеңездән илтимасмын: үзеңездән башка фәрде вахид күрмәсә икән.

Кәминә Закир.

26 октябрь, 905 сәнә. Приискалар.

Оренбурга гаеде шәриф үткәч, берәр атнадан соң чыкмак булып торамыз, Ходa кушса.

ТМА, 1370 ф., 2 тасв., 20 эш, 16, 16б битләр.

мөнтәзыйр – өмет итүче
тәшәббес – бер эшкә тотыну, керешү
мәркәз – үзәк
әхвале сәясийә – сәяси хәлләр
хөсне тәбәддел – яхшыга үзгәрү
хөррияте тамм – тулы ирек
галәбә тапса – җиңсә
мозтар – чарасыз
мәванигъ – каршылыклар
хөсне тәвәҗҗеһ – яхшы теләк
мәмнүн – шат
мәхрәманә – сер итеп
дәргаһедә – өстенә алу
икътидар – булдыра алу
милләт нәзедендә – милләт каршында
мәсьүлияте – җаваплылыгы
мөйәссәр – җиңел, җайлы
хөсне итсифадә – яхшы файдалану
зыяг – югалту, әрәм
илтимас – үтенү
фәрде вахид – бер кеше дә

4. Государственный Дума әгъзасы Закир әфәнде Рәмиевтән мәктүб*

Үземез Петербургка сәламәт килдек. Килеп керү илән вәкаләт эшләре тулкынына кереп киттек. Әтрафка күз салырлык вакыт булмастан Дума мәҗлесләренә керелде. Мәҗлесләр ун-унике сәгатьләр дәвам кыла, шуның белән хат язарга да вакыт табып булмый.

Думаның кәммиййәте – составы хөррият ноктаи нәзарыннан яхшы күренә. 17 октябрь[1] һәм аннан уң булганнар 30 кадәрдән артык булмас. Әмма, ниһаять, суң [сул] тарафлар байтак күп күренә.

«Трудовая группа»[2] фиркасенең беразы, ниһаять, сулда күренә, гәрчә тәмам ачык беленеп беткән юк әле.

Дума әүвәлге көннәре тәшкиләте дахилия вә идарә әгъзалары интихабы белән мәшгуль булды. Моның бәгъзендә «тронный речькә» җавабән адрес тәэлиф итмәк өчен 33 кешедән гыйбарәт бер комиссия тәшкил итеп адрес проектасын тәэлиф кылуны сәпареш иткән иде.

Проекта хәзерләнде. Яхшы чыккан күренә, гәрчә хөкүмәт фикереннән гаять бәгыйд язылмыштыр. Кичә һәм бүген шул проектаны Дума тикшерелмәктәдер. Ораторлар күп вә озын сөйләп эшнең тиз бетмәвенә сәбәп булалар. Адресны мөмкин кадәр тизрәк падишаһка тапшыру зарур күренәдер.

Чөнки адреста башка зарур йомышлардан магада амнистия хосусында сүз бар. Бәгъзе маддәләрдә дә күп сүзләр вә игътиразлар була.

Әлбәттә, мәгънәле игътиразлар да юк түгел. Шундый игътиразлар сәбәбеннән проектага ике-өч поправка кертелде – бәлки янә булгалар. Чөнки ошбу 4 нче май сәгать 3 кә кадәр

---

* Ачык хат рәвешендәге бу язма Закир Рәмиев (Дәрдемәнд) имзасы белән «Вакыт» газетасының 1906 ел, 11 май санында дөнья күргән. Хатның тексты һәм искәрмәләр Җәүдәт Миңнуллин тарафыннан әзерләнде.

Русиядә I Дәүләт Думасы 1905 елгы 17 октябрь манифесты нигезендә чакырыла һәм 1906 елның 27 апреленнән 8 июльгә кадәр эшли. Анда төрле сәяси партияләрнең фракцияләре барлыкка килә.

проектаның Государственный Совет хакында әйтелгән сүзләренә кадәр каралды, шуннан түбәне инде каралачак.

Думада сәяси фиркаләр гәрчә билгеләнеп тәшкил кылынып килсә дә, тәмам ачыкланып төпләр кылып йиткәне юк әле.

«Халык иркенчелеге»[3], «17 октябрь», «Демократический реформ»[4], автономистлар[5] яхуд федералистлар, «Парламентская трудовая группа» – шундый фиркаләр күренә. Моның өстенә милли фиркаләр үз алдына берәр фирка булып, зикер кылынган фиркаләргә төрле рәвештә дәхел булалар.

Әмма ләхләрнең, ягъни полякларның, милли фиркаләре икегә бүленгәне ачык күренә. Иҗтимагый һәм милли мәсьәләләрдә оешып бетә алмыйлар. Янә җәнүби Русия белән бу тараф крестиянләре арасында җир мәсьәләсендә, ягъни аграрный мәсьәләдә оешып җитмәүләре күренә.

Дума шул адрес белән мәшгуль булып, башка мәсьәләләрне бер дә бу көнгә кадәр телгә дә ала алган юк әле. Адреска кертү хосусында гына һәр мәсьәлә карала, ләкин канун ләихәсе рәвешендә түгел.

Хәзергә һичбер кавемнең милли мәсьәләсе хакында сүз юк әле. Чөнки иң алда әсас мәсьәләләр тикшереләчәк.

Закир Рәмиев. (5 нче май иртә белән.)

ноктаи нәзар – караш, берәр нәрсәгә караш
тәшкиләте дахилия – [дәүләтнең] эчке төзелеше
интихаб – сайлау, сайлап алу
тәэлиф – язу, төзү
сәпареш (сефареш) – йомыш, йөкләмә, заказ
бәгыйд – ерак
магада – башка, бүтән, гайре
игътираз – кире кагу, каршы сөйләү
зикер – искә алу, искә төшерү, телгә алу
дәхел – катнашу, керешү, йогынты, тәэсир
җәнүби – көньяк
ләихә – проект
әсас – төп, нигез

Искәрмәләр

1. 17 октябрь партиясе (октябристлар) – «17 октябрь союзы» уң либераль алпавытлар, земство әһелләре, чиновниклар, сәүдә-сәнәгать буржуазиясенең сәяси партиясе. 1905 елгы 17 октябрь Мани-

фесты игълан ителгәч 1906 елда оеша. Партия халык вәкиллеге, демократик ирекләр, гражданлык тигезлеге һ.б. максатларны алга сөрә. 1915 елда эшчәнлеге туктый.

2. Парламентская трудовая группа – I Дәүләт Думасында крестьян, эшче һәм интеллигенция депутатлары тарафыннан 1906 елның 28 апрелендә оештырылган фракция. Программалары түбәндәге таләпләрне үз эченә алган: демократик ирекләр, крестьян биләмәләреннән кала барлык җирләрне национализацияләү, 8 сәгатьлек эш көне.

3. Халык иркенчелеге – конституцион-демократик партия (кадетлар) – либераль буржуазиянең сәяси партиясе (1905-1917 еллар). Программ таләпләре: конституцион һәм парламентар монархия, демократик ирекләр, халыкларның мәдәни үзбилгеләнүе, алпавыт җирләрен мәҗбүри рәвештә сату, «эшчеләр мәсьәләсен» закон нигезендә хәл итү һ.б.

4. Демократический реформ – Демократик реформалар партиясе. Санкт-Петербургта 1905 елның декабрь аенда барлыкка килә. Оештыручылары — ике төркемнән гыйбарәт булган либераль интеллигенция вәкилләре. Партиянең сәяси программасы ике төп принципка кайтып калган: конституцион монархия белән закон чыгару функцияләренә ия булган парламент һәм хакимиятнең бүленүе.

5. Автономистлар – Автономистлар союзы. Санкт-Петербургта 1905 елның 19 ноябрендә оеша, союзның парламент төркеме 1906 елның май аенда барлыкка килә. «Автономистлар союзының парламент төркеме» – I Дәүләт Думасында төрле сәяси партия һәм милли оешмаларда әгъза булган милли азчылык вәкилләреннән торган фракцияара берләшмә. Бу берләшмәгә кергән депутатлар милли азчылыкны тәшкил итүче халыкларның хокукларын тану, милли һәм дини кысуларны бетерү, Россиянең бөтенлеген һәм бердәмлеген таныган хәлдә дәүләтне идарә итүдә киң күләмдә децентрализация принципларын тормышка ашыруны һәм империяне федерализацияләүне яклап чыгалар.

5. Закир Рәмиевтән Ризаэтдин Фәхретдингә һәм Фатыйх Кәримигә*

Биисмиһи

Мөхтәрәм Ризаэтдин хәзрәткә вә Фатыйх әфәндегә сәламнәремезне күндерәмез.

Идарә кулындагы ачларга ярдәм акчасы тугрысында мәктүбеңезгә телеграф белән җавап биргән идек.

Ачлар исемләнеп килгән акча ачлар ихтыяҗына сарыф ителгән яхшы булыр иде. Бу хезмәтне Оренбург «Җәмгыятемез», ничектер, матлуба башкарып йитә алмады. Имди Казан тарафында әгәр һаман да ихтыяҗ бар булса һәм Казан ачлар комитеты үз хезмәтендә яхшы дәвам кылмакта булса, идарәдәге акчаны Казанга йибәрүне мәслихәт күрәмсез. Ләкин мулла Апанаев исемендәге әүвәл йибәрелгән акчаның ачлар комитетына вакытында тапшырылганыннан һәм тиешле урынына сарыф ителмәктә икәненнән безнең хәбәремез юк. Сезнең, бәлки, хәбәреңез бардыр. Әгәр хәл Сезгә дә мәгълүм булмаса, ул вакыт ибтидаән хәбәрләшеп-белешебрәк, акчаны шуннан соң йибәрмәк тиеш булыр. Акчаны Сөләйман Аитов исеменә йибәреп, комитетка тапшыруны үтенелсә, ничек булыр икән. Безнең белүемезчә, бу кеше хәл-әхвальне белешеп, язышу өчен дә муафыйк булса кирәк.

Янә Самар вә Уфа губерналарда ачыккан һәм бик йончыган авыллар идарәгә мәгълүм булса һәм шул тирәләрдә кулына акча тапшырганда ышанычлыгы һәм инабәтлелеге үзеңезгә мәгълүм кешеләр булса, идарәдә туры шул кешеләргә азаплап акча бирү җаиз булса кирә дип уйлыймыз.

Инде әгәр әтрафта ачлыклар вә ихтыяҗ беткән булса вә яхуд йибәрелгән акчаның тәләф булмаенча, ачларга сарыф ителәчәгенә күз йитмәсә, ягъни күңел ышангандай булмаса,

---

* Хатта Ф.Кәрими кулы белән 1907 елның 18 июнендә алынуы һәм 17 июльдә җавап язуы теркәлгән (төз. иск.).

ул хәлдә акча хәзергә идарә кулында калып торсын. Бу хәлдә акчага бер монасыйп мәсраф эзләнер. Шакир абзый фикеренчә, акчаның беразрагын (тәхминән 300 тәңкә) Мисырда казанлы шәкертләренең «Тәгавын җәмгыяте»нә йибәрмәк, калмышын «Иттифакы мөслимин» милкенә тапшырмак муафыйк булыр кебек күренәдер. Янә Сез ничек монасып күрерсез. Әгәр Сез дә шуны мәслихәт күрсәңез, «Иттифак»ның уставы тәсдыйк кылынганнан соң «Вакыт»та мәсәлән: «Фәлән көннән соң фәлән вә фәлән шәһәрдән килгән, мәҗмугы фәлән кадәр акча ачларга сарыф ителмәенчә, «Вакыт» идарәсенең кулында калды. Бу акчаның 300 тәңкәсен Мисырның «тәгавын җәмгыятенә, калмышын «Иттифак» милкенә тәсаррыфына тапшырылмакны монасыйп күрәмез. Бинаән галәйһи, әгәр иганә кылучылардан бу эшкә разый булмаганнары булса, ике ай эчендә идарәгә мәктүб язып бәйане хәл кылсыннар вә акчаларына үзләре мәсраф күрсәтсеннәр» мәэлендә бер игълан басу хаҗәт булыр. Оренбург «җәмгыяте» кулындагы акчаны тиешле урынына сарыф кылып бетмәгән булган, бу акчаны әүвәл «җәмгыять»кә бирүне бер дә мәслихәт күрмимез.

Кинә җәнабеңезнең бераз вакытлар хәстәләнгәнеңезне ишеткән идек вә редакция хезмәтенең дә авырлыгы төшү ихтималын тәхмин кылган идек. Фил-хакыйкать шулай булган икән. Бу тугрыда сәбәпче без булып, мәхҗүбмез. Гафуыңызны үтенәмез. Фатыйх әфәнде Петербур баргач күңел аның, анда бераз күбрәк торуын теләде. «Вакыт»ны бик яратамыз. Аз-маз мөнәсәбәтсез шәйләрдән ниндәй газета булса да хали түгелдер.

Газиз гомерләреңезгә бәрәкәт теләп кәминә Закир Рәмиев.

12 июнь, 1907 сәнә.

Приискәдән.

Җәнабеңезгә һәм мөхтәрәм Фатыйх әфәндегә Шакир абзый күп сәлам күндереп, догаларыңызны үтенде.

ТМА, 1370 ф., 2 тасв., 23 эш, 14 бит.

матлубча – тиешенчә

ибтидаән – башта, алдан

инабәтле – ышанычлы
җаиз – тиеш
яхуд – яки
тәләф – әрәм
мәсрәф – чыгым
тәхминән – якынча
тәгавын – ярдәм
тәсдыйк – раслау
тәсаррыф – идарә итү
бинаән галәйһи – шуңа күрә
бәйане хәл – хәлне белдерү
мәэл – эчтәлек
тәхмин – чамалау
фил-хакыйкать – чынлыкта
мәхҗүб – оятлы
шәй – нәрсә
хали – азат

6. Закир Рәмиевтән Фатыйх Кәримигә

Биисмиһи

Мөхтәрәм Фатыйх әфәнде җәнабләренә чук сәламнәремне күндердем. Үземез, Ходага шөкер, сәламәтлектәмез.

Язган мәктүбләреңез тапшырылып торды, типография өчен свидетельство да килде, рәхмәт алып йибәрүеңезгә. Типография кирәкләре алынды, ләкин акча күбрәк чыгадыр. Әүвәл чамалаганнан кыйммәтрәк төшәр, ахрысы. Монда алынган нәрсәләр 15 мең сумнар чамасында, двигатель, трансмиссияләрдән башка. Госман Нури әфәнде Кырымга кайтып китте. Туй итәчәк, шуннан соң Мисырга бармак булып китте. Насыйп булса, Оренбур кайткач, кайсы хоруфат мәслихәт күренсә, шуны хәбәр итәрмез. Оренбурга матбаганы идарә кылыр өчен килергә вәгъдә кылды.

Галимәрдан бәкне[1] ошбу көн суд хөкемен иҗра кылырга, ягъни хәбескә алып киттеләр. Аның белән берлектә янә уннан артыграк «выборгчы»ларны алып киттеләр. Бу хакта ошбу көн телеграм Сезгә бирдем, юлыккансыздыр, әлбәттә. Фракция ятим калды. Озаткан кешеләр бик күңелсезләнделәр. Галимәрдән бәк Сезгә азрак үпкә сыманрак сөйләнде. Үз хакында судның хөкеме булачак һәм бабасының вафаты мөнәсәбәте белән «күп кешеләрдән тәсәлла вә тәгъзия хатлары килде, әмма Фатыйх әфәндедән алмадым», ди. «Комитет хәлен дә бер дә белешмәде», ди. «Бюро»ның киләчәге мали җәһәттән бер дә тәэмин ителмәгән. Бу хәл һәркаюсының эчләрен пошыра. «Эшләр бик күп, эшләр гаять авыр – «бюро» бик кирәк» диләр. Хосусан, Галимәрдан бәк башка кәсепләрен ташлап, эшләрен ташлап, бу эшкә бөтенләй бирелгән. Әмма киләчәктәге хәлләр мали җәһәттән бер дә мәгълүм түгел. Бик күңелсез.

Бу сәнә Макариядә ни булыр, өмидне шуңа багълап торалар. Дума членнарының күбесе Макариядә булмак булып торалар.

Кинә Ризаэтдин хәзрәтнең «Мөселманнар хакында хөкүмәт тәдбирләре» дигән әсәренең беренче җөзъэ хакында монда югары урыннарда күп сүзләр булган дип, мәүсуф урыннан ишеттем. Хөкемгә бирергә уйлап йөреп, бара-бара басылганнар.

Бу тарафта һавалар салкын. «Вакыт» укучылар арасында бик игътибарда. Хөкүмәт кешеләре дә бик дикъкать кылалар, имеш. Күп статьялары русчага тәрҗемә ителә һәм тиешле урыннарда дикъкать белән тикшерелә, имеш.

Кинә үзегезгә мәгълүм Төркестан тарафына сановник Палин сенаторский ревизия ясар өчен барачак. Аны йибәрүдә максудның берсе – ул тарафларның әхвален изучать итеп кайту диләр, яңа законнар чыгарылса, материал булу өчен. Шул хакта монда белгән кешеләр әйтә: Төркестан мөселманнары хәзерләнеп торып, үзара киңәшеп иң мөһим хаҗәтләре хосусында граф Палинга бер докладной записка кертсәләр, файдасыз калмас иде диләр. Ләкин иң кирәкле йомышларын гына соравы тиеш диләр, һәм вак-төяк просьба белән керә торган мөселманнарга андай вак йомыш белән мәшәкатьләмәскә нәсыйхәт итсәләр яхшы булыр иде диләр. Бу кешене мөселманнарның хаҗәтен яхшы аңласа, файда китерә торган кеше диләр. Бу хәлне кыскарак һәм ыспайрак рәвештә «Вакыт»та язып, Төркестан мөселманнарының дикъкатен җәлеп кылган яхшы булыр иде.

Кинә бер тимер юл накладное йибәрдем, префировальный машинага. Барса, алып куярсыз. Үзем 15 нче майларга кадәр, бәлки артыграк та, торырмын.

Кинә мәдрәсә хакында Гайса мирза[2] һәм Бать[3] белән мин дә кул куеп бер мәктүб йибәргән идек, тапшырылгандыр. Эшне ялгыз Собрание үтә йөртүне бигүк муафыйк күреп йитмәделәр. Әгәр алай утвердиться ителсәк, аннан соң особый устав бирмәсәләр, обший положениегә кертеп йибәрерләр дип уйлыйлар. Ягъни Гайса мирза белән Батьнең фикере, шуның өчен янә бер департаментның тын алышын чамалап карыйк диделәр. Әмма директорны күреп сөйләшмәк һаман

мөяссәр булган юк – начальник отделения белән күрешеп, Гайса мирза бер утырып сөйләште. Ул кадәр күңелле вәгъдә алып кайтмады. Озакламый директор белән күрешеп сөйләшергә иҗтиһад кыла. Ни хәл булыр? Бу хосусны кайткач подробный сөйләрмен.

Мөтәвәллиләрнең үзгәртергә ясаганнарын монда Гайса мирза һәм Бать урынсыз дип әйтмәделәр.

Монда директор безнең таләпләрне кабул иткән хәлдә дә хәвеф бетми, Совет министровның составы безнең эш өчен муафыйклы түгел кебек. «Ана телен бирмимез, рус телендә укытсыннар фәннәрне» дип әйтеп куюлары ихтимал.

Галим хәзрәт «бер физический кабинет белешеп кайтыгыз» дип язган иде. Белештем, алып кайтамын. Биш йөз тәңкәдән дүрт мең тәңкәлек кадәр физический кабинетлар кечкенәрәк урта дәрәҗә ышкуллар өчен ясала икән.

Ихсан абзый килде, сәламәт. Франциягә барып, хезмәтенең өстендә тырышып йөргән кебек күренә.

Кинә мәгълүм Шакир Мөхәммәдъяровны[4] күрдем. Ару гына фикерле егет күренә. Монда русча укып йөри. Оренбурга барса, укуына халәл килер кебегрәк әйтте, мин дә артык тәклиф кылмадым. Икенче берсе бар: барасы да килә, бик яшь кеше, Бикчурин исемле. Ләкин үзем бик муафыйк күрмәдем. Болар Казаннан сәяси сәбәп белән киткәннәр. Хәзер, бик строгость артып торганда, «Вакыт»ка зарар булып төшмәсен дип куркам. «Вакыт» бер безгә генә түгел, укыган халыкка да газиз күренә башлаган.

«Шура»га клишеләр барып өлгергән икән, яхшы чыккан. Ләкин мөндәриҗәсен укый алмый калдым, карарга дип алып киттеләр. Иртәгә алып укый алырмын.

Мөхтәрәм Ризаэтдин хәзрәттән догаларын үтенә[м]. Аңарга һәм Габдеррахман[5] мәхдүмгә, Ярулла әфәндегә[6] сәлам.

Хәзрәтнең йибәргән китабы тапшырылды, искә төшерүенә рәхмәт дип кәминә Закир.

Петербург.

8 нче май, 1908 сәнә.

Петербург мәсҗид урынының рәсемен алдырдым, клише ясатачакмын. Мәсҗиднең рәсемен һәм комитетның рәсемен Газиз әфәнде Дәүләтшин үзе ясатып йибәрмәк булды. Ул авырып, рәсемнәр бүгенгә кадәр алынмый торды.

ТМА, 1370 ф., 2 тасв., 24 эш, 65-66 бит.

хоруфат – хәрефләр
хәбес – кулга алу
тәсәлла – юату
тәгъзия – кайгы уртаклашу
җөзъэ – кисәк
мәүсуф – кайбер
максуд – максат
мөяссәр – насыйп
иҗтиһад – тырышлык
халәл – зарар
тәклиф – кыстау, өндәү

Искәрмәләр

1. Галимәрдән бәк – Галимәрдән Тупчыбашев (1862-1934), җәмәгать эшлеклесе, присяжный поверенный, Дәүләт Думасы депутаты.

2. Гайса мирза – Гайса Еникеев (1864-1931), Дәүләт Думасы депутаты.

3. Бать – Бать А.Г., Казанның присяжный поверенные.

4. Шакир Мөхәммәдъяров (1883-1967) – җәмәгать эшлеклесе, педагог, публицист.

5. Габдеррахман мәхдүм – Габдрахман Ризаэтдин улы Фәхретдинов (1887-1937), журналист, «Вакыт» газетасының икенче мөхәррире (1913-1916), репрессияләнгән.

6. Ярулла әфәнде – Ярулла Вәли, Закир Рәмиевнең кияве, язучы, драматург, 1906 елдан «Вакыт» журналында финанс-хуҗалык эшләрен башкаручы, репрессияләнгән.

7. Закир Рәмиевтән Фатыйх Кәримигә*

Биисмиһи

Мөхтәрәм Фатыйх әфәнде! Җәнабеңезгә сәламнаремне гарыз итәмен.

Кайтканнан бирле Сезнең белән хәбәрләшә алганым юк, инша Алла, кәефләр хуштыр, «Вакыт», «Шура» килмәктә икән. Үзем Орски өязе Суындык тарафларында йөреп, яңа кайттым. Сигезләрендә янә берәр айга китәчәкмен, Авзяно-Петровский заводка.

Типография машинасының накладной дубликаты монда килгән икән. Моннан Сезгә йибәргәннәр, инша Алла, алынгандыр.

Типографиягә электричество куәте бирү мәсьәләсе ни хәлдә, мәсьәлә Дума мәҗлесенә куелдымы? Өмид бармы?

Госман Нури әфәнде Мисырдан йөреп Кырымга кайткан, кирәк нәрсәләрне ала алмаган. Язган телеграмнарыннан алуга өмид бар кебек аңлашыла. Ләкин, ни өчендер, минем белән күрешеп сөйләшү хаҗәт булган. Телеграм белән үзен монда, ягъни Авзян заводына чакырдым.

«Вакыт»та Йосыф әфәнде Акчуринның[1] бәндләре бер дә күренми: белмим, кулы йитми, белмим, безне онытты! Шакир әфәнденең дә япон хәбәрләре бик аз күренде.

Кинә Казаннан Бикчурин исемле егет бераз тәрҗемә йибәрдем дип язган. Тәрҗемә кылган кадәресенә тиешле әҗерен бирәсез, янә хәзергә аръягын тәрҗемә кылмай торырга язсаңыз, яхшы булыр иде. Эшен күреп һәм сезнең фикереңезне аңлагач, иҗабына карар идек.

Госманлыларның «Кануне әсаси»се[2] белән Сезне барыңызны тәбрик кыламын! Госманлыларның хәзерге хәрәкәтләренә караганда, төрек-татар славяннардан, гаҗәмнәрдән узар кебек! Кәнҗ төрекләрнең хәзерге программнары бик га-

* Хатта Ф.Кәрими кулы белән 1908 елның 10 августында алынуы теркәлгән (төз. иск.).

кыйланә тәртип кылынган кебек күренә. Хода муаффәкыять бирсен!

Кыргыз, башкорт эчендә чыккан кечкенә бер татар газетасының тавышы гәрчә Истанбулда колакка алынмас, шунда да «Вакыт» үз вазыйфасын әда кылып, кулыннан килгән мәслихәтен язып яткан яхшы булыр иде. Солтанны алыштырамыз дип яки иҗтимагый мәсьәләләр чыгарып, эшләрен мөшкелләндермәсәләр ярар иде. Кануне әсасине, мөмкин кадәр киң иҗра кылып, идарәне яхшы төзәтә алсалар, шул да канәгать итәрлек бер эш булыр иде.

Сәламәтлекләреңезне теләп кәминә Закир.

Мөхтәрәм Риза хәзрәттән догаларын үтенеп, сәламемне йибәрдем. Ушандак мөхтәрәм Ярулла әфәнде вә Габдеррахман мәхдүмгә сәлам күндерәмен.

5 нче август, 1908 сәнә.
«Искәндәрский»дән.

ТМА, 1370 ф., 2 тасв., 24 эш, 77-78 бит.

гарыз – җиткерү
бәнд – мәкалә
иҗаб – җавап бирү
«Кануне әсаси» – төп канун, конституция
гаҗәм – фарсы
кәнҗ – яшь
гакыйланә – акыл белән
муаффәкыять – уңыш
әда – үтәү
иҗра – башкару
ушандак – шулай ук

Искәрмәләр

1. Йосыф Акчура (1876-1935) – җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе, публицист.

2. «Кануне әсаси» – сүз 1908 елгы Төркия Конституциясе турында бара.

8. Закир Рәмиевтән Фатыйх Кәримигә

Биисмиһи

Мөхтәрәм Фатыйх әфәнде!

Йосыф[1] әфәнденең ляихәсен «Вакыт» идарәсе хисабыннан бастырырга ярый. Ничек вә кемнән тәрҗемә кылдыруны үзеңез Йосыф әфәнде белән язышып, мәслихәт кылышырсыз. Тәрҗемә кылмакны мокътәдир кешегә бирелсә, әҗерен бирергә ярый. Русчасын да бастыру, бәлки мәслихәт булыр. Әгәр мәслихәт күренсә, аны да «Вакыт» идарәсе хисабына бастырырга ярый. Ләкин корректур яхшы кылынырга тиеш, әлбәттә.

Кинә Госман[2] әфәнде килде. Хәзергә Харитонов хоруфаты сипарыш кылып, шуның белән тизрәк матбаганы ачмага мәслихәт күрдек. Госман әфәнде моннан Казан йөри, хоруфат заказать итәр өчен. Шуннан Оренбур кайтып, квартир табып, машиналарны утырта башламак булды.

Мөхтәрәм Ризаэтдин хәзрәткә сәламемне күндердем дип кәминә Закир.

13 август [1909 ел].

ТМА. 1370 ф., 1 тасв., 20 эш, 73 бит.

ляихә – проект
мокътәдир – көче җитәрлек
кинә – янә, тагын
сипарыш кылып – кушып
Казан йөри – Казанга бара
хоруфат – хәрефләр
кәминә – фәкыйрь

Искәрмәләр

1. Йосыф Акчура.
2. Госман Нури Акчокраклы.

9. Закир Рәмиевтән Борһан Шәрәфкә*

... Фатыйхта тугры сүз, төпле фикер, хакыйкать, халыкка мәхәббәт, яшьләрне дөньяга туры карашлы итеп үстерү, киләчәккә өмет белән карау...

Үзен күрсәтергә теләү, үзен югары тоту кеби ваклыклар Фатыйхта һич юк. Бөек адәмнәрдә генә була торган, чын әдипләрдә генә була торган сыйфатлар Фатыйхта...

Закир Рәмиев.
11 май, 1911 сәнә.
Орский өязе.

Закирә Шәрәф. Фатыйх Кәрими//Фатыйх Кәрими: Фәнни-биографик җыентык=Фатих Карими: Научно-биографический сборник. – Казан: Рухият, 2000. – Б. 94.

---

* Хатның шушы өзеге генә сакланган (төз. иск.).

10. Закир Рәмиевтән Фатыйх Кәримигә*

Биисмиһи

Мөхтәрәм борадәрем Фатыйх әфәнде!

Тәбрик телеграмыңызны алып бик шатландым. Үзем бишун сүз тәбрик тә яза алмаганмын. Начарлыгымны икърар кылсам, гөнаһымның гозере була алыр микән?.. Ничек тә һәркайсыңыздан үтенәм: косурымны кичеңез.

Шакир абзыйның биографиясен карый алганым юк. Бик кичекте. Инде белмим, ничек ителер икән. Ахыры, күзгә калды.

Сезнең мәктүбеңезне һәм Борһан әфәнденең[1] Казаннан язган мәктүбен алдым. Сайлау эшләре Оренбургта ни хәлдәдер, өметләр ничек – языңыз. Садрый әфәнде[2] сайлануга бик дәрт итмирәк китте, дүртенче Думада яхшы өмете юк. Аның хилафына мөселман газеталарында берәр мәкалә-фәлән булса-нитсә, рәддия язып, Садрый әфәндене «Вакыт»та поддержать итә күреңез. Әлбәттә, шулай итәчәксез, тик сүз чыккач, күңелдәге каләм очына төште.

Муса әфәнденең[3] мөфти интихабы тугрысындагы «Идел»дәге[4] мәкаләсен[5] укыдым. «Вакыт», «Вакыт»чылар хакында әйткән сүзләрен хаксыз дип әйтә алмыйм. Миңа да өлеш биргән.

Хат язгалаңыз әле.

Мөхтәрәм Ризаэтдин хәзрәткә, Борһан әфәндегә, Габдрахман әфәнде, Ярулла әфәнде[6], Шәриф әфәнделәргә, Кәлимуллага[7] – барчаңыза күп сәлам күндердем.

Үземнең бәдәнем сәламәт.

Кәминә Мөхәммәтзакир Рәмиев.
5 август, 1912 сәнә.

ТМА, 1370 ф., 1 тасв., 21 эш, 18 бит.

* Хатта Ф.Кәрими кулы белән 1912 елның 13 сентябрендә алынуы теркәлгән (төз. иск.).



13 سنتابر 1912 ده

مح

محترم فاتح افندی!

تبریک تیلوی مزنی آلب بیک شادلاندم. اوزم بیش اول سوز
تبریک ده یازا آلماغانمن. ناچارلغمنی اقرار قلسام گناهمنک عذری
بولا آلورمیکان؟.. نیچک ده هرقایسیکز دان اوتنم قصورمنی کیچکز.
شاکرد آبری‌نک بیوغرافیه‌سن قاری آلغانم یوق، بیک کیچکدی. ایندی بلمیم
نیچک اتیلور ایکان. آخری کوره‌گه قالدی.
سزنک مکتوبکزنی هم برهان افندی‌نک قزاندان یازغان
مکتوبنه آلدم. هایلاو اشلری اورنبورغده نی حالده در؟ امیدلر
نیچک؟ یازکز. صدری افندی هایلاوغه بیک دردانیمی راک کیتدی،
دورتنچی دوماده بختی امیدی یوق. آنک خلافنه مسلمان غزته‌لرنده برار
مقاله‌لر بولسه نیتیسن ردیه یازب صدری افندی‌نی «وقت»ده یوددیرزالیت
ایته کورکز. البته شولای ایته حکسز آتیک سوز چقماچ کوکلده گی قلم اوچونا
توشری.
موسی افندی‌نک «مفتی انتخابی خصوصنده» «ایل»ده گی مقاله‌سن اوقودم.
«وقت»، «وقتچیلار» حقنده ایتکان سوزلری حقسز دیب ثبت آلمیم.
میکا ده اولوشی بیرگان.
خط یازغاللاک ئلی.
محترم رضاء الدین حضرتکه برهان افندی‌گه عبدالرحمن افندی یارالله افندی شریف
افندی‌لرگه کلیم الدنغه یارچه‌لرکه کوب سلام کوندررم.
اوزم منک بدنم سلامت. تمنیه محمدزاکر رامیه
٤ اوغوست ١٩١٢

Закир Рәмиев хаты.
(ТМА, 1370 ф., 1 тасв., 21 эш, 18 б.)

косур – кимчелек
аның хилафына – аңа каршы
интихаб – сайлау

Искәрмәләр

1. Борһан әфәнде – Борһан Шәрәф (1883-1942), дин һәм җәмәгать эшлеклесе, язучы, педагог, «Шура» журналының икенче мөхәррире.

2. Садрый әфәнде – Садретдин Максудый (1878-1957), дәүләт эшлеклесе, юрист, II һәм III Дәүләт Думасы депутаты.

3. Муса әфәнде – Муса Бигиев (1875-1949), философ, дин галиме, публицист.

4. «Идел» – Әстерханда 1907-1913 нче елларда нәшер ителгән газета.

5. «Идел»дәге мәкалә – сүз М.Бигиевнең «Идел» газетасында 1912 елның 17 августында (№ 479) басылган «Бездә фикер дүнлеге» исемле мәкаләсе турында бара.

6. Шәриф әфәнде – Шәриф Камал (1884-1942), язучы, ул чорларда «Шура» журналы хезмәткәре.

7. Кәлимулла – «Вакыт» газетасы хезмәткәре.

11. Закир Рәмиевтән Фатыйх Кәримигә*

Биисмиһи

Мөхтәрәм Фатыйх әфәнде!

Төрек мәҗрухләре файдасына дип приискадагы кешеләр бераз акча чыгарганнар иде (йиде йөз илле сум), шул акчаны ошбу көн почта илә редакция исеменә перевод ясыймын.

Төрек илчеханәсендә бу хосуска иганә җыюга тәшәббес кылынган икән, белмим «Вакыт»та иганә дәфтәре ачуга имкян бармы? Монасыйп эш булырмы, рөхсәт итәрләрме? Анда Сезгә бу мәсьәләләрнең җавабы ачыграк булса кирәк. Рөхсәт сорамый ачу, әлбәттә, муафыйк булмас. Әгәр, юлы табылып, истихаләсез ачу мөмкин булган тәкъдирдә бу йибәрелгән акчаны «Вакыт»та язып, шуннан тиешле урынына тапшырырсыз. Әгәр иганә дәфтәре ачу бер-бер җәһәттән тугры килсә, туп-туры төрек илчесе әһлиясе ханым әфәндегә тапшырылмак үзрә тиешле юлы белән йибәрерсез.

Иганә кылган кешеләр исемнәрен яздырмадылар. Верхнеуральск уездында бер кешедән 300, берәүдән 200, берәүдән 50, янә берәүдән 50, янә берәүдән 50, берәүдән 51, берәүдән 25, берәүдән 10, берәүдән 10, берәүдән 3, берәүдән 1 сум. Җәмгысе 750 сум.

«Вакыт»та язылса да яки язылмый, тугры йибәрелсә дә, цифрларында, шул рәвешчә, аерып язган муафыйк булыр кебек.

«Вакыт»та иганә ачуга имкян булып ачылса, иганә булыр иде кебек күренә. Кеше бирәсе килсә дә, ничек бирергә юлын тапмый кебек күренә. Әгәр «Вакыт»та иганә дәфтәре ачылмаса, илчеханәнең иганә кабул итү адресын «Вакыт»та ачыграк күрсәтеп булмасмы?

Бәгъдә Ибраһим әфәнде Галимҗанов[1] бер китап йибәргән иде. Бастырырга кабул иткән идем, әмма идарәгә йибәрә алганым юк. Үзем барганда алып барырмын. Гонорар улмак үз-

---

* Хатта Ф.Кәрими кулы белән 1912 елның 27 октябрендә алынуы теркәлгән (төз. иск.).

рә Ибраһим әфәнде акча сораган. Ошбу көн сезгә телеграм йибәрәмен «Ибраһимовка Киевкә 75 сум акча йибәреңез» дип. Бу акча югарыда зикер ителгән китап өчен булачак.

Оренбурга гаед узмый бара алмамын кебек.

Ярдәм җәмгыятенә мине сайлаганнар икән. Җыелыш булса, җәмгыятькә миннән рәхмәт бәйан итәргә үтенәмен бу хосуста. Мәгаль-мәмнүният кабул иттем.

Үзеңезнең хакта министерстводан җавап килгән юкмы, ягъни арест мәсьәләсе тәмам беткән юкмы?

Мөхтәрәм Ризаэтдин хәзрәттән дога үтенәмен. Ушандак Борһан әфәнде, Габдрахман әфәнде, Ярулла әфәнде, Шәриф Камал, Сабир, Кәлимулла әфәнделәргә һәркаюсына сәлам күндердем.

Кәминә Мөхәммәдзакир Рәмиев.
22 октябрь, 1912 сәнә.

ТМА. 1370 ф., 1 тасв., 23 эш, 32 бит.

мәҗрух – яралы
иганә – ярдәм
тәшәббес – эшкә тотыну
имкян – мөмкинлек
монасыйп – яраклы
истихалә – каршылык
әһлия – хатын

үзрә – өчен
җәмгысе – барлыгы
бәгъдә – аннан соң
улмак – булу
зикер – телгә алыну
мәгаль-мәмнүният – шатланып
ушандак – шулай ук

Искәрмәләр

1. Ибраһим әфәнде Галимҗанов – ашыгычлык белән язучы Галимҗан Ибраһимовның исем-фамилиясе бутап язылган.

12. Закир Рәмиевтән Фатыйх Кәримигә*

Биисмиһи

Мөхтәрәм Фатыйх әфәнде!

Әгәр сугыш урынына[1] мөхбирлек кылу өчен баруны зарур тапсаңыз, мөмкинлек булса, һәм расхут, рәттән тыш зур булмастай булса, барырга ярый. Инде мөхбирлек нәүбәте Габдрахман[2] әфәндегә тиеш иде, әмма Төркия сугышында төрекчә яхшырак белү хаҗәт булыр кебек күренә. Сез барсаңыз, төрекчә өстенә французчаңыз да бар, ул бер плюс күренә. Шуның өчен, бәлки, Габдрахман әфәнде нәүбәтне Сезгә уступить иткәне яхшы булыр иде. Әгәр, барыбер, бер сәбәптән тугры килмәсә, Йосыф әфәндегә[3] телеграф биреп торырлык акча җибәрсәңез, мөһим хәбәрләрне белдереп торырга, бәлки, ул авырсынмас иде. Мөхбир булып йөрүне өстенә аласы килмәстер, ихтимал. Кыенсынмаса, йөрү расхутына да акча җибәрергә ярый дип.

Закир.

Ашыгыч булды, аңларсыз, инша Алла.

Барчаңызга сәлам.

Искәрмәләр

1. Төркия-Балкан сугышлары күздә тотыла.
2. Габдрахман Фәхретдинов.
3. Йосыф Акчура.

* Хатта Ф.Кәрими кулы белән 1912 елның 29 октябрендә алынуы теркәлгән (төз. иск.).

13. Закир Рәмиевтән Фатыйх Кәримигә

Сезгә ерактан, немечләрнең баш шәһәреннән самими сәлам. Шәһәрне ике көн күрдек. Бүген тугры Италиягә йөрмәк буламыз.

Тәэссөратым: бунда халык тәрбияле, мәдәният көчле, байлык зур, хәят, мәгыйшәт шул дәрәҗә уңгайлы тәртипкә салынган, хәйратта калмаслык түгел. Немеч хәяттан чынлап ләззәт алып тереклек кыйла, ахры, безнең кебек мөттәсыйль газап чикми.

Искәндәр каршы килеп торган иде. Бергә йөрү уңайлы булды.

Барчаңызга сәлам әйтеп Закир Рәмиев.
27 март, 1914. Берлин.

ТМА. 1370 ф., 2 тасв., 31 эш, 51 бит.

тәэссөрат – тәэсирләр
бунда – монда
хәят – тормыш
мәгыйшәт – яшәү
хәйрат – хәйран калу, гаҗәпләнү
мөттәсыйль – тоташ

14. Закир Рәмиевтән Ризаэтдин Фәхретдин һәм Фатыйх Кәримигә*

Мөхтәрәмнәрем Ризаэтдин хәзрәт!

Фатыйх әфәнде!

Хафиз Рәфгать әфәнде хәзрәтләренең мәктүбләрен йолыкдым. Бер ай кадәр Тургай областендә сәфәрдә булганлыгымнан мәктүбләрне соңрак күрдем. Янә Екатеринбург тарафында да йөреп, яңарак приискага кайттым. Гариф Мидхәтләргә 500 сум перевод ясарга үтенеп телеграм биргән идем, шаять перевод ителгәндер. Хафиз Рәфгать әфәндегә мәктүб яза алганым юк. Фатыйх әфәнде, җәнабеңездән үтенәм, зинһар җәнабләренә бер тәшәккер мәктүбе язып, мине ояттан бер дәрәҗә коткара күреңез. Үзем язмак ниятендәмен дә, язарыма ышанып йитә алмыйм.

Мөфти мәсьәләсе.

Һәм газеталар һәм халык бу мәсьәләне тикшерергә чынлап керештеләр. Мокаддәмдә берничә эшләнә алмый, терәлеп торган милләт эшләре «Вакыт»ның тәдбире, Оренбург җәмәгатенең иштирәге аркасында ансат кына эшләнеп киткән мисаллар бар. Аңлавыма караганда, халык бу мәсьәләдә дә «Вакыт»тан юлбашчылык көтә чамасы. Сугыш туктамый, хөкүмәт мәсьәләне карамас әле дигән фикер башка килсә дә, Казан муллаларының хәрәкәтләре вә бәгъзе башка урыннардан хәрәкәтләр матлуб булмаган берәр кешенең тәгаен ителүен мөнтәҗ булмагай иде дип тә башка килә. Шуның өчен бу мәсьәләне дә «Вакыт» үз кулына алу һәм ашыктыру мәслихәт булмасмы?

Мәсьәләгә җитди каравыңызда шөбһә итмим. Ләкин ниндәй мәслихәт, ниндәй тәдбир уйлаганыңызны, әлбәттә, бел-

---

* Хатта Ф.Кәрими кулы белән 1915 елның 29 июлендә алынуы теркәлгән (төз. иск.).

мим. Үз фикеремә килгәнне язмакчы булдым, мәслихәтене карарсыз.

Бервакыт «Йолдыз»[1] вакытсызрак анкет ясаган иде. Анкета өчен момент яңа килде дип беләм. Минемчә, «Вакыт»ның беренче сәхифәсендә эре хәрефләр белән бер анкета ачарга кирәк. «Мөфти булырга кем муафыйк?» дигән кыска сөаль. Җавапка бер яки күп булганда ике кешенең исемен-фамилиясен генә күрсәтсеннәр. Ләякат, сыйфат-фәлән язу хаҗәт түгел. Чөнки алары газеталарда күп тикшерелде. Җавапка бер кеше яки дүрт-биш кешегә кадәр кул куярга ярый. Әмма һәркем үз кулы белән имза итәргә тиеш. Юкса, җавап бер кешенеке дип саналыр. Җаваплар «Вакыт»та басыла барыр. Саналу мөддәте бер ай куелса, йитәр кебек. Анкета җаваплары өчен «Вакыт» мөштәриләренә открыткалар басып йибәрергә дә ярар.

Мөфтине халык сайлау, әлбәттә, законда юк. Хөкүмәт халыкка ихтыяр иткән тәкъдирдә дә, хәзердә, зур сугыш барган вакытта, интихаб рәсмиятен организовать итү мөмкин эш түгел. Әмма анкета тарикы белән бер нәүгъ явочный порядкада кандидат күрсәтелсә, хөкүмәт игътибарга алу вә гайре матлуб кандидатларга юл киселү мөмкин эш.

Мөфти булырга кем муафыйк?

Мин үз фикеремне язам. Минемчә, Садрый әфәнде Максудов муафыйк. Бунда гаилә мөнәсәбәтенең тәэсире юктыр дип беләм. Милләт эшендә андый тәэсирдән сакланып тырышам. «Вакыт»та вә гайре газеталарда саналган матлуб сыйфатлар арада бу кешедә мөкәммәлрәк табылса кирәк. Милләтпәрвәрлеге һәркемгә мәгълүм. Моның өстенә Садрый әфәнде ватанпәрвәр дә. Игъни мөселманнар өчен иң хәерле юл – ватанымызның садыйк гражданнары булу, вә Русиягә хәер теләү игътикадында. Мөфти булса, әлбәттә, шул игътикадына муафыйк гамәл кылачак һәм халыкка да шул юлда тәэсир итә алачак. Әгәр Садрый әфәндене Сез дә муафыйк күрсәңез, «Вакыт»та вә гайре уңае чыккан урында аның намзәдлеген тырыштыруыңызны үтенәм. Шулай ук «Вакыт» һәйәтеннән дә шуны сорыйм.

Ничек мәслихәт күрерсез. Оренбург мәхәлләләреннән фракциягә телеграм бирелсә, мәслихәт булмасмы? Заһидулла ахунд вә гайре хәзрәтләр белән мәслихәт итеп, җомгада берәр кеше фракциягә телеграм бирергә үтенсә, халык һәркайсы кушылыр иде, мәхәллә исеменнән хәзрәт телеграм бирер иде фракциягә, «Мөфти булырга без фәлән кешене муафыйк күрер идек, шуны министрдан үтенәсез» дип.

Телеграм киткәннән соң «Вакыт»та хәбәр кыйсьмендә шул язылса, башка шәһәрләрдән дә шул тарикта морадларын хөкүмәткә ирештерергә бер мисал булыр иде.

Закир Рәмиев.

23 июль, 1915 сәнә. Приискадан.

ТМА. 1370 ф., 2 тасв., 32 эш, 24 бит.

мәктүб – хат
тәшәккер – рәхмәт
мокаддәм – элек
тәдбир – чара
иштирәк – катнашу
матлуб – теләнгән
мөнтәҗ – нәтиҗә
ләякат – лаеклылык
мөддәт – вакыт, срок
мөштәри – абонент
интихаб – сайлану
тарик – юл, ысул
нәүгъ – төрле
гайре матлуб – теләнгән
мөкәммәл – камил
садыйк – турылыклы
игътикад – инану
намзәд – кандидатура
һәйәт – редколлегия
морад – максат

Искәрмә

1. «Йолдыз» – 1906-1918 нче елларда Казанда Һади Максуди тарафыннан нәшер ителгән газета.

15. Закир Рәмиевтән Фатыйх Кәримигә

Һу

Мөхтәрәм Фатыйх әфәнде!

Җәнабеңезгә барчаңызны шөмулән чук сәлам күндердем. Мөхтәрәм Ризаэтдин хәзрәттән дога үтендем.

Бәгъдә Орский тимер юлының Рысай ыстансасыннан 25 чакрымда участкага килгән идем. Хәзер шунда ятам. Монда һава яхшы, хозур, җәмәгатькә дә хәбәр йибәрәм килергә. Бәлки килер. Ул килсә, ихтимал, бер-ике ай чамалы бире булырмыз. Ләкин хәбәр ишетергә, укырга «голодать» итәм. 13 еннән бирле гәзитә күрмәдем дип әйтерлек. Бик кызыклы хәбәрләр бардыр кебек тоела. «Вакыт» йибәртә күреңез?! Кулыңыз йитсә, хат та рәхим итә күреңез?! Адресымны түбәндә күрсәтәм.

Үзеңезнең хәлләр ничек, дачага яки җәйләүгә чыктыңызмы?

Сәламәт буласыз дип

Закир.

28 май, 1916 сәнә.

Ысбулган (?)

Почт. отд. Петропавловское

Орского у. Закиру Мух. Рамееву

ТМА. 1370 ф., 2 тасв., 33 эш, 34 бит.

һу – Ул, ягъни Алла

чук – күп

барчаңызны шөмулән – һәммәгезгә

бәгъдә – аннан соң

16. Закир Рәмиевтән Фатыйх Кәримигә*

Мөхтәрәм Фатыйх әфәнде!

Яңада[н] Ярулла[1] әфәндегә бер мәктүб язган идем, Фатыйх әфәнде белән киңәшеп, «Вакыт» әһелләренең барына да мәгаш арттырырга. Ләкин микъдарын өзә язмаган идем, сезгә хәвалә кылган идем. Инде, Сезнең фикереңезчә, әүвәл алган жалуанияләренә 50 процент килү микъдарында арттырыңыз. Әлбәттә, үзеңез һәм хәзрәт[2] тә мөстәсна түгел.

Кәбир Бәкер[3], Шәриф[4] әфәнделәрнең 120 шәр булса, бу шул 50 процент килә дигәндәй, ягъни аз аерма – ярый шулай булсын.

Һәркаюңызга сәламәтлек, гафият телим, хосусый Ризаэтдин хәзрәттән дога үтендем.

Оренбургка декабрьсез барып булмас кебегрәк күренә. Сәламәтлек.

Хөрмәт белән Закир Рәмиев.
18 октябрь, 1916 сәнә. Прииска.

ТМА. 1370 ф., 2 тасв., 33 эш, 42 бит.

мәгаш – хезмәт хакы
хәвалә кылган – йөкләгән, тапшырган
мөстәсна – чыгарма
гафият – исәнлек, саулык

Искәрмәләр

1. Ярулла Вәли.
2. Ризаэтдин Фәхретдин.
3. Кәбир Бәкер (1885-1944) – драматург, театр һәм әдәбият тәнкыйтьчесе.
4. Шәриф Камал.

* Хатта Ф.Кәрими кулы белән 1916 елның 25 октябрендә алынуы теркәлгән (төз. иск.).

БИБЛИОГРАФИЯ

Дәрдемәнд шигырьләре

1. Абдул Абдуличкә // Шура. – 1910. – №8. – Б.248.

2. Агарган кыл = Поседевшая струна: Шигырьләр / Төз. һәм кереш сүз авт. Р.Харис. – Казан: Мәгариф, 1999. – 111 б.

3. Аллага тәвәккәл! // Шура. – 1911. – №8. – Б.248.

4. Атам-анам йорты өчен...; Татарлыктан татар һич гъәр итәрме... // Мәгариф. – 1977. – №12. – Б.29.

5. Әгәр йөз напәсәнд (тәрҗемә) // Шура. – 1909. – №10. – Б.304.

6. Әй, кая ул... // Тукаев Габдулла. Мәктәптә милли әдәбият дәресләре. – Казан: Мәгариф, 1911. – Б.60-61; Шул ук. – Казан: Татар. китап нәшр., 2000. – Б.74.

7. Әй, мөхәррир (Үз ләһҗәмездә) // Шура. – 1908. – №1. – Б.3.

8. Балалар, әйдә мәктәпкә! (Көйгә салмый укыган артык) // Шура. – 1908. – №4. – Б.126.

9. Бәллү // Шура. – 1909. – №2. – Б.55.

10. Бәллү / Рәссам – Т.Хаҗиәхмәтов. – Казан: Татар. китап нәшр., 990. – 12 б.

11. Бәллү; Туган-үскән җир...; Көлемсерәп көн башланды // Ялкын. – 1979. – №8. – Б.14.

12. Бәллү; Чыкты кояш...; Туган-үскән җир... //Аргамак. – 1995. – №4. – Б.204-205.

13. Без // Шура. – 1908. – №2. – Б.33.

14. Bez // Казан утлары. – 1992. – №10. – Б.189-190.

15. Бер хәзинә // Хәсәнова М.Х., Миңнуллин Р.М. Уку китабы: Дүртьеллык башлангыч татар мәктәбенең 4 нче сыйны-

фы өчен дәреслек. – Үзгәртелгән икенче басма. – Казан: Мәгариф, 1999. – Б.101-103.

16. Беренче апрельдә зиярәт портретын җибәргән «дустыма» // Шура. – 1910. – №8. – Б.248.

17. Бүзләрем маналмадым // Шура. – 1908. – №8. – Б. 255.

18. Бүзләрем маналмадым... [һ.б. шигырьләре] // Агыла да болыт агыла: Татар һәм рус мәктәпләренең 6-7 сыйныфларында укучылар өчен өстәмә әдәбият / төз. З.М.Гыйниятова. – Казан: Мәгариф, 1993. – Б.33-37.

19. Бүзләрем маналмадым... [һ.б. шигырьләре] // Мирас. – 2001. – №9. – Б.37-41.

20. Гөрләгән сулар башында... //Казан утлары. – 1997. – 8. –Б.4.

21. Дәрдемәнд // Татар поэзиясе антологиясе. – Казан: Таткнигоиздат, 1956. – Б.198-207.

22. Дәрдемәнд // Татар поэзиясе антологиясе. 1 китап. – Казан: Татар. китап нәшр., 1992. – Б.445-451.

23. Дәрдемәнд әсәрләре. – Казан: Яңалиф, 1928. – 108 б.

24. Дәрдемәнднең тууына 130 ел // Идел. – 1989. – №6. – Б.42-43.

25. Җырлыйм әле.. [һ.б. шигырьләре] // Казан утлары. – 1966. – №7. – Б.123.

26. Җырлыйм әле... [һ.б. шигырьләре] // Шигырь бәйрәме / Төз. И.Юзиев. – Казан: Татар китап нәшр., 1968. – Б.22-24.

27. Замана // Вакыт. – 1906. – 13 апр.

28. Играли, кувыркались...; Прости любимая...; Принеси залетный ветер / Перев. с татар. Р.Кутуй // Казань. – 1999. – №12. – Б.85-87.

29. Игътизар // Шура. –1908. –№3. – Б.89; 1915. – №16. – Б.498.

30. Исә җилләр: Шигырьләр. Истәлек-парчалар. Вак хикәяләр / Төз. һәм искәрмәләрне язучы Р.Даутов. – Казан: Татар китап нәшр., 1980. – 254 б.

31. Каләмгә хитаб // Казан мөхбире. – 1906. – 6 февр.

32. Каләмгә хитаб; Нәсыйхәт; Абдул Абдуличкә; [һ.б.шигырьләре] // Татарстан. – 1996. – №12. – Б.71–76.

33. Каләмгә хитаб; Яз чәчәге [һ.б. шигырьләре] // Татар әдәбиятыннан хрестоматия: Татар урта гомуми белем мәктәбенең 10 нчы сыйныфы өчен хрестоматия / Төз. А.Г.Әхмәдуллин, Ф.Г. Галимуллин. – Тулыландырылган 2 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2000. – Б.179-186.

34. Кил ки, зарым! // Шура. – 1911. – №11. – Б.327.

35. Килсә кулдан (тәрҗемә) // Шура. – 1909. – №11. – Б.325.

36. Кичә күр, иркәм // Вакыт. – 1906. – 30 март.

37. Козгын (тәрҗемә) //Шура. – 1911. – №8. – Б.251.

38. Кораб // Шура. – 1908. – №1. Б.3.

39. Колыбельная / Пер. с татар. – Р.Моран // Радуга: хрестоматия по татарской литературе для 1-4 классов русских школ. – Казань: Магариф, 1995. – С.112-114.

40. Кораб; Рәсем (Нәваидән)... [һ.б. шигырьләре] // Хатипов Ф.М., Галимуллин Ф.Г. Унберьеллык мәктәпнең 7 нче сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия. – Казан: Мәгариф, 1993. – Б.76-81.

41. Кораб; Рәсем (Нәваидән)... [һ.б. шигырьләре] // Хатипов Ф.М., Галимуллин Ф.Г. Әдәбият: Унберьеллык мәктәпнең 7 нче сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия. – Казан: Мәгариф, 1993. – Б.76-81; Шул ук. Үзгәртелгән икенче басма. – Казан: Мәгариф, 1997 – Б.76-81.

42. Кораб; Тал чыбык... [һ.б. шигырьләре] // Яхин А.Г. Унберьеллык мәктәпнең 9 нчы сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия. – Казан: Мәгариф, 1994. – Б.228-240.

43. Кораб // Тукаев Габдулла. Мәктәптә милли әдәбият дәресләре. – Казан: Мәгариф, 1911. – Б.102; Шул ук. – Казан: Татар. китап нәшр., 2000. – Б.110.

44. Корабль; Мы / пер. С.Олендера // Сборник татарской литературы (дореволюционной). Под. ред.П. Радимова. – М.–Л: Гос. изд-во худ. лит., 1931. – С.6.

45. Көн кызды!.. // Вакыт. – 1906. – 18 апр.

46. Кыйтга (Әгәр йөз напәсәнд...) // Шура. – 1915. – №17. – 534.

47. Кыйтга (Ни гамь – бөлсәм?..) // Вакыт. – 1906. – 3 апр.

48. Кыйтга (Тәмам булмаган бер әсәремнән) // Шура. – 1908. – №8. – Б.254.

49. Кыйтга: Төрек ләһҗәсен тәкълид кылып маташкан чакларның ядкәре (Каргалы шагыйре мәрхүм Сибгатулла хаҗига язган бер мәктүбемнән) // Шура. – 1908. – №1. – Б.2.

50. Кыйтга (Һөҗүм иткән фәләк..) // Шура. – 1908. – №3. – Б.89.

51. Кыйтга (Ятимнәр күңлене кырдың...) // Вакыт. – 1906. – 8 апр.

52. Кыш көннәре // Шура. – 1908. – №23. – Б.741.

53. Кышкы төн // Әдәбият капчыгы. 8 кисәк. («Вакыт» газетасының 119 санына кушымта). – Оренбург, 1907.

54. Нәниләргә. – Казан. Татар. китап нәшр., 1959. – 16 б.

55. Нәсихәт // Аң. – 1913. – №3. – Б.38.

56. Нәсихәт // Шура.- 1909. – №10. – Б.304.

57. Өмидләр // Шура. – 1912. – №5. – Б.144.

58. Прошедшие дни; Твой родственник [и др. стихотворения] / Пер. с татар. С.Липкин // Поэзия народов СССР. XIX – нач. XX в. (Б-ка всемир. лит.) – М: Худож. лит. – 1977. – С.557-561.

59. Прошедшие дни / Пер. С.Липкина; Прости меня, любимая; Поэту /Пер. Н.Беляева; Гроза / Пер.В.Ганиева; Мы /пер.С.Липкина; Разве сравнится... / Пер.Л.Григорьевой; Надежды; Обращение к ветру; Лето ушло; Не огорчаюсь / Пер. Н.Беляева // Аргамак. – 1998. – №11/12. – С.120-123.

60. Рәсем (Нәваидән) // Шура. – 1908. – №6. – Б.184.

61. Сабый // Шура. – 1909. – №2. – Б.55.

62. Сайланма әсәрләр. – Казан: Татар. китап нәшр., 1959. – 126 б.

63. Сон волосы причешет для дороги дальней: ..Громадные валы прошли...; Росток тала; ...Ну, что изменится когда узнаю?..; ...В награду мне печаль...; Не перекрасить савана; ... Играли, кувыркались...; ...Прости, любимая...; ...Принеси, залетный ветер / Пер.с татар. Р.Кутуй // Казань. – 1999. – №12. – С.85-87.

64. Стихи / Пер. с татар. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1970. – 95 с.

65. Тал чыбык // Вакыт. – 1906. – 22 март.

66. Tatarlьqtan tatar hic gər itərme?.. // Казан утлары. – 1998. – №2. – Б.182-185.

67. Ты кровь моя, любовь моя... / Пер. с татар. Р.Моран // Книга нежности: Колыбельные песни народов СССР. – М: Молодая гвардия, 1982. – С.27-28.

68. Ты кровь моя, любовь моя... / Пер. с татар.Р.Моран // Книга нежности: Колыбельные песни народов СССР. – М: Молодая гвардия, 1985. – С.31-33.

69. Урысча күп сүзең, азы татарча...; Кил, өйрән, и туган, бер башка телне... // Мәгариф. – 2001. – №5. – Б.110.

70. Үткән көннәр // «Гафил бине Габдулла» [Ризаэтдин Фәхретдин псев.]. Әсма, яки Гамәл вә җәза. – Оренбург, 1903. – Б.21.

71. Үткән көннәр: Каләмгә хитаб... [һ.б. шигырьләре] // Татар әдәбиятыннан хрестоматия: Урта мәктәпнең 9 нчы классы өчен / Төз. М.Х.Гайнуллин, М.С.Мәһдиев. – Тугызынчы басма. – Казан: Татар. китап нәшр., 1990. – Б.327-331.

72. Хәят // Шура. –1908. –№6. –Б.184-185.

73. Хәят //Азат хатын. – 1989. – №12. – Б.15.

74. Хикәяи гыйшык (Безнеңчә) // Шура. – 1908. – №2. – Б.63.

75. Шагыйрьгә // Әдәбият мәҗмугасе. 12 сан. («Вакыт» газетасына кушымта). – Оренбург: Вакыт, 1907.

76. Шагыйрьгә // Мәгариф. – 1997. – №9. – Б.26.

77. Шәйхе Сәгъдидән // Шура. – 1910. – №8. – Б.248; 1916. – №5. – Б.115.

78. Чамасы гыйльме шәп... // Вакыт. – 1906. – 18 апр.

79. Четверостишие // Комсомолец Татарии. – 1962. – 14 янв.

80. Ышкулниккә // Шура. – 1908. – №3. – Б.89.

81. Яз чәчәге // Вакыт. – 1906. – 22 март.

Башка публикацияләр

1. Балалар өчен вак хикәяләр: Башка телләрдән күчерелеп тәртип ителде / Мөрәттибе: Дәрдемәнд. – Оренбург: Вакыт, 1910. – 34 б.

2. Дәрдемәнднең Ф.Кәримигә язган хатлары / Матбугатка әзерләүче – Рамил Миңнуллин // Гасырлар авазы=Эхо веков. 1999. – №1/2. – Б.184-188.

3. Закир Рәмиевтән Фатыйх Кәримигә [хат] // Фатыйх Кәрими: Фәнни-биографик җыентык=Фатих Карими: Научно-биографический сборник /Төз.-авт.: Р.Мәрданов, Р.Миңнуллин, С.Рәхимов. – Казан: Рухият, 2000. – Б.262.

4. Хатты табагать: Фәкать табагатә махсус улмак үзрә иҗат вә тәрсим иделмеш улан айры хәрефләрең әлифбасыны вә у хәрефләр илә тәртиб иделмеш бер кач нәмунәләре хавидыр / [Төз. Мөхәммәдшакир һәм Мөхәммәдзакир Рәмиевләр]. – Оренбург: Вакыт, 1911. – 21 б.

Рәмиевләргә багышланган әдәбият

1. Адеева Р. «Күңел һәр җирдә гөл эзли» // Татар иле. – 1999. – №48 (дек.). – Б.5.

2.Афзал Гамил. Дәрдемәнд // Татарстан. – 1991. – №10. – Б.76-77.

3. Афзал Гамил. Дәрдемәндкә тәкълид // Мәдәни җомга. – 1998. – 2 окт.(№40).

4. Әхмәтҗанов М. Фатыйх Кәрими мирасына яңа сәхифәләр // Казан утлары. – 1999. – №6. – Б.177-182.

5.Баттал Г. [Дәрдемәнд] // Баттал Г. Казан төрекләре. – [Истанбул, 1925]. – Б.203-204.

6. Баттал Г. [Дәрдемәнд] // Баттал Г. Казан төркиләре: Тарихи язмалар. – Казан: Татар. китап нәшр., 1996. – Б.124-126.

7.Бәдретдинов Ирек. Энҗе-алмазлар югалмас // Татарстан яшьләре. – 1979. – 22 нояб.

8. Бәшири З. Дәрдемәнд – Закир Рәмиев // Мәдәни җомга. – 1998. – №34. – 21 авг.

9. Бәшири З. Замандашларым белән очрашулар: Язучы истәлекләре. – Казан: Татар. китап нәшр., 1968. – Б.85-92, 216-217.

10. Богатые тоже плакали... // Казанские ведомости. – 1997. – 10 дек.

11. Ботвинник М. Дәрдемәнд оныгы – Бәшир: Мәшһүр шагыйребез Дәрдемәнднең оныгы Бәшир Дәрдемәнд сигезенче дистәне ваклаучы вафат // Ватаным Татарстан. – 1994. – 14 сент.

12. Б.Ш. [Борһан Шәрәф]. Киңрәк нәзарлы кеше // Вакыт. – 1912. – 30 март (№946).

13. «Вакыт». Аңлашуның җавабы // Вакыт. – 1907. – №196.

14. «Вакыт» вә «Шура» һәйәте тәхририясе. Олуг зыйаг // Вакыт. – 1912. – 23 март (№943).

15. Валидов Дж. «Дердменд» и С.Рамиев // Валидов Дж. Очерк истории образованности и литературы татар (до революции 1917 г.). – М. – Петроград: Госиздат, 1923. – С.99-100.

16. Вәзиева Җамал. Дәрдемәнд: Тууына 100 ел тулу уңае белән // Азат хатын. – 1959. – №12. – Б.15.

17. Вәзиева Җамал. Дәрдемәнд – балаларга // Совет Татарстаны. – 1959. – 21нояб.

18. «Вакыт» вә «Шура» һәйәте тәхририясе. Олуг зыйаг // Вакыт. – 1912. – №943.

19. Габдуллин Габдулла. Ислам галәме: Нәваи хәзрәтләренә тәкълид, шагыйре мөхтәрәм Дәрдемәнд әфәндегә тәкъдим // Шура. – 1914. – №10. – Б.313.

20. Гайнуллин М. Выдающийся татарский поэт // Сов. Татария. – 1959. – 22 нояб.

21. Гайнуллин М. Дардман // Дардман. Стихи. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1970. – С. 3-12.

22. Гайнуллин М. Дәрдемәнд // Дәрдемәнд. Сайланма әсәрләр /Төз. – И.Рәмиев. – Казан: Татар. китап нәшр., 1959. – Б.3-18.

23. Гайнуллин М. Дәрдемәнд: Тууына 100 ел тулу уңае белән // Совет әдәбияты. – 1959. – №11. – Б.103-111.

24. Гайнуллин М. Дәрдемәнд // Гайнуллин М. Татар әдипләре: Иҗат протретлары. – Казан: Татар. китап нәшр., 1978. – Б.156-171.

25. Гайнуллин М. [Дәрдемәнд] // Гайнуллин М. Татарская литература и публицистика нач. XX в. Изд. 2-е доп. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1983. С.130-137.

26. Галеева З.Р., Зарипова Ч.А. Новое исследование о Дардменде // Научный Татарстан. – 1998. – №2. – С.95-96.

27. Галимуллин Ф. Дәрдемәнд (Закир Рәмиев) // Әдәбият (XX йөз башы һәм 20 нче еллар татар әдәбияты): Татар урта гомуми белем мәктәбенең 10 нчы сыйныфы өчен дәреслек / М.Хәсәнов, А.Әхмәдуллин, Ф.Галимуллин, И.Нуруллин; А.Г.Әхмәдуллин ред. Тулыландырылган 2 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2000 – Б.153-168.

28. Гарифуллин Д. Тайсуган, сиңа күпме сер сыйган...: // Мәдәни җомга. – 1999. – 26 нояб. (№48). – Б.15.

29. Гафури М. Шагыйрьнең алтын приискасында // Гафури М. Әсәрләр. 4 томда. Т.4: Совет чоры прозасы. – Казан: Татар. китап нәшр., 1981. – Б.236-314.

30. Гәрәй Й. Чөйгәне шоңкар булган... (Дәрдемәнд шигырьләренең теле) // Казан утлары. – 1979. – №2. – Б.176-178.

31. Гобәев Р. Дәрдемәнднең тормыш юлы һәм шәҗәрә: XX йөз башындагы татар әдәбияты // Мәгариф. – 1995. – №10. – Б.25-27.

32. Госманов М. Яңа табылган әдәби, тарихи истәлекләр // Казан утлары. – 1966. – №7. – Б.118-120.

33. Госманов М., Хисамов Н. Дәрдемәнд әсәрләренең яңа басмасы // Казан утлары. – 1982. – №3. – Б.163-166.

34. Давлетшин Т. [Закир Рамиев] // Давлетшин Т. Советский Татарстан. – Мюнхен, 1974. – С.266.

35. Дәрдемәнднең тууына 130 ел // Идел. – 1989. – №6. – Б.42-43.

36. Даутов Р., Нуруллина Н. Дәрдемәнд // Даутов Р.Нуруллина Н. Совет Татарстаны язучылары: Био-библиографик белешмә. – Казан: Татар. китап нәшр., 1986. – Б.165-166.

37. Дәрдемәнд // «Заман» календаре. 1915 ел өчен. – Казан, 1914. – Б.55.

38. Дәрдемәнд: Тууына 110 ел тулу уңае белән // Казан утлары. – 1969. – №11. – Б.177-178.

39. Дәрдемәнд: Татарның күренекле шагыйре // Совет әдәбияты. – 1944. – №6. – Б.71.

40. Дәрдемәнд // Яңа вакыт. – 1993. – Нояб. (№36).

41. Дәрдемәнд: Тууына 100 ел // Ялкын. – 1959. – №11. – Б.32.

42. Дэрдменд // Средневековая татарская литература (VIII–XVIII вв.). – Казань: Изд-во Фэн, 1999. – С.90-91, 103, 132, 231.

43. Дэрдменд. Стихи /Пер. с татар. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1970.

44. Дәүләтшин Габделгалим. Мәрхүм Мөхәммәдшакир әфәнде Рәмиев хәзрәтләренең гаиләи мөхтәрәмәсенә // Вакыт. –1912. – 29 март (№945).

45. Жданов Мөхәммәдсәлах. Йөк (Максуд): Мөхтәрәм М.-Шакир әфәнде Рәмиевнең вафатыннан соңгы тәэсирләр // Шура. – 1912. – №17. – Б.540.

46. «Җәләй» [Җәмал Вәлиди псев.] «Татар шагыйрьләре» (Әдәби мөсахәбәләр) // Вакыт. – 24-26 июль.

47. Җеназа мәрасиме // Вакыт. – 1912. – №943.

48. Закир әфәнде Рәмиев // Төрек йорды. – 1914. – №5. – Б. 2174.

49.Закир Рәмиев // «Заман» календаре. 1915 ел өчен. – Б. 55.

50. Зәйнетдинов Минвәгыйзь. Дөньяда яшәр өчен гыйлем, төзек әхлак, тырышлык кирәк // Заман-Татарстан. – 1999. – 19 нояб. (№47).

51. Зиннуров Ш. Дәрдемәнд иҗаты – илһам чыганагы // Соц. Татарстан. – 1989. – 8 июль.

52. Ибраһимов Г. Татар әдәбияты: Хисап урынында // Татарстан хәбәрләре. – 1922. – 7 февр.

53. Ибраһимов Г. Татар әдәбияты: Хисап урынында // Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда. Т.5: Әдәбият һәм сәнгать

турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910-1933). – Казан: Татар. китап нәшр., 1978. – Б.286.

54. Ибраһимов Г. Татар шагыйрьләре. 1 бүлем: Сәгыйть Рәмиев, Дәрдемәнд, Габдулла Тукай. – Оренбург: Вакыт. – 1913. – 103 б.

55. Ибраһимов Г. Татар шагыйрьләре // Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда. Т.5: Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910-1933). – Казан: Татар. китап нәшр., 1978. – Б.74-156.

56. Ибраһимова Ф. Россиянең иң бай татары, яки Дәрдемәнднең абыйсы // Татарстан хәбәрләре. – 1994. – 15 июль.

57. Исхакый Гата. Дәрдемәнд // Исхакый Гата. Әдәбият юллары: Рөшди мәдрәсәләребез өчен дәреслек. – Казан, 1920. – Б.134-135.

58. Кашшаф Г. Дәрдемәнднең шигырьләрен аңларга тырышып утырам // Совет әдәбияты. – 1946. – №1. – Б.122-123.

59. Кәримев Фатыйх. Истанбул мәктүбләре. – Оренбург: Вакыт, 1913. – Б.3-4.

60. Кәримов Ф. Дәрдемәнд // Дәрдемәнд әсәрләре /Төз. – И.Рәми. – Казан: Яңалиф, 1928. – Б.8-18.

61. Кәрими Фатыйх. Аурупа сәяхәтнамәсе // Кәрими Ф. Морза кызы Фатыйма: Сайланма әсәрләр. – Казан: Татар. китап нәшр., 1996. – Б.150-310.

62. Кәрими Ф. «Дәрдемәнд шигырьгә югары бер нәфис сәнгать дип карый иде...» / Текстны әзерләүче – Миңнуллин Рамил // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 1999. – №1/2. – Б.176-183.

63. Кәрими Ф. Кем иде Шакир әфәнде? (Мәрхүмне искә төшерү) // Вакыт. – 1912. – 25 март (№944).

64. Кәрими Ф. Ул шигырьгә нәфис сәнгать дип карады / Текстны әзерләүче – Миңнуллин Рамил // Шәһри Казан. – 1999. – 15 окт.

65. Кәрими Ф. Яурупа сәяхәтнамәсе. – СПб: И.Бораганский матб., 1902. – 191 б.

66. Курбатов Х. Два поэта демократизации литературного языка // Анализы текстов по истории татарского литературного языка. – Казань. – 1987. – С.59-73.

67. Малахальцев А. «Душа всюду ищет цветы...» //Татарские края. – 1999. – №51 (Дек.). – С.3.

68. Мансур З. Нәфис шигырьләр остасы: шагыйрь Дәрдемәнднең тууына 100 ел тулу уңае белән // Совет Татарстаны. – 1959. – 22 нояб.

69. Мәңгелек шагыйре // Сөембикә. – 1999. – №12. – Б.7.

70. Мәрданов Р. «Шура» журналы // Гасырлар авазы=Эхо веков. – 1999. – №1/2. – Б.227-243.

71. Мәрданов Р. «Шура» журналында әдәбият мәсьәләләре // Казан утлары. – 1999. – №4. – Б.161-165.

72. [Мәрхүм Мөхәммәдшакир әфәнде хакында...] // Вакыт. – 1912. – 29 март (№945).

73. Мәрхүм Шакир вә Хөсәен әфәнделәр // Төрек йорды. – 1912. – №12.

74. Мәһдиев М. Бер тәрҗемә турында // Соц. Татарстан. – 1981. – 28 июнь.

75. Мәһдиев М. Рәмиевләр нәселеннән берәү // Казан утлары. – 1989. – №12. – Б.176-177.

76. Минһаҗ Рәшит. Гөрләгән сулар башында // Ватаным Татарстан. – 1993. – 2 июль.

77. Миңнеәхмәтова Т. Дәрдемәнд иҗаты буенча класстан тыш уку дәресе // Башкортостан укытыусыһы. – 1997. – №11. – Б.57-59.

78. Миңнегулов Х. Аһ, туган каумем газиз! // Татарстан. – 1996. – №12. – Б.71-74.

79. Миңнуллин Җәүдәт. Шигъриятебез шоңкары // Казан утлары. – 1987. – №10. – Б.160-161.

80. Митина О. «Золотая страница» татарской поэзии // Респ. Татарстан. – 1999. – 26 нояб. – С.5.

81. Морат Г. Дәрдемәнд кабере // Казан утлары. – 2001. – №8. – Б.70-71.

82. Мортазин С. Тагын «Дәрдемәнд әсәрләре» турында // Безнең юл. – 1929. – №9/10. – Б.19-24.

83. Мөхәммәдзакир Мөхәммәдсадыйк угылы Рәмиев // Вакыт. – 1906. – 23 апр. (№18).

84. Мөхәммәдшакир әфәнде Мөхәммәдсадыйк угылы Рәмиев дөньядан рихләт кылды // Шура. – 1912. – №7. – Б.193.

85. Мөхәммәдшакир Мөхәммәдсадыйк угылы Рәмиев дәрелфәнадан дарелбәкайә иртихалә итте // Вакыт. – 1912. – 23 март (1943).

86. Мустафин Р. «Дердменд» – значит «опечаленный» // Лит. Россия. 1971. – 12 фев.

87. Мустафин Р. Дердменд – значит «опечаленный» // Казан. ведомости. – 1999. – 1 дек. – С.7.

88. Мустафин Р. Золотые прииски поэта // Дружба народов. – 1971. – №16. – С.274.

89. Нигъмәти Г. Шагыйрь Дәрдемәнд һәм аның әдәби иҗаты // Дәрдемәнд әсәрләре / Төз. – И. Рәми. – Казан: Яңалиф, 1928. – Б.19-37.

90. Нигъмәти Г. Дәрдемәнд турында (Тулы җыелмасы басылу уңае белән) // Кызыл Татарстан. – 1929. – 29 сент.

91. Нигъмәти Г. Шагыйрь һәм аның әдәби иҗаты // Мәдәни җомга.- 1997. – 11 июль.

92. Нуруллин И. XX йөз башы татар әдәбияты. – Казан: Ун-тет нәшр., 1966. – Б.64-68.

93. Нуруллин И. [Творчество Дердмэнда] // Нуруллин И.З. Путь к зрелости: О зарождении и развитии критического реализма в татарской литературе. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1971. – С.169-173.

94. Патыйи К. Шакир әфәнде Рәмиев җәнабләрене тәзкирән // Шура. – 1913. – №9. – Б.283.

95. Рамеев М. М. // Мусульманские депутаты Государственной Думы России. 1906-1917гг. Сборник документов и материалов / Сост. Л. Ямаева. – Уфа: Китап, 1998. – С.300-301.

96. Рәми Исмәгыйль. Дәрдемәнд (Әдәби сүзлек) // Татарстан. – 1992. – №11/12. – Б.126.

97. Рәмиев З. XX йөз башы татар әдәбияты: авторлык, төп текст һәм хронология мәсьәләләре. – Казан: РИЦ «Школа»,

2000. – 180 б. [Дәрдемәнд турында: Б.5, 11, 80, 88, 108, 125, 131, 152, 161].

98. Рәмиев Сәгыйть. Шакир Рәмиевнең вафаты // Идел. – 1912. – 20 март; шул ук // Вакыт. – 1912. – 29 март (№945).

99. Рәмиевнең үлүе мөнәсәбәте илә // «Йолдыз». – 1912. – 29 март (№812).

100. Рәхимкулова М. Рәмиевләр йорты // Яңа вакыт. – 1994. – 1 дек.

101. Ризаэтдин Фәхретдин: Фәнни-биографик җыентык = Ризаэтдин Фахретдинов: Научно-биографический сборник. – Казан: Рухият, 1999. – Б. 49, 57, 120, 127, 157, 158, 190.

102. Ризванова Л. Дәрдемәнд иҗаты компьютерда // Татарстан. – 1997. – №1. – Б.74-75.

103. Салихов Р. Два лика поэта // Изв. Татарстана – 1992. – 15 окт.

104. Салихов Р. Тайна Дердменда // Казань. – 1999. – №12. – С.82-84.

105. Самдун Ф. Мөхәммәтшакир Рәмиев // Әлмәт таңнары. – 1998. – 29 дек.

106. Сафаров Р. Дәрдемәнд тәхәллүсе ни аңлата? // Мәдәни җомга. – 1998. – №18. – 1 май. – Б.96.

107. Сафаров Р. Дәрте-дәрманы – халык гаме // Шәһри Казан. – 1999. – 26 нояб.

108. Сафаров Р. Ике псевдоним турында // Ватаным Татарстан. 1999. – 13 гыйн.

109. Сафиуллин Ә. Шагыйрь күргәзмәсе // Ватаным Татарстан. – 1999. – 10 дек.

110. Саяпова А. Возвышенное в поэзии Дардменда // Идель. – 2001. – №5. – С.18-19.

111. Саяпова А.М. Дардменд и проблема символизма в татарской литературе начала XX века. Автореф. дисс. доктора филологических наук. – Казань, 1998. – 45с.

112. Саяпова А.М. Идеи суфизма в творчестве Дардменда: Суфизм-философия антропологическая. Эстетическая философема поэзии Дардменда. Мистическая философема поэта.

Источник любви совершенный человек // Науч. Татарстан. – 1996. – №3. – С.62-66.

113. Саяпова А. «Кемгә тансык бу замана?» // Казан утлары. – 1996. – №8. – Б.164-167.

114. Саяпова А. Поэзия Дардменда и символизм. – Казань, 1997. – С. 210.

115. Саяпова А. Тукай и Дердменд: к проблеме суфийских традиций в творчестве поэтов // Тукай и духовная культура XX века: Материалы научной конференции, посвященной 110-летию со дня рождения Тукая. – Казань, 1997. – С.109 – 115.

116. Сәгъди Г. Дәрдемәнд // Сәгъди Г. Татар әдәбияты тарихы: Дәреслек-кулланма. – Казан: Татарстан дәүләт нәшр., 1926. – Б.231-236.

117. Сәрдар Әхмәт. Чин-мачин юлында мөхтәрәм Шакир әфәнде Рәмиев җәнабләре // Шура. – 1912. – №11. – Б.349-351.

118. Сөнгати Г. Исте җилләр... сипте карлар. (Дәрдемәндкә тәкълид); // Мирас. – 1999. –№3. –Б.30-44.

119. Стихи татарского поэта Рамиева / Пер. Е. Орловой // Пролетарий Татарстана. – 1926. – №4. – С.18.

120. Султанбеков Б.Ф. Поэт в Думе // Султанбеков Б.Ф. История в мифах: Историко-документальные очерки. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1997. – С.13-15.

121. Сүнчәләй С. ... Мәхәббәтем (Дәрдемәндкә багышлыйм)... // Казан утлары. – №2. – Б.182-185.

122. Сүнчәләй С. Мәхәббәтем (Дәрдемәндкә багышлыйм); // Мирас. – 1999. – №4. – Б.30-40.

123. Татар әдәбияты тарихы: Алты томда. Т.1: Урта гасырлар дәвере // Казан: Татар. китап нәшр., 1984. – 567 б. [Дәрдемәнд (Закир Рәмиев) турында: – Б.137, 206, 290].

124. Татар әдәбияты тарихы: Алты томда. Т.2: XIX йөз татар әдәбияты. – Казан: Татар. китап нәшр., 1985. – 575 б. [Дәрдемәнд (Закир Рәмиев) турында: – Б.350, 407, 416, 553.

125. Татар әдәбияты тарихы: Алты томда. Т.3: XX гасыр башы. – Казан: Татар. китап нәшр., 1986. – 600 б. [Дәрдемәнд

(Закир Рәмиев) турында: – Б. 8, 39, 56, 60, 62-64, 89, 94, 97, 99, 100, 227, 235, 236, 292, 323, 330, 346-347, 423, 450, 455, 469, 474, 482, 484, 506, 509, 522-524, 526-530, 537, 542, 545, 555, 559, 567, 570, 574, 577.

126. Татар әдәбияты тарихы: Алты томда. Т.4: Татар совет әдәбияты (1917-1941). – Казан: Татар. китап нәшр., 1989. – 568 б. [Дәрдемәнд (Закир Рәмиев) турында: – Б. 106, 171, 224, 305, 433, 496, 536].

127.Татар әдәбияты тарихы: Алты томда. Т.5: Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы еллар әдәбияты (1941-1960). – Казан: Татар. китап нәшр., 1989. – 544 б. [Дәрдемәнд (Закир Рәмиев) турында: – Б. 67, 244-245, 484-485, 500, 507, 538].

128.Тәгъзия телеграмнары, тәгъзия мәктүбләре // Вакыт. – 1912. – 23, 25, 29, 30 март; 1, 5 апрель (№№943-947, 949).

Толымбайский. Иске мирасларның берсе // Безнең юл. – 1929. – №18. – Б.20-23.

130. Тукаев Габдулла. Аңлашу // Йолдыз. – 1907. – 12 июль.

131. Усал М.-Ф. [Фуад Туктаров псев.]. Беренче, икенче вә өченче Думада мөселман депутатлар һәм аларның кылган эшләре. – Казан: Х. Әбүзәрев, елы күрсәтелмәгән. – 238 б. [Закир Рәмиев турында: Б.154-156].

132. Усманова Д. Мусульманская фракция и проблемы «свободы совести» в Государственной Думе России (1906-1917). – Казань: Мастер-Лайн, 1999. – 164 с. – [О З. Рамееве – С.135.

133. Үтәбай-Кәрими Р. Дәрдемәнд // Кызыл таң. – 1999. – 13 июль.

134. Фатыйх Кәрими: Фәнни-биографик җыентык=Фатих Карими: Научно-биографический сборник. – Казан: Рухият, 2000. – Б.86-88, 94-96, 179-180, 211, 233, 235-238, 240-241, 245, 247, 254, 262, 267.

135. Фәхреддин Ризаэддин. Әхмәд бай. Икенче табгы. – Оренбург: Вакыт, 1911. – 55 б. [Рәмиевләр турында – Б.53.

136. [Фәхреддин Ризаэддин] Мөхәммәдшакир әфәнде Рәмиев // Шура. –1913. – №6. – Б.186-188.

137. Фәхреддин Ризаэддин. Мөхәммәд галәйһиссәлам: Фәхре кяинат әфәндемез рәсүле әкрәм салаллаһу галәйһи вәссәлләм хәзрәтләренең мөбарәк шәҗәрәсе, нәсел вә нәсәбләре вә бәгъзе әхвале язылмыш бер рисаләдер. – Оренбург: Вакыт. 1909. – 64 б. [Рәмиевләр турында – Б.3.

138. Фәхреддин Ризаэддин. Мөхәммәдшакир әфәнде Рәмиев / Текстны әзерләүче – Р.Мәрданов // Гасырлар авазы=Эхо веков. – 1999. – №1/2. – Б.243-247.

139. Фәхреддин Ризаэддин. «Кадь хаттатна әл-мәгали мәзҗәга, вә дәфнә әл-фазли вәд-дөнәя мәга»* // Шура. – 1912. – №7. – Б.224.

140. Фиракый. Сезне, милләт кызлары... // Шура. – 1916. – №4. – Б.93.

141. Хаҗиев В. Дәрдемәнд – мәгърифәтче шәхес // Ватаным Татарстан. – 1998. – 27 гыйн.; Татар иле. – 1998. – фев. (№7).

142. Халит Г. Дәрдемәнд // Татар әдәбияты тарихы: Алты томда. Т.3: XX гасыр башы. – Казан: Татар. китап нәшр., 1986. – Б.194-214.

143. Халит Г. Концепция мира и истории в поэзии Дэрдменда // Халит Г. Портреты и проблемы: Избранные статьи разных лет. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1985. – С.69-91.

144. Халит Г. Многоликая лирика. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1990. – 336 с. с.154-165.

145. Халит Г. Шагыйрь иҗатында дөнья һәм тарих концепциясе // Казан утлары. – 1979. – №12. – Б.146-156.

146. Хасанов Х. Формирование татарской буржуазной нации. – Казань: Татар. кн.изд-во, 1977. – С.218.

147. Хәким С. Шагыйрьнең осталыгы // Дәрдемәнд. Исә җилләр: Шигырьләр, истәлек-парчалар, вак хикәяләр. – Казан: Татар. китап нәшр., 1980. – Б.3-14.

148. Хәмидуллин Л. Дәрдемәнд матбагасы даирәсе // Мәдәни җомга. – 1999. – 3 дек. (№49). – Б.12.

* «Чынлап та, дәрәҗәле урынга яткырдык һәм аның белән олуг мәртәбәне дә күмдек» мәгънәсендә (гарәп телендәге шигырьдән өзек).

149. Хәмидуллин Л. Дәрдемәнднең соңгы айлары //Мәдәни җомга. – 1998. – 9 гыйн. (№2.) – Б.17-18.

150. Хәмидуллин Л. Дәрдемәнд шәҗәрәсенә өстәмәләр // Мәдәни җомга. – 2000. – 24 март. (№12). – Б.12.

151. Хәмидуллин Л. Җилкәнен киргән кораб... // Татарстан хәбәрләре. – 1994. – 22 нояб.

152. Хәмидуллин Л. Матбагачы Рәмиевләр // Мәгариф. – 2000. – №2. – Б.24-25.

153. Хәмидуллин Л. Офыктагы рәшәләр: Тарихи повесть // Хәмидуллин Л. Офыктагы рәшәләр: Хикәя һәм очерклар. – Казан: Татар. китап нәшр., 1990. – Б.73-129.

154. Хәмидуллин Л. Офыктагы рәшәләр // Казан утлары. – 1991. – №2. – Б.121-155.

155. Хәмидуллин Л. Рәмиевләр шәҗәрәсе // Шәһри Казан. – 1994. – 16 дек.

156. Хәмидуллин Л. «Танылмыйдыр кеше тышыннан...» // Казан утлары. – 1999. – №12. – Б. 172-180.

157. Хәмидуллин Л. Яңа табышлар // Казан утлары. – 1994. – №3. – Б.161-166.

158. Хисамов Н. «Будь настоящим соловьем!..» // Идель. – 1989. – №6. – С.38-39.

159. Хисамов Н. Дәрдемәнд: Тормышы һәм иҗаты турында очерк // Казан утлары. – 1989. – №12. – Б.165-175.

160. Хисамов Н. Дәрдемәнд әсәрләренең яңа басмасы // Хисамов Н. Бәрәкәтле чишмәләр: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләр. – Казан: Татар. китап нәшр., 1987. – Б.134-140.

161. Хисамов Н. Дәрдемәнднең «Хәят» шигыре // Азат хатын. – 1989. – №12. – Б.14.

162. Хисамов Н. Дәрдемәнд поэзиясендә туган ил мотивы // Совет мәктәбе. – 1969. – №2. – Б.26-29.

163. Хисамов Н. Дәрдемәнд шигырьләре рус телендә // Казан утлары. – 1971. – №1. – Б.163-168.

164. Хисамов Н. Осталык мәктәбе // Хисамов Н. Бәрәкәтле чишмәләр: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләр. – Казан: Татар. китап нәшр., 1987. – Б. 99-104.

165. Хисамов Н. Поэзия остасы: Дәрдемәнднең тууына 100 ел тулу уңае белән // Татарстан яшьләре. – 1959. – 24 нояб.

166. Хисамов Н. Шигъри осталык мәктәбе: Дәрдемәнднең тууына 120 ел тулуга карата // Соц. Татарстан. – 1979. – 23 нояб.

167. Хисамов Н. Шагыйрьне заманча укып карау // Хисамов Н. Бәрәкәтле чишмәләр: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләр. – Казан: Татар. китап нәшр., 1987. – Б.117-133.

168. Шагыйрь Дәрдемәнднең тууына 100 ел // Совет әдәбияты. – 1959. – №11. – Б.126.

169. Шагыйрь Дәрдемәнднең юбилее // Совет әдәбияты. – 1960. – №1. – Б.124.

170. Шакир әфәнде Рәмиев // «Йолдыз». – 1912. – 20 март (№808).

171. Шакир әфәнде Рәмиев // Йолдыз. – 1912. – 29 март (№812).

172. Шакир әфәнде Рәмиевнең вафаты // Йолдыз. – 1912. – 25 март (№810).

173. Юзиев Н. Традицияләр яңарганда. – Казан: Татар. китап нәшр., 1966. – Б.98-99, 102-103.

174. Яхин Ф. Борынгы татар әдәбияты традицияләрендә Дәрдемәнднең «Кораб» шигыренә анализ // Гыйльми язмалар=Ученые записки ТГГИ. 1999. – №7. – Б.64-68.

175.Яхин Ф. Дәрдемәнднең билгесез тәхәллүсе // Идел. – 1996. – №11. – Б.38-42.

Книга «Братья Рамиевы»

Представленная вниманию читателей книга из серии «Шәхесләребез» («Личности») посвящена жизнедеятельности братьев Рамиевых.

Закир Рамиев-Дэрдменд (1859-1921) известен не только как автор глубоко философских стихотворений, но и как владелец многочисленных золотых приисков, депутат I Государственной Думы от Оренбургской губернии, член Оренбургского городского правления, председатель и член общественных благотворительных организаций – комитета помощи бедным и комитета по воспитанию сирот. А вот о его брате Шакире Рамиеве (1857-1912) до этого времени было известно немного. Но благодаря этому изданию читатель откроет для себя много нового из жизни этого интересного человека – мыслителя, издателя, промышленника, изобретателя, приверженца новых идей, оказавшего наиболее благотворное влияние на формирование личности своего младшего брата. Здесь же приводятся подробные сведения о родословной Рамиевых.

В книге достаточно широко освещена их общественная жизнь, которая была направлена служению национальной идее, просвещению и культурному развитию татарского народа, ради которых они не жалели ни средств, ни сил. Существенным результатом их деятельности в этом направлении было издание газеты и журнала на татарском языке. Так, с 21 февраля 1906 года в Оренбурге начала выходить газета «Вакыт», а двумя годами позже – с 10 января 1908 года – журнал «Шура». Редакторами этих либеральных изданий были выдающийся деятель татарской культуры начала XX

века Фатих Карими и ученый-энциклопедист Риза Фахретдинов. В редакциях журнала и газеты сотрудничали яркие представители татарской литературы Г. Ибрагимов, Ш. Камал, М. Гафури, Ш. Бабич, З. Сагида, З. Башири, Г. Тукай и др. Благодаря журналу «Шура» читатели знакомились и с творчеством самого Дэрдменда. Таким образом, постепенно вокруг газеты «Вакыт» и журнала «Шура» формировалась сильная литературная среда.

В представленное издание также впервые включены статьи, посвященные Рамиевым, опубликованные на страницах татарских газет и журналов начала XX века. Читатель здесь также найдет материал о завоевавших огромную популярность среди татар и других тюркских народов журнале «Шура» и газете «Вакыт».

Достоинством этой книги является то, что впервые здесь были собраны и представлены без сокращений письма Рамиевых, хранящиеся в архивах.

Безусловно, украшением книги стали образцы благозвучной поэзии Закира Рамиева-Дэрдменда. Значительную часть издания представляют материалы о самом поэте, написанные как его современниками, так и современными исследователями.

В книге также представлен библиографический указатель публикаций Дэрдменда и литературы о Рамиевых.

Жизнь и деятельность братьев Рамиевых, несомненно, оставили значительный след в общественной жизни начала XX века и сегодня могут служить эталоном порядочности, интеллигентности и просвещенности.

ЭЧТӘЛЕК

«Бертуган Рәмиевләр» китабы (төзүчеләрдән) 3
М.Госманов. Яңадан танышу, яки Фидакяр хәйриячеләребез хакында 5
Л.Хәмидуллин. Тарихта үз эзләре бар 34
Л.Хәмидуллин. Рәмиевләр матбагасы 69
Р.Фәхретдин. «Вакыт» матбагасында беренче китап 80
Җ.Миңнуллин. Рәмиевләрнең алтын приискалары 82
Р.Фәхретдин. Мөхәммәтшакир әфәнде Рәмиев 92
Ф.Кәрими. Дәрдемәнд 102
Бертуган Рәмиевләр турында XX йөз башы татар матбугаты материаллары («Вакыт», «Шура», «Асар», «Йолдыз» һ.б.) 110
З.Бәшири. Рәмиевләр турында истәлекләр 138
Р.Мәрданов. «Шура» журналы һәм Рәмиевләр 150
Р.Мәрданов. «Вакыт» газетасы 161
Дәрдемәнд шигырьләре (сайлап) 164
Г.Ибраһимов. Дәрдемәнд («Татар шагыйрьләре»ннән) 224
Җ.Вәлиди. Татар шагыйрьләре (Г.Ибраһимов мәкаләсенә рецензия) 244
Г.Сәгъди. Дәрдемәнд 249
Г.Халит. Шагыйрь иҗатында дөнья һәм тарих концепциясе 256
Н.Хисамов. Дәрдемәнд: Тормышы һәм иҗаты турында очерк 279
Тукай-Дәрдемәнд мөнәсәбәтләре 302
Хатлар 305
Библиография 341
Резюме 359

«Шәхесләребез» сериясеннән нәшер ителгән китаплар

Шиһабетдин Мәрҗани. – Әлмәт: Рухият, 1998. – 175 б.

Китап мәшһүр татар галиме, тарихчы, дин һәм җәмәгать эшлеклесе Шиһабетдин Мәрҗанинең 180 еллык юбилее уңаеннан нәшер ителде. Киң катлау укучыларга галимнең тормышы хакындагы тәфсилле мәгълүмат аз билгеле иде. Шуны исәпкә алып, Шәһәр Шәрәфнең 1915 елда «Мәрҗани» исемле җыентыкта басылып чыккан язмасы гарәп имлясыннан күчерелде һәм фоторәсемнәр белән баетылды. Китап хәзерге татар әдәби теленә якынайтылып тәкъдим ителә.

Книга посвящена татарскому историку, богослову и общественному деятелю XIX века Шигабутдину Марджани (1818-1889) и подготовлена к его 180-летию со дня рождения. В сборник включен, переработанный на современном татарском языке, материал статьи Шахар Шарафа, посвященный жизни и деятельности ученого и просветителя и изданный в сборнике «Марджани» 1915 года.

Ризаэтдин Фәхретдин: Фәнни-биогр. җыентык = Ризаэтдин Фахретдинов: Науч.-биогр. сборник. – Казан: Рухият, 1999. – 224 б.

Китап мәшһүр татар галиме, тарихчы, дин һәм җәмәгать эшлеклесе Ризаэтдин Фәхретдиннең 140 еллык юбилее уңаеннан нәшер ителде. Җыентыкта Р.Фәхретдиннең үзе тарафыннан язылган тәрҗемәи хәле, кызы Әсма Шәрәфнең әтисе турындагы истәлекләре урын алды. Китапка галимнең җәмәгатьчелеккә моңарчы аз мәгълүм булган хатлары һәм фоторәсемнәре, шулай ук архив документлары һәм чит ил матбугатында басылган мәкаләләр дә кертелде.

Китап милли тарихыбыз белән кызыксынучы киң катлау укучыларга тәкъдим ителә.

Сборник, посвященный 140-летию со дня рождения известного татарского ученого, историка, религиозного и общественного деятеля Ризаэтдина Фахретдинова, включает в себя неопубликованные материалы: автобиография, воспоминания его дочери – Асьмы Шараф, в сборник включены также малоизвестные ранее широкой общественности письма, фотографии, архивные материалы и статьи из зарубежной татарской печати.

Издание рекомендуется для широкого круга читателей, интересующихся национальной историей татарского народа.

Бертуган Бубыйлар һәм Иж-Бубый мәдрәсәсе: Тарихи-документаль җыентык. – Казан: Рухият, 1999. – 240 б.

Җыентыкта XX йөз башында төрки-татар һәм мөселман халыкларының иҗтимагый фикер үсеше һәм мәгариф тарихында шөһрәт казанган бертуган Бубыйлар һәм Иж-Бубый мәдрәсәсенә караган документаль чыганаклар һәм материаллар туплап бирелде.

Китап милли тарихыбыз белән кызыксынучы киң катлау укучыларга тәкъдим ителә.

Сборник посвящен одному из лучших мусульманских учебных заведений начала XX века – медресе деревни Иж-Боби. Основу сборника составляет работа А.Бобинского «История медресе Боби», материалы и архивные документы по делу братьев Бобинских, материалы следственного дела Мухлисы Бобинской и др.

Издание рекомендуется для всех, интересующихся историей татарского народа.

Фатыйх Кәрими: Фәнни-биографик җыентык = Фатих Карими: Научно-биографический сборник. – Казан: Рухият, 2000. – 320 б.

Китап күренекле татар әдибе, журналист, педагог һәм тәрҗемәче, җәмәгать эшлеклесе Фатыйх Кәриминең 130 еллык юбилее уңаеннан нәшер ителде. Җыентыкта Гыйльман ахун һәм Фатыйх Кәримиләрнең тәрҗемәи хәлләре, иҗтимагый эшчәнлекләре буенча документаль материаллар, хатлар, фоторәсемнәр һәм мәкаләләр тупланды. Ф.Кәриминең «Истанбул мәктүбләре» китабыннан өзекләр дә бирелде.

Китап милли тарихыбыз белән кызыксынучы киң катлау укучыларга тәкъдим ителә.

Книга посвящена известному татарскому публицисту и прозаику, педагогу, ученому, общественному деятелю Фатиху Карими (Каримов) и издается к 130-летнему юбилею со дня его рождения. В книгу вошли биографические очерки о Ф.Карими, его отце Гильмане, документальные материалы, статьи, фотографии, письма. В сборнике также представлены отрывки из книги Ф.Карими «Письма из Стамбула.»

Гайнетдин Әхмәрев: Тарихи-документаль җыентык. – Казан: Хәтер, 2000. – 384 б.

Китапка күренекле татар тарихчысы, педагог һәм җәмәгать эшлеклесе Гайнетдин Әхмәревнең Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгы тарихларын өйрәнүгә багышланган гыйльми хезмәтләре, милли тарихыбызның башка өлкәләренә дә караган мәкаләләре тупланды. Җыентыкта шулай ук галимнең тормыш юлын һәм эшчәнлеген тулырак ача торган документаль чыганаклар урын алды.

Китап тарихыбыз белән кызыксынучы киң катлау укучыларга тәкъдим ителә.

В книге представлены научные работы, отдельные статьи известного татарского историка, педагога и общественного деятеля Гайнутдина Ахмарова, посвященные периоду Волжской Булгарии, Казанского ханства и в целом истории татарского народа. В сборник вошли также документальные источники, отражающие жизнь и деятельность самого автора.

Издание рекомендуется для широкого круга читателей, интересующихся историей татарского народа.



Газиз Гобәйдуллин: Фәнни-биографик җыентык = Газиз Губайдуллин: Научно-биографический сборник. – Казан: Рухият, 2002. – 336 б.

Китап күренекле татар тарихчы галиме, әдип һәм педагог Газиз Салих улы Гобәйдуллинның тууына 115 ел тулу уңае белән нәшер ителде.

Җыентыкта галимнең улы Сәлман Гобәйдуллин тарафыннан әтисенең тормыш юлын тәфсилле тасвирлаган очерк дөнья күрде. Газиз Гобәйдуллинның рус һәм татар телләрендәге тарихи, әдәбият тарихына багышланган мәкаләләре һәм хикәяләре урын алды. Шулай ук Г.Гобәйдуллинга багышланган фәнни мәкаләләр, аның турында истәлекләр, архив материаллары һәм хатлар, фоторәсемнәр һәм библиография туплап бирелде.

Китап тарихыбыз белән кызыксынучы киң катлау укучыларга тәкъдим ителә.

Издание сборника приурочено к 115-летию со дня рождения известного татарского ученого-историка, писателя и педагога Газиза Салиховича Губайдуллина.

Помимо подробного биографического очерка о Г.Губайдуллине, написанного сыном ученого Сальманом Губайдуллиным, в сборник вошли отдельные научные статьи по истории, истории татарской литературы, рассказы Г.Губайдуллина, а также материалы на русском и татарском языках, посвященные самому ученому: статьи, воспоминания о нем, архивные документы, письма, библиография, фотодокументы.

Издание рекомендуется для широкого круга читателей, интересующихся историей.

Научно-биографический сборник

Братья Рамиевы

(на татарском языке)

Ответственный редактор: Ильсияр Хайруллина
Компьютерная верстка: Василий Порсев
Компьютерный набор: Гузель Тагирова
Корректор: Разина Салахиева

В сборнике использованы архивные документы и материалы из фондов Национального архива РТ, Научной библиотеки им. Н.И.Лобачевского Казанского государственного университета, Национальной библиотеки РТ.

Формат 84х108 1/32. Печатных листов 11,5.
Цветная вклейка 1 п/л. Тираж 2000 экз. Заказ № Б-320

Отпечатано в типографии ГУП ПИК «Идел-Пресс».
420066 г.Казань, ул. Декабристов, 2